www.kazanutlary.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ
ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН
БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

БАШ МӨХӘРРИР СҮЗЕ

Илфак ИБРАҺИМОВ. Рухыбыз учагы – «Казан утлары» журналына – 95 яшь. ........................3

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА. Очкын бар каләм очында. *Шигырьләр*. ..........................................................6
Вахит ИМАМОВ. Карабәк. *Тарихи роман*. .........................................................................................11
Рәшит БӘШӘР. И җанымның садә чаклары. *Шигырьләр*. .............................................................77
Вакыйф НУРИЕВ. Мәһдиев һәм... *Бәян-хатирә*. ...............................................................................81
Флёра ТАРХАНОВА. Моң таралды ачык тәрәздән. *Шигырьләр*. ..................................................96
Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ. Иске Казан – Кирмән нигезе. *Лирик поэма*. ..............................................101

*100 нче бит:* Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Һәр саны бәйрәм. ........................................................................100

*Безне котлыйлар*: Римма РАТНИКОВА, Мостафа ӨНӘР, Данил САЛИХОВ,
Рәлиф КИНЙӘБАЕВ, Диләвер ОСМАН. .................................................................................................74

*Фотомизгелләр*. ..................................................................................................................................105

*Мәшһүрләр мөнбәре* (Хәсән Туфан, Гази Кашшаф, Фатих Хөсни, Миркасыйм Госманов). ....106

*Мөхәррир сорау бирә:* Әдәбиятыбызда «Казан утлары» яктысы.
Рамил ХАННАНОВ әзерләде. ................................................................................................................108

*Истәлекләр:* Мәгъсум ХАРИСОВ. Укытучы иртә чалара. *Автобиографик сәхифәләр*. .......118

*Юбилейлар:* Фоат ГАЛИМУЛЛИН. Сизгер күңел – нәзберек каләм. .........................................134

*Сәфәрләр, очрашулар, тәэсирләр...* .................................................................................................138

*Тарих*: Әгъзам ФӘЙЗРАХМАНОВ. Арча музейлары. .....................................................................140

«КАЗАН УТЛАРЫ» ЖУРНАЛЫНА – 95 ЕЛ

Фоат ГАЛИМУЛЛИН. «Безнең юл» журналы һәм Галимҗан Ибраһимов. ............................150
«Безнең юл»: Шәриф БАЙЧУРА. Патша хөкүмәте вакытында Төркестанда татар
мөгаллимнәре. ......................................................................................................................................156
«Яңалиф»: Мөхәммәт ЯУШЕВ. Боз кузгалды. .....................................................................................160
«Атака»: Ж.ИРТУГАНОВ. Донбасста татар матур әдәбияты. ..........................................................163
«Совет әдәбияты»: Г.КАМИЛОВ. Фронт газеталары. ........................................................................164
Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары. .....................................................................................................167
«Казан утлары»: Надир ДӘҮЛӘТ. Татар диаспорасы һәм Тукай. .....................................................168
Рәфикъ ЮНЫС. Сер саклаучы фотолар. .............................................................................................173
Миргазиян ЮНЫС. Соңгы сулыш. ......................................................................................................175
Мөхәррәм ШӘРИПОВ. Нинди җир ул Суслонгер?..............................................................................183
Булат СОЛТАНБӘКОВ. Татарлар һәм Игнатьев. ................................................................................185
«Рухи тормышыбыз энциклопедиясе». ..............................................................................................188

«Казан утлары» архивыннан. ..........................................................................................................116, 148
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ..............................................................................................190

Гамәлгә куючы –
«Татмедиа»
акционерлык
җәмгыяте

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Илфак Мирза улы**
**ИБРАҺИМОВ**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Рәдиф Җамалетдинов**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Дамир Исхаков**
**Зиннур Мансуров**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Вакыйф Нуриев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Данил Салихов**
**Айрат Сибагатуллин**
**Энгель Фәттахов**
**Равил Фәйзуллин**
**Рамил Ханнанов**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Рәфикъ Юныс**

---

*Мөхәррирләр:* **Айгөл Әхмәтгалиева, Гөлзадә Бәйрәмова, Фәнил Гыйләҗев, Камил Кәримов, Ләйсән Солтанова, Рәфикъ Юныс.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Наил Кадыйров.**

*Сайт мөхәррире:* **Рәзилә Хәйретдинова.**

*Исәп-хисап бүлеге:* **Люция Сөләйманова** (баш бухгалтер).

---

✉✉: Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир – 222-05-50 (өст. 1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1266).*
☽: **Факс** – (843) *222-09-83 (өст.1612).*

💻: **E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 03.05.2017, график буенча 03.05.2017.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108$^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ А-1108. Тираж 5250.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекслар: 73210 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен), П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), 16262 (Татарстаннан читтәге юридик затлар өчен), П2368 (Татарстандагы юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2017 ел

# РУХЫБЫЗ УЧАГЫ – «КАЗАН УТЛАРЫ» ЖУРНАЛЫНА – 95 ЯШЬ



«Казан утлары» журналы – бөтен дөньяга сибелеп яшәүче татар халкы өчен төп әдәби басма. Ул 95 ел буена берөзлексез халкыбызның әдәби сүзе, иҗтимагый-эстетик мөнбәре булып хезмәт итте, халкыбызның күңел җәүһәрләрен, рухи кыйммәтләрен, җанын-рухын үзенә ирештереп торды.

Әлбәттә, тарихы мең еллар белән исәпләнгән милли әдәбиятыбызны дөньяга танытучы башка газета-журналларның булуы да мәгълүм. Дистәләрчә исемдәге ул басмаларның географиясе дә Казан каласы белән генә чикләнмәгән. Санкт-Петербург, Уфа, Оренбург, Җаек, Әстерханда һәм Рәсәйнең башка төбәкләрендә, чит мәмләкәтләрдә милли байларыбыз, зыялыларыбыз бу саваплы эшкә алынганнар. Халкыбызның асыл улы, олуг шагыйре Дәрдемәнднең фатихасы һәм матди ярдәме белән Ризаэтдин Фәхретдин, Фатих Кәримиләр 1908 елда ук «Шура» журналын бастыра башлыйлар... 1912 елда меценат Әхмәтгәрәй Хәсәни тулысынча үз канаты астына алган, Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Рәхим, Г.Гобәйдуллин, Г.Ибраһимов, Җ.Вәлиди кебек талант ияләре тарафыннан нәшер ителә башлаган «Аң» журналы исә, нәкъ бүгенге «Казан утлары» кебек үк, «әдәби, фәнни, сәяси вә иҗтимагый рәсемле журнал» буларак таныла.

Әдәбиятчы галимнәребез билгеләп үткәнчә, узган гасырның башында гамәлгә куелган милли матбугат битләрендә 400дән артык шагыйрь, язучының әдәби иҗат үрнәкләре нәшер ителүе билгеле.

1922 елда «Безнең юл» исеме белән дөнья күргән әдәби журналыбыз, ягъни бүгенге «Казан утлары»ның әнкәсе, халкыбызның соңгы биш гасырлык тарихында беренче тапкыр дәүләт тарафыннан гамәлгә куелган әдәби басма. Дәүләт тарафыннан бар ителгән әдәби басма, әлбәттә, шул дәүләтнең, дөресрәге, дәүләт идарәсе башында торган сәяси фирканең рупоры, идеология коралы булмыйча кала алмый. 95 ел дәвамында «Безнең юл»ның «Яңалиф», «Атака», «Совет әдәбияты» исемнәренә үзгәртелүе дә матбугат чараларының ил-көндә урнашкан сәяси вазгыятькә бәйле булуын күрсәтә.

Редакция архивында әлеге исемнәрдә чыккан барлык журналларның төп нөсхәләре саклана. 1100дән артык данә. Редакциядә элгәре эшләгән хезмәттәшләребезнең бик тә җаваплы кайгыртучанлыгы белән яхшы сакланган алар. Битләренә сарылык йөгерсә дә, таушалмаган, һәр хәреф-юллары бүген басылгандай ярылып тора... 2017 елга чыкканда, республикабызның

Милли китапханәсе тарафыннан ул архивтагы барлык нөсхәләр тулысынча цифрлаштырылып, аларның электрон форматлары – нөсхәләре булдырылды... Никадәрле зур эш эшләнде... Никадәрле олы хәзинәбез заманча әйләнешкә кертелде! Иң мөһиме, бүгенге көндә әлеге хәзинәдән бөтен дөньяга сибелеп яшәүче милләттәшләребез бернинди түләүсез файдалана ала. Моның өчен «Казан утлары» журналының сайтына керү җитә.

Ил-дәүләттәге вазгыятькә карап исемнәре үзгәрсә дә, төп әдәби басмабызның бернинди үзгәрешсез дәвам иткән олы максатлы юлы бар. Ул – газиздән дә газизрәк Ана телебезне саклау. Дөнья әдәбиятының барлык төрләре, жанрлары үрнәгендә милли әдәбиятыбызны үстерү, әдәбият белеме фәненә өлеш кертү, милли әдәбиятыбыз, сәнгатебезне халкыбызның рухи тормышы-яшәешенең аерылгысыз кыры-бакчасы итү, милли әдәбиятчыларыбызның яңадан-яңа буыннарын тәрбияләү кебек максатларны берләштерә ул олы юл!

Кешелек үткәннәре белән яши дигән гыйбарә бар. Үткәннәр киләчәккә бару юлында сабак алу өчен кирәк. Халкыбызның рухи бакчасы булып торган милли әдәби басмабызның үткәне сокланырлык, горурланырлык. Ил-көндә үзгәртеп корулар башланганчы, «Казан утлары» журналы СССРның бөтен союздаш, автономияле республикалары, өлкәләренең китапханәләренә, уку йортларына мәҗбүри нөсхә буларак җибәрелә, АКШ, Канада, Кытай, Япония, Төркиягә һәм Европа илләренә таратыла... Журналны яздырып алучылар саны 1981 елда йөз меңнән арта...

Агымдагы елның гыйнвар аенда Төркиянең Измир шәһәренә эш сәяхәтенә баргач, Мәрмәрә университетының төрки әдәбиятлар факультеты китапханәсендә «Казан утлары» журналының дистәләрчә еллар буе тупланган саннарын да, бүгенгеләрен дә күреп, горурлык хисләре кичердем... Очрашуга килгән галимнәр «Казан утлары»н дәреслек буларак куллануларын, бүгенге татар әдәбияты, шигъриятенең дөнья әдәбияты үрнәкләре югарылыгында булуын әйттеләр.

Бу саннар, бу мисаллар милли әдәбиятыбыз, сәнгатебезнең бүгенге глобаль дөньяда халкыбызны милләт буларак үз йөзен саклап калуда, аның рухи дөньясын бар итеп торуда никадәр әһәмияткә ия икәнен дәлилли. Халык рухы, халык хәтере, традицияләре, тормыш көтү тәҗрибәсе язма мәдәният рәвешендә генә яши, дәвам итә... Электрон форматлар, интернет – барчасы язма мәдәниятне туплау, заманчалаштыру, саклау формалары, технологияләр генә.

Электрон китаплар, китапханәләр булсын өчен әүвәл язма әдәбият үзе кирәк. Ул исә фәкать әдәби журналларда, язучы һәм мөхәррирләрнең бердәм тырышлыгы белән генә дөньяга килә. Әлеге әдәбиятны укучының кайсы форматтан алып куллануы исә һәркемнең үз ихтыяры...

Үткәннәрдән сабак алып, киләчәгебез турында уйланганда, без милли матбугатыбыз, шул исәптән милли әдәби басмаларыбызны әле музейларга куярга ашыкмыйбыз.

Республикабызда дәүләт бюджетыннан нәшер ителә торган әдәби басмалар – «Казан утлары», «Сөембикә», «Идел», «Мәйдан», «Безнең мирас» журналлары, «Мәдәни җомга» атналык газетасы редакцияләре бүген Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендәге сәясәтен тормышка ашыру буенча кайчандагыга караганда да тырышыбрак хезмәт куя. Бу олуг миссияне үтәүдә

дәүләт структуралары, фәнни үзәкләр, иҗат берлекләре, киң җәмәгатьчелекнең дә йогынтысы көчәйде. «Казан утлары» журналының редакция советы тарафыннан аның үсеш перспективалары, әдәби иҗат барышын оештыру, укучылар даирәсен киңәйтү юллары билгеләнде. Республикабыз дөнья җәмәгатьчелеге алдында тотрыклы яшәү төбәге булып танылган икән, моңа фәкать халкыбызның зыязатлыгы, йөзләрчә еллар китаплы халык булуы белән ирешүе – һәркемгә мәгълүм.

Әдәби басмаларыбызның киләчәге милли зыялыларыбызга бәйле. Бүген милли байларыбыздан нәшер итү өчен, шөкер, матди ярдәмгә мохтаҗлыгыбыз юк... Бүген милли хәзинәбезгә тиң әдәби басмаларыбызны халкыбызга җиткерү өчен һәр зыялы затның шәхси үрнәге, милли гаилә традицияләрендә яшәве, миллилектән читләшмәве кирәк.

Әдәби басмаларыбызның киләчәге турыдан-туры милли мәгарифебез белән бәйле. Төркиянең Мәрмәрә университеты галимнәре өчен генә түгел, үзебезнең югары уку йортлары, педагогик колледжлар, гомуми мәктәпләр өчен дә дәреслек дәрәҗәсендә кулланылырга тиеш милли матбугат чаралары. «Казан утлары» журналы үзенең эчтәлеген мәгариф эшенә җәлеп итәрдәй яңадан-яңа сәхифәләр, темалар белән баета... «Мөгаллим мөнбәре», «Ак җилкән», «Укучыларыбыз иҗаты», «Хикәя яза аласызмы?», «Яңа исемнәр», «Каләм тибрәтүчеләр» рубрикалары – соңгы елларда гамәлгә куйган яңалыкларыбыз...

Мәгариф министрлыгы белән хезмәттәшлек итүебез нәтиҗәсендә барлык мәгариф учреждениеләре, бигрәк тә милли гимназияләр белән элемтәләребез ныгыды. Соңгы өч елда «Казан утлары» журналын укучылар даирәсе мәктәп укучылары, укытучылар бәрабәренә бермә-бер артты.

Милли басмаларыбыз яшәсен өчен, әлбәттә, аның язучылары, укучылары булу кирәк. Шөкер, республикабыз язучыларының иҗат активлыгы кимегәне юк. Бигрәк тә яшь каләм ияләренең каләмнәре үткенләнгәннән-үткенләнә бара. Агымдагы елда гына да без журналыбызда берсеннән-берсе мәртәбәле биш роман тәкъдим итәчәкбез. Алдагы елның апреленә кадәр хикәячеләр бил алышачак.

Журналыбызга – 95 яшь. Ул – үз яше белән аксакал да, үз авторлары, үз мөхәррирләре, үз укучылары һаман яшәрә барган рухи учак та... Аның җылысы, нуры көчәйгәннән-көчәеп, озак еллар халкыбызның рухын яктыртып торыр әле! Шулай булсын, Аллаһым бер!

**Илфак ИБРАҺИМОВ**



Ркаил
Зәйдулла

# ОЧКЫН БАР КАЛӘМ ОЧЫНДА

## Юл

*«Казан утлары» журналының 95 еллыгына*

Юллар чуалган чорларда,
Чуалып зиһен, акыл да,
Хыялый булып, саташып
Җирдәге җәннәт хакында,

Безнең юл, менә безнең юл! –
Кем дәшкән? Кемнәр сөрәне?
Фетнәдән азган киләчәк
Тырнагы күзгә терәлде.

Сүзләрне тезеп кәгазьгә,
Әйтерсең гаскәр тезелә! –
Тартышып яшибез һаман,
Хак бар яшәргә безнең дә.

Өзелә гомер бу юлда,
Гарьлектән үзәк өзелә.
Җил искәнне көтә кузлар
Тузгыган учак эзендә.

Караңгыда адашсак та,
Төн әле безне йотмады:
Очкын бар каләм очында,
Эч тулы – гыйсъян утлары...

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА (1962) – *шагыйрь, прозаик, драматург; «Мәгарә», «Ташка ордым башны», «Саташкан сандугач» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

## Гомер тирәге

Гомер тирәгеме соң бу?
Нигә алайса бик яшь...
Бу бит... бу бит миңа түгел,
Минем улыма тиңдәш.

Чал ирне аңламас һич тә,
Һәм бирә алмас киңәш.
Төс түгел сызлануларга,
Шаулап утыра – көләч!

Сер сөйләргә, мактанырга,
Якланырга юк ярым.
Гомерем тирәге! Синме бу? –
Тыңла алайса зарым.

Тыңла!
Йөзеңне каплап һич
Борылма миңа аркан.
Имгәк шикелле кимсенәм,
Сары сагыштай артам.

Ялгыз калдым яр буенда...
Артка юл юк.
Алда – су...
Көймәсез, җырсыз һәм атсыз...
Һәм хаксыз!
Язмышмы бу?

Тыңлады тирәк...
Кабарды,
Күкләргә тиде башы.
Миңа тигән дөньяны да
Каплады ябалдашы.

## Төркестан

Төркестанның кайнар туфрагында,
Эргәсендә Әхмәд Хуҗаның,
Карап калдык башын горур чөеп
Янәшәдән дөя узганын.

Профессор! Әйтче, остазым,
Кузгалдың да янды күзең,
Һәм,
Нигә үз артыңнан кыстадың? –
Киттек бергә дөя эзеннән...

Иясе бар икән дөянең дә:
– Тезлән! – диде. Дөя тезләнде.
Эссе кояш, сары яфрак сыман,
Каплаганда безнең күзләрне, –

Искәрмәдең, үрмәләдең өскә.
Сары яфрак сыман җиңел син!
Аваз бирде дөя. Әйтте гүя:
Татар һәрчак өстә күренсен...

Юкса аның юри генә иде
Кылануы, мәзәк ясавы.
Дөя чөйгән биеклектә калып...
Җиргә чумган төштә Ясәви.

Профессор! Әйтче, остазым,
Кузгалдың да янды күзең,
Һәм,
Нигә үз артыңнан кыстадың?

Анда инде кәрван тезелгән!
Мин дә киттем дөя эзеннән...

*Төркестан шәһәре. Май, 2016 ел.*

## Таң

Бәләкәй йорт, нәни инеш.
Тонык су агар-акмас.
Җил дә һаман тынган килеш –
Төн китмәс тә таң атмас.

Теге якта киңлек. Якты!
Тик нигәдер бу таба
Ялгыз тирәк басма тапты,
Итәгеннән нур тама.

## Фәрештә

Күгем минем тоташ болыт иде,
Томаланган иде күңелем.
Син килдең дә күтәрелде пәрдә,
Ләйсән яңгыр булып түгелдең.

Һәм сафланды һава. Кояш чыкты.
Күрдем шунда – дөнья киң икән! –
Су буенда тал-тирәккә кадәр
Сәҗдә кылыр өчен иелгән.

Мин таныдым сине – син Фәрештә!
Юл күрсәтеп мине чакырдың.
Учларыма кояш суздың юмарт,
Һәм сугарды җанны яңгырың.

Кочакларга теләп бу җиһанны –
Кочак җитәлмәслек олы ул! –
Кеше булам диеп юлга чыктым...
Тик һай авыр кеше булуы.

Каршыладың канатыңны җәеп,
Мәрхәмәтле, газиз Фәрештә...
Җитәклә син сикәлтәле юлда,
Юнәлгәндә хәтта гарешкә.

Оялт, юат, өндә якты көнгә –
Килдең миңа артык соңарып...
Нурларыңда эреп юкка чыгыйм,
Мин – гади бер шагыйрь сыңары.

## Күрән

Кып-кызыл миләшләр!
Сап-сары өрәңге.
Вак яңгыр сибәли. Сүрән көн.
Күзләрем, ниһаять, күнекте көзләргә...
Мине дә көз бераз өйрәнде.

Кып-кызыл миләшләр!
Сап-сары өрәңге...
Күрергә судагы күрәнне
Килдемме бу ярга? Күңелем ямансу...
Сары җил урый тик тирәмне.

Кып-кызыл миләшләр!
Сап-сары өрәңге...
Тын сулар чайкала. Тирән күл.
Тукта, җил! Чал ирнең уенда ни булмас, –
Бу салкын тыныңны өрмәле.

Кып-кызыл миләшләр!
Сап-сары өрәңге...
Җил исә – тарала серләре.
Мин төсен югалткан күрәндәй, нишлим соң? –
Баш җуеп көзләргә керәмен.

Сап-сары миләшләр...
Кып-кызыл өрәңге...

## Боз астында кояш

Кычкырды үсмер олан,
Ул, әлбәттә, мин булам:
– Тәзкирә! Тәзкирә!
Ярга борынын терәп
Кояш әнә су керә.
– Син соң әллә тилеме?

Еллар үтте, ул инде
Кемнәрнеңдер килене.
Хатын инде кемгәдер...

Кайттым илгә. Иңрәдем:
– Тәзкирә... Тәзкирә...
– Әллә соң син юләрме?
Киттең... Беттең... Оныттың
Безне... Туган илләрне.

...Боз каплаган су өстен.
Бәкесе бар. Су эчтем.

Тәзкирә-ә!..
Боз астында күр әнә –
Бер кояш бәргәләнә.

## Бер кош канат какты

*Гәрәй Рәхимгә*

«Хәлең ничек?» – дип сорадым...
Бик авыр, диден, эшләр.
Күңелне сыза зур сагыш,
Яшертен үкенечләр.

«Бирешмә!» – дип үтендем мин...
Тышта, диден, кар төшә...
Урын эзләп һәр бөртеге
Берсен-берсе этешә.

Бер кош канат какты әнә,
Нәни кош... Күзендә яшь.
Күреп яшәү һәвәслеген
Нинди күңел кинәнмәс.

Канатыннан тамды кинәт
Нур тамчысы яп-якты...
Күзем карасына тиеп
Акты биттән...
Уятты!

Эш дип йөгердек һәмишә...
Кадалып китсен эшләр!
Кешене кеше итә тик
Вак-төяк сөенечләр.

## Аваз

*Каләмдәшем Илсөяргә*

Күземнең төсен таный алмасаң,
Узып киткәндә сәлам дә бирми,
Ачуланма, дус, ерак әле таң,
Тик шәфәкъ кенә күңелдә дөрли.

Казанда торып таралдык күптән,
Иңгә иң куеп атлый алмадык.
Безгә кадәр үк яу дәрте үткән,
Кулдагы әләм – ертык ямаулык.

Тузанлы юлдан яңгыр көткәндә,
Кемнәр өчендер бераз каралдык...
Тик ис китмәде: башка сибәргә
Килер кышлардан учлап кар алдык.

Тамырлар сыкрап укмашкан җирдә
Аваз булырга без дә ярадык.
Сөенмәсеннәр, таптадык, диеп, –
Баш күтәрербез көлдән яралып.



Вахит
Имамов

# КАРАБӘК

ТАРИХИ РОМАН

*Ерак бабам, бөек Карабәк рухына багышлыйм.*

**1**

– Туктамыш ханнан чапкын!

– Яңа хан чапкыны!

Ихатада яңгыраган шушы хәбәр барча кирмән эчендә корт күчедәй мәхшәр куптарса да, сарайның түр бүлмәсендә яткан Карабәкнең күңелендә кыл да кыймылдамады. Тышта, табаннарына ут капкан шикелле, йөзбашлар белән ясавыллар[1] чабыша, хәтта меңбашлар да ни кылырга белми изалана: әттәгенәсе, күз өстендә каш булырлык затлы җайдак килгән, Урда мәркәзендә чираттагы хан калыккан икән! Юкса, төкерәсе! Бик күп булды андый түнтәрешләр. Карабәк үзе дә – Сарай тәхетенә ике тапкыр арт тидергән таждар. Беренчесенә – егермегә якын, икенче кабатына унбишләп ел үткән. Ә аннан соң, күк йөзендәге Ай шикелле, Урда тәхетендә дә ай саен йә ярты ел саен хакимнәр алышына. Бер хакимнең йөзен күреп калырга, алдына тезләнеп бигать[2] китерергә дә өлгермиләр, анысын тагын да кансызрагы, залимрәге суеп ыргыта да, бөке кебек, яңа таждар калка. Тик ул табадагы коймак шикелле яңарып торучылар олуг хан таҗын үлчәп карарга да өлгерми, анысын да йолкыш бүре урынына куып җибәрәләр. Кара гавамның, бичара, таҗдарларның исемнәрен дә ятлап калганы юк...

Карабәкнең үзенә Туктамышның исеме күптән таныш. Сабый чактан бирле, дип күпертсәң дә ярый. Егерме ел чамасы элегрәк аларның олыслары бер-берсеннән кул сузымында гына иде. Карабәкнең әтисе Дәүләт-Хуҗа Сакмар буендагы Актүбә олысына йортбаш булып торды, Туктамышның атасы Туйхуҗа бәк алардан шәрык ягынарак сузылган Җаек ярындагы Сарайчык олысында кышлау-җәйләү тотты. Кырым-йорт, Болгар иле, Күк Урда атлы

[1] Ясавыл – кала-кирмәннәрдәге эчке сакчы.
[2] Бигать – тугрылыкка ант.

Вахит ИМАМОВ (1954) – *язучы; «Татарларның Ватан сугышы», «Сәет батыр», «Утлы дала» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе, Г.Исхакый исемендәге әдәби премия лауреаты. Казанда яши.*

үзбаш йорт төзүләр, каш ясыйм дип күз чыгарган кебек, Сарайдан аерылып йөрүләр юк иде ул заманда. Дәүләт-Хуҗа олысы – нигездә гәрәйлеләр, Туйхуҗа бәкнекеләр ак мангыт дип аталса да, барча ыру-кабиләләр, лапасларга бикләнгән маллар төсле, Алтын Урда атлы гомумтүбә астында мәгыйшәт асрый иде. Шул елларның берсендә Сарайда Җанибәк атлы олуг хан сырхаулап егылды да, Җучи төзеп калдырган шанлы Алтын Урда, комнан әвәләгән йорт шикелле, янтайды да төште.

Тәүге гаеп кемдә? Чыңгыз әманәт итеп калдырган «Яса» кануннарын таптап, Алтын Урда нигезен әүвәл кем какшатты? Каһәр-ләгънәт атлы күз яшьләре, иң беренче чиратта, кемгә тиеш?

Тирәнгә үк чумып тормыйм дисәң, һәлакәт һәм мәхшәр Җанибәкнең атасы Үзбәк ханнан башлангандыр, бәлки. Туктай атлы хан, әле түшәккә ауганчы ук, үз урынына өлкән угылы Илбасмышны утыртырга васыять иткән була. Иллә мәгәр хан җәнапләре әле исән чакта ук хата җибәрә – ул Харәзем дәүләтендә шәех булып утырган Имаметдин хәзрәтне үзенә якынайта. Аның вәгазьләренә мөкиббән киткән Туктай-таҗдар шәех Имаметдинне Сарайга чакырта да, үз теләге белән дилбегә тоттырган төсле, сәед итеп куя. Ә Туктай хан хаста булып егылуга ук, ошбу сәед агулы җимгә тиң үз вәгазен башлый.

– Сарай белән Үргәнеч калалары – ике игезәктер. Сезгә имамнарны Бохарага җибәреп гыйлем эстәтү дә, асыл затлы суфилар кулында булган Харәзем мәмләкәте илә сәүдә итмеш тә килен төшерү төсле бик муафыйк гамәл. Мүнкә-Тимер хан оныгы вә Тагрул угылы булган Үзбәк атлы әмир-солтанымыз Коръән-хафиз булмыш өстенә суфилар мәмләкәтенә йөз тотуы илә дә танылмыштыр.

Сәеднең мондый татлы вәгазеннән аеруча Үргәнеч белән Бохара ягына сукмак салган сәүдәгәрләр кавеме мәмнүн кала. Үз чиратында, шулар әмир белән бәкләр колагына тукран төсле тукый.

– Сәүдә гамәлләре вә иҗтиһад – мәмләкәтне көч-куәтле итүнең нигезедер. Тауар-нигъмәт белән берлә байлыгы да, салымы да кайта. Ат аунаган җирдә төк кала ди, табын-казналарның мөбарәк булуы – түрә кавеме өчен дә коргаксымас кое. Безгә тәхтемезгә Үзбәк солтанымызны күтәрү отышлырак.

Нәтиҗә шул: байлар, сәүдәгәрләр ул елны ак киезгә Үзбәкне күтәрә. Яңа таҗдар һич вакланып тормый – вәли гаһед[3] булган Илбасмышны гына түгел, аны яклап йөргән йөз егерме түрәне дарга озаттыра.

Хыйлаф үрнәк – үләттән дә яман. Мәгълүм ки, җиде йөз дә кырык ике санәдә[4] дөнья куйган чакта Үзбәк үзе моны күз чалымына да китереп карый алмый. Ул да, беркатлыланып, үзе урынына өлкән угылы Танибәкне варис иткән була. Бәхетсезлегенә, Танибәкнең Сарайдан еракта, Нишапур-Кәшмир якларында, Чагатай туруннарына[5] каршы яу кылып йөргән чагы. Ә тәхетне чебен төсле сырып алган түрәләрнең һәркайсында тешләренә сөяк йә калҗа каптырган этнеке шикелле үк начар гадәт – алар калҗага хәтта үзләренең газиз балаларын да якын китерми. Ханбикә ятагына иялә шкән Тайдула да юрганны олуг ир булып җитлеккән Танибәк белән бүлешүне тарсынган бит. Ире Үзбәк күзен йомуга ук, берәм-берәм каршысына тезеп, әмирләре алдында җыр башлаган.

– Олы улым бәләкәй чагыннан ук мән белмәде, ә ханымыз аны башлы-күзле иткәч, энеләрен генә түгел, әмирләрне санга сугу дигән гадәтне дә онытты.

---

[3] Вәли гаһед – тәхеткә кануни варис.
[4] Миладиа белән 1342 ел.
[5] Турун – оның улы яки оныкның оныклары.

Танибәк алга табан мәмләкәтне хосусан үзе вә хатыны илә биетеп тотар сыман. Үзбәк ханымыз, әнә, бер Үргәнеч каласында гына да шәех Шәриф, Түрәбан хан, чичән Нәҗметдин Кобра пулатларын, Ак Кала кирмәнен, башка тарафларда ничәмә-ничә җәмигъ мәчетләр вә алтын илә нәкышләнгән мәрмәр төрбәләрдә төзеттереп куйды. Дәүләт илә, Үзбәк ханымыз төсле, әмирләр вә бәкләр берлә киңәшләшеп, күмәкләшеп идарә кылу фарыз. Ә Танибәк кансыз. Ул, юньсез бозау сыман, әмирләрне талап имүдән башканы белмәячәк.

Тамчы ташны тишә. Җанибәкне, ашык-пошык кына, тәхеткә иңдерделәр. Ул да түгел, Урда күген көпә-көндез яшьнәгән яшен төсле хәбәр айкап үтте.

– Дилбегәне Тайдула ханбикәбез кулдан ычкындырмый, ул угылы Җанибәк илә бергәләп идарә итәчәк, ди.

«Танибәк кайта», – дигән хәбәр таралуга, Тайдула үзенә бигать китергән әмирләрне асыл варис олавына каршы куды.

– Вәгъдәләшкән гамәлне үтәп кайту насыйп итсен сезгә. Хан җәнапләре сезнең тугрылыкны мәңге онытмастыр...

Танибәкне Сарай-Бәркәдән ике тәүлекле юл арасындагы Сарайчык каласына чаклы каршы барып уен ясадылар. Танибәк мондагы әмир сараена үтеп мәҗлес корган булган.

– Юлда кайткан чакта чит итмәсен өчен без шушында ук бигать китерәмез. Һәркайсымыз, эргәсенә кереп, кул үбәргә әзер.

Шундый күндәмлек күрсәтүләргә яраннары каршы тора алмаган. Ә соран[6] әмирләр залда Танибәкне урап алганнар да күз ачып йомган арада буып үтергәннәр. Сөенечле хәбәр җиткерүгә, Җанибәк үзенең бердәнбер энекәше Хасарны да буып ташлаттырган. Тик Җанибәк тә үзен нинди канлы тәкъдир сагалап торуын чамалый алмаган шул.

Җанибәкнең тәхеткә менүенә унбиш ел тулганда, мәмләкәттә көтелмәгән елан пәйда булды. Каф тау өркәчләре артына таралган азәриләрнең Әшрәф атлы бәге, тавык кетәклегендәге куначасын онытып, бөркет сыман тоя башлагандыр, шул хөрәсән үзен мәлик-солтан дип игълан иткән! Әтәчләрнең кайсысы гына төн уртасында саташып бугаз ярмый, анысына гына төкерер дә идең. «Моннан ары Сарай тарафына сыңар арбалык та ясак озатмыйбыз!» – дип шәрран ярып хат язган бит әле. Мин-минлеге чуан шикелле сытып уятылган Җанибәк, өч төмән гаскәр кузгатып, Каф таудагы тарлавыклар арасына чумарга мәҗбүр булды.

Дәште Кыпчактагы барча татар «Тимер Капка» дип йөрткән Дирбәндне дә, аның артыннан Ширбән каласын да тиз үттеләр. Дәрьял тарлавыгында берьюлы ике яктан турап ташларга ниятләп, мәлик Әшрәф төмән ярым җайдак белән генә каршы чыккан булган. Мәгәр урдалылар тарлавыкны җәйрәндәй тиз узды, ә тигез яланда азәриләрне зур боҗрага алып, давыл шикелле котырынып, дулап тукмадылар. Мамай атлы меңбаш мәликнең шәхсән үзен аркан ташлап әсирлеккә алган. Мамай кичә генә кияү егетедәй үз-үзенә хозурланып йөргән Әшрәфне олуг ханның аяк астына китереп ташлагач та, Җанибәк, күркә сыман кабарынып, бик кукраеп дәште:

– Монда суйсам, дошманнарың гына күрә, сабак алучы юк. Җиңүчегә кан дошманын үз илендә, туганнарының күз алдында җәзалап үтертүдән дә татлырак ширбәт, ләззәт булмас. Мин синең төн уртасында саташып кычкыра торган әтәчнекедәй буш башыңны мәркәз үзәгендә, Тәбриз мәйданында чаптырып ташлыйм әле!..

Җанибәккә тау һавасы ярамады, ахры, ул түшәккә ауды, ут шикелле

[6] Соран – төсен үзгәртүче җәнлек, хамелеон.

кызышып, тоташ укшып ятты. Ике-өч тәүлектән соң, чатырына чакыртып, янындагы улы Бирдебәкнең колагына тиз-тиз пышылдады.

– Тәбризгә чаклы барып йөрердәй гайрәтем юк. Мин ике төмәнне үз артымнан ияртәм дә кайтыр юлга чыгам. Син сүземне үтә. Тәбризгә җит. Әшрәф гыйсъянчының башын зур бүкәнгә куеп чаптырмыйча калма. Үзең өчен гомерлеккә ятла. Ханияләр өчен гыйсъянчы яраннарыннан да хәтәррәк бәла-каза юктыр. Читтән килгән дошман хәвеф түгел, алар синең тәхетеңә менми, акыртып талый вә ахыр чиктә төянә дә китә. Ханияләр өчен үз мәмләкәтендә баш күтәргән гыйсъянчылар – иң әшәке дошман.

– Мәлик Әшрәфнең башын чаптырмый кайтмыйм, әткәй, – дип тел кузгаткан Бирдебәкне сәйяхчы хан ярты сүздә бүлде.

– Әшрәфнең җанын кыйганнан соң да кайтмыйча тор әле. Аның урынына яңа җасус[7] табылуы мөмкин. Фәрман әзер. Мин сине Тәбриздә Урда каладары[8] итеп тәгаенләп китәм. Хаҗәт туса, шундук чакыртырмын...

Хан чатырыннан чыгуга ук, Бирдебәк солтан меңбаш Мамайны үз янына дәште.

– Ияреңә сикер, юл буенча бер адым да калмыйча, хан җәнапләренең янында йөр. Чире тотып, тормастай егыламы, җанын тәслим кыламы, әллә үзе урынына минем берәр борадәрне калдырырга васыять яздырамы – барысы хакында да шундук миңа җиткер. Ә Сарайга кайткач, шыпырт кына бәйләрбәге Тулбайга да белгерт. Ул да, син дә – таянырдай якын яраннарым. Мин тугры яраннарны соңыннан алтын-мәрҗәннәргә күмми калмам.

...Җанибәкне исән-сау көенә кайтарып җиткергәннәр, ул Сарайда да ике-өч атна буе сырхаулап яткан әле. Бер төндә ханның һуштан язуын күргәч, Тулбай үзе ясавыллар арасына чыгып, меңбаш Мамайны иярге күтәрттергән.

– Табын әзер. Кунаклар сугым ашын гына көтеп утырадыр. Алар дога кылачак хәзрәтнең килүенә нык сусаган. Шушы сүзне түкми-чәчми тапшыр...

Берәр айдан соң ун гына җайдак ияртүкән Бирдебәк авыртмаган башка тимер тарак кебек кайтып җитсә, Җанибәк хан сырхавыннан туктап, аягына басарга җыена икән. Чигенердәй ара калмаган бит, Бирдебәкнең фәрман бозуын белсә, ханзадәнең башсыз калуы да озак йөрмәс. Гыйсъянчылар, тараканнар төсле, Тулбай бәкнең йорт эченә кереп бикләнәләр. Ил юынтык суы булмаган йорт шикелле үк гайбәтсез дә тормый, хәтта җансыз койма-капкаларның да колагы бар. Качаклар турында Җанибәк ханга да илтеп җиткерәләр. Аның таянычы – бәйләрбәк бит! Ул, җилем сыман тартып-сузып тормыйча, Тулбай бәкне дәшкән.

– Бирдебәк нишләп монда? Аны кайсы мәкерлесе Тәбриз каласыннан чакырттырып алган?

– Мин ачыклармын, төбенә төшми калмам. Баш өсте, баш өстедер, ханым җәнапләре, – дип билен бөккән булган икейөзле әмир.

Ә сарайдан чыгуга, кабат көянтәдәй бөгелеп, ханбикә Тугай-әкә янына барып кергән.

– Нинди ният илә кайтканлыгын белсә, Җанибәк хан Бирдебәкнең башын чаптырачак. Син – Бирдебәк анасы. Газиз угылыңның җанын коткар.

Хан булса да, Җанибәк тә – адәм баласы бит, киңәш-уңашка дип хатынын чакырттырган. Тугай-әкә, күрәсең дә, улын кызгангандыр, кызу-кызу тезгән.

– Бирдебәк каян килеп монда булсын инде? Аның хакындагы гайбәт – барысы да ялган. Ышанмасаң, үз яныңа каравылбаш Гарифҗанны чакыр,

[7] Җасус – астыртын, мәкерле рәвештә килеп җан кыючы.
[8] Каладар – наместник.

шаһитлеккә Тулбай бәкне дә дәш. Һәркайсының йорты кул сузымында гына, кирәк икән, үзем чакыртам да кертәм...

Тәбриздән бирле төн йокламый кайткан һәм хәзер инде Тулбай бәкнең кибәндәй гәүдәсе артына яшеренеп кергән чапкын ирләр, тәхет залының түренә үтүгә үк, таҗ иясен тавык чебеше урынына буып аткан. Хан җәсәден йокы бүлмәсенә ертык юрган төсле кертеп яшерүгә, Бирдебәкнең үзен чакырганнар. Бирдебәк нәкъ этисен бугазлап үтергән келәм өстенә аякларын бөкләп утырган да кан катарлык әмер ташлаган.

– Берәм-берәм, бөтен энекәшне сөйрәп китерегез!..

Юлда чакта ук ишәк урынына кыйналган бичаралар кереп бил бөгәргә яисә ант китерү өчен авыз ачарга да өлгерми, Бирдебәк һәрберенең йә билен сындыртып, йә суйдырып бара. Уникенче саналган төпчек энекәшен, сигез ае да тулмаган нарасыйны, һич югы монысын кызганмасмы дип, Тайдула әбисе күкрәгенә кочып кергән булган.

– Юк, үсеп җиткәч, монысы да барыбер җан кыячак! – дип үкергән дә, әбисенең күкрәгеннән үләксә бүлешкән сыртланнардай йолкып, Бирдебәк сабыйны ишек ниргәсенә башы белән орган...

Ә язмыштан барыбер узмыш юк бит. Ике ел үтүгә үк, әмирләре Бирдебәккә каршы фетнә корган. Шулар бер төн эчендә канэчкеч ханны да, икейөзле бәйләрбәге Тулбайны да суеп үтергәннәр. Ә аннары Урда Сараенда – шайтан туе! Дөрләп янган учак яисә кайнап торган казанны хәтерләткән хан сараена моннан ары һәркем кул селтәр, дип уйлаганнар иде, ни әкәмәт, мичкәсе белән ширбәт тапкан бал кортлары кебек, кабат ябырылдылар. Урдадагы барча әмир шашты.

Ул чагында даими гаскәрдәге бер канатка Мамай ия иде. Ул – хан кияве, куенында Бирдебәкнең кызы Гөләндәм бар. Әмма Мамай – тәхеткә дәгъва итәргә бөек Чыңгыз ханның нәселеннән түгел. Шуны чамалапмы, ул үзенә бабай тиешле Бирдебәк хан исән чагында ук әүвәл ике-өч төмәнгә йөгән ташлап өлгерде, аннары Сарайдан ерактарак, Идел тамагы ягында Үкәк атлы кала корып куйды. Аның хакында «Мамай бабасы Бирдебәк ханны суюда катнашкан», «Бабасын суюны Мамай оештырган», дигән уттай кайнар имеш-мимешләр дә тараттылар. Мамай – шомарган таш, түнтәреш хәтле түнтәрештән аның читтә калуы да бик икеле. Хакмы-ялганмы бу хәбәр, ачыклаучы юк бит. Мамай үз эзләрен елан төсле тиз яшерә белде. Чынлыкта исә, пошмас бәндә сыман, тау башында кысла сызгыруын көтеп йөрмәде ул. Сарайдагы тәхет бушануга, Кырымны тез астына бөгеп салды да, аерым хан төсле, ясакны үз биштәренә тупларга тотынды, мәркәзне гел онытты. Аннан күрмеш, Урда ханы исеменнән Болгар олысына ясак җыярга барган Тимер-Булат үзен әмир дип игълан итте, Болгар-Җүкәтаулар аерым йорт шикелле аерылып чыкты. Кичә генә Бирдебәк кул астында әмир булып йөргән Хаҗи-Чиркәс Хаҗитархан каласын учына сосып алды һәм хаким кыяфәтендә баш калкытты. Җаек буендагы олысларда һәм Сарайчык каласында Айбәк атлы әмир үзбаш булды. Мәркәзләре Мукшы булган олысны Сәркиз атлы әмир үз кулына алды һәм Сарай фәрманнарын кире борды. Билгеле ки, Владимир, Сүздәл, Тверь, Мәскәү, Рәзән каласында утырган кенәзләр дә авыз ачып калмады, аларның да һәммәсе Сарай казнасына ясак озату дигән гадәтләрдән бизде.

Җидесу[9] атлы зур олыста утырган Чымтай углы Ырыс[10] барысына караганда да елгыр, үткер икән. Ул әүвәл бер-бер артлы Сыгнак, Сауран, Әтрәр атлы

[9] Җидесу – Сыр-дәрья белән Әму-дәрья арасы.
[10] Ырыс – иске төрки телдә «бәхет» дигән сүз.

калаларны учына җыеп алган, ә аннары инде үзен, Күк Урда дигән аерым йорт ханы итеп, ак киез өстенә күтәрткән дә куйган. Сасы көзән, кетәклеккә керсә, бер генә тавыкны буып туктыймы соң! Гоҗ тамаклы хаким Харәзем таҗы булган Үргәнеч каласын да үзенә кушып куйгач, инде Алтын Урдадагы Сарай-Бәркәгә дә күз ташлаган. Ә гаскәр җитенкерәми, булганы – бик көчсез. Меңкышлак олысына таралган ак мангыт кабиләсеннән дә чирү сораган бу. Башлык булып торган Туйхуҗа бәк Җучи олысын тез астына салырга маташкан Ырыска төмән җыеп бирүдән баш тартырга батырчылык иткән. Ә Ырыс хан Туйхуҗаны үсмер угылы Туктамыш һәм барча бәкләр күз алдында дарга озаттырган. Шул кайгы һәм мәсхәрәгә түзмичә, Туктамыш Сәмәркандта әмир булып калыккан Аксак Тимер янына качып киткән. Дөнья чиләктәге юынтык су шикелле айкала да, чайкала да бит ул. Менә, өч ел элек Туктамыш үзе шул зобани Ырыс хан урынына Күк Урданың хуҗасы булып калды. Тик монысы да, сасы көзән йә чүл бүресе кебек, һич туюны белмәс, гоҗ бер ерткыч. Карабәк барысын да, мең кат белеп тора. Туктамыш та Сарай тәхетен ул иясез чакта, Мамай мирза Тверь кенәзе Михаилны яклап урыс олысына яуга киткән атналар эчендә килеп эләктерде бит. Тын елга буендагы Шөлди кырында[11] Мамай яу барышына кул селтәп китткәч тә, Мәскәү кенәзе Митрәй үзенең исән калу турындагы сөенечен, галәмдә күрелмәгән зур җиңүдәй күпертеп, барыннан да элек, Сарайга кереп оялаган Туктамышка язган. Димәк, мәскәүлеләр Туктамышны яклап яуга кергән, киләчәктә ул аларга ясак җыюда ташлама ясаячак, дигән сүз бу. Митрәй кенәз яңа ханның тәхеттә ныгып калуына ярдәм итә, ул аның колына әверелеп өлгергән инде, димәк. Мәскәү боярлары гына түгел, Туктамышка хәтле гасыр ярым буе гомер сөргән Урда әмирләре өчен дә никадәрле хурлык!..

Менә шул Туктамыш үзенең Күк Урдасыннан тыш бөтен Алтын Сарай иленә дә бугалак ташларга, тышау салырга җыенадыр инде. Кырым хәтле Кырым җиренә дә чапкын куган икән, димәк, Карабәк шикелле әмир-бәкләрне дә үз каршына тезләнеп китертмәкче, антлар иттермәкче. Тик шунысы сәер: Мамай мирза Кырымга исән-сау көенә әйләнеп кайтты, Мәскәү өстенә үч явы белән бару өчен кабат гаскәр җыя. Ә Туктамыш мондый чакта Мамайны нишләтмәкче? Мамайның кул астында бүген үк өч төмән бар, аның канат ышыгына иртәгә тагын шуның чаклы җайдак җыелуы мөмкин. Ахыр чиктә Мамай мирза, нәкъ Митрәй өстенә баргандагы кебек, Каф тау буендагы әрмәннәрне, алан-чиркәсләрне, Дәште Кыпчак буйлап чәчелгән кумык-бәҗәнәкне яки Кәффа каласында үзбаш булып яшәүче җәнәвиз[12] яугирләрен дә яллап җыя ала. Анда алтын-якут, байлык-нигъмәт дигәннәре кәрван-кәрван. Шыр-тилеләр үз-үзләрен «иелгән башны кылыч кисми», дип юатса да, Мамай мирзаның, бу рәвешле гаярь була торып, Туктамыш каршында тезгә чүгәсе юк. Ул очракта Җучи илен, андагы олысларны тагын өр-яңа яу, үзара суеш-кырылыш көтеп торамыни? Әллә... әллә Мамай мирзадан башка яшерен генә чакырып, Туктамыш хан минем шикелле әмирләр кулы белән утлы учактан күмер сосмакчымы?..

Карабәк, ятаган-хәнҗәрләрен тагарга онытмыйча, алгы як бүлмәгә атылып чыкты. Каравылбаш Нургали бәк болай да аягүрә басып көтә иде, хуҗа әмир күренүгә, капылт әсәренде.

[11] Шөлди кыры – Дон елгасы буенда 1380 елның 8 сентябрендә Мамай мирза белән Дмитрий кенәз яу үткәргән Куликово кыры.
[12] Җәнәвиз – Кырым ярларында колония төзеп яшәгән генуэз-венециялеләр.

– Йә, чапкын мондамы соң? Әллә инде куып җибәрдеңме?

Хуҗа сер бирмәгән булып шаяртса да, йөрәге каен тузы шикелле бөгәрләнеп, чатнап яна инде, аны гына күз алдына китермәскә Нургали бәк беркатлы шалкан түгел.

– Юк, кумадым. Сине ашыктырмас өчен, аны тамак ялгап алырга утырткан булдым әле. Ясавыллар аның чаптарын чистарткандай итеп кыйлана. Чапкынның гаебе юк, ул бичара да камчылап куылган адәм баласы бит.

Карабәк киң елмайды. Ап-ак тешләрен ялтыратып елмаю аңа бик килешә. Аның йөзе беркая да качмыйча, гомер буе кояшның иң эссе, рәхимсез нурлары астында каралган бакыр ләгән йә җиз комган сыман. Нургали белә-белгәннән бирле Карабәкнең маңгай-яңаклары кара-кучкыл. Ул белгәннән бирле Карабәк барча кеше белән ачык йөзле. Кычкыруны-җикерүне белми. Кешеләргә түгел, эткә дә таяк күтәргәне, сукканы юк. Шуңа кара гавам, гади сугышчылар аны гел үз итеп Карабәк йә Бәкчура дип йөртә дә бит инде.

– Юлчы кешене өзлектереп булмас, йә соң, әйдә, чакыр, – дип эндәште ул, тагын риясыз елмаеп.

Чапкын яугир, залга иңүгә үк, җиләненең җиң эченнән алып, мөһерле хат сузды.

– Олуг ханымыз Туктамыш хәзрәтләре сине үз янына, корылтайга дәшә, олуг Габдулла хан!

Чапкын моны билен бөгеп, башын иеп әйтте, ә Карабәкнең йөрәгенә әйтерсең лә хәнҗәр кададылар. Ул тешләрен ком капкандай шыгырдатып кысты, йөзендәге ярсуын күрсәтмәс өчен, сыңар учы белән маңгаен һәм ияген угалады.

– Хатыңда да шул ук сүзләрме соң? – дип ашыгып сорау бирде.

– Шул ук чакырудыр, ханым, мин бит укымадым. Чөнки Туктамыш хан аны сүзләр белән дә җиткерергә кушты. Габдулла ханның килүен бигрәк тә нык көтәм, дип, аерым да өстәргә онытмассың, диде.

Карабәк тел очына килгән яңа чәнечкеле сораудан үзен тыя алмады.

– Миннән соң тагын ничә әмиргә хат илтәсең әле?

– Туктамыш хан һәрбер олырак бәк илә әмирләр янына аерым чапкын куды. Җәмгысы никадәрле бәкне чакырадыр, ул тиклесен белмим, – дигән җавап тотты чапкын, берни яшермичә.

– Ә Мамай мирзаны? Мамайны чакырамы?

– Анысы да миңа дөм-караңгы, – дип җаваплады чапкын элеккечә, аннары барыбер дә тиз-тиз пышылдады. – Чакырмыйча калмас. Мирза килсә, иң төп имән ава, ил-койманы тоткан зур багана ава. Баганасы ауса, койма-киртәләр, чапкан печән сыман, бик тиз егыла ул.

«Менә сиңа гап-гади бер чапкын! Ил тоткасы кемнәр булганны да, ханнар ни кылырга җыенып йөргәнне дә алдан белеп тора», – дип нәтиҗә ясады күңеленнән генә. Чапкын күз алдыннан чыгып югалуга, каравылбаш Нургали тарафына катгый әмер бирергә онытмады.

– Ашыгыч рәвештә Сарай каласына чапкын җибәр. Туктамыш атлы яңа килмешәк нинди эшләр кырып ята анда, аның тирәсенә нинди этләр килеп оялаган? Мамай янына да шымчы чапсын. Аны Туктамыш янына чакыраларммы-юкмы, ул мирза Туктамышка каршы нинди этлек әзерли, безгә барысын да белеп тору хәер.

Кабат түр бүлмәгә кереп бикләнгәч, Карабәк ирексездән янә хатирәгә чумды.

## 2

Габдулла хан. Чынлап баксаң, мондый атны ил халкы да, Карабәк үзе дә онытты бит инде. Әйе, аның да кайчандыр тәхет өчен янып, хан исеме күтәреп йөргән көннәре бар иде. Күптән артта калды бит инде ул хәлләр, дивар сыман тезелешкән карурман эчендә йомылып һәм онытылып калды.

...Беренче нәүбәттә, тагын шул Бирдебәкне эттән-эткә салып сүкми булмый. Чөнки соңгы егерме елдагы бар түнтәреш, һәммә канлы мәхшәр башында Бирдебәк хан тора. Үзенең барча энекәшләре белән газиз малайларын бертоташтан юк итүен күргәч, олуг хандагы залимлек угының үзләренә төбәлүеннән шик-шөбһәгә төшкән әмирләр, җыйнаулашып, Бирдебәкне йокы бүлмәсендә суеп җанын кыйды. Ләкин айныгач эзләнсәләр, Җучи ханның барча туруннары кырылып беткән, Бирдебәк бу нәселнең соңгы орлыгы булып торган икән. Бушбугазларга, үз җанына куыш табалмыйча ил буенча тәгәрәп йөргән дүңгәләкләргә юл ачылды шулчак.

– Мин – Җанибәк ханның җариядән туган улы булам, Сарай тәхете хәзер миңа тиеш! – дип, Көлнә атлы ниндидер вак бер әмир ил түренә үтәргә җөрьәт итте.

Аны, ничәдер ай үтүгә, нәкъ шундый ук уйнаштан туган Нәүрүз тотып суйды. Мондый мәсхәрәгә бик салмакчы булып, Иртеш аръягыннан Җучиның бертуган энекәше Шәйбан ханның туруны Хызыр бәреп кергән.

– Миндә бөек Чыңгыз каны ага! Бату агам нәселен юк иткәнсез икән, аның йортын мин, Шәйбан хан оныгы, үз кулыма алам! – дип Хызыр оран салгач, Сарайга күсе кебек кереп оялаган сатлыкҗаннар Нәүрүз бәкнең үзен генә түгел, аның хатыннары белән малайларын, хәтта бүлмәдән-бүлмәгә йөреп, саташа-саташа нәни оныгын эзләүче Тайдуланы да арканнарга бәйләп китергәннәр. Тик Хызырга асып үтерелгән Нәүрүз гаиләсенең газапларын күргәч тә озак вакыт тантана итәргә язмады шул, җәллад ханны үзенең газиз улы Тимерхуҗа идән буенча тәгәрәтеп суйды. Тик исеме булса да, җисеме белән ул бичарага да Сарай тәхетенә ияләнү, үзен хуҗа итеп тою бәхете эләкмәде.

Бирдебәк кияве булып канат җәйгән, өстәвенә Урда гаскәренең яртысына хуҗа булып алган Мамай мирзаның дистәләгән олысларга ятьмә ташлаган, тамырларын бик тирәнгә җибәргән чоры иде. Шул мирза әүвәл Тимерхуҗага каршы усал яу оештырды да, тегене бәҗрага алып капкынга эләктергәч, чатырына иңеп җанын кыйды. Аннары инде гаскәр башында Сарайга бәреп керде һәм унбиш яшьлек Габдулланы тәхеткә утыртты да куйды. Аерым олыс бәкләре яисә әмирләрнең Мамай мирзага теш күрсәтерлек куәте юк иде, барчасы да, юаш бозау сыман, яңа ханга бигать китерде. Габдулла хан әле яшь булса да, нәселе өчен шикләнерлек түгел, аның чишмәбашы Бачман тарханнан ук инеш ярган иде. Болгар илендәге Саксин каласын бирмичә каршы торган Бачман бабасының башын Чыңгыз ханның улы Мүнкә чабып өзгән. Ә Бачманның җиткән кызы Зөбәйдәне үзенә хатынлыкка алып куйган. Габдулла менә шул үзе җәллад та, үзе каһан да булган Мүнкә ханның бер туруны иде.

Турунлыкка турун, әмма таяныргa Мамай шикелле икейөзле мирзадан башка нигез-терәк табылмады аңа. Ә тегеңә илне үз кулында биетеп тоту өчен тәхеттәге балбал гына кирәк. Гаскәр фәкать аны гына тыңлый, меңлек яки төмәннәр башында – Мамай белән бергә Тимер Капка, Баку калалары янында, Дәрьял тарлавыгында азәриләргә, аланнарга[13] каршы сугышта сыналган сыбай[14] һәм әмирләр. Габдулла тәхетне саклап утырган кыяфәт чыгара, ә Мамай мирза йә Кырымга, йә Рәзәнгә

[13] Аланнар – чукынгач, осетинга әверелгән кавем бабалары.
[14] Сыбай – офицер. Төрекләрдә һаман да шул исемдә.

барып орыша да төмәнбашларның һәммәсен дә талап кайткан байлыгына күмә. Башына таҗ элгән Габдулла ничарадан бичара кыяфәттә әле теге, әле бу әмирне чакыртып кармак сала, үз ягына аудармакчы була, ә тегеләр, кабыгын алыштырган елан төсле, икенче таңда ук аны мирза колагына барып чага.

Мәскәү белән Тверь калаларыннан икесе берьюлы, әмма аерым-аерым юлдан Сарайга килеп төшкән Митрәй һәм Михаил кенәзләр каршында да көчсез булып калды Габдулла хан. Берәм-берәм Сарайга иңдергәч, аларның тел төпләрен чамалау өчен бөкресе чыкканчы һәм сакалы чаларганчы гыйлем эстәгән мөхтәсиб йә мөдәррис булу да һич кирәкми. Икесенең телендә дә бер үк гозер:

– Олуг кенәз ярлыгын фәкать миңа гына язып бирче, зинһар? Шуны бирсәң, мин урыс илендәге барча калалардан ясак җыяр идем дә аны түкми-чәчми сиңа гына китереп бирер идем.

Ә Габдулла хан яшүсмер көенә дә яттан белеп тора – җыйган ясакның яртысын үзләренә йомып калдырачак та шуның хисабына мәркәз ныгытачак, гаскәр ишәйтәчәк, ахыр чиктә идән-түшәмнәрне дер селкетеп типтерәчәк болар. Һәр бәндәнең бармагы елан мөгезедәй үз ягына кәкре, бу ике кенәз дә Аллаһының кашка тәкәләре түгел.

Берәм-берәм үтеп кергән саен боларның һәр икесе Габдулла хан каршына бүләк-нигъмәт өя. Мәскәү каласыннан килгән кенәз Дмитрийга унике яшь кенә, әле борын астында мыек төртә башларга да бик нык иртә. Карап торышка да күндәм, юаш сыман, моның ише яшь бозауның аран җимерүе, сөзешә башлавы да бик икеле. Менә шуны үлчәп, Габдулла хан олуг кенәз ярлыгын яшь кенәзгә язып биргән иде. Дмитрийны сарай тупсасыннан озатуы булды, икенче мизгелдә, котырынып-шашып, тәхет залына Мамай атылып керде.

– Син нәрсә монда бер кәрҗин сасыган күкәй хакына ярлык өләшәсең? Атаң мирас итеп калдырган ханлыгың бармы әллә? – дип, ярсый-ярсый төкереген чәчә.

Габдулланың тораташтай утыруын күргәч, усал этәч сыман, янә очып куна.

– Тверь кенәзе миңа унике мең данә алтын тәңкә салды, ярлык аңа тиеш! Анасының имиеннән аерылмаган Митрәйне һичбер кала боярының олуг кенәз итеп таныйсы юк. Аннан ясак көтмә! Әгәр Михайлога син бирмисең икән, мин ярлыкны аңа үзем бүләк итәм!

– Соң, мин ярлыкны Митрәй кенәзгә язып бирдем ләбаса инде! Иртәнге акылы кичкә алышына торган таҗдар буламыни! – дип, яшь Габдулла тузгып караса да, картлач төлке Мамай аны, ялтыравык тәтәй күргән сабый урынына, бик тиз сатып алды.

– Төш вакыты үтүгә үк ачып чыга торган ашны пешермәскә, бер тапкыр кискәнче мең үлчәргә өйрән! Ә үкенмәс өчен, Михайло өеп калдырган алтын тәңкә тавының яртысын керттерәм мин сиңа!..

Габдулла хан эндәшмәде, эченнән генә пескәк яңгыр булып елады-сыкрады да тынды инде ул чак. Ә ике кенәзнең икесе дә бер үк төрле ярлык алып китте. Кайтуга ук Тверьдагы Михаил яндагы Владимир каласын да барып яулаган, аны Мәскәү авызыннан тартып алган икән. Әле ярый, Дмитрий яшь булганга, Мәскәү кенәзлеге белән Алексий атлы атакай идарә итә, ә ул, җавап итеп, Ростов белән Галич калаларын үзенең чиркәвенә буйсындыра алган.

Яшь Габдулла белән төлке Мамай менә шулай, бер каенанага ярамаган ике көндәш килен төсле ызгышып ята иде, Күк Урда ягыннан Шәйбан ханның яңа бер туруны – Урда-Мәлик атлы солтанның бәреп керүен сизмичә дә калды. Сарайдагы гаскәр бик аз иде, Габдулла хан белән Мамай мирза икесе тиң Идел аръягына чыгып сызды.

Сарайга иңгән Урда-Мәлик тә әллә ниләр майтарып өлгермәде. Аның Сарайдагы әмир һәм бәкләрне, уңга-сулга аерып тормыйча, дарга озатуын күреп алуга, исән калган аксөякләр фетнә оештырган һәм таҗ залында ук аның җанын кыйган. Мамай мирза ул вакытта үзенең биләмәсе булган Үкәк каласында качып ята иде, түнтәреш турында белешергә шактый соңга калган. Гаскәр туплап Мамай кузгалганда, Урда мәркәзе Бату ханның яңа бер энекәше – Тукай-Тимер нәселеннән булган Килдебәк хан кулына эләккән иде инде.

Атасының йорты Актүбәдә качып яткан Габдулла хан янына әмир йә бәк шикелле түрәләрне түгел, хәтта гади чапкын җибәреп тә вакланып тормадылар. Бактың исә, Чыңгыз йортының үз эчендә яман ызгыш купкан, бөек бабалары әманәт итеп калдырган изге «Яса» кануннарын тишек кәвеш урынына җиргә ыргытканнар, Шәйбан токымнары Тукай-Тимер нәселенә каршы чыккан икән. Шулар Алтын Урда иленә гаскәр җыеп килгән, Килдебәкне тотып үтергәннәр. Җучи тәхете хәзер инде ике ел элек суелган Хызырның бертуган энекәше Морад кулына кайткан. Иллә мәгәр Морад ханның Идел аръягына кулы җитми, анда Мамай хуҗа. Ни әкәмәт, урыс кенәзләренә ярлыкны да чиратлашып өләшә башлаганнар. Митрәй белән Михайлоның олуг кенәз ярлыгы алып кайтуларына бик нык рәнҗеп, Морад хан каршына Сүздәл белән Җүнкала[15] хуҗасы булып торган Константин[16] кенәз килеп җиткән. Аның авызында да – иске бер җыр:

– Олуг кенәз ярлыгын миңа кайтарыгыз? Ул шалапай Митрәйгә караганда ясакны мин күпкә шәбрәк җыям! Владимир каласы, каз оясы төсле, гомер-гомергә Суздальныкы булды, ул да миңа тиеш!

Яңа ярлык алып хан сараеннан чыкса, Константин каршына киртә булып икенче чапкын баскан.

– Син Иделнең уңъяк ярына кем хуҗа икәнлеген белмисеңме әллә? Исән-имин кайтырга исәп тотсаң, Мамай йортына сугылмыйча калма!..

Мамай мирзаның Үкәктәге, Идел ярындагы калкулык өстендә күркә сыман кукраеп утырган ап-ак сараена[17] Морадныкына караганда ике тапкыр зуррак бүләк кертеп өйгәч, хуҗа моңа өстәмә ярлык сузган.

– Моннан ары Сарай ханын онып, мине санга сана. Сыер көтүенә чыбыркысын җуйган көтүче түгел, шәпле үгез хуҗа. Җыйган ясак миңа килә икән, олуг кенәз ярлыгы гомереӊ буе синеӊ кулда булыр. Танучы булмаса, минем камчы әзер!..

Сүзе җилгә очмасын дип тырышкандыр, ахры, Мамай мирза Константин кенәзне рус җирендә олуг итеп таныттыру өчен хан исеменнән Арык-Буга атлы зур илчене куган. Шуннан яңа бер әкәмәт: Мәскәүдәге Митрәй белән Тверьдагы Михайло хәзер инде яңа хан алдында бил бөгү өчен, олауны мул төяп, юлга кузгалган ди.

Алар Морад ханны күрергә өлгерә алмый калды. Әллә каян гына Газиз шәех атлы әмир табылды да, шул килмешәк Морад гомерен кыйды. Мондый башбаштаклык Мамай мирзага һич кенә дә ошамаган икән, ул яллаган җанкыярлар, Идел суын кара төндә кичеп, Газиз шәехне йоклаган түшәгендә буып үтергән.

Бичара Габдулла бу хәлләрнең һичберсен дә белми, әтисенең олысында туй хәстәре белән яна иде. Сарай тарафыннан көтмәгәндә зур илчелек килгәч, аптыраудан гел таралып төште.

[15] Җүнкала – Түбән Новгородның Алтын Урдадагы атамасы.

[16] Суздаль-Нижгар кенәзенең тарихтагы исеме Дмитрий Константинович. Ике Дмитрий арасында буталдырмау өчен, монысының атын үзгәртергә булдык.

[17] Бүгенге атаклы Мамай курганы – элек мирза сарае урнашкан калкулык ул.

– Мамай мирза җәнапләре синең хозурыңа безне куды. Ил бәкләре синең кабат Сарай тәхетенә кайтуыңны сорый.

– Нинди тәхет кабат, нинди ханлык? Мин соң сезгә Мамай сыйрагына ярамаган саен алыштыра торган кәвешмени? – дип әүвәл күкерттәй кабынып караса да, даладагы ялгыз учак сыман, бик тиз сүнде.

Шулай икән, тәхет һәм таҗ атлы шайтан коткысы зәмзәм суы, газиз ана кочагы, сөекле ярның оҗмах бакчасы, күкрәкләре очындагы татлы чия төшләре шикелле үк ымсындыргыч вә һич туйдырмас икән. Габдулла, үз башына, бу юлы да риза булды инде, тискәре кәҗә тәкәседәй аяк терәп каршы тора алмады. Ә Сарайга килсә, шул ук Мамай кубызы да Мамай чыбыркысы.

Габдулла Актүбәдә бикләнеп яткан айлар арасында урыс кенәзләре туктаусыз яу йөргән. Әүвәл әле яңа гына олуг кенәз ярлыгы алып кайткан Суздаль кенәзе Константин Владимир атлы каланы кулына эләктергән Михайло кенәз өстенә ташланган ди. Михайло чигенмәгәч, тверьлыларга ярдәмгә мәскәүлеләр гаскәре килеп җиткән. Бердәм һөҗүмгә каршы тора алмаган, Константин кабат Суздалена качкан. Митрәй белән Михайло, этәчләнеп, моны Җүнкалага тикле куа барган. Ахыр чиктә Константин үзенең бер кызын унбиш яшьлек Дмитрийга хатынлыкка биреп кенә котыла алган икән.

Ә көтүдә үгезләр үзара сөзешә башладымы, бүреләргә бәйрәм. Кенәзләрнең гаскәр дә калдырмыйча калаларын ташлап йөрүен белгәч, Сәркиз бәкне куып, Мукшы җирен үз кулына эләктергән Гарәбшаһ атлы әмир хәзер инде урыс калалары өстенә ыргылган ди. Өч кенәз дә, бердәм гаскәр туплап, мукшыларга каршы чыккан-чыгуын, иллә мәгәр урыс яугирләре, ни галәмәт, нәкъ Пьяна дигән елга ярында, ыстан да кормыйча, исерешеп-тәгәрәшеп яткан. Гарәбшаһ аларның һәммәсен Пьяна ярына кысрыклап, сарык көтүе урынына тотып ярган икән. Урыс ирләренең күпчелеге кызган баштан елга суына сикергән дә шунда батып үлгән. Юлы уңгач, берочтан, Гарәбшаһ Җүнкаланы да тоташ талап качкан. Кенәзләр соңыннан, ак эт бәласе кара эткә дигәндәй, бер гөнаһсыз Болгар иленә зур яу белән чапкан.

Урда тыныч түгел, һәр тарафта ызгыш, һәрбер почмагында яңа учак. Кырым атавыннан чапкын килеп житте.

– Рум диңгезе[18] аша йөзләп кораб килде. Гаскәрләре санап бетергесез. Алпарлары[19] тоташ көбәләргә төренеп беткән. Атау ярындагы Кәффа белән Солхат[20] калаларын кулга эләктерделәр. Аларны коры куллар белән генә кире куып булмый. Корабларының диварлары тулы бакыр туп та, тимер таганнары саен грек уты.

Мамай мирза өч төмән гаскәр ияртеп, шәхсән үзе чыгып киткән иде, ике айдан әйләнде дә кайтты.

– Рум иленең Генуя илә Венеция калаларыннан җыелышып килгән җәнәвизләр анда. Алар Урда казнасына зыян-зәүрәт салмый. Кала-дәүләт төзеп, остаханә ачып, сәүдә корып гомер итмәкчеләр. Башлыклары тамга салымын да, ясакны да икеләтә түләргә әзер тора. Алар Мәскәүдәге юеш борын Митрәй дә, Болгардагы астыртын Тимер-Булат та түгел. Боларда әйткән сүз – аткан ук. Җәнәвизләр җир җимертеп эшли һәм яши дә белә. Менә, утыз олауга төяп, иң беренче ясакларын алып кайттым инде.

Габдулланың тәхеттә бишектәге сабый бала кебек тын да чыгармыйча гына утыруы да, Мамай кубызына биеп йөрүе дә олыс бәкләренә ошамаган. Мукшы

[18] Рум диңгезе – Кара диңгез.
[19] Алпар – рыцарь.
[20] Кәффа – хәзерге Феодосия каласы.Ә Солхаты Аксак Тимер тарафыннан юкка чыгарылган.

җиреннән Гарәбшаһ куып җибәргән Сәркиз белән Болгардагы Тугаш атлы бер бәк Урда ханының мәркәздәге сараена килде. Зарлары, койма-капкалары җимерелеп беткән тол хатыннарныкыдай, гел әрнүле.

– Илдә хаким бетте, яклаучы-саклаучы юк. Ата – улын, ана – кызын белми. Ханнар туктаусыз алышынып торган тотрыксыз дәвердә яшәүдән дә бәхетсезрәк, өметсезрәк замана юк икән. Һәрбер түрә үз ягына каера, һәрбер олыс хуҗасы ил казнасын талап, ана каз шикелле, бар байлыкны үз канаты астына туплауны хуп күрә. Алга карап, ил турында уйлап яшәү бетте. Ил өстендә хуҗа берәү генә булса, ул йортын талатмас, аны үз улына төзек, бөтен, берәгәйле итеп калдырып китү өчен ут йотар иде. Ә болай, ай саен йә атна саен хан-таждарлар алышынып торгач, ул вакытлы хакимдарлар ил турында кайгырта димени?! Аларга бит үз гомере, үз тәгаме якын. Талап калыйк, баеп калыйк дип, сасы көзән сыман котыралар. Яфрак ярып, яшь үсенте җибәреп утырган ямь-яшел агачларга су да сибүче юк. Ә сипмисең икән, йөзьяшәр имәннәр белән йөзьяшәр карагайлар да коргаксып егыла ул...

Боларның һәрбер сүзе кайнар энә урынына Габдулланың җанын өтеп ала, ул утлы таба өстенә утыртылган кебек боргалана һәм кыбырсый иде. Мукшы белән болгар халкы исеменнән килгән бу ике илченең дә аңа һәр фикере якын, күңеленнән алар белән ризалаша иде. Ләкин авыз ачып җавап кайтарырга бер җае да юк бит. Сарайның һәр ишеге, һәр ярыгы саен эче мәкер белән тулы Мамай мирзаның уяу шымчылары тыңлап тора. Илчеләргә шәфкать күрсәттеңме, кичен сине Мамай җанкыярларының тотып суюы бар.

Илчеләрнең дә җавап көтә-көтә тәкате корыгандыр, иң беренче булып, мукшы Сәркиз урыныннан купты.

– Сазаган кыз чит-ят бала ярсып еласа да, ул сабыйны үз кулына алмас, аны юатмас ди. Кара гавам хәлен җиде кат болытлар өстендә йөзгән хаким каян белсен? Иллә мәгәр барча адәмнәр дә сугым малы сыман бер карусыз түгел. Ятим бала җылынырга учак тапмый калмас. Үз илеңдәге чишмәне корытсалар, бичара бәндә балалары күршедәге сасыган күл суына ирен тидереп булса да сусавын баса ул...

Сәркиз бәкнең кинаясе юкка булмаган бит, ул Мәскәү кенәзе Дмитрий чатыры астына баш тыккан да шунда чукынган ди. Ә Тугаш бәк чәнечкеле, күмерле дә булган башка юл сайлаган. Болгар илендәге пырдымсыз һәм үҗәт татар түрәләре Шәйбан олысыннан Хәсән атлы әмирне чакырган да, күмәк кубып, күз ачып йомган арада Сарай диварлары янына килеп җиткән.

– Мамай дәвере бетте, безнең кулда Алтын Урда өчен яңа тәсбих. Без Бирдебәк йә Хызыр хан шикелле җанкыярлар түгел. Алтын Капка ачык, Габдулла ханны чыгарып җибәрегез. Кан коймыйбыз. Ә Сарай тәхетенә үзебезнең ханны, Хәсән ханны кертеп утыртабыз.

Мамай-монафыйкның нәкъ мәркәзгә килгән чагы иде, дивар өстеннән даладагы төмәннәргә күз салуга, ашыга-кабалана итекләрен киде.

– Боларның исәбен санап бетергесез. Кала эчендәге өч мең ясавылны алар тәгаменә калҗа итеп ташлыйк та, Хәзәр капкасы аркылы ипләп кенә качыйк. Бүген безнең өчен күктә кояш тотылды. Иншалла, ул иртәгә кабат чыкмый калмас...

Мамай белән Габдулла хан әүвәл бергәләшеп Кырым тарафына чыгып качкан иде, кабих мирзада ярты юлны үткәнче үк яңа мәкер туган. Габдулла Кырымда җилән итәгендәге тузаннарын да кагып өлгермәде, Сарай хозурыннан утлы хәбәр килде.

– Мамай, Үкәк каласындагы бар гаскәрен күтәреп, Сарай өстенә барган.

Хәсән кабат Болгар ышыгына чыгып качкан. Мамай мирза исә Сарай тәхетенә Мөхәммәт-Бүләк атлы ханны күтәргән ди...

Габдулла ул вакытны, япь-яшь, сау-сәламәт көенә «талак» сүзе белән куылып кайткан бәхетсез киленнәр шикелле үкси-үкси, идәннәрне, чирәмнәрне төйде. Яраланган бүрене көтүендә дә бер дә яратмыйлар, кайтып күрендеме, ботарлап үтерәләр. Әнә шуңа күрә кабат этисенең олысына, Актүбәгә әйләнеп кайтмады ул. Мин-минлеген һәм ярсуын учларына бикләп, ул Кырымда калды.

**3**

Беренче чапкын әллә нинди утлар эчендә яндырмыйча, тиз әйләнеп кайтты.

– Туктамыш хан иң ерак почмакларга да чапкын куып, бик күп әмир вә бәкләрне янына җыеп алган. Кайсына яңа кала, кайсына олау-олау бүләк биреп, һәрберсен үзенең кыйбласына таба аудара ди. Гади антны гына нык азсына, зур корылтай җыеп, ул гомумбигать китертергә, үзен каһан итеп күтәртергә исәп тота икән.

– Анысын мин күптән чамаладым, – дип, Карабәк ияк кагып куярга гына мәҗбүр булды. – Берьюлы ике Урдага йөгән ташлый алгач, Туктамыш бигате кешенеке төсле генә булмас инде...

Ә Мамай тарафына юлланган чапкын аны гүя кайнап торган казан эченә салды.

– Мамайга да Туктамыштан махсус илче килгән. Мамай Ак-Хуҗаның сакалларын йолкып, җиләннәрен ертып, җитмәсә әле карт ишәккә утыртып җибәргән ди. Хәзер гаскәр җыя. Ни галәмәт, җәнәвизләр «төмән бирә алмыйбыз, ә үзеңне, бик теләсәң, Генуяга җибәреп булса да исән коткарабыз», дип хәйләгә керешкәннәр. Шулай да, Мамай барыбер өч төмән тирәсе җайдак җыйган. Алар белән кай тарафка ташланырга чамалыйдыр инде?..

Ул арада Сарай тарафыннан, Карабәк ише әмирләр яллаган яңа чапкын килде.

– Туктамыш хан олы гаскәр белән Кырым өстенә бара, ул Мамайны тезгә чүктермәкче. Җанында дәүләт гаме, Алтын Урда кайгысы калган асыл ирләр Туктамышка чиру алып килсен...

Ил агалары булып саналган бәк-әмирләр бер-берсенә кунакка чабышты, ерак араларга хатлар куды.

– Тагын ил эчендә үзара кан коюга ирек куеп булмый. Болай да соңгы елларда татар каны елгалардай акты. Ике ишәккә кибәк аера белмәгән сантый кебек буталып йөрүне туктатырга кирәк. Бер көймәче дә берьюлы ике як ярга да борын төртә алмый. Әйдә, катгый бер карарга килик тә икенең берсен сайлыйк. Йә Мамай мирза алдында һаман элеккечә, тезләнгән көенчә, якты кояш йөзен күрми гомер кичерәбез, йә Туктамыш ханга бигать китерәбез...

Һәрбер чапкын Карабәккә әмирләрнең шәхси тамгалары төшерелгән сөян таяк алып кайтырга тиеш иде, санап бакса, алар өч дистәдән арткан. Аеруча Барын, Ширин, Аргын, Яүләш бәкләр – барысы да Туктамышны яклый. «Бөркетләр өстеннән гади бер әтәчне башлык итеп куйсаң, бөркетләр дә кетәклектән югарырак очуны онытачак», дигән гыйбрәтле әйтем бар бит. Димәк, йолкыш әтәчләргә генә буйсынудан туйган инде болар. Барын-Шириннәр нәселенә дә кетәклекләр биеклеге түгел, күк капусы тансык!..

Мамайның астына да кайнар су йөгергән, чапкыннарны бер-бер артлы куып кына тора.

– Кырымнан чykканчы, Җанкай каласы янындагы Каратал яланына туктап тупланабыз. Шунда ыстан корып, чирүләргә тикшерүләр үткәрмичә

булмас. Кайсы әмир чирү белән килми, шуның олысыннан җәза нөгәрләре көл калдырып уза!..

Әмирләр буйсынды, нишләсеннәр инде? Әмма Каратал яланында чатырларны аеры корсалар да, казан астындагы учакны бергә кабыздылар. Зур ашъяулык җәеп мәҗлес корган чакта яугирләрнең эчтә күмер шикелле көйрәгән утларын чамаларга да, вәгъдәләр беркетергә дә уңай форсат туды. Аеруча Шөлди кырында җиңелү ачысы кичереп кайткан меңбашларның күңелендә гарьләнү дә, үч тә кайный икән, ярсуларын яшерә алмыйча, әүвәл шулар тезде.

– Мамай сәрдәр түгел, валлаһидыр, түгел! Туктамыш хан белән йөзгә-йөз очрашса, аңа яу кырын ташлап ычкыну берни тормый. Койрыгын төлке шикелле генә ялтырата да, эзләп кара аннан. Тын дәрья буендагы Шөлди кырында да Мамай аркасында гына җиңү кошын кулдан ычкындырдык. Әүвәл Митрәй кенәзнең алгы төмәннәрен пыран-заран китереп бетергән идек бит инде, сәргаскәр киеменә төренгән карачкыларын да тимер җәядән очырган уклар белән тетеп аткан идек. Соңыннан гына белдек, ул карачкы Митрәй кенәз булып чыкмаган. Җебегән, куркак кенәз үз өстендәге сәргаскәр киемен Бренко атлы гап-гади бер бояр иңсәсенә аткарган булган икән. Үзе, мөртәт, гади яугир киемендә, астына җибәрә-җибәрә, башкаларның артына посып йөргән. Урыс гаскәрендә сәрдәр башлык калмаган иде ул вакытта, әләмнәре дә күптән ауган иде. Менә шул чагында Мамай мирза татар төмәннәрен алга куган булса, без ул яртылаш кырылып беткән, юлбашчысыз калган урысларны таптап-сытып кына узасы идек бит, аһ, изәсе идек! Ә Мамай, тинтәк, яу кырына алтын-көмеш тәңкәләргә ялланып килгән әрмәннәрне, аланнарны, кумыкларны куды. Кич җитүгә үк кесәләрен акча белән тутырырга хыялланган кеше яу кырына баш югалту өчен керәме соң?! Юк, кермәде, баш югалтып орышмады алар. Ялан буйлап, бүре кугандагы сыман улый-улый, кыяфәт өчен генә йөгереп йөрделәр дә, Боброк атлы кенәз поскындагы төмәннәрне чыгаруга, барысы да койрык чәнчеп качты. Аларны күрүгә, Мамай шыр җибәрде. Безне киртә итеп тезеп куйган булса, әле качак әрмәннәрне, аланнарны да туктата ала идек. Иллә мәгәр Мамай капылт чигенергә әмер бирде. Татар төмәннәрен саклап кала, ул аларны кырдырттырмый, имеш. Менә шулай итеп адәм хурына калып кайттык инде. Юк, дим бит мин сезгә, мең мәртәбә юк, Мамай сәрдәр түгел!

– Алайга китсә, Туктамыш та Чыңгызхан йә Искәндәр түгел инде, – дип, Ширин бәк дөрләп янган утка дары сипте. – Сәмәркандка качкач, Аксак Тимер аңа Сыгнак каласына бәреп керү өчен өч мәртәбә өчәр төмән биргән, Туктамыш өчесендә дә бар гаскәрен пыр туздыртып качкан. Дүртенче тапкырында Аксак Тимер шәхсән үзе төп сәргаскәр рәвешендә юнәлмәгән булса, Туктамыш әле бүген дә Сәмәрканд әмиренең тәлинкәсен ялап яшәр иде...

Бәхәсләрдән соң вәгъдә куештылар.

– Туктамышка каршы корал тотып сугышуның кирәге юк. Дөрес, Туктамышның да, Мамайның да акылы бик чамалы. Болар беткә үч итеп туннарын утка тотып яккан ике сантый сыман. Без беренче булып яуга керәчәк түгел. Башын иеп килгәннәргә – муенчак, ия белмәгәннәргә элмәк кидерәләр бит ул, шунысын да истән чыгармыйк. Туктамыш уңай торса, үч алулар белән янамаса, аңа тугрылыкка бигать китерербез. Ә Мамай коралга чакырса яки яуга куса, аның үзен Туктамышка биреп котылырбыз...

Мамай килеп җиткәч, һәр меңлекне күз уңыннан кичереп узган булды, өч-дүрт йөзлекне хәтта ыстан читенә үк куып чыгарды. Болар яу кылырга да түгел, кәрван йөртергә дә ярамыйлар, имеш. Үзен дөнья кендегедәй тоеп атлаганда, шапыруына бөтенләй чик-чама юк.

– Көтүдәге аксак-туксак биш-алты сарыкны куып җибәрүдән чистарабыз гына. Алар урынына алмаш табылмыйча калмас. Минем кул астындагы халык чүлдәге ком шикелле – санап бетергесез. Кирәк икән, Каф тау ягыннан да, Идел буеннан да көтү-көтү куып китертермен.

Аннары меңбаш белән әмирләрне үзенең чатырына җыеп алган булды. Билгеле ки, үзе түргә куелган кәнәфигә менеп кунаклады. Келәмнәргә тезелешеп утырган бәк-әмирләр каш астыннан гына, сүзсез күзәттеләр.

Берчакта да хан булырга дәгъва итмәде ул, гәрчә җай табылган саен: «Минем Каранай бабам – Бату ханның иң шанлы меңбашы! Минем бабам – урысларның Мәскәү кенәзләрен тетеп салган сәрдәр!» – дип шапырынырга бик тә һәвәс иде. Ә Каранайның нинди меңбаш булганлыгын мулла-мунтагайлар җитез ачыклады. Бактың исә, Бату хан урысларның Владимир каласын яулап алгач, андагы Юрий атлы өлкән кенәзләре, олау-олау алтыннарын төяп, Новгород ягына чыгып качкан. Бату хан Мамайның ерак бабасы Каранай меңбашына менә шул качак кенәзне куып тоту бурычын йөкләгән ди. Ертауллар Юрий кенәзнең Сөт елгасындагы боз өстеннән качып баруы турында хәбәр җиткергәннәр. Каранай, Бату хан каршында барысына караганда да өлгеррәк, елгыррак күренеп, өскә үрмәләргә маташкандыр инде. Ул Юрий кенәзне, юлын кисеп, тозак корып, кулларына эләктермәкче булган. Тик таныш түгел җирдә һәр адымны сукырларча капшанып кына атларга кирәклеге турында оныткан шул. Бу төбәктә адым саен яулык кадәр күлләр, аларның арасы да тоташ сазлык икән. Иләт атлы күл өстенә кергәч, куна тактасыдай юка боз элпәсе чытырдап ярылган да Каранай җайдаклары, йөзәр-йөзәр булып, су төбенә киткән. Каранай элмәк кидерергә хыялланган Юрий кенәзне болгар җайдаклары куып тураклаган. Ә гаскәрен югалтып, чаптары урынына буш йөгән тотып кайткан көтүчедәй бушбугаз Каранайны Бату хан хәзер инде үзе Үләт дип яңача исемләгән күл төбенә илтеп батырткан ди...

Менә бу, биек кәнәфидә күркә урынына кукраеп утырган Мамай мирза – ерак бабасы булган Каранайның тап-тач игезәге. Нәфес чиген белми, киртә-тыюларны күз чалымына кертми. Барча Урда буенча талап җыйган байлыгы кәрван гына түгел, кораблар да йөртә алмаслыктыр. Кая алып китмәкче ул аларны, нишләтмәкче? Һичбер кәфенлекнең дә кесә-бөрмәсе юк. Егылып төшсә, һәрбер адәм баласына – ике аршын урын. Шуны белә торып, нигә гожланырга?!

Карабәк бу адәм актыгын тәмам күрә алмый, җирәнгеч ул аңа. Ять-яшь егет язмышы белән ничә еллар буе кансыз уйнады бит. Бирдебәктән башлап никадәрле хан аламаларын суеп үтерделәр. Ходайның рәхмәте, Карабәк исән калды. Әмма, барыбер, гомере гомер түгел. Яшәештә бер мәртәбә тәхеткә иңгән кеше җир өстендә, кара гавам арасында, тирес өемендә чокынудан ләззәт тапмый икән. Кайчакларда Карабәкнең колакларын томалап, күзләрен бәйләп, җиде тау артына, карурманнар эченә кереп югаласы килә. Әмма тәхет күләгәсе, ил язмышы, ахыр чиктә шушы Мамай мирзаның тәкъдире дә һаман бәйләп тора. Шушы ерткычның кадалып төшкән мизгелләрен бер күрәсе килә. Тик... һаман шуңа үлем тели алмый. Җаны-нәфесе коточкыч гожь булса да, Мамай мирзада бер юньле сыйфат бар – Туктамыш хан шикелле, ул Аксак Тимер кебек дошманнар ышыгына качып, илен сатмады. Илне талавын-талады, меңәрләгән адәм баласының җанын кырмыскадай кырды, әмма шушы сасы көзәндәй җирәнгеч мирза үз татары өстенә, туган йорт эченә дошман чирүен ияртеп килмәде бит!..

Күршедәге әмирләр дә Мамайга төбәлгән. Кемдер күз яшерә, андыйлары,

мөгаен дә, нәкъ Карабәк шикелле үк, явыз мирзаның чәнчелгәнен көтеп йөридер инде. Икенчеләр Мамайның маңгаендагы чалмасына төбәлгән, андыйларның мирза җанын ничек итеп, ни рәвешле кыю хакында баш ватуы мөмкин. Күздән кичерсәң, Мамайга тугрылык белән, мөкиббән китеп, сокланып утыручы бәкләр бөтенләй юк сыман. Алай икән, аһ, газаплы, аһ, кызганыч булачак икән бит синең соңгы көннәр!..

Кышның беренче карлары уйный башлаганда, Кырымны калдырып чыгарга әмер булды. Тын елга ярына якынайган чакта алга озатылган ертауллар кайтты.

– Туктамыш хан белән ике арада ун фәрсах юл калды. Гаскәре зур түгел, дүрт төмәннән артмас.

Мамай яклы бәк-әмирләр, махсус ишарә көтеп тормастан, бергә җыелды. Мирза әләме астына тупланган гаскәр дә аз түгел-түгелен. Һәм иң мактанычы – аның өч төмәнен дистәләгән яулар кичкән, хәтта әле ике ай элек кенә Шөлди кырында да сынау үтеп кайткан яугир тәшкил итә. Билгеле инде, орышуга калса, боларның берсе дә яу кырын ташлап качачак йә дошман тарафына ычкыначак түгел. Һәрберсенең коралы җиткелекле, өсте-башы таза. Әмма иң яманы – Мамай әләме астына баскан бер генә җайдак та яуга ашкынып тормый. Комсыз мирза хакына үлемгә ыргылуның асыл мәгънәсе юк.

Һичбер төрле фәрман ташламыйча, меңбашлар һәм әмир-бәкләр Мамай мирза гаиләсен чолганышка алды. Әйе, мирза бөркәвечле, көймәле арбаларга хатыннарын, балаларын, хәтта пешекче һәм зәркарләрен дә утыртып чыккан иде. Олау тирәсендә кысыла баручы боҗраны шәйләүгә үк, ул әүвәл, котырынып, билендәге Шам кылычын кулына алган булды. Һаваны ялгыз калган аккошныкына охшаш аянычлы һәм әрнүле тавыш ярып узды.

– Хыянәтме? Алдан сүз беркетеп, түнтәреш кордыгызмы? Мин үземне генә түгел, хәтта сабыйларымны да Туктамыш хәсис җан кулына бирдертәчәк түгел! Андый мәсхәрәгә калдырганчы, мин аларны үз кулларым белән турап атам!

Һичбер шик юк, Мамай мирза эт шикелле ыргылып, олаудагы хатыннары, оныклары өстенә ташланырга әзер иде инде. Олау уртасыннан мирзаның инде утыз яшен тутырган улы Мансур калкып чыкты.

– Алайса, башта мине тура инде, әткәй. Гайрәтең мине аударырга җитсә, аннан калганнарны.

Ата белән улга кылыч орышына ташланырга бик санаулы мизгел калган иде, тимеркүк айгырын арт аякларына күтәреп, алгы сафта Карабәк аваз салды.

– Арабыздагы һичбер әмир-түрә сине Туктамыш кулына тотып тапшырырга ният тотмый. Без үзебезне һичкайчан да синең колың итеп санамадык, Туктамыш колына әверелергә дә җыенмыйбыз әле, иншалла. Сиңа юллар ачык, дүрт ягың да кыйбла. Олаудагы барча хәзинәңне ал да күз алдыбыздан ычкын. Ходай Тәгалә ошбу гөнаһ өчен безне ярлыкасын...

Мамай үз олавын боҗра читенә чыгара башлагач, өч меңләп чамасы ир, барыбер дә, аңа иярде. Шөлди кырындагы яуга яки ил эчендәге талау сәфәрләренә йөргән чакта җыйган гөнаһлары мәҗбүр итәме, эт шикелле тугрылыкмы боларда, саташумы – һични аңламассың. Ни галәмәт, Кырым гаскәрендә качакларга, җасус сораннардай, арткы яклап, ук йә сөңге очыручы вак җан табылмады. Мәет белән хушлашкандай, һәркайсы да мирза олавын сүзсез-нисез генә озатты.

Саранча көтүедәй ике гаскәр Кәлтә елгасы ярында йөзгә-йөз килеп якынайды. Туктамыш төмәннәренең яуга әзерләнүен күргәч, әүвәл башлап Кырым ягыннан килгән ил агалары, төмәнбашлар ияреннән төште. Алар

үрнәгенә меңнәр иярде. Бер аяклары белән җиргә тезләнгән көенчә, һәрбер яугир бигать кабатлады.

– Бер-беребез өстенә яу йөрүдән, кан коюдан туйдык. Безне үз канатың астына ышыкла да Җучи олысын кабат аякка бастыр, таҗдар?!.

**4**

Мамайның җанында тоташ ут давылы, ике битендә ачы яшь эзләре. Дошманын кырып, ганимәтне мул төяп кайткан җиңүченең бөрмәсеннән бет эзләргә беркем базмый. Ә җиңелгән, җебегән, булдыксыз дигән мөһер белән каралгансың икән, син сазлыкка кереп баткан яралы фил шикелле йә мескен ат хәлендә. Һәрбер йолкыш узгынчы сиңа тамак ярып акыра, күсәк күтәрә, чыбыркысын уйната, тибеп китә, ахыр чиктә таш ыргыта ала. Үз-үзеңне яклап, ул хөрәсәннәргә җавап бирү, орышу-типкәләшү өчен синең кул-аягың тышаулы, гайрәтең юк.

Югыйсә бит Мамай җиңелүче түгел. Ир сүзе бер булыр. Мамай Тын елга буендагы Шөлди кырына Тверьдагы Михайло кенәз ялваруы буенча килеп баскан иде.

– Сарай тәхетенә иңгән Ырыс атлы яңа хуҗабыз олуг кенәз ярлыгын янә Дмитрий кенәзгә биреп кайтарган бит. Ул Мәскәүле Митрәй Ырыс хан алдына мин китергәннән өч мәртәбә күбрәк бүләк кертеп тезгән. Аннары күлмәк якасын ерта-ерта яшь түккән ди. «Ясакны Тверьдагы карт ишәккә караганда өч мәртәбә күбрәк китерермен. Владимир илә Серпухов, аларга кушып Ростов белән Галич калаларын гына берүк миңа кайтар», янәмәсе. Аныкы чаклы бүләкләрне синең өчен мин дә таба алам. Әлеге биләмәләргә Дмитрийны кертмә. Әйдә, бергәләшеп арт сабагын укытыйк. Гаскәр туплап бар да олуг кенәз ярлыгын миңа кайтар. Мин дә сине Мәскәүгә каршы яуда барча калаларны куптарып каршылармын.

Икәүләшеп, Мәскәү кенәзе туплый алырдай көч-куәтне күз алдыннан кичерделәр ул чак.

– Суздальдагы Константин – аның бабасы бит. Шул ук Константин Нижгарга да хуҗа. Кияү аның алдына барып тезләнмичә калмас. Ул очракта Константин үз киявен якларга барып басар сыман. – Мамай мирзаның баш кашуын шәйләп, кенәз Михайло шундук өстәп куйды. – Мәскәү белән Суздаль кенәзләрен Рязаньдагы Олег та һич өнәми, һәр икесенә үте кайнап тора. Мин Рязань кенәзен безнең якка аударуны үз өстемә алам.

Валлаһи да ишәк булган шушы кенәз сүзен тыңлап, Мамай гаскәр җыйды. Булгач булсын дия-дия, ләһ[21] таҗдары Ягайло янына да илче куган иде. Җавап бик тиз килде.

– Мин Мәскәү кенәзенә дә, Суздальныкына да күптәннән теш кайрыйм. Аларны Тын елгадагы Ростов каласыннан да, Стародуб, Воронеж тирәләреннән дә биздерергә кирәк. Ул калалар минем биләмәләр янәшәсендә, мин аларны икенче мәркәзем булган Киев олысына кушып кую яклы. Син, барыбер, Тын елга ягыннан һөҗүм итәсең бит. Мин син билгеләгән тәүлектә гаскәрем белән килеп җитәргә әзер.

– Бердәм һөҗүмне кайчанга билгелибез? – дип сорады Мамай, янып.

Тверь кенәзеннән «беренче сентябрь», дигән җавап алгач, Ягайло тарафына тагын бер мәртәбә чапкын җибәрергә туры килде. Ходайга мең шөкер, ләһ хакиме үз сүзендә таш кыялар сыман мәгърур торды.

[21] Ләһ – поляк халкының элекке атамасы.

– Ким дигәндә өч төмән алпар белән Тын елга ярына килеп басмый калмам!..

Тверьдагы Михайло да, Рәзәндәге Олегныкын кушкач, иң аз дигәндә дә өч төмән сугышчы белән килергә ышандыра. Кәффа белән Солхаттагы җәнәвиз байларына Мамай күптән бер ат арбасы алтын-көмеш биреп куйды инде. Алар бер төмән алпар юлларга вәгъдәлиләр. Терек, Кура, Сунҗа елгалары буена сыенган кыпчак белән бәҗәнәк, алан һәм кумык бәкләре дә ике төмән җайдак җыймый калмас. Мамай аларга да бүләкне мул юллады. Ә Идел белән Чулман арасына җәелгән Болгар олысы бәкләре бүләксез дә килә. Өч ел элек кенә андагы Кашан белән Болгар, Җүкәтау һәм Казан калаларын урыс кенәзләренең берләштерелгән гаскәре талап кайтты. Җүнкаладагы икейөзле Константин ул чакта зур дружина белән үзенең бертуган энекәше Борисны юллаган иде. Волын каласыннан Витаутас куып җибәргән кенәз Боброк Мәскәүдәге Дмитрий канаты астында сыену тапкан булган. Дмитрий бу качак әрәмтамак булып ятмасын әле, дип, камыт кидергәндер. Боброк урыс гаскәренең баш сәрдәре сыйфатында юлга чыккан булган. Ахыр чиктә ышанычын аклаган бит, каһәр. Ике каланы яртылаш яндырып, ә Казан белән Болгардагы Мәхмүт солтан белән әмир Хәсәннән күп йолым түләтеп, гаскәрен кырдырмыйча, Боброк кире кайткан. Качак Боброк хәзер дә Мәскәүдә воевода булып йөри, диләр. Димәк, хәзер ул качактан үч алу өчен Болгар олысындагы татарлар оран салып тормасаң да килеп җитәчәк. Аларның юл өстендә олысларын шул ук урыс кенәзләре талап киткән мукшылар, ар вә чирмешләр бар. Бөтенесе җыйнаулашып килсә, аларның да ике-өч төмән чамасы булулары мөмкин. Ул чагында... ул чагында Мамайның үзенә өч төмәннән артык гаскәр сөйрәп интекмәсә дә була. Җаек аръягыннан Алтын Урда җиренә Сыгнакта үзен хан дип игълан иткән Туктамыш аяк баскан. Мәскәү кенәзен тезгә куйганнан соң, Мамайның әле Туктамыш атлы бушбугазның да тузанын кагасы бар. Гаскәр туздырып йөрү саваплы эш түгел. Гаскәрнең иң зурысы Туктамышка каршы яуда чүлдәге сәйяхка бер йотым су шикелле кирәк булачак бит...

Печән өсте, чиллә вакыт дип тормыйча, Мамай төмәннәре җиде йөз дә сиксәненче елның[22] җәй уртасында Борын-Инеш[23] елгасына җиткән иде инде. Җәнәвизләр, Каф таудан ук төшкән әрмәннәр, Көбә үзән[24] аръягыннан килгән кыпчаклар, аланнар, кумыклар – һәммәсе дә монда. Казан ягыннан Идел яры буйлап юыртучы татар-болгарлар, чирмеш-мукшылар Җүнкаладан соң башланган сазлык белән карурманнарны үтә алмый җәфалана икән, Мамай аерым ыстаннар корып көтәргә мәҗбүр булды.

Беренче төндә үк аның ыстаныннан ялгыз җайдак чыгып югалуын шәйләмәде дә ул. Ә чаптар иясе нәкъ менә Борын-Инеш белән Тын елга боргаланып, бер-берсенә кушыла язган дугалыктагы җәйләүләргә җәелгән нәни олыс хуҗасы Хазбулат бәк иде. Чилләдәй җәй уртасында бу якларда төн дигәнең бер саплам җеп шикелле гаҗәеп тә кыска. Качак чапкын, каршысында очраган агач ботакларына йөзен сыдыргалап, бик аз чапты. Аннары дала учагы шикелле ялтырап, шәрык якта кояш кабына башлады, сукмакларны абайлау җиңеләйде. Коломна юлына баскач, артына һәм як-ягына каранып торуны бөтенләй ташлады ул. Бу якларга татарларның теше үтми, аларның күчмә торгакларыннан шөлләү артык иде.

– Дошман! Дошман! Татар ертаулы! – дип сөрән сала-сала, кечерәк бер

[22] Милади белән 1380 ел.
[23] Борын-Инеш – Воронеж елгасы.
[24] Көбә үзән – Кубань.

елга аша салынган күпер астыннан аның каршына әзмәвердәй гәүдәле бер ир йөгереп чыкты. Кулында ике тәртә озынлыгы киртә. Китереп орырга өлгерсә, сөяк-санагыңны җыеп алуың да бик икеле.

– Дошман түгел, сезнең хезмәтчегез Хазбулат мин! Хопрадагы Демьян атлы кенәзегез янына илтеп җиткерегез тизрәк. Мин Тын елга дугасы янында ул яллап калдырган махсус шымчы булам, – дип кычкыра-кычкыра ияреннән сикереп, чапкынның җир өстендә тиендәй бөтерелә башлаганын күргәч, каравылчы әзмәвер дә киртәсен ташларга мәҗбүр булды.

Әтәчлеген басу өчен генә бер-ике мәртәбә муен тамырына кундырып алганнан соң, барыбер дә, ике кулын артка каерган көенә, чапкынны елга аръягындагы торгаклар ыстанына алып киттеләр. Куе чытырманлыкка яшеренгән бер чатыр эченнән, ниһаять, яка һәм җиң очлары көмеш җепләр белән каймалы җиләнгә төренгән түрә килеп чыкты.

– Анаңны фәлән итим, Пулат пәк бит бу, безнең әшнә Пулат! – дип, ике кулы белән сакал-мыегына ябышкан токмач кисәкләрен сыпыра-сыпыра күз акайтып килгән торгакбаш, күрәсең лә, каравылчылардан чапкын таләп иткән Демьян кенәз иде.

Кулларына ябышкан торгакларны, җиң очларын тигәнәк-сырганактан чистарткандай читкә этә-төртә, канатланган Хазбулат тезеп китте.

– Мамай мирза Воронеж елгасына килеп җитте инде. Карасу[25] каласыннан йөз чакрым арада тукталып ыстан корды. Аның әләме артыннан ияргән җайдаклар тулы тугыз төмән. Әле Мамайга тагын Тверь кенәзе Михайло белән Кияү каласындагы[26] Ягайло да килеп кушылачак ди. Мәскәүдәге бөек кенәземезгә барча урыс олысларын күтәрмичә булмас.

– Мамай төп һөҗүмен кайсы якка юнәлтергә ниятли? Безне кайсы көнне туздыра башлаячак? Әйт, дим, тизрәк әйт, анаңны сатыйм! – дип, кенәз аламасы хәзер инде үзе Хазбулатны якасыннан алып җилтерәтергә тотынды. Сатлык чапкын тамагыннан өзек-өзек җавап гыжлап чыкты.

– Төгәл кайсы якка төбәләсен Мамай үзе дә белми. Теге ике аркадашы белән кушылгач ачыкларга ният тоталардыр. Ә Ягайло хозурына чапкын куган чакта нык кистереп әйтте. Алма чуагы беткәч. Сентябрьнең бере!

Берникадәр вакыт баш чүмечен кашып торуга ук, кенәз Демьян торгакларга таба борылып җикеренде.

– Ике ат әзерләгез, Митрәй кенәз янына шәхсән үзем барам! – Аннан гына, мескен бер сальчега хәер ыргыткандай, татар бәге тарафына сүз ташлады. – Митрәйгә җиткерермен, синең өлкән угылыңны үзенең сараена өлкән сакчы итеп алмый калмас. Вәгъдә – иман!..

Сатлык Хазбулат икенче төндә әйләнеп кайткан чакта Мамай урыныннан гел купмаган иде, утары кул сузымында гына яткан бәкнең югалып торуын төпченердәй түрә табылмады...

Ике күзеңне акайтып кына һичбер юлбарыс белән арсланнарны өннәренә кире кертеп булмый. Мамай Воронеж ярыннан купмыйча ике атна буе бик тилмереп көтсә дә, ул вәгъдәләшкән Тверь белән Киев тарафыннан сыңар гына җайдак та күренмәде. Мирза урыс олыслары эченә бер ертаул да куып вакланмаган иде, ләкин уяу колаклар аша, барыбер дә, шөпшә төсле, көтелмәгән шөбһә-хәбәр килде.

– Унсигезенче августта Митрәй кенәз Коломна атлы калага килеп җиткән.

[25] Карасу – Елец каласы.
[26] Кияү кала – Киев.

Үзе белән алтмыш меңле гаскәр алып килсә, Коломна янында аның кул астына тагын илле меңгә якын ир өстәлгән икән!

Бушка узган һәр көн – дошман тегермәненә яңа бер инеш ул. Өстәвенә, яу булачак кырны дошман карамагына тапшыру да зыян. Юньле сәрдәр, иң беренче нәүбәттә, отышлырак ялан-кырны үзе сайлый, мәхкуль булган һәрбер адымында ятьмә-тозак үрә, дошманны өненә ябылган аю-төлке урынына шунда куып кертә дә, аннары инде аранга бикләнгән җанвар хәленә китереп тукмаклый да җиңә! Юк, яу кырын сайлап алырга ирек куеп, Митрәй сыман йолкышларны сөендереп булмас!

– Алга кузгалабыз! Тын елга ярына! Ягайло белән Михайло чирүләре безне шунда көтә! – дип, бик һавалы әмер ташлады Мамай бер иртәдә.

Төмәннәр, бер-бер артлы, буар елан сыман сузылып Тын елгага таба төбәлүгә, урыс олыслары ягыннан яңа хәбәр килде.

– Митрәй Ука елгасын кичеп чыкты инде. Аңа Сүздәл, Җүнкала, Рәзән кенәзләренең берсе дә сыңар гына да яугир җибәрмәгән. Шуңа карамастан, Митрәй канаты астына җыелган сугышчылар саны йөз илле мең чамасы чутлана ди инде.

– Ялган, ялган! – дип акылдан шашкандай шаркылдады Мамай. – Бу хәбәрне китергән бушкуыкны дарга озатыгыз! Урыс кенәзләренең һичбер вакытта да йөз илле меңлек гаскәр җыйганы юк![27]

Барыбер дә, Мамай төмәннәренә адымны кызулатырга туры килде. Тын елга ярына килеп төртелүгә, тораташтай калып шаккаттылар. Тын елга белән кечерәк бер инеш кушылган киң кыр уртасында канатларын ике якка җәйгән бөркет сыман гаскәр басып тора. Биек кенә калкулык өстенә корылган чатыр түбәсендәге әләмнең кан шикелле кызгылт төсенә карап чамалау кыен түгел – Митрәй гаскәре бу, дошман-мәскәүлеләр...

Ике көнгә якын вакыт әзерлектә үтте. Билгеле ки, Мамай мирза өчен дә чатыр корырдай тау бар иде анысы. Мамай үзе дә шуннан тын да алмый күзәтүне белде, аның әмере буенча, меңбашлар да төрле якка чабып кына йөрде. Алардан тыш, Мамай Ука елгасы тарафына да, Тын елга буйлап та дистәләгән чапкын куган иде. Гел бертөрле, өметсез җавап кайтты.

– Ягайло төмәннәренә чаклы бер йөз чакрым ара. Синең ашыгырга чакыруны тыңлап торган, соңга калуына бик үкенгән сыман. Мәгәр төмәннәре ташбакалар төсле акрын кыймылдый шул. Бер аягын атлаганчы, икенчесен эт ашый, дип нәкъ менә Ягайлоныкылар турында әйтәләрдер...

Ә Ука ягыннан бөтенләй кара җавап.

– Митрәй кенәз Михайло хозурына бер меңбашын куган. Үз туганнарыңны кыру өчен монда килеп җитсәң, яудан соң барча гаскәр белән Тверь өстенә юнәләбез дә синең кенәзлегеңнән кара күмер генә калдырып чыгачакбыз, дип бик нык кисәткән ди...

Җиденче сентябрь киченә сугыш кыры әзер булып бетте, Мамай аны, үзенчә, шактый төгәл күзаллады сыман.

Ике канатта – ике олы гаскәр, аларның һәркайсында икешәр йә өчәр төмән бар да бар инде ул. Үзәктәге чирү ике катлы. Иң төп полк Митрәй чатырын юан дага сыман нык уратып алган. Ләкин аңа җиткәнче алгы полк дигәнен дә кырып-сытып узасы бар әле. Кенәз чатыры артында

[27] Рус елъязмачылары тудырган «Задонщина» һәм «Сказание о Мамаевом побоище» атлы хикәятләрдә Куликово кырында руслар ягыннан 303 мең сугышчы яуга кергән, шуларның 259 меңе һәлак булган, дип тасвирлана. Әлбәттә инде, хакыйкатьтән гаять ерак саннар.

да бер чирү шәйләнә, куендагы полк дигәннәре, мөгаен дә, шулдыр. Бу үзәктәгеләрен дә кушып исәпләсәң, валлаһи да, Митрәйнең гаскәре йөз илле меңнән артмый. Саны байтак, тән чымырдатырлык, иллә мәгәр кораллары, килеш-килбәтләре бигрәк кылка инде. Тимер-бакыр көбәгә төренгән сугышчылар саны өч-дүрт төмән чамасы да юктыр. Җайдаклар да биш төмәннән артмас. Калганнары – бары да җәяүлеләр. Һәрберсендә диярлек кылыч, озын сапка утыртылган балталар бар-барын. Әмма сөңгеләр урынына меңәрләгән сәнәк, чалгы, ыргак, ахыр чиктә күсәк күтәргәннәр. Бу мескеннәр Мамай мирзаның Каф тауларда, Җаек аръягында яуда йөреп чыныккан арсланнарына, юлбарысларына каршы тора аламыни соң инде?! Болар җәнәвизләр, алан вә кыпчаклар яудырган уклар яңгырыннан соң кырау суккан үлән урынына кырылып бетәчәк бит!..

– Бүтәнчә көтеп булмый, – дип нәтиҗә ясады сәрдәр-мирза төнге зур җыенда. – Ягайло таҗдар утыз гына чакрымда, орыш башлануга килеп җитәчәк ул. Тверь кенәзе Михайло да юлда, безне һич ташламас. Таң атуга, арысланнар, юлбарыслар төсле, ярсып-кайнап, дошман өстенә ташланырга кирәк. Һәрбер яусыз үткән сәгать – дошман файдасына. Алар – үз җирендә, аларга өстәмә көчләр, тамчылап булса да, гел өстәлеп тора. Урыс гаскәренең үгез урынына көрәюен, көч җыюын көтеп торып булмас. Кояш калкуга ук яуга ташланабыз. Яуга, яуга!..

Яр буенда томан таралуга, иң беренче итеп, ялгыз батырларны алга чыгардылар. Чилу бәк – Мамай мирза белән дистәләгән яуны бергә үткән яугир, үзен бүгенге орышта да кыр хуҗасы сыман иркен тотты. Атлар өстендә беренче мәртәбә күзгә-күз карашып узгач та, боҗра читенә чыгып, корыч калканын җиргә атып бәрде.

– Бу монахның өстендә көбәсе юк, ә батырлар көрәше гаделлекне сорый, – дип, ике як гаскәр дә ишетерлек итеп оран салды. – Көчләр ике якта да тигез калсын өчен, мин калканны ташлыйм.

Ике кыя, ике тау шикелле кузгалып, алга ыргылдылар. Аралары күз ачып йомганчы якынайды. Икесенең билендә дә озын кылыч, кулларында тәртә буе сөңге. Бер-берсен иярдән сугып төшерергә генә ният иткәннәр иде дә, икесенең дә мәгърур сөңгеләре күкрәкләрен ярып-сытып керде. Ике батыр да чаптарлары белән җир өстенә ауды. Монах җиләненә төренгән орышчының чып-чын яугир булганлыгы шундук ачыкланды – ертык җилән астында өзелгән тимер көбә боҗралары чәчелеп ята иде.

– Чилу бәк җиңә алмады, начар фал бу, – дип, сәрдәр-мирза чатыры алдына тезелешеп баскан тәнсакчылар усал сүгенделәр. – Аның каравы, урыс батыры да үз үлемен тапты. Ике якта да өмет тигез әле...

Сафлар тын калуга, Мамай мирза җәнәвизләр төмәнен яуга ташлаттырды. Алар – җәяүлеләр, әмма һәммәсе дә мең тәңкәле корыч көбәләрдән. Очлымнары чүлмәк сыман тоташ, күз ерымнары гына чекрәешеп тора. Калканнарын бергә тезделәрме, дивар хасил була. Беренче рәттәгеләрдә – кылыч та ыргаклы җиңел сөңге. Боҗра эчендә калганнар дошман өстенә туктаусыз ук яудыра. Җәнәвизләр урысның алдынгы полкын, сарык көтүенә ташланган бүре өере сыман, сытып кына барды. Болар ике төмән сугышчыны кырып бетерүгә, дошманның Митрәй кенәз кул астындагы үзәк алаена[28] барып төртелделәр. Мамай янына Болгар олысыннан тупланган аерым төмән башлыгы Бигеш килеп җитте.

– Митрәй әле өч ел элек кенә безнең Болгар тирәсен дә, Җүкәтау илә Казан тарафын да тоташ талап китте. Мәхмүт илә Хәсән бәкләребез йолым салымы

[28] Алай – полк.

чыгарып түләгәннән соң гына кире борылдылар. Безнең үчебез чиксез. Болардан да каннар костырырга безгә рөхсәтең бир!

Мамай алга таба кулын изәүгә үк, болгарлылар яуның үзәгенә бәреп керде. Болар – әле мәркәзләрен Митрәйдән саклаган чакта ук туплары һәм тимер җәяләре белән урысларның котын алган кавем. Бу юлы да тимер җәя мәргәннәре кыл уртада икән. Борһан атлы мәргәннәре колаклары уч төбе кадәрле, озынлыгы сөңге буе булган иң тәүге укны зеңләтеп очыруга, кызгылт әләм астына ялтыравык киемнәргә төренеп баскан кенәзләре әйләнде дә төште.

– Кенәз, кенәз, олуг кенәз вафат! – дигән зур хәвефне иң беренче булып кайсы як кычкыргандыр, икенче мизгелдә үк аны меңәрләгән яугир кабатлады.

– Олуг кенәз, Митрәй кенәз вафат!

Ул арада мәргән Борһан икенче угын да корып өлгергән бит. Ул тәтә җебен ычкындыруга, кенәз чатыры түбәсендә торган кызгылт әләм чәчрәп читкә очты. Инде урыс гаскәрен ике кулсыз да калдыргач, Мамай яклыларга гайрәт инде.

– Җиңү, җиңү! Урыс башсыз калды! Әләмнәре ауды! Җиңү безнең якта! – дип илерә-илерә бердәм үкерделәр.

Әмма Мамай урыс кенәзенең нинди мәкерле көчне поскында тотуын алдан күрә белмәгән шул. Көтмәгәндә әүвәл җиз сорнай тавышы яңгырады да, Тын елга буендагы бер тау ышыгыннан саранчалар күчен хәтерләткән ташкын килеп чыкты. Ара ерак түгел, Мамай барысын да төгәл күреп торды. Дошманның сул канат ясап якынлашкан төмәнен Серпухов кенәзе Андрей әйдәп килә, уң яктагы төмәннәрне Боброк җитәкләгән. Мамай аларның икесен дә яттан белә, йөз кат күргәне бар. Андрей атлысы үз каласында хакимлек итү өчен дә, якын кардәше булган Дмитрийны Мәскәүдәге олуг кенәз кәнәфиендә калдыру өчен дә, йөз суларын түгеп һәм бүләкләр төяп, Сарай тупсасына унбиш ел чамасы туктаусыз килеп йөрде. Ә Боброгы әле биш еллар чамасы элек кенә Волын каласында кенәз булып утырды, аннан аны латышлар кенәзе Витаутас гаскәре себеркеләп куды. Шуннан Мәскәүдәге Митрәй кенәз сараена иңеп куыш тапкан булды. Әмма кайсы гына хуҗа утарында өрми йә таламый торган әрәмтамак эт асрасын инде? Митрәйгә ярыйм дип, качак Боброк Тверьдагы Михайло өстенә дә, хәтта караучысыз калган Болгар олысына да яулар белән йөрде. Дөрес, өч ел элекке явында Болгарга да, Казанга да бәреп керә алмады, ләкин, барган яллык, барыбер дә олау-олау күн итекләр, кенәз хатыннары өчен читек төяп китте. Менә, шушы качак Боброк хәзер мәскәүлеләр ягында олуг сәрдәр, ә тирәнрәк чокысаң, яллап китерелгән бер ау эте инде.

Шулчагында Мамай чатыры янына икеме-өчме төмәнбашы берьюлы чабып килде. Йөзләрендә аптыраш вә хәвеф.

– Митрәй кенәз исән! Әнә, Боброк әләме янындагы бер җайдакны кара. Иярендә исерек кеше шикелле ава-түнә генә утырса да, Сарайга ярлык өчен мүкәләп килеп йөргән Митрәй кенәз бит ул. Без аларның үзәк алаенда, сәрдәр шушы дип алданып, Мәскәүнең Михайло Бренко атлы гап-гади бер боярын атып үтергәнбез. Митрәй кенәз – җебегән, куркак мөртәт – үзенең киемнәрен шушы Бренкога салып биргән булган. Мондый җебегән кенәзгә каршы орышка чыгып йөрү – үзе үк зур хурлык!..

Мамай хәзер үзе дә чамалады. Олуг кенәзнең исән калуы гади сугышчыларга да куәт-дәрт өстәде, аларның хәтта яу кырында яраланып-миңгерәп ауганнары да кабат кубып, Кырым гаскәренә ташландылар. Боброк җитәкләгән поскын гаскәргә дә төмән артыннан төмән өстәлеп тора, алар Мамай чакырып китергән алан, кумык, кыпчак, бәҗәнәк чирүләрен арба тәгәрмәче астында калган камыл

урынына сыта башладылар. Мамайның бәбәкләренә кан йөгерде, ул келәмгә ауды. Берникадәр арадан соң шашкан кешедәй сикереп кузгалды да иярenә менде. Теш арасыннан сытып чыгарган әмерен ишеттеләр:

– Яуга кергән кыпчак-чиркәс алайларын кире чакырмагыз, алар безне каплар өчен калсын. Ә татар төмәннәренә фәрман таратыгыз, без китәбез!..

Килгән сукмакка аяк баскач та басылмады Мамай, артта калган Мәскәү кенәзенә янап, йодрыкларын болгый-болгый сытып сүгенде ул:

– Митрәй кенәз, ул тәхеттә калсын дип, юкка гына Туктамышның арт санын тугры эттәй ялый. Ул Туктамыш, вакыты җиткәч, аһ, Митрәй кенәзне табан астына салып биетәчәк әле!..

Әйе, Мамай өчен менә шул рәвешчә тәмамланды ул Шөлди явы. Өч-дүрт атнадан соң төрле хәбәр кайтты:

– Митрәй «без Мамайны җиңдек, куркак мирза яуны ташлап качты», дип Туктамышка аерым чапкын куган.

– Шөлди кырын мәетләрдән чистарта башлаганнар. Урыслар ягыннан йөз мең чамасы җәсәд санаганнар ди. Кырымлылар арасыннан кырык меңнән артык яугир корбан булган...

Менә шулай, Мамай җиңмәде дә ул Шөлди кырында, тар-мар да ителмәде. Хәтта инде аның хакында җиңелгән дип сафсата сатсалар да, Мамайның, гомумән, гомерендә дә үз кул астындагы гаскәрне хурлыкка калдырган башка бер генә орышы да булмады бит. Урданың үз эчендә әмирләр вә бәкләр, угыр кәҗә тәкәләре шикелле, бер-берсенең олысларын, калаларын таларга күп йөрде анысы. Иллә мәгәр Мамай Урда җирләренә бер генә чит-ят дошман гаскәрен керттермәде, мәмләкәтне таркатмый-талатмыйча саклый-яклый белде.

Әлбәттә, ул фәрештә түгел. Сарай тәхетенә утырткан ханнарны байтак еллар буе үзенең кубызына биетеп кенә тотты. Әлләни хата юк бит. Тәхет тирәсе – этәчләр йә сыртланнар сугышы кебек үк яу кыры инде ул. Йә син дилбегәне үз кулыңда тотасың, йә дошманнар талый. Алар да аз булмады. Чыңгыз туруннары гына түгел, Болгар, Хаҗитархан, Мукшы, Сарайчык шикелле олыс әмирләре булган Хәсән, Хуҗа-Чиркәс, Гарәбшаһ, Айбәк бәкләр дә Урда тәхетен эләктерергә тырышып карады бит. Әйе, куды аларны Мамай, себеркеләп, һау-һаулатып куды. Чөнки илне җыен вак-төяк һәм хуҗасыз этләрдән талатканчы, бәйгә куйган һәм симертеп тоткан үз этләре аның өчен отышлырак иде. Хәзер кай тарафтан, нинди әнчек этләр генә капка асларыннан тавыш ташламасын, юк, йөгәндә тотты, таркатмыйча тотты Мамай мирза бөек Җучи йортын. Ә җил кай якка иссә, шунда ава, үз куышын йөз кат алыштыра торган Туктамыш газиз йортны Мамай шикелле үк какшатмый-аудармыйча тота алмаячак. Юк, ирек бирәчәк түгел аңа Мамай! Бүген аны куып җибәрдек, моннан котылдык, дип юкка сөенәләр. Кәффага кереп бикләнием, беркадәр тын алыйм, ә аннары утлы күмер өстенә мендереп биетәм әле мин сезне, җыен соран, җыен сатлыкҗаннар! Кайнар таба өстендә биергә әзерләнә тор, әрсез Туктамыш хан!

## 5

Тын елга ярында кырымлылар бигать китергәннән соң, Туктамыш хан берничә тәүлек буена ау оештырып, чаптарлар ярышы үткәреп күңел ачкан иде, буранлы кыш башлангач, Кәффа каласыннан аның күңеленә май булып ятардай хәбәр китерделәр.

– Җәнәвиз сәүдәгәрләре Мамай мирзаны әүвәл колач җәеп каршылаган булган, ә ул, нәфесен тыймыйча, бер рум сылуына кул суза башлагач, тегеләр

моны буып үтергән. Олау-олау төяп килгән хәзинәсен талап бетергәннәр. Мамайның өлкән улы Мансур гына иң якын яраннары белән чыгып кача алган. Башка якта ул әмиргә куыш юк бит инде. Аптыраганнан, Киев каласында утырган латыш кенәзе Витаутас янына юл тоткан ди.

Туктамыш Карабәкне, менә шул хәбәрне алганнан соң, үз чатырына чакырды да инде. Карабәк моны һич көтмәгән иде, юл буена шабыр тиргә батып, кырык төрле уй кичереп барды. Габдулланы заманында Мамай мирза хан итеп тәхеткә күтәрде бит, Туктамышның шуның өчен үч алуы, йә булмаса, үз тәхетенә дәгъва итәрдәй барча дошманнарыннан арынырга маташуы мөмкин. Яки Карабәк Мамайның бар ниятен, һәммә серен белеп яшәгән дип уйлап, Туктамыш хәзер инде мәрхүм булган мирзаның хәзинә яшергән, байлык күмеп куйган куышын элеккеге хан ярдәме белән эзләп тапмакчымы? Аңа өмет итсә, бөтенләй беркатлылык. Чүл бүресе, сыртлан, сусар, төлке кебек җанварлар гына түгел, әрлән, йомран, кумак сыман вак-төяк корткычлар да – һәркайсысы тапкан ризыкларын, аулаган дошман үләксәләрен бер-берсеннән читкә яшерә, үзләренең үсеп җиткән балаларының күзләренә дә күрсәтми бит хәтта. Ә Мамай шикелле мең кат эрләнгән һәм мең кат җилгәрелгән хәйләкәр үзенең хәзинәсен Карабәктәй ачыкавызларга белдереп яшиме соң!

Туктамышның тагын Мансур язмышы, дөресрәге, Мамай белән Витаутас бәйләнеше турында сорашасы киләдер, дигән очкын да бар. Ләкин Карабәкнең Мамай хуҗа булган Үкәк каласыннан гына түгел, хәтта мирзаның сәфәрләргә, ауга чыккан чакта кора торган ефәк чатырыннан читкә тибелүенә дә унбиш еллап гомер үтте инде. Шулай икән, нинди генә сер алмакчы була соң бу Туктамыш? Карабәкнең яңа ханга нигә хаҗәте бар?..

– Хуш килдең, Габдулла хан, әйдүк, мәйлең! – дип, Туктамышның ике кулын сузып каршылавын күргәч, Карабәк хәтта мәлҗерәп үк төште.

Үткән сынау, күргән мең төрле кимсетелү һәм газаплар эзсез каламы соң! Ул күз төпләренә сытылып чыккан ачы яшьләрен кул аркасы белән сыпырып куярга мәҗбүр булды. Туктамыш бөтенләй үк туң бүкән түгел, ахры, аның бу кыланышын күрмәмешкә сабыша белде һәм элеккечә үк җылы тавыш белән дастарханга дәште.

– Мин сине кайчандыр, әле малай чагында ук бер мәртәбә күреп калдым сыман, – дип якын туганыдай сүз башлады. – Ялгышмасам, моннан егерме биш ел чамасы элегрәк, Җанибәк хан Җаек буена ауга чыккан чакта, синең атаң Дәүләт-Хуҗа белән минем атам Туйхуҗаны да бер сәйранга дәште. Үз гомеремдә беренче мәртәбә мин шунда чакматашлы озын мылтык күрдем. Ул синең атаң кулында иде, шуның белән ул бер җәйрәнне екты. Син ул чакта ияргә ияләнеп кенә килүче, сыер боты чаклы гына малай идең әле. Шулай да, атаң белән шапырынасың килгәнгәдер инде, гел җәйрән тирәсендә бөтерелеп, авыз ерып йөрдең. Чакматашлы мылтык күңелемә бик нык бәргән иде, шуңадыр, ахрысы, син, бәләкәч Габдулла да, хәтеремдә калдың.

– Ә мин моны оныткanмын инде, – дип җавап кайтарырга мәҗбүр булды кунак, үзе барыбер дә җитдирәк сүз көтте.

– Мин сине, билгеле ки, сабый чакны сагынып утырырга вә чәй эчәргә генә чакырмадым, – дип аңлап алды хуҗа. – Минем сараема йөзәрләгән киңәшчеләр, аркадашлар, Җучи бабабыз корган бар олысны кабат бер учка җыюда ярдәм итәрдәй олы бәкләр кирәк. Әйе, әйе, күзеңне бик акайтма, Җучи олысын өр-яңадан җыюда минем исәп. Мондый олы юлда байтак гамәлләр кылынды да сыман. Күк Урда белән Алтын Урда хәзер минем кулда. Шәйбан

этләре эләктергән Меңкышлак олысын, Арал буйларын кайтару да әлләни ерак йөрмәс. Магулстан мәркәзе Алматыдагы Камәретдин әмир белән Харәземдәге Сөләйман суфи да безнең Урдага кушылу ягында. Миңа аркадашлар, ярдәмчеләр Җучи олысын тулаем җыйнап бетерү өчен кирәк тә бит инде.

Карабәккә җиде катлы болытлар өстенә менеп киткән ханны итәгеннән сөйрәп төшерергә туры килде.

– Тыңлап утырам, син гел, Үзбәк хан шикелле, һаман шәрык ягын, шәрык олысларын гына кайгыртасың. Ул да, менә, Сарай мәркәзендә яки Кырым илә Болгарның кайсындадыр мәрмәр мәчетләр дә, затлы пулатлар да калкытмаган. Аның каравы, бер Үргәнеч каласында гына өч-дүрт төрбә-пулат, хәтта Мисырдан кәрван-кәрван итеп ташылган мәрмәр ташлардан Ак Кала да төзеттереп куйган. Ә югыйсә, бизмәннәргә салсаң, Җучи олысын иң беренче чиратта Кырым белән Болгар олыслары туендырып яши. Син кереп утырган алтын нәкышле сарай да Болгар осталарының кулы белән җирдән күтәрелгән. Алардан тыш, тагын әле Таш Билбауны тирәләп алган, Ак Идел, Чулман, Әтил, Нократ дәрьялары буйлап сузылган күпме олыс бар. Ахыр чиктә син урыс кенәзлекләрен дә күз уңыннан чыгарып ташларга бик ашыкма әле. Алар Алтын Сарайга ясак озатуны бөтенләй онытты. Әнә, Мамай мирзаны Шөлди кырыннан куып җибәрүгә, хәзер ярлык сорап Сарайга килүче кенәзләр дә бетте.

– Юк, аларның борын чөеп яшәвенә ирек куясым юк! – дип шашып кычкыра-кычкыра элеп алды Туктамыш. – Алтын Урда каһаны барлыгын санга сукмыйча, үзбаш булып, баш бирмичә яшәргә ымсынып карасыннар. Мин аларны борыннары белән үзләренең нәҗесенә тыгып куям әле!

Карабәк туктамады.

– Әгәр бер олыс бәгенә йомшаклык күрсәттеңме, иртәгә сине башка азгын бәкләр корт күче шикелле сырып ала һәм иң котырган кигәвеннәр, зәһәр шөпшә сыман талый башлый. Яман шешне ул борын күрсәтүгә үк яндырып йә көйдереп юк итәргә кирәк. Син беләсең булыр, вак чуанны вакытында сытып бетермәсәң, ул аннары тәнне эт имчәге сыман сырып ала. Соңыннан ул җәфадан төбе-тамыры белән йолкып котылалар. Ә урыслар Бату бабабыз аларның олыс-калаларын буйсындырганнан бирле узган йөз илле елдан соң беренче мәртәбә Урда гаскәренә азау тешен күрсәтте. Гап-гади бер ялгыз мирза чирүен кире борганнармы, әллә Урда ханына каршы чыкканнармы – кара гавам өчен дә, аларның поплары өчен дә аерма юк. Иң мөһиме, нибары сыңар Кырым олысыннан гына Мамай мирзаның япа-ялгыз көе җыйган чирүен куып җибәрүне дә алар барча Урда гаскәрен пыран-заран китергән вә тарихта күрелмәгән олуг җиңү төсле бүрттереп, буыннан-буынга тапшырып шапырыначак. Угыллары, оныклары хәтта үзләрен Урда ханнарыннан азат кавем дип тә саный башлавы бар.

Карабәк сүзләре үтенә тиде, ахры, Туктамыш учактагы казан шикелле кайнап чыкты.

– Юк, дидем мин сиңа, олыс бәкләренә, нәкъ хатыннар белән эш иткәндәге шикелле, уч төбен күрсәтергә һич ярамый! Мөгезе чыкмаган бозау кебек торсаң, шул хатыннар төсле үк алар әүвәл итәгеңә, аннан муеныңа үрмәли башлаячак. Ярар, минем сүзне үтәп, Митрәй кенәз Мамай мирзага гаскәр җыеп каршы чыкты. Үзен хан итеп саный башлаган Мамай мордарны чәнчелдереп төшерү өчен шулай кирәк иде. Ул мордардан котылмыйча торып, бердәм Урда төзү турында хыяллану да тәмле төш кенә иде. Аны чәнчелдердек. Иллә мәгәр хәзер инде Митрәй Урдага буйсынудан чыккан еландай баш калкытты. Чиратта

ошбу еланның да башын өзү хәер. Һәр түрәне, абзардагы мал шикелле, үзенең аранына, үз кетәклегенә бикли белү кирәк. Шуңа мин, иң беренче гамәлем итеп, Мәскәү өстенә яу белән барачакмын, монысы һич бәхәссез!

Карабәк күзәтеп утырды, комарга бер керсә, Туктамышны бәйдән ычкынган эттәй тотып тыешлы түгел, бу теләсә кайсы киртәләрне дә сикереп чыгачак икән. Мәмләкәт чаклы мәмләкәткә йөгән кидергән таждарга салкын канлы, аек зиһенле булса отышлырак та бит, мәгәр олы юл башында канат җилпеп гайрәт күрсәтү дә бик кирәкле шәйдер.

– Иллә мәгәр һәрбер дәүләт тылы белән генә түгел, чик буйларын йозакка бикли белүе белән дә көчле була ала. Иң тәүге нәүбәттә, безгә нәкъ менә шул урыс кенәзлекләре чиген таш кирмәннәр сыман ныгытып кую хәер. Менә шул нияттән мин сине Болгар олысына әмир итеп озатырга дигән ныклы уйга килдем, Габдулла хан.

Туктамышның үзенә төбәлеп утыруын шәйләп, Карабәк йөзен югарырак күтәреп бакты.

– Болгар – минем туган йортым Актүбәдән кул сузымында гына, якын олыс, таныш җир анысы. Әмма Кырымдагы халыкның да яртысы – гәрәйлеләр. Әгәр чынлап та мине бер олыс әмире итеп күтәрергә ниятләгәнсең икән, шәхсән үземә Кырым җире якынрак. Монда минем туганнарым, дистәләрчә яуларда сыналган җайдакларым. Ә син мине бөтенләй икенче тарафка, шимальдәге Болгар олысына ук күчереп куярга ният иткәнсең. Бу һаман мине Мамай мөриде, Мамай чирен эләктергән гыйсъянчы дип уйлаудан түгелдер бит? Яисә әмирләрне үзенең туганнарыннан ерактагы чит олыска утыртып, үзеңчә, Урданы фетнә-түнтәрешләрдән азат итәм, дигән ышанычмы соң бу?

– Асылда, Габдулла, миңа аркама пычак кадамый торган тугры җаннар, теләктәшләр кирәк. Заманында Мамай моны ике мәртәбә тәхеткә күтәргән, дип кенә синең кебек абруйлы вә Чыңгыз канын йөрткән әмирләрне табын түреннән куып, ат карарга озату йә гади нәүкәр итеп орышларга кертү – ул өстеңдәге затлы җиләнеңне салып ташлап, сальченекедәй кылка-сәләмәгә төренү шикелле үк тилелектер. Ата-бабалардан калган бер гыйбрәтле әйтемне ишеткәнең бармы? «Әтәч булып кычкырырга маташып көчәнә торгач, карга шартлап ярылган». Тач шуның шикелле, нинди генә булдыклы хан да ышанычлы әмирләрдән, сәүдәгәрләрдән, мигъмарлардан[29], ахыр чиктә кәтибләрдән башка да берни кыра алмый. Шуңа күрә, әйдә, Болгар олысын ал син үз кулыңа. Таянырдай, ышанырдай көчле әмирем бул. Болгар – урыс олысларына иң якын җир. Аны ушкуйларның[30] да, кенәзләрнең дә әтәч сыман бертуктаусыз чукып-талап торуларын беләм. Син ашыгыч рәвештә кирмәннәр кор анда, сәүдә эшен җайла, гаскәр тупла. Болгар олысы Мәскәү белән ике арада кыя кебек калкып басмаса, Урдага да кәфенлекләр әзерлисе була. Шуңа кичекмәстән мәскәүлеләр өчен шәрык ягына бар юлларны бикләү.

Карабәкнең һаман бер җавапсыз утыруын күргәч, риясыз елмая-елмая, өстәп куйды:

– Мин сиңа җаның теләгән кадәр гәрәйлеләрне дә, кыпчак яки бәҗәнәкләрне дә үзең белән Болгарга алып китәргә рөхсәт итәм. Тик ул олысны ашыгыч рәвештә кыя-кирмәннәргә әйләндер син.

[29] Мигъмар – төзүче оста, архитектор.

[30] Ушкуй – елга баркасы. Шуларга төялеп Болгар яки Алтын Урда калаларын таларга килүче урыс юлбасарларын элек шулай атаганнар.

## 6

Карабәк ничәнче тәүлек буе озын, авыр юлда. Үзе, күбесенчә, кәрванның иң башында, әмма ярты гына сәгать тә тыныч барганы юк. Аның артыннан, әллә ничә чакрымга сузылган олы дәрьядагы язгы ташкынга охшап, ун меңгә якын арба тезелешеп килә. Арбаларның зур-зур печән кибәннәредәй бөркәвечләләрен дә, көйләп куелган түбәләрен киндер яисә мал тиреләре белән яртылаш ябылганнарын, үрәчә-кабыклардан гына корып куйганнарын да санап бетергесез. Аларда чүлмәк-казаннар, савыт-саба, чаршау-мендәр, ястык-юрган, чалгы-сәнәк, балта-чүкеч, пычкы-шөшле, очлым-калкан, итек-көбә, бәбкә-чебеш, кәҗә яки сарык бәтиләре, яңа гына туган колын һәм бозаулар, авырлы хатын-кыз, карт-коры, бала-чага... тагын бетмәс-төкәнмәс кирәк-ярак, кием-салым, сугыш кораллары... Арбалар янында дистә меңәрләгән кыз-кыркыннар, яшь-җилкенчәк, чәчләре чалара башлаган ирләр һәм хатыннар атлый. Артта дистә меңәрләгән сарык, кәҗә, сыер, дөя, бия, айгыр, алаша, ишәк көтүләре. Һәм биш йөз яки бер мең арба арасында хәрби киемнәргә төренгән уяу сугышчылар. Һәрберсе ашыкмыйча, каударланмый гына атлый сыман, ләкин әлеге буар елан алга шуышкан саен, күк йөзенә тузан болыты, тыеп булмас шау-шу күтәрелә.

Карабәк һәр тарафка күз-колак булырга тырышып, әле алга, әле артка чаба. Болай да кара-кучкыл йөзе, муены, хәтта колаклары да эссе кояш астында чуен төсле, чутырдай янып чыккан. Ике күзе дә тешләре генә утлы күмер төсле елкылдап күренә. Аңа күз ташлаган саен, гәрәйлеләр елмаймыйча калмый, аларның канәгать йөзен күреп, әмир үзе авызын җыя алмый.

Елмаеп йөрерлек кәефе бар хәзер Карабәкнең. Хыялларыннан айный башладымы, күз алдына Туктамыш хан аңа фатиха биргән сәгать күз алдына килә. Үпкәләрлек түгел, Туктамыш хан, Солхат читендәге киң яланга дистә меңгә якын кеше җыеп, ә чынлыкта исә, барча кырымлылар каршында күтәреп олылады. Билгеле ки, иң беренче чиратта фәрман укыдылар.

– Тугры ярдәмчебез, Габдулла хан Дәүләт-Хуҗа углын, Болгар олысының олуг бәге итеп билгелибез. Аңа, хуҗа булып алуга ук, ошбу олысыбызның яңа әмиренә, Болгар, Казан, Җүкәтау, Имәнкала[31], Кирмәнчек, Кашан, Чаллы, Алабуга кебек барча калаларны кирмән итеп корып куюны һәм гареб тарафында ур вә ныгытмалар төзүне әмерлибез. Ошбу максатларны ашыгыч төстә үтәп чыгу җәһәтеннән, яңа әмиребезгә башка олыслардан җаны теләгән сандагы инсаннарны Болгар төбәгенә күчереп утырту яисә үзе белән алып китү хокукы иңдерелә. Болгар олысына яңа күчкән гавам биш ел әйләнәсенә мәмләкәт вә ханыбыз файдасына ясак-хәреҗ түләүләрдән азат ителә...

Әле фәрманны тыңлап бетерүгә үк, халык гөж килә башлаган иде дә, тау итәгенә корылган чатыр алдында Туктамыш хан үзе пәйда булгач, яңгыр явып үткән күл өсте шикелле, гавам шундук тынды.

– Җанибәк ханымыздан бирле Урдамызның ипле-имин мәгыйшәт күргәне юк, – дип башлады ул сүзен, тешләрен шыгырдатып. – Шул ханымыздан соң узган егерме сәнә эчендә мәркәземездә өч дистәгә якын узгынчы алышынды. Эте дә, бете дә ханиямез таҗын үзенә яратмакчы, җыен әтрәк-әләм Урда мәмләкәтен сугым малы кеби бугазлап ташламакчы булды. Нәтиҗәдә, Җучи бабамыз төзеп калдырган мәмләкәт кулдан ычкынган касә урынына ватылып вә теткәләнеп бетте. Кем иренми, хуҗасыз сыердай күреп, аны килеп сава башлады. Мамай мирзаның гоҗлыгы аркасында җиңелү хурлыгын, иң тәүге нәүбәттә, менә сез күрдегез. Урыс

[31] Имәнкала – бүгенге Уфа урынындагы кирмән.

кенәзләре безнең кулдан китәргә вә Сарайдан аеры яшәргә җыена. Әгәр бер генә тәкәгә читкә качарга ирек куйсаң да, аннан күрмеш, барча мал да уҗым эзләп чабачак, көтү таралачак. Без Җучи бабамыз төзеп калдырган татар мәмләкәтен көтүчесез калган мал өере урынына таратып бетерүгә ирек куя алмыйбыз.

Туктамыш бик үтемле итеп сөйли иде, гавам аңа дикъкать салып торды. Арада Мамай мирза белән Шөлди кырында җиңелү ачысы кичереп кайткан ирләр дә бар, ахры, аерымрак баскан өч-дүрт төркем, Туктамышның әрем төсле ачы сүзләреннән башын иеп тора.

– Без Урдамызны Җучи бабамыз калдырганча яңартырга тиеш, – дип кабатлады Туктамыш хан. – Күрше ихатасына таш атканчы, иң элек үз йортыңның капкаларын, коймаларын ныгытып кую хәер. Ошбу мәсләктән, карарымыз әзер, барчагыз ишеттегез. Без гамәлемезне һәммә олыс илә барча калаларны кирмән вә үтмәс диварларга әйләндерүдән башлыймыз. Иң тәүге чиратта – Болгар. Яңа әмиремезгә – тулы ирек. Аның әләме артыннан кузгаласыз икән, сез дә – ясак-хәреҗләрдән азат кавем. Хәерле сәгатьтә! Бисмиллаһи-иррахман-ирраһим!..

Менә шулай, фатихалар алып кузгалганнар иде, күз тимәсен, меңәрләгән гаилә иярде бит. Карабәк бик чамалый: Мамай изүеннән дә, Сарайдагы һәр яңа хан талавыннан да туйган инсаннар бу. Кырым Сарайдан кул сузымында гына, ә Болгар – шималь ягында, мәркәздән еракта ул. Кырымнан бирле сузылып бару ансат булмаса да, алар соңыннан талау-изүләр күрмичә, азат булып яшәүгә өметләнә. Үзенә ышанып җиде дәрья артына кузгалган кара гавамның менә шул өметләрен акларга насыйп булсын әмир Карабәккә!..

## 7

Карабәк Иделгә җиткәнче үк Көбә үзәнгә дә, Каф тау итәгенә дә, хан фәрманының нөсхәләрен тоттырып, дистәләгән чапкын куган иде. Үзенең өметләрен аклаган хәбәрләр кайтып җиткәч, колакларына ышана алмый торды.

– Маҗар каласыннан бер мең чатыр синең олавыңа килеп кушылачак. Яхшыбай бәк Идел ярында ыстан корып көтүеңне сорый.

– Дирбәнд олысыннан алты йөздән артык олау кузгалды да инде. Алар юлда ишәйми калмас әле.

Иделнең нәкъ Сарайга каршы ярында тукталып ыстан коргач, Карабәк чатырына үзенә җигән[32] тиешле Көңгер бәкне, меңбашлары итеп билгеләнгән Бүрәкәй һәм Гайсарны да дәште.

– Ошбу тирәләрдә Иделне кичеп булмый, монда дәрьяның диңгез кеби җәелгән урыныдыр. Иделне Сәмәр җәясе янында кичү хәвефсезрәк. Анда дәрья уртасында утраулар да бар, туктап тын алсаң да, комачау кылучы булмас. Яхшыбай илә Кадыйр-мөхәммәт бәкләр килеп җитешсә, сезгә Иделнең үрге агымына таба кузгалу хәерлерәк. Ә миңа Сарайга кереп, Туктамыш хан каршында янә бер мәртәбә тез чүкмичә булмас. Безнең ыстан гына түгел, хәтта сәфәремез хакында да аңа адым саен хәбәр итәләрдер. Борыным илә килеп төртелгән көенә илтифат күрсәтмәсәм, аның миңа артын куюы бар. Аннары, Иделне бер чыккач, үземнең туган нигезем Актүбәгә дә җитез генә сәфәр кылып алыйм. Алар да безнең олауга кушылмыйча калмастыр дип beләм...

Сарайга кереп бил бөгүгә, билгеле ки, Туктамыш хан үтә мәмнүн калды. Үзен төп хуҗа санау бик ошыйдыр, ахры, яңа гына кияү мунчасыннан кайткан яшь килендәй көләчләнеп, сүзне юмарт тезә. Гәрчә һәрбер сүзе җитди яңгырый үзенең.

[32] Җигән – бертуганның улы, русча – племянник.

– Барып төртелгәч тә, син бер тарафка игътибар итми калма. Элек Болгар олысының терәкләре булган Казан, Җүкәтау, Кашан, Кирмәнчек, Алабуга калаларын, Болгарның үзен дә урыс ушкуйлары яртылаш рәвештә җимереп бетергәннәр. Сәбәп бердер, чөнки аларның барчасы да Чулман, Нократ яисә Идел дәрьялары ярына нигезләнгән. Калаларны елга буена корып кою, бер яктан гөманласаң, бик тә матур вә уңышлы сыман. Каланы бер тарафтан елга саклап тора, дип тә күңел юатасың. Иллә мәгәр мәгыйшәттә алай килеп чыкмый. Елга ярында утырган кала-салаларны һәр узгынчы талап уза башлый. Әлеге олыстагы Ашлы, Аккирмән, Суар калаларының вәйран ителеп бетүе – һәммәсе дә кирмәннәрне яр өстенә корып куюларның йомгагы ул. Ач-әрвах ушкуйлар шуңа күрә аларны иркенләп талаган вә бөтенләе белән юкка чыгарган да инде.

– Ул яктан бәяләсәң, синең Сарай да Идел ярында бит, – дип каршы төшеп карады Карабәк. – Мәгәр Бәркә хан корганнан бирле, гасырдан артык гомер кымшанмый да утыра бит әле.

Туктамыш туктальп та тормыйча кире какты.

– Сарайны да кыя таулар рәтендәге кирмәнгә санап булмый. Аны өч-дүрт сәнә элегрәк шул ук ушкуйлар да талап китте инде, аңа Җидесу ягындагы кыргыз-кайсакларның да күзе төшүе бар. Шуңа берәр заман Урда мәркәзен дә мәмләкәтнең куен түренәрәк күчереп кую җәһәте пешеп җитәр. Бүген әле мәркәз күчерү кайгылары түгел, чик буйларын ныгыту мәслихәтрәк.

– Уйлаган юк иде, – дип сүз кыстырды Карабәк, тик хан ишетмәде.

– Әле Аксак Тимер янына ычкынганчы, аптыраган үрдәк арты белән күлгә чумган дигәндәй, мин Болгар җиренә дә качып караган идем. Анда куен ачып торучы гына табылмады. Әмма шул чагында Болгар җәйләүләрен хәтергә алып, мыекка чорнап кайттым.Чулман дигән зур дәрьяны кичеп, башкорт кавеме ягына барган чакта Мәнзәл, Зәй, Ык, Сөн, Чәрмәсән атлы ваграк елгаларга барып төртеләсең. Аларның берсе дә бака туе җыеп ята торган сазлык яисә ерганаклар түгел. Җаның тели икән, алар буйлап эре-эре баркаслар яисә кырык-илле яугир сыешлы тирән каеклар җибәрү дә берни тормый. Ул елгаларда балык-сусарлар да, ярларында урманнар вә җәнлекләр дә хәтсез. Тик, ни галәмәт, аларның хуҗасы юк, анда калалар юк. Сиңа иң тәүге ыстаннар кору вә казан асу өчен менә дигән урын. Андагы урманнар, инеш-күлләр – һәрберсе кирмән. Менә ул төбәккә ушкуйлар яисә кыргыз-кайсакларның гомер буена да үтеп керәсе юк.

– Мин, һичшиксез, син күрсәткән почмакларга аяк басмый калмам, – дип вәгъдә бирде әмир.

Туктамышның күңеле булды, ахры, ул Карабәккә өч мең җайдаклы өстәмә гаскәр, Шам ятаганнары, тимер көбә, алтын-көмеш бүлеп бирергә фәрман әзерләтте. Иң сөендергәне – яңа җиргә килеп төпләнгәч, сыенып тору өчен йөзәрләгән чатыр, киез тирмә, тау-тау итеп балта-пычкы юллау турында да онытмаган иде.

Хан яныннан чыкса, сарай тупсасында нәкъ үзенә яшьтәш булырдай бер ир көтеп тора. Пәһлеван ук түгел, әмма гайрәтледер үзе. Әнә, иңбашлары гына да һәркайсына чүмәлә утыртырдай. Киемнәре затлы, кыяфәт шәп. Хәтта шулар да сызганулы җиң астыннан ишелгән бау шикелле күренеп торган сеңерле-егәрле беләкләрне яшереп бетерә алмый.

– Хәсән бәк булам мин, – дип сүз кушты ул, ачылып сөйләшә алмаганга кыенсынган төсле. – Хәсән бәк.

Карабәк корт чаккандай әле куырылды, әле котырынды. Бәрәкалла, моннан унбиш ел чамасы элегрәк аны Сарай тәхетеннән себереп төшергән Хәсән бит бу!

– Син Болгарга атап юлга чыгасың, ә мин шул туфрактан, – дип дәвам итте ул, җавапны һич көтмәстән. – Сине озатып калу минем дә бурычым шикелле, шуңа синең күзләреңә күренергә булдым.

«Әйе, әйе, Хәсән бәк Болгардан бит, – дип ушын җыйды Карабәк. – Ул Сарайга мукшы Сәркиз һәм дә Ык елгасы буендагы җәйләүләр хуҗасы Тугаш бәк котыртуы буенча килеп җиткән иде. Тәхетне Күк Урдадагы Ырыс хантуганы булган Морад бәк дәгъвалый башлагач, Хәсән кабаттан Болгарына качты. Дмитрий илә Боброк кенәзләр яу сәфәре белән килгән чакта һаман Болгар әмире булып санала иде әле, аннары ипләп кенә Казан каласына күчеп утырды ул. Дүрт ел элек Ырыс хан шәхсән үзе Сарайга бәреп кергәч, ул Хәсәнне, бәйләрбәге итеп, Сыгнак каласына алып киткән дигәннәр иде. Сыгнак, Сыгнак... Димәк, Туктамыш басып алгач, шул ук Хәсән яңа хаким диванына да күчеп утырган булып чыга инде. Ырыс хан янында да бәйләрбәге, Туктамыш ышыгында да – һаман шул баш әмир. Түбәтәен гел яңартып торган шикелле, хуҗаларына җайлаша белә дә соң адәм баласы!..»

– Ханиямез Ак-Хуҗаны Мәскәү тарафына юллады. Ак-Хуҗа илә Карача мирза Туктамыш ханны моңарчы гел уч төбендә генә биетеп яшәде бит. Дивандагы олуг әмирләрнең берсе булгач, бигрәк тә Ак-Хуҗа мине дә, Ырыс ханга ияреп, Сыгнакка киткәннән бирле гел ят күреп килде. Имеш, Казанчы бәк Мәскәү җырын җырлый, гел Мәскәүне яклый, янәмәсе. Шуңа Мәскәү кенәзен тез чүктерү өчен дә үзе китте. Аның йөгәненнән котылгач, Туктамыш хан мине бәйләрбәге итеп куйды әле, менә, – дип, Хәсән үзе дә, Карабәк уйларын сизеп торгандай, тиз ачыклык кертте. – Теләсәң-теләмәсәң дә, моннан ары синең да минем аша эш йөртергә туры киләчәк бит. Ике араны ачыклап куйыйк, төеннәр калмасын, дигән нияттә мин.

– Мин сиңа үч тотмыйм, – дип телгә килде Карабәк. – Аннары йөкне икебез ике якка тарту, дилбегә бүлешүләр дә мәмләкәткә куәт өстәмәстер. Без, мәҗлескә чакырылган мулла-мунтагайлар төсле, заманында бер-бер артлы Сарай тәхетенә килдек, булдыра алган чаклы дога укыдык та китеп бардык. Беребез дә Урдага ясин чыгу яисә тәһлил уку кебек хурлык кичермәдек, Аллаһка мең шөкер. Үткән эшкә салават, ди картлар. Бигайбә, бәйләрбәк. Инде тагын бер үк басмаларга кереп сөзешүләрдән Ходай Тәгалә үзе саклый күрсен, Ярабби!

– Амин, амин! – дип кабатлады Хәсән һәм, Карабәкнең беләкләрен кысып, кайнар хисләр белдерүдән дә тартынмады...

Карабәк шушы ук Идел ярындагы Хаҗитарханга сугылып чыгуны да артык санамады. Әле аның элек тә анда әмир булып утырган Сәләчи бәкне үз күзләре белән күрү теләге бар иде. Аның хакында сәер дә, кызганыч та хикәят сөйлиләр бит.

Имеш тә ки, Болгардагы Шәймәрдән атлы әмирнең кызы Бибисара белән Кашанда утырган Гомәр угылы Өмәт, этиләренә ияреп зур сәйранга чыккач, бер-берсенә гашыйк булганнар ди. Кире кайтып киткәч, Кашанда – Өмәт, ә Болгарда Сара этиләрен тыкырдатырга тотынган ди икән.

– Миңа шул ярымнан башка бер тормыш юк, безгә кавышырга рөхсәтең бир.

Ике ата да үз балаларының сүзен тыңламый, чөнки сәйрандагы ауда кайсы җәйрәнне кем екканын бүлешә алмыйча, болар үзара яман бозылышкан. Ахыр чиктә, этисе Гомәрне күндерә алмыйча, Өмәт Болгар каласына качып киткән. Тик монда да, фатиха булмагач, яшь Өмәткә капка ачып торучылар юк бит инде. Ике гашыйк качып-посып кына күрешә башлаган һәм, мәгълүм ки, угыллары

туган. Сараның гөнаһы ачылгач, әтисе моны зинданда тотылган еланнар күченә ташлаттырган. Әмәт тә, сөйгәнен коткармакчы булып сикергәч, буар елан кочагыннан котыла алмаган. Шәймәрдән үз оныгын үтерү турында да фәрман биргән булган, иллә мәгәр яраннары ятим сабыйны бик нык кызганганнар. Аны бер сал түренә бәйләп салганнар да Идел буйлап агызып җибәргәннәр. Ни галәмәт, Хаҗитархан янындагы ярга килеп төртелгән чагында да сал эчендәге сабый исән булган. Аны баласыз парга биреп үстергәннәр. Ә егет булгач, шушы сабыйны Хаҗитарханның әмире итеп күтәргәннәр. Чын исемен белмәгәч, сабый чакта аны Салчы дип кенә йөргәннәр, әмир булгач кына ул үзен Сәләчи дип үзгәрттергән икән. Менә сезгә гыйбрәт...

Хаҗитарханда янына барып кергәч, Карабәк тә нык аптырап калды. Валлаһи да, япь-яшь егет бит бу. Тәгам өстәле янында киная ташлагач, егет үзе рәхәтләнеп көлә.

– Ә мин, асылда да, әти-әнине белмим. Бер иш халык аларны Җанибәк хан чорында котырган үләт зәхмәтеннән егылган, икенче ишләре Сарай түнтәрешләре вакытында әрәм булган, диләр. Мине кала халкы багып үстерде, һичбер арттыру юк. Монда мин тамак ялгамаган йорт калмады бугай, шуңа бөтенесе үз угылы итә.

– Синең хакта биш ел элек ушкуйларга гаять оста тозак корган, дип соклану сүзләрен күп ишеттем, шуны сөйлә әле, сабак өчен кирәк булуы бар, – дигән сораудан соң гына Сәләчи беркадәр җитдиләнде сыман.

– Ул сәнәдә ушкуйлар Наугырыттан Чулман аша төшкән, Колын каласында да, Аккирмән илә Болгарда да аларны кирмән башлыклары сизенмичә калган. Дивар аша елан кеби төнлә үтеп кергәч, әүвәл шыгавылларны тоташ суеп чыккан, аннары өч каланы да рәхәтләнеп талаганнар инде. Болар, тәмам азып, Сарайга ябырылгач, урыс юлбасарлары турындагы хәбәр безгә дә килеп җитте. Шуннан мин Сарайга чапкын озаттырдым. «Сәләчи Хәзәр диңгезендә азәриләр бәге Ясакны талап кайтты, кораб-кораб итеп туплаган хәзинәсен Куштамак дигән утрауга яшереп саклый», имеш. Ясак бәк илә Куштамак утравының атларына тикле үзем уйлап чыгардым, моны аңлыйсыңдыр. Тегеләр шикләнеп тә тормаганнар, ут капкандай килеп җиткәннәр бит. Ә без аларны, асылда да, Идел елгасындагы бер утрауга куып кертә алдык. Аннары кырык көн буена бер адым да читкә чыгармадык. Берәрсе генә күршедәге утрауга омтылдымы, анда безнең укчы мәргән көтә. Ашарларына бер кабым ризык калмады, ач сыртланнар төсле, бер-берсен кыра, үтерә башладылар. Болар өрәк урынына кибешеп, гел коргаксып бетте. Ахыр чиктә атаманнары миңа бер каекчы куган. «Аккирмән, Болгар, Сарайлардан талаган бар байлыкны, һәмишә җарияләремне Сәләчигә бирәм, коры җир өстенә чыгып аяк сузарга гына рөхсәт итсен берүк?» – дип гозерли. Җавап кайтармадык. Соңыннан аны минем нәүкәрләрем утрау читендәге чокырдан табып алды. Бил тиңелтен су эчендә басып торган көе аяк сузган теге...

Карабәкнең Болгар каласына төбәп кузгалуы турында да, әлбәттә, хәбәрдар ул.

– Йөз илле ел элек кенә без Болгар белән бер мәмләкәт булып яшәгәнмез. Аның аякка баса алмыйча, ятим баладай мәгыйшәт кичерүе – безнең өчен дә гарьлек. Амбарларыбыз ризыклардан бүселеп тормаса да, бер мең арба ашлык бирәм сиңа. Олаучыларым да, билгеледер, хатыннары-балалары белән синең янга китә.

Сәләчинең шушы карарын ишетүгә, дымланган күзләрен күрсәтмәскә омтылып, Карабәк аны кочагына алды...

Актүбәлеләр дә, ниһаять, аның кануни һәм аерым әмир булып күтәрелүе белән чиксез горурланган. Озатырга чыккач, туганнары аермачык әйтте.

– Сәмәрканд ягыннан, Аксак Тимер атлы әмирнең кысуына түзмичә, меңәрләгән тирмә кыргызлар качып чыкты. Үзебезнекеләр янына аларны да кушып, сиңа өч мең чатыр ияртеп җибәрәбез. Мин – чит олыс хуҗасы дип, борадәрләреңне читкә кага күрмә...

Төп олауны куып җитүгә үк, Карабәк әмер таратты.

– Кичү вакытында меңбашлар янәшәсенә олауларны санап үткәрүче хисапчылар билгеләп куярга да онытмагыз. Хаҗитархан илә Актүбә нөгәрләре безне сулъяк ярда көтә.

Иделне өч тәүлек буена кичкәннән соң, хәзер инде кәрванда төп сәрдәрләр булып исәпләнә башлаган Яхшыбай бәк белән Көңгер-җигән Карабәкнең чатыр хозурында җавап тотты.

– Ике як яр буенча килгән кәрванны да кушсак, синең канат астында унҗиде мең арба исәпләнә. Син кузгаткан халык санын һаман булса ерып чыга алмый интегәбез. Инсаннарның саны йөз илле мең үренә җитеп килә.

**8**

Иделдәге Чулман тамагына килеп җиткән чакта Карабәк кәрванын Янтык бәк каршы алды. Таныш түгел калабәк килештерә белә, ул яраннары белән яланда ялгыз кибән төсле кукраеп утырган Айгыр тау өстенә менеп баскан. Мәһабәт, шәп урын. Аста, диңгез хасил итеп, ике дәрья килеп кушыла. Тау үзе, асылда да, шушы дәрьялар ярына чабып килгәч, арт аякларына күтәрелеп баскан айгыр төсле: елга яклап – гаҗәп биек, текә кыя, ә дала ягына таба тау итәге сөзәкләнеп төшә.

Янтык – Казан бәге. Мөгаен дә, аны үзе Ырыс ханга ияреп киткән чагында Хәсән утырткандыр. Җәйләүләре Казан каласыннан Чулман ярына тикле сузыла ди. Үзе – утыз яшьләр чамасындагы бер ир. Күпчелек татарлар шикелле үк эре сөякле, таза бәдәнле ул. Ияргендә уч төбе кадәрле генә пөхтә, түгәрәк сакалы бар. Дегет төсле чем-кара мыек чылгыйларын шактый мул үстергән. Үз-үзе белән соклану чире дә купкандыр шикелле – әледән-әле чылгый очларын бөтереп, сакалын сыйпап куя. Хәер, булдыксыз да түгел, ахрысы. Әнә бит, янында инде кул астына керергә әзер булган өч такыр башлы малай тезелешеп тора. Өс-башлары бөтен, мохтаҗлыктан интекмиләр, димәк.

– Казан кирмәне сине каршыларга әзер, төкле аягың белән, олуг әмир! – дип, кулларына бер бөтен икмәк тоткан көе, сыңар тезенә чүгеп каршылады Янтык.

Карабәк аны беләгеннән капылт күтәреп аягына куйды. Усал сүз әйтүдән тыелып, тешен кысты. Янтык кына Карабәкнең бәясен аңламады сыман, көр күңелле тавыш белән янә телгә килде.

– Туктамыш хан фәрманын күптән алган идек, синең нинди олы кәрван ияртеп киләсеңне шундук чамаладык. Казан кирмәне ким дигәндә өч мең гаиләне үз түбәсе астына сыйдырырга әзер.

– Ә мин аларны аналарын төлке урлап киткән каз бәбкәләре урынына төрле ояларга өләшеп йөрергә җыенмыйм бит әле, – дип телгә килде Карабәк, кипкән ботак сынгандай коры тавыш белән. – Җүнле ана – кызларын, хуҗачыл ата угылларын кырлардагы игеннәрне җыеп келәтләргә салганчы үз янында тота. Яучыларга шуннан соң гына капка ачалар вә башлы-күзле булган улларны да көзге чебешләргә тикле санаганнан ары гына башка чыгаралар.

Янтык бәкнең йөзе җимерелде. Иңбашына кулын салып, Карабәк аны читкә алып китте.

– Кунакларга йөрешер чагым түгел, бер урнашып алгач, махсус урамый калмам. Хәзергә син яңа илдәшләреӊ табынына булдыра алган кадәр ризык озат та, үз калаңнан артырдай балта осталарын, ташчылар бүл. Билгеле ки, яңа нигез кора башлаган инсаннарга хәтта тишек комган илә ярык тактасы да артык түгел. Килмешәк көенә моны сиңа сөйләп торасым юк, син – илтотмыш бәк, үзеңә боларның һәммәсе дә мәгълүм. Ә сиңа аннан тыш та аерым гозерем бар.

Айгыр тауның Идел өстендәге каш очына баскач һәм читтә гөрләшә башлаган яраннар төркеменә күз ташлагач кына, Карабәк, Янтыкның йөзенә текәлеп, уйчан төскә керде.

– Чит йортларга яки күрше ихатасына кереп тузан да күтәрмиләр, акыл да сатмыйлар, анысын гына беләм. Ләкин Болгар олысы минем өчен чит-ят туфрак та түгел. Гасыр ярым элек без бер күмәк йорт булып яшәгәнбез. Мин сезгә кунак булып килмәдем, мин Болгар йорт вә Казан йортлар өчен үләргә дип килдем.

Янтык рәхмәт белдергән шикелле башын түбән иде, Карабәк моны чамалап өлгерсә дә, барыбер туктамады.

– Мәгълүм ки, тукталып нигез корырдай урын табуга ук, мин кала бәкләренең һәммәсен дә җыеп алмый калмам. Әмма синең колагыңа аерым сүзем бар. Казан – Болгар олысының төннәр ягындагы иң олы, иң терәк кирмәне. Аның урыс кенәзлекләре янәшәсендәге иң соңгы кала булуы – бер хәтәр булса, иң яманы – ул Идел ярына терәлеп утырган кала, дәрья буендагы барча сәүдә юлын үз кулында тота. Моны бүген әле, мөгаен, урыс кенәзләре дә, Урда ханнары да бәяләп бетермидер. Иллә мәгәр шушы сәүдә юлы өчен иртәгә үк яман орыш кубасына һичбер шик юк. Менә шул мәсләктән Казан кирмәнен иң беренче нәүбәттә ныгытырга кирәк, аны Болгар-йортның төп калканы итү – мәҗбүри вә котылгысыз гамәл. Бу, әлбәттә инде, синең белән минем җилкәләргә ятасы олы бурыч. Моннан ары һәрбер яңа йорт, һәр карыш диварны шул мәсләктән күтәр.

Көн шактый гына эссе булса да, Айгыр тау өстендә Идел ягыннан күтәрелгән талгын җил уйнаклый. Исең китеп егылырдай гүзәл, камил төбәк. Җилән белән каешларыңны салып ташла идең дә ярты сәгать кенә булса да шушы шаян җилнең кытыклавыннан рәхәтләнеп, онытылып ят идең!

– Мин ишеттем, Туктамыш хан Мәскәү тарафына Ак-Хуҗа атлы бер әмирен куган. Аны озатып йөрү, ә чынлыкта ясак төяп кайту өчен җиде йөз җайдаклы чирү дә юллаган ди. Җиде йөз җайдак – ушкуй көймәсе түгел, алар сиңа сиздермичә үтмәс.

– Идел уртасындагы Сыерлар атавына посып, елга өстен вә яр буйларын өч йөз яугир саклый. Ак-Хуҗа сәфәре хакында безгә дә хәбәр килде. Алар Сура елгасын өске яклап үткән. Сарай нәүкәрләре урысларның Мөрем каласына ермак илә тарлавыклар аша сузыла торган яңа юл тапкан.

Яңагына кемдер чылтыраткан кебек, Карабәк ярсып кабынды.

– Менә күрәсеңме, теләгәндә дошман яңа юлны һәрчак табып тора, май кисәген телгән хәнҗәр төсле, ил эченә тавыш-тынсыз үтеп керми калмый. Син – урыс белән ике арадагы соңгы кирмән бәге, нәкъ менә син уяулыкны ун мәртәбә, йөз мәртәбә арттырырга тиеш! Әгәр ихатабыз аша үтеп йөргән Ак-Хуҗаны, аннан да яманы – карак илә дошманнарны да тоймый йокы симертеп ятсак, безнең урын дарда!

– Соң, Ак-Хуҗа безнең Казан яныннан үтмәде, дип такылдыйм лабаса!

Янтыкның тавыш күтәрүен колагына элеп тә карамады.

– Казан кирмәнен кичекмәстән көчәйтергә, поскын чирүләр санын ишәйтергә кирәк. Мин әйтте диярсең, Ак-Хуҗа урыслар ягыннан нинди дә булса җиңү яулап кайта алмаячак. Әгәр әле исән-имин кайтса. Шөлди кырын Мамай ташлап качкач, алар нык азынды. Уен-муен түгел, йөз илле елдан соң ирешкән тәүге җиңүләре. Мамай кул астына япа-ялгыз Кырым олысының кеп-кечкенә чирүе тупланган булуны да санга сукмый алар. Исереккә диңгез тубыктан бит. Ә алар бер котырса, ерак урамдагы дошманына буе җитми икән, күршесенең булса да тәрәз-ишекләрен җимермичә калмый. Көт тә тор, аларның иртәгә безнең олыска да кул сузуы мөмкин.

Янтык белән хушлаша башлагач, Карабәк янә тиз-тиз кабатлады:

– Ак-Хуҗаны куып кайтаралармы, исерешкән урыс кенәзләре, тол хатынга санап, безнең итәкләргә үреләме – һәммәсе хакында да ашыгыч хәбәр юлла. Син әзерләп торган ашлык-казылыклар мин ияртеп килгән халыкка, әлбәттә, бик кирәк, әмма аларны алмыйм, кулым күтәрелми. Без тары боткасы, чишмә суы белән булса да тамак ялгарбыз, аякны сузмабыз. Сиңа ризык-нигъмәт безгә караганда да ныграк кирәк. Балта осталарың илә мигъмарларны да минем эздән кузгатма, үз яныңда калдыр. Казанны күтәр син, аһ, Казанны күтәр!..

**9**

Нократ, Чулман елгаларын кичтеләр, Саба, Аккирмән, Кашан, Алабуга, Чаллы кирмәннәре тезелеп артта калды. Карабәк тирә-якта җәйрәп яткан каенлыклар, әрәмәлек, елга-күлләр белән сокланып туя алмый. Ходай Тәгаләнең шушы хәтле күңел биреп, юмартланып яраткан оҗмах бакчалары булса да булыр икән!

Аһ, гаҗәеп бу як! Идел буеның бер ягы – каен, имән, карагай, нарат, усак, чыршы, тирәк агачларыннан хасил карурман; икенче яр өсте биек таулар итәгенә җәелгән киң яланнар иде. Казан каласын тирәләп алган эреле-ваклы күлләрне, вак-вак инешләрне, Нократ буенда челтерәгән чишмәләрне санап кына бетермәле түгел. Чулман ярына якынайган саен, таулар сөзәкләнә, бу тарафта инде араннарын җимереп качу шатлыгыннан сикереп уйнаклаган тайларны хәтерләткән текә кыялар юк. Гаҗәп: биредәге тау сыртлары белән алар арасында яткан иңкүлек-яланнар диңгез дулкыннары сыман кабатланып килә. Унбиш-егерме чакрым буе ашъяулыктай кырлар сузыла да, берзаманны түбәсенә ияреңнән дә төшмичә күтәрелердәй таулар калкып чыга. Шуның түбәсен үттеңме, алда тагын бөрлегән-җиләкләр сибелгән тау итәге, аннан янә ким дигәндә унбиш чакрым сузылачак ялан. Инеш белән чишмә тирәләрен камырлык, шомырт, гөлҗимеш, чия, карагат куаклары сырып алган. Нократка килеп кушыла торган йөгерек инешләрдә йөзәрләгән сусар. Төпләренә күзләреңне чекерәйткәнче карап утырсаң да, мәңге ышанмаслык – үзләре терсәк буе, үзләре кабартылган турсык кебек симез шул җәнлекләр, колач җитмәс зирек белән усакларны егып, инеш аша күпер салганнар бит! Кешеләрдән дә курыкмый үзләре, син якынаерга егерме-утыз адым калганчы, арткы аякларына күтәрелеп, алгыларын түшләренә кушырып, күзәтеп тик тора. Аннан гына, «ә, вакытлыча хуҗа булуда икән синең исәп», дигән төсле, өннәренә чумып югалалар.

Күлләрендә кыр казлары, үрдәк, аккош, торна, челән. Урманнарда көртлек, поши, бурсык, кабан, байбак-суар, төлке, бүре, куян, хәтта аюлар да мыжгып тора, диләр. Кырымның да, Хәзәр диңгезенең дә табигате бик шәп, ләкин анда бу яктагы кош һәм җәнлекләрнең эзе дә юк бит инде. Биредә ничек сакланып кала алган моның ише оҗмах бакчалары?!.

Мәнзәл[33] дип йөртелгән егерме-утыз йортлы авылга җитүгә үк, Карабәк үз янына Яхшыбай белән Сарман атлы бәкләрен дәшеп алды.

– Туктамыш хан киңәш иткән төбәккә килеп җиттек. Үзегез дә шәйләп баргансыздыр, Чулманнан соң бу беренче торак. Әйләнеп кайткан ертауллар да раслый, Ак Иделгә терәлгән Түгәрәк тау өстендәге Имәнкалага җиткәнче өч йөз чакрым арада бүтән кирмәннәр юк. Безгә нигез кору өчен иң уңайлы урын. Сез бер төмәнне аерып алыгыз да шушы елга яры буйлап таралыгыз. Син, Яхшыбай, авыл нигезләрен ачыклауга, янә минем янга кайтып кушылырсың. Сине, Сарман бәк, соңыннанрак бер урамый калмам.

Ык елгасын үткәч, бүтәнчә түзә алмыйча, Карабәк үз янына барча төмәнбашны дәште.

– Ярмөхәммәт, Шәймөхәммәт, Кадыйрмөхәммәт, Исәймөхәммәт! Төмәннәрегез илә ерак бабаларымыз намен йөрткән алдагы Сөн елгасын кичеп чыгыгыз да Чәрмәсән илә ике арада чәчелеп урнашыгыз. Безнең сафта Актүбәдән бирле ияреп килгән кыргыз меңнәре бар, аларның да берсен сезнең кулга бирәм.

Өч абруйлы бәк тә ияк кагып күздән югалуга, Карабәкнең камчы очы бүтән төмәнбашлар шәүләсе өстеннән сикергәләп узды.

– Кормаш, Балтач, Уразай, Кизүкәй бәкләр! Гәрәй кабиләсенең төше сезнең кулыгызда. Сезгә сул якка борылып, Ак Идел ягына таралырга вә шул тарафта төпләнеп калырга әмер бирәм. Белеп торыгыз, тикшерүне, иң беренче итеп, сезнең йорттан, үз йортымнан башлыйм.

Карабәк моңаеп та калган, тынгысызлана да башлаган төмәнбашларына таба борылып басты.

– Аккүз, Уразмөхәммәт, Бүрәкәй, Гайсар! Әнә, юл күрсәтү өчен ертауллар көтә. Алар артыннан Сөн ярына тикле барыгыз да, аннары уң якка каерып, халыкны Ыкның дугасына кадәр җәелгән яланнарга таратып утыртыгыз.

Янында инде санаулы гына бәкләр торып калгач, Карабәк җилдә яргаланып беткән кулларын шулар арасында икесенең җилкәсенә салды.

– Исәнбай! Төмәнәй! Туктамышның киңәше дә фәрман. Шуңа карамастан, икегезне ул кушмаган төбәкләргә озатырга җөрьәт итәм. Исәнбай бәк, сиңа Ак Идел суларын кичеп чыгасы бар. Аның аръягындагы урманнарда арлар илә эрҗә ырулары гомер сөрә, диләр. Киекләрне кырып бетерәләр, безгә калмый дип, мөгаен, тәүге айларда сәнәк-сөңге күтәреп каршыларлар. Берүк алар белән бәрелешкә кермә, дошманлыктан саклан. Ә сиңа, Төмәнәй бәк, Сөн елгасы башланган чишмәгә чаклы атларга туры килер. Сөннең чишмәбашында да һичбер авыллар юк, ул якларда тоташы илә карурманнар икән. Тәүге айда ук, ул төштәге агачларны егып, Сөн буенча безнең якка саллар агызырсың...

Карабәк янында җигәне Көңгер белән унөч яшен тутырган өлкән улы Солтан торып калды да Болгар олысының сәеде булырга дип килгән Хөсәен хәзрәт Гомәр углы гына аптырап калды. Ярый әле ике-өч атнадан соң яннарына Яхшыбәй бәк авыз ерып кайтты.

– Сарман бәкне танымалы түгел. Мәнзәл буенда агачлар егуга ук, өстендәге көбә-күлмәкләрен салып ыргытты да, кулына балта алып, үзе бура бурарга тотынды. Кулына күз иярми, йомычкалар мамык кеби оча. Төмәнбаш булып йөргән кешедән мин һич кенә дә бу чаклы балта остасы чыгар дип уйламаган идем!

[33] Мәнзәл – ямчылар өчен билгеле бер ара саен Бату хан төзеткән элемтә ыстаннары. Минзәлә атамасы шуннан туган.

– Ә без ни көтеп утырабыз? – дип сикереп торды Карабәк. – Без Сарманнан кимме? Кая, балта китерегез миңа, балта китерегез! Мин дә үземә тиешле йортны үз кулларым белән бурап салам!

Карабәк балтасы астыннан йомычкалар чәчрәп оча башлагач, моны туктатып булмасына тәмам ышандылар.

**10**

Туктамыш хан юкка гына өметләнеп куган, Ак-Хуҗаның юлы уңмады шул. Урыс кавеменең якты йөз катмасы Рәзән чикләренә керүгә үк, бүселеп чыккан иде. Урда илчеләре дугаларына җиз кыңгырау тагып йөрүне гадәт иткән. Шуның чылтыравы ишетелә башладымы, бистә-салалардагы барча халык йә өй эченә, йә юлдан читкә кача. Элеккечә юл читенә тезләнеп каршы алу, бил бөгеп озату кебек гадәтләрнең хәзер эзе дә юк.

Рәзән кенәзе Олег Иван угылы гына Ак-Хуҗаны кара төлке тунының чабуларын үбеп каршылады. Туктамыш хан каршында тамчыдай гөнаһы булмаса да, илченең бер – алдына, биш артына төшә.

– Кенәзлектән тиеш барча ясакны да көз керүгә үк тамчысына тикле җыеп озаттык бит. Бөек ханыбыз каршында бер тиен дә бурычыбыз юктыр.

Ак-Хуҗа тегеннән кыеклап-хәйләләп Мәскәү хәл-әхвәлен, Шөлди кырыннан соң ясаган тантаналар турында сораштыра, Олег кенәз тәмам саңгырау шикелле җавап бирми, еландай боргалана.

– Мин Дмитрий Иванычның баҗасы да, кодасы да түгел. Аны белсә, миннән ары яткан Нижгардагы Константин гына белер инде. Эшләре пешмәсә дә, Нижгар кенәзе – Дмитрий Иванычның бабасы бит.

«Элек Мәскәү кенәзе моның өчен Митя, йә булмаса Митрәй генә иде, хәзер, кара, олы Иванычка әверелгән. Шул, Шөлди кырындагы җиңүнең кайтавазы инде бу, бүтән берни түгел», – дип үз эченнән генә сүгенде Ак-Хуҗа, күңелендә купкан ярсуын Олегка күрсәтмәде.

Дүрт көн, дүрт төн буе күңел ачканнан соң, Җүнкалага төбәп кузгалдылар. Дивар янына килеп туктасалар, капка ачучы, каршы алучы юк. Җиде йөз җайдак башлыгы калкан белән бәреп дөмбердәткәч, капкаларын эчке яктан тибеп кенә ачып җибәрделәр. Эчкә күз салсалар, әстәгъфирулла, тәмам баш бетмәле. Капка төбеннән башлап кенәз йортына чаклы юлның ике ягына да халык тезелеп баскан. Кайсының кулында – күсәк, кайсында – сасыган йомырка да кыяр. Арада билләренә кылыч-хәнҗәр таккан ирләр дә күренгәли. Саный калсаң, болар дүрт-биш мең тирәсе бардыр. Урда җайдакларын тыймый калсаң, боларның җиде йөз нәүкәрне ботарлап атуы бар.

– Нөгәрдәге барча җайдак дивар читендә калсын! – дип әмерләде Ак-Хуҗа чирү башлыгына. – Ә кала эченә синең белән мин генә керәбез. Әйдә, тагын унлап җайдакны ал.

Юк, алай да ошамады бу азган урысларга. Илче белән меңбаш халык дивары уртасына атлап керүгә үк, төрле яктан йә ачы итеп сызгыра, йә авыз тутырып сүгенә башладылар. Илче унлыгы дәшмәгәч, алар өстенә сасыган йомыркалар, бозык кыяр очты. Шулай да, баскыч төбенә чыгып, билен бөгеп каршы алды аларны Җүнкала кенәзе. Ак-Хуҗа халык алдында аның сакалына ябышмыйча көч-хәл белән түзде. Ә йорт эченә иңгәч, бәйдән ычкынган эт шикелле, аңа ябырылды.

– Син хан әмиренә каршы монда нинди этлек әзерләп ятасың, әйт дим, кенәз тәре! Әгәр шушы мәсхәрәне түкми-чәчми ханга кайтып әйтсәм, ул синең Нижгарың урынында көл таулары гына калдыра бит!

– Мин гаепле түгел, Ак-Хуҗа бәк, – дип, Константин тезләренә чүгеп, елый-елый, илче кулын үпте. – Мәскәү каласыннан килгән әллә нинди явызлар котырртты бит. Мәскәү хәзер Сарайга ясак түләми, ул Урдадан азат, безгә кушылыгыз, дигән коткы тараттылар. Хәзер мин, бичара, үз йортымда да үземне хуҗа итеп сизмим, кара сарык – холоплар да буйсынмыйлар миңа.

– Миңа Дмитрий янына үтеп, Мәскәү олысыннан ясак җыеп кайту бурычы җиткерелгән. Нишләргә соң инде миңа хәзер? – дип аптырап сораугa да Җүнкала кенәзе башын чайкый-чайкый гына киңәш бирде.

– Барма, Ак-Хуҗа бәк, аннан синең исән кайтуың да бик икеле. Анда Дмитрий үзен җитмеш ил яулаган Искәндәр Зөлкарнәйдән дә яман тота, аяк астындагы җирне күрми, кикрик күктә. Аннан күрмеш, бөтен Мәскәү азды, ярты ел буена һаман айнымыйлар. Барып күренденме, шайтан туена чумган холопларның сине чебеш урынына ботарлавы мөмкин...

Хуҗа кушса, бичара кол хәтта үзенең уч төбендә дә тәбә кыздырып китерергә мәҗбүр. Ходай Тәгаләдән үлем язган икән, котылырмын димә, ул бала-чагалар ярата торган качышлы уен түгел. Берничә көннән соң Ак-Хуҗага да, барыбер, итекләрен кияргә туры килде. Константинга соңгы гозерен җиткерүдән дә тыелып кала алмады.

– Ичмаса, син монда калган җиде йөз җайдакны казалардан сакла. Үзем белән ун гына атлыны алып юлга чыгам. Дарга асылу тәкъдире көтеп торган инсан сасы күл эченә чумдырсалар да, барыбер, тончыкмастыр...

Мәскәү эчендәге таш кирмәндә Ак-Хуҗаны әүвәл күз уңына да алып тормадылар.

– Нинди Сарай илчесе ул тагын? Туктамышны хан дип санамыйбыз. Хәзер безгә Дмитрий Иваныч үзе падишаһтыр!

Кайсы ишеккә барып сугылырга белми иза чигә иде, аңа түрәләр киемендәге бер ир саф татар телендә сүз катып туктатты.

– Әллә кенәз янына юл биклеме, илче?

Ак-Хуҗаның шүрәлегә юлыккандай акаюын шәйләп, үзен таныштырды.

– Кырымдагы Мәхмүт бәк Хөсәеннең оныгы мин. Тукай-Тимер нәселе, аеруча аның туруны Толык-Тимер талавына түзмичә, бабам илле еллар элек Рәзән олысына чыгып качкан. Ука ярында бер биләмә алу бәхетеннән бабам әтиемә дә шул елга исемен кушкан. Сәерме? Бик сәер. Мәгәр ул биләмәне Дмитрий кенәзнең шәхсән үзенә сатып җибәрдем дә аның мәрхәмәте белән, менә, сараена күчтем. Атымны да үзгәртергә туры килде инде. Чукынганнан соң мин хәзер Александр Укович Бахметьев булып чутланамын. Юрий атлы бер абыем Куликово кырындагы урманда кенәзебез Дмитрий Иванычны агач төбеннән табып алучыларның берсе булган. Шуның өчен Дмитрий Иваныч абыема Уканың икенче як ярында яңа биләмә бүләк итәргә өлгерде дә инде.

Ак-Хуҗаның һаман зәхмәт суккандай авызын да йоммыйча басып торуына каршы ярсый-ярсый санап китте бу карайөз.

– Син нәрсә, Бахметьевларны монда берьялгызы дип беләсеңме әллә? Татар Мәскәүдә умарта күчедәй күптән үрчеп ята. Әнә, ун-унбиш ел чамасы элек кенә Гарәпшаһ атлы бер ханыгыз Мукшы каласыннан Сәркиз бәкне себеркеләп куып җибәргән булган. Кая барсын? Ул монда килеп сыену тапты. Аның улы хәзер Андрей Саргизович атлы булып йөри. Сарайдан чыгып качкан Апраксиннар, Шереметьевлар бар. Мещера каласы янында биләмә тоткан Мещерский, Мещериновлар – санап бетергесез.

«Җыелышып, бергә кадалыгыз!» – дип эченнән генә сүгенеп алды илче, ә тышкы кыяфәте белән ялварудан тыелып кала алмады.

– Кенәз белән биләмәләр дә алышасыз икән, димәк, якын кеше. Җаен табып, хозурына иңдер. Туктамыш хан янына шушы килеш кенә әйләнеп кайтсам, үлем көтә ләса...

Ун көн чамасы көткәч, Александр Укович, асылда да, аны олуг кенәз янына иңдерде бит. Ак-Хуҗа әүвәл, хан илчесе дигән дәрәҗәне саклап, бик көрпәле генә сүз башлаган булды.

– Бөек ханымыз Туктамыш, хатларда язышкан вәгъдәңне үтәмичә, аны бөек хан булуы белән котларга килмәгәнең өчен бик нык рәнҗи. Аннары соңгы биш ел буена Сарай каласына бер тиен дә ясак илтмәгәнсең һәм олуг кенәз ярлыгын яңартырга килмәгәнсең икән. Бөек ханымыз Туктамыш, аның сүзен тыңлап, угры Мамай мирзаны урыс олысына үзбаш хәлдә тыкшынудан туктатканың өчен сине үз угылыдай якын күрә, әмма шуңа карамастан, ярлык сорап, үз каршына килүеңне таләп итә.

Дмитрий кенәз, үз-үзен белештермичә кәнәфиеннән сикереп, зал түренә төште һәм төкерекләрен чәчә-чәчә җикеренергә дә тотынды.

– Мин Сарайга ярлык сорап барасы кеше түгел! Мәскәү кенәзлеге Туктамышка ясак озатудан туктый! Моннан ары һичбер вакытта да Туктамышка угыл булып саналып йөрисем юк! Шушы сүзләремне ханыңа төкми-чәчми кайтарып тапшыр. Күз алдымнан югал!..

Теләсә-теләмәсә дә, Ак-Хуҗага кенәз алдында баш иеп чыгарга туры килде. Туктамыш еракта ул, кенәз күпме генә төкеренсә дә, зыяны аңа тими. Ә этәч төсле кукрайган кенәз сүзләрен кайтарып җиткерү өчен булса да, башны бик нык сакларга кирәк тә кирәк әле...

Ә Сарайга кайтса, билгеле ки, Туктамыш хан аны эттән алып эткә сала-сала пыр туздырды.

– Мин Мәскәүгә азау тешен чыгарган, чәч чаларткан әмиремне кудым, ә ул Сарайны тизәккә батырып, аны сатып кайтты. Ул җиде йөз җайдакны Җүнкалада калдырма, шул чирү белән булса да Мәскәүнең таш кирмәне өстенә ташлан идең. Бер татар яугире өч урыска тора. Таш кирмәнен вәйран китермәсәң дә, ким дигәндә ике мең урысны кырып салыр, Митрәй кенәзне Сарай тупсасына шуышып килергә мәҗбүр итәр идең. Комың коела башлагандыр инде, акламадың син минем өметне, ай-һай, акламадың. Дүрт ягың да кыйбла, күз алдымнан югал!

Ак-Хуҗа артыннан ишек ябылуга, Туктамыш сарайга бәйләрбәге Хәсән белән үзәк чирү башлыгы Карача мирзаны чакырттырды. Карачасы – аңа туган тиеш кеше, әле Сыгнак өчен яуларда да күп сыналган сәрдәр.

– Ниләр киңәш итәсез? – дигән сораудан соң, дәрәҗәсе буенча, Хәсән җавап тотты.

– Кичекмәстән сугыш, фәкать яу сәфәре! Сөзгәк үгез яки кәҗә тәкәсеннән генә түгел, хәтта чукый торган этәчтән дә суеп котылалар. Ә котырган эт хуҗасын талый башлый, менә моны Мәскәү кенәзенең үрнәге дә раслый. Бәйдән ычкынган этне имгә китереп булмый, фәкать яу белән барып кына Дмитрийны кабат оясына куып кертеп була.

– Бәйләрбәге борча күргән төсле каударлана, ә каударлык, асылда да, борча эләктергәндә йә кызлар түшен кармаган чагында гына отышлыдыр. Ханымызга үз халкымыз гына түгел, барча җиһандагы дошманнары карап, күзәтеп торуын да онытмаска кирәк. Чаптар атлар тәүге бәйгесендә бер

абынса, аннан алар чираттагы чабышларда да өркеп туктый йә читкә ыргылып кача торган була. Туктамыш ханымызның Сарай тәхетенә килеп утыруына икенче ел гына. Без Урданы тулысынча аякка бастырырга, үгез төсле көрәйтергә өлгермәдек әле. Яуларда сыналган төмәннәр бик санаулы гына. Без Мәскәүгә төбәп кузгалсак, арткы якны капларлык яңа чирү дә юк. Әнә тегендә киек күрсәттеләр дип, ау этләре шикелле йөгереп йөрсәң, тәхеттән колак кагуың да ерак йөрмәс. Менә шушы мәсләктән мин булган гаскәрне яуга күтәрмәскә, ә Мәскәү кенәзе янына яңа илче җибәреп карарга киңәш итәм.

– Кемне күз алдында тотып сөйләшәсең? – дип кистереп сорау бирде шундук Туктамыш хан.

– Рөстәм угылымны, үземнең уң кулымны! – дип шундый ук кискенлек белән җавап тотты мирза. – Егермесен тутырды бит инде, аңа да мәмләкәт язмышы өчен бәйгеләрдә сыналырга вакыт.

Берникадәр уйланып утырганнан соң гына Туктамыш кул изәде.

– Мин күзәтеп йөрим, бик акыллы җигән. Мәгәр кайнар. Кызып китеп, харап булмагае. Хәер, егет чакта кемнәр генә дуамал вә кайнар булмаган соң! Әйдә, җибәрегез!..

Ике айдан хәбәр кайтып төште:

«Митрәй кенәз Рөстәм бәкне имән бүкән өстенә ташлап, кисәкләргә чапкалап ботарлаткан!..»

Туктамыш хан елан чаккан сыман котырып әмер бирде.

– Өч төмәнне сәфәргә әзерләгез! Яу башлыгы булып үзем барам! Әмма Мәскәү ягына «Урда Тәбриз өстенә кузгала, азәриләр өч ел буе ясак түләмәде, Туктамыш гаскәрне шул сәбәпле җыя», дигән ялган таратыгыз. Аннары Болгар каласына чапкын озатыгыз. Нинди генә урыс сәүдәгәре килеп күренмәсен, Габдулла аларның берсен генә дә кире җибәрмәсен. Зинданга ыргытамы йә бөтенләй суеп ташлыймы – бер сүзем юк. Ә тауарларын талап алсыннар да халыкка өләшсеннәр. Аларга хәтта ертык капчыкның да бик-бик кирәк чагы...

## 11

Туктамыш хан Казан турысына килеп җиткән чакта аны Зөя елгасы ярында ук Карабәк һәм Болгар, Чаллы, Казан әмирләре бергә каршылады. Кәефе шәп түгел иде, шундук сизенделәр. Исәнләшеп дога кылуга ук, ул Карабәкне читкә дәшеп алды.

– Синең исән-имин килеп төпләнүең турында шундук җиткерделәр. Төмәннәрне җиде-сигез елга ярына таратып утыртуыңа бер сүз дә юк. Иллә мәгәр кулыңа балта тотып, бура бурап маташуың артык. Шамакайлык хәтта. Ирлек үзенекен итә, без һәммәбез дә үз кулларыбыз илә йорт тергезеп калдырырга тиешле инсаннарбыз, анысын гына аңлыйм. Тик синең бурычың шәхси йорт тергезү түгел, Болгар-йортны аякка бастырудыр. Егетләнеп, иләсләнеп йөрүеңне туктат, Болгар-йортка ябыш. Әнә, Сарай ханына каршы Мәскәү эте өрә. Аның өстенә гаскәр ияртеп барырга мәҗбүр булдым. Ә синең миңа кушып җибәрердәй сыңар төмәнең дә юк. Ярар, бу юлы синең күчеш чоры, нигез кору дип ташлама да ясап карадым ди. Мәгәр син бит зөфаф төне үткәрергә дип бикләнгән кияү егете түгел, гел-гел болай булмас, башка вакытларда читтән генә үтмәм. Моннан ары ерак сәфәрләргә яу атларың иярләнгән булсын...

Туктамыш Мәскәү өстенә Җүнкала аркылы барырга ният иткән икән. Каладагы кенәз Константинга Сарай чирүе хакында Туктамыш инде Иделне кичеп чыкканнан соң гына китереп җиткергәннәр. Өне алынудан калтырап төшкәндерме, Туктамышны каршыларга җиткән ике улын гына озаткан бу. Теге ике бүкән аның алдына килеп тез чүккәч, Туктамыш хан әүвәл аларның кем икәнен дә аңлый алмый торды. Икесе тиң, тезләнгән көенчә, авыз эчләрендә ботка пешергән шикелле, тиз-тиз быгырдыйлар.

– Атабыз авырыбрак тора. Инде илледә бит. Олыгайган кеше корый башлаган агач кебегрәк инде ул, аз гына җил истеме, шыгырдый ук башлый. Атабыз да түшәккә сузылу җаен гына карап тора. Атай безне юллады. Синең алда бил бөгәргә дип. Сиңа гомер буе хезмәт итәргә. Атай бик рәхмәтле. Мәрхәмәтең өчен һәрчак шәм кабыза. Без дә рәхмәтлебез. Аның ике улы. Василий да Семён. Синең һәр фәрманны без үтәргә әзер.

Ниһаять, Туктамыш та төшенеп алды бугай, ашыгып сорау ташлады:

– Артта сыртка пычак кадардай вә аумакай көч калдырып булмый. Рәзән өстенә иң кыска юлны күрсәтә аласызмы?

– Күрсәтәбез, бөек ханыбыз, хәзер үк ияртеп китәргә дә әзер...

Рәзән кенәзе Олег каяндыр ишетеп өлгергән, ул Урда гаскәрен кенәзлекнең чигенә үк килеп каршы алды. Йөзе көлдәй соры, күренеп тора, гаҗәеп нык шүрли. Туктамыш ханны кунак итү өчен олы чатыр корган, ә алдында тау-тау төлке, ас, чәшке, кеш тиреләре, көмеш савыт-саба, корыч кылыч-калкан...

Чатыр эченә тезеп утыртуга ук, Туктамыш хан урыс кенәзләрен усал элмәккә эләктерде дә куйды.

– Миңа урманнар эченнән бара торган иң яшерен юл кирәк. Анда киекләр дә сунарчылар гына йөри торган булсын. Сазлык ише җиргә кертеп батырасыз икән, һәркайсыгызны иң беренче очраган каен ботагына мендерәм дә асам!

– Мин, мин беләм андый яшерен сукмакларны! – дип, иң беренче, Җүнкаланың яшь кенәзе Семён чәчрәп чыкты.

Абзый тиешлесе дә әллә җәза алудан, әллә бүләксез калудан курыккандыр, ахры, ул да сикереп торды.

– Аппарабыз, аппарабыз, Дмитрий гына түгел, бүреләр дә сизмәс!..

Хактан да, Ука буен каплаган урманнарның иң яшерен ерымнары һәм сукмаклары аша алып китте болар. Кайчагында әрәмә-куаклар кырмавык йә тигәнәк шикелле җиңнәргә һәм җилән итәкләренә ябыша, ыргакка эләктергән төсле бер урында тота, ләкин җайдакларның да кулларында ятаганнар, айбалталар да бар бит, бер селтәнү белән үсемлек-еланнарны күз ачып йомганчы юкка чыгаралар.

Йөз чакрымга якын ара үтеп киткәч, Олег кенәз чәчрәп алга чыкты.

– Уканы кичеп чыгу өчен иң хәвефсез урын. Бу турыда елга киңәйгән шикелле, аның каравы, суның тирәнлеге атның корсагына да җитми. Хәтта олаулардагы шайманнар[34] белән ризыклар да суга тимәячәк.

– Башта үзең ыргыл! – дип җикерде Туктамыш, Олег кенәзнең каршы як ярга аяк басуын күрүгә, калганнарга карап әмер бирде. – Әйдә, минем арттан!..

Сай кичүдән соң кул сузымында гына Серпухов атлы кечкенәрәк кала ята икән.

– Минем кала түгел, кызганып та әйтмим, мәгәр анда туенырдай бер байлык та юк шул, – дип, Олег кенәз туктатырга җыенып маташса да, Туктамыш колак та салмыйча, алга кул изәде.

[34] Шайман – хәрби кием яки сугыш кораллары.

– Минем бүреләрне дә ярсытырга кирәк. Кан исен сизмәсә, бүре котырмый ул...

Ни галәмәт, шушы кеп-кечкенә кирмән аламасы да капкаларын ачмый интектерде. Ә җайдаклар, Туктамыш теләгәнчә, эттәй котырынды. Алдагы бер төмән тау түбәсеннән ычкынган ташкын шикелле өерелеп килде дә агач кирмән диварларын сытып кына узды. Урамга йөгерешеп чыккан ир-ат белән карт-корыны ятаганнар белән турадылар, өй һәм келәт эченә кереп качканнарын, арканнарга чылбыр-чылбыр бәйләп, Сарайга озаттылар...

Август ахырында Туктамыш үзенең төмәннәрен Мәскәү диварлары каршындагы ачык кыр өстенә таратып урнаштырды. «Без өч төмән яугир белән генә килдек, син күреп тор, һични яшермибез, мәгәр шушы көч белән дә синең Мәскәвеңне тетеп атачакбыз, капкаңны үз теләгең белән ач син», янәмәсе. Юкка гына янады Туктамыш хан, калада аны ишетердәй түрә калмаган да иде. Бу хакта шәһәр эченнән качып чыккан шымчы хәбәр итте.

– Синең Казан каласы янын узуың хакында Хазбулат атлы соран бер ай элек үк чапкын куган иде, ә Дмитрий кенәз бармакка-бармак та сугып карамады. Диварларны ныгытырга да, яңа дружина белән корал җыярга да вакыты билдән иде, юкса. Айнымыйча типтерде-типтерде дә, каланы Киприан атакайга ташлап, үзе чыгып качты. Кострома каласында гаскәр җыя, имеш. Хәтта, корсаклы хатынын да үзе белән алып китмәде бит, адәм тәганәсе! Илләэ мәгәр казнаны эләктерергә генә бер дә онытмаган! Шул куркак җан да Шөлди кырында Мамайны җиңүче булып чутлана бит әле! Җир дә йотмый үзен, валлаһидыр, хурлык!..

Калада кенәзләре дә, гаскәр дә булмагач, хан кадәрле хан өчен гомумһөҗүм башлау да зур түбәнлек иде, ике тәүлек буена ни кылырга белмичә, кузгалмыйча торды.

– Кычытканның зәһәрлеге кырау төшкәнче генә ди, менә ничек мыскыл итте бит Митрәй безне, – дип сүгенде Туктамыш, якында торганнар гына ишетерлек итеп. – Эт килгәндә кулда таш юк иде, таш табылгач – эт килми, дип көлә иде картлар. Шулар төсле мәзәк хәлгә калдык.

Ул арада киң ерым өстенә төшерелгән күтәрелмә капка аркылы шәһәр читенә япа-ялгыз олау чыгардылар. Ертауллар шундук аңлатма да бирде.

– Җебегән Митрәй калада ташлап киткән Киприан атакай белән кенәзбикә болар. Кенәзбикә куркуыннан баланы иртә тапкан, хәзер атасы янына, Җүнкалага ычкынмакчы икән.

– Кадалсын ла, икесе дә китсен, – дип кул селтәде Туктамыш, ә күңелен, әйтерсең лә, кырыкмаса-кырык елан талый иде...

Кичке якта каладан яңа хәбәр чыкты.

– Митрәйгә ияреп, каладан боярлар да чыгып качкан икән бит. Холопларга ирек ачылган. Боярларның идән астындагы шәраб мичкәләрен табып, урамга тәгәрәтеп чыгарганнар да бөтен Мәскәү халкы ду китереп хәмер чөмерә башлаган. Калада Литвадан сәүдә белән килгән Остей атлы яшь кенә бер кенәз аламасы адашып калган булган. Исерек холоплар шуны воевода итеп сайлап куйганнар ди, ә үзләре аның бер генә әмеренә дә буйсынмый, шәрабны чиләге-чиләге белән дуңгыз сыман чөмерәләр икән. Исереккә диңгез тубыктан бит, боларны хәзер коры кул белән яуласаң да була.

Туктамыш иллешәр яугирне, төркемнәр оештырып, кала диварларына якынаерга әмер бирде. Дивар өстендә туплар тезелешеп киткән, араларында хәтта арба тәгәрмәче чаклы ташлар ата торган түфәкләр дә күренгәли. Урда яугирләре диварлар астына килеп җитте инде, ә җавап итеп өстән сыңар

гына туп та аваз салмый. Исерекләр көтүенә ташланудан ханга нинди файда? Соңыннан, барыбер, Туктамышны исерек сарык көтүен яулап алды, дип мыскыл итәчәкләр...

Икенче таңда Җүнкала кенәзенең малайлары Василий белән Семённы капка каршысына юлладылар. Диварда биш-алты дистә чамасы ирләр күренгәли, болары айнырга өлгергән «әтәчләрдер» инде. Яшь кенәзләр шуларга сүз катты.

– Без – Дмитрий кенәзнең яраткан каенишләре. Ул безнең апабыз Ольгага өйләнде бит. Ягъни дә мәсәлән, без – Мәскәүгә туган тиешлеләр. Каланы бик җәллибез. Чөнки Туктамыш хан санап бетергесез гаскәр белән килде. Монда аның өч төмәне генә, калган төмәннәре Кострома янында куып җитеп, Дмитрий кенәзне тулаем тар-мар итте. Ул, бичара, Аккүл ягына чыгып качкан булган, мәгәр Туктамыш хан җайдаклары янә куа киткән. Ягъни дә мәсәлән, Дмитрийдан ярдәм көтмәгез сез, ул Мәскәүгә бернинди дә гаскәр алып кайтмый. Юкка кан коюның файдасы юк. Мәскәү үз теләге белән капкаларын ачса, Туктамыш хан бер генә холопның да җанын кыймаячак.

Дивардагы сәрхушләрнең аптыраудан баш кашуын күргәч, Василий белән Семён – икесе тиң муеннарындагы тәреләрне изүдән чыгарып, кызлар урынына, чуп-чуп китереп, үбә үк башладылар.

– Менә, Иисус Христос исеме белән ант итәбез, Туктамыш хан Мәскәү каласына бер зыян да салмый!..

Дивар өстендәге ирләр, җил сыпырып төшергәндәй, шундук юкка чыкты. Берникадәр ара шәһәр урамнарында ыгы-зыгы авазлары да яңгырап торды бугай. Урданыкылар да киң ерымнар эченә төшеп югалдылар.

Кичке алты тулып килгән чакта шәһәр капкаларын киң ерымнар өстенә төшерделәр. Олаулар белән ажгырып йөрерлек киң басмага тәре белән Иисус рәсемнәре тоткан поплар, шәһәрдән качу өчен сак дружиналары ялларга өлгермәгән бояр аламалары, маңгайларына кәккүш элгән чибәр-чибәр кызлар тезелешеп чыкты. Туктамыш хан кала каршына нибары өч мең җайдак кына алып килгән иде, хәзер инде алар арасыннан да нибары дүрт йөз нәүкәрне генә ияртеп, капка турысына төбәп китте. Аның сөттә коендырып чыгарылгандай ап-ак төстәге айгыры асылмалы күпер өстенә менеп баскач, мәскәүлеләрнең һәммәсе аһ итте.

Ханның өстендә зәңгәрсу төстәге чәшке тиресеннән тегелгән бик затлы тун. Баш түбәсенә елкылдап торган алтын очлым кигән. Аякларында алтын җепләр белән чиккән сафьян итек. Бармакларында әллә якут, әллә мәрҗән ташлар белән затлыланган зур йөзекләр. Ә ат йөгәнендәге барча аел-нукталар, ияр сиртмәләре белән өзәңгеләр, дирбиядәге бизәк, хан җиләнендәге җиң кайтармалары, каеш аеллары, ятаган сабы, кыны – барчасы да тоташы белән алтын. Айгырның сыртына ябылган хәтфә келәмдәге бизәкләргә чаклы алтын-көмеш җепләр белән чигелгән бит!

Бояр аламалары белән поплар шаккатудан авызларын да яба алмый тора иде, кулларына ипи-тозлар тотып, Остей кенәз беркадәр алга чыкты.

– Мәскәү сине җиңүче итеп каршылап тез чүгә һәм синең мәрхәмәтлелегеңә өметләнә, бөек Туктамыш хан!

Аны Мәскәү кенәзе, һич югы боярлары да түгел, ә нindидер килмешәк һәм япь-яшь воевода каршылавы Туктамышның битенә төкерү сыман яңгырады. Үз-үзен белештермичә, ул ятаганын суырып чыгарды да аның очы белән әүвәл Остейның бугазына төртеп алды.

– Ни пычагыма дип чит кенәзлек эшенә тыкшынып йөрисең син, сасы чүл бүресе? Нигә мәскәүлеләрне миңа каршы котыртып яттың монда?

Остейның сер бирмичә елмаеп торуы Туктамышның соңгы түземлек серкәсен дә сытты. Ятаганын өскә күтәрде дә килмешәк кенәзнең муенын күз ачып йомганчы кыеп төшерде ул. Аннан инде ярсуын тыя алмыйча, нәүкәрләре ягына борылып әмер бирде.

– Мәскәү эченә, алга! Каланың бер генә сараен да калдырмыйча кырып бетерегез! Каланы бер тәүлек буена таларга тулы ирек бирәм. Мәскәү урамнарына сыймаган төмәннәр бистәләргә чапсын. Дмитрийга буйсынган Можай, Звингурыд, Борау, Руза дигән калалар борын төбендә генә. Алардан тыш, имеш, әле аның үз исемендәге Дмитрий каласы, Юрий илә Вүлдәмир кенәзләрнең зур-зур кирмәннәре, кайтыр юлда җебегән кенәз төбәп качкан Коломна каласы бар. Берсен дә кызганып тормыйча, акыртып таласагыз да була. Чөнки үзен Искәндәр Зөлкарнәйн дип саташа башлаган куркак кенәзнең инде биш-алты ел буена Алтын Урдага ясак илткәне юк. Сез Дмитрий малын түгел, ә шул карак кысып-кымтып калган Урда нигъмәтләрен үзебезнең йортка алып китәсез. Ул карак кенәзне гомер бакый гафу кыласым юк! Моннан ары урыс кенәзләренең сыңары гына булса да минем каршыма ярлык өчен шуышып килмичә карасын!..

**12**

Карабәк Болгар каласында имән бүрәнәләрдән яңа дивар күтәртү белән мәшгуль иде. Туктамышның Мәскәүне тез чүктереп кайтуын ишеткәч тә, нык хәйранга калды. Ханның Сарай тәхетенә менүенә ике ел чамасы гына булып килә, ә ул, әнә, үзен Чыңгыз-сәрдәр, Бату-сәрдәр тиңе санап йөргән Дмитрий кенәздән дә бик тиз кан костырды. Каты куллы, усал тотынды бу. Моның һәрчак миһербанлы, мәрхәмәтле булып хакимлек кыласына өмет баглап яшәү – нык саташу. Эт симерсә, хәтта үз оясында үсеп җиткән көчекләрен дә артыксына, талый-тешли башлый. Ә Карабәк – көндәш. Туктамышның казна коргаксыды йә фәлән дошман миңа сугыш белән яный, дигән кырык сәбәп табып, иртәгә дә, аннан соң да бертуктамый Карабәкнең баш түбәсен чүкеп торуы да мөмкин. Их, үзбаш булып, беркемгә дә буйсынмыйча яшәрдәй дәүләт төзе идең! Әнә, башка чыгып, үз йортын һәм келәтләрен корып яшәгән гаиләгә бер күрше дә ник сыерыңны иртән-кич савасың йә нишләп әле бер каз оясы бәбкә үрчетәсең, дип кереп бәйләнми бит. Балаларыңа дога ятлатасыңмы син, әллә инде типкәләп йөртәсеңме – анысына да читләр тыкшынмыйлар. Бер күрше икенчесенә ясак түләүне, сугыш аты, яугир бирүләрне, бер-берсенең каралты-кураларын җимереп китүләрне, талауларны белми. Күршеләрнең бер-берсенә гозере төшә икән, сәнәк кирәк булса, оны бетеп китсә, кибән куйган йә йорт күтәргән чакта ярдәм кирәксенсә, ахыр чиктә инде килен төшерсә йә кызын кияүгә-фәлән бирсә... Ә дәүләтләр менә шушы кагыйдәне боза, кара гавамга түгел, ә казнага, ил табынына хуҗа булып алган таҗдарларга һаман байлык җитми. Һәммә сугыш, барча даулашулар – санаулы гына караклар аркасында.

Халкыңны иярт идең дә күз күрмәгән, колак ишетмәгән ерак җиргә китеп олак идең! Бер генә күрше дә сиңа низаг белдермәсен, һичбер дошман өстеңә яу йөрмәсен, сине ничек яшәргә икәнен өйрәтмәсен иде. Әмма Казан, Болгар, Чаллы, Алабуга, Кирмән, Җүкәтау, Кашан калаларын тутырган татарыңны, оясыннан куптарып, кайсы якка гына алып китәсе соң? Татар барып сыенырдай иясез дала-таулар калмаган бит инде җир йөзендә. Синең Болгар олысың төрле яктан киртәләп куелган һәм капкыннар корылган гомумурда, гомуми читлек эчендә. Болгар – чиксез мәмләкәтнең сыңар алачыгы, мал абзары, тегермәне,

остаханәсе, ахыр чиктә, бер имчәге генә. Мәркәз каракларының тәгамен тыгар өчен ит китер, сөтен-маен, тире-киндер, тырма-сабан, ат вә сыер, җариялектә әрәм булачак җиләк кебек кызлар, мәет булып сытылачак яу ирләре китер. Аһ, ничек кенә котыласы соң бу этләр тормышыннан?!.

Карабәк Казан каласын да, Җүкәтау, Чаллы, Кашаннарны да биш әйләнеп чыкты. Әй, беткән соң, җимерелгән, таланган бу җирләр! Болгар каласында элек сәед булып торган Низами карт сөйли:

– И-и, апаем! Кем иренми, кем җокламый, барысы да эт шикелле килеп талады инде. Җегерме ел элек әүвәл Наугырыттан җиде җөзләп кенә ушкуй төшкән иде. Безнекеләрнең Сарайга үзара ызгышып җаткан Хызыр илә Килдебәкнеңме, әллә Хызыр илә Тимерхуҗаныңмы кайсысындыр җаклап җауга киткән чагы. Теге ушкуй җулбасарлар каян гына моны белеп алганнардыр, шул җиде җөз кеше, гарасат сымак җимереп кереп, Болгар сарайларын нигезенә тикле талап җугалдылар. Безнекеләр җимерелгән җыртыкларны да җамап өлгермәде, җәренгә, икенче җылны әйтәм, көзге җәмсез җаңгыр төсле әйләнеп килделәр дә, җәнә барча келәт-лапасларны корыттылар теге җулбасарлар. Өченче җылны тагын. Җәмгысы җиде тапкыр килеп таладылар. Җимерелмәгән җорт, җыртылмаган койма калмады. Шуннан нишләп безнең Болгар мантысын ди инде? Безне җаклар өчен Сарай җагыннан сыңар гына да җаугир килмәде, Сарай безгә җыгылып җатканда да җәрдәм кулын суза белмәде бит. Шуңа без ни җыртыгыма дип һәм дә нинди җөз илә ул ханнарга хөтбә укыйк ди соң?!.

Низами картны тыңлау да ширбәт түгел, ә үзе әллә ничә кабат яуга кереп йөргән Җәүдәт атлы ирдә дә үч вә рәнҗеш һич бетмәгән әле.

– Чулман буйлап төшкән ушкуйлары бер хәл, алар таласа да, көймә белән каекларына сыймаган байлыкны барыбер дә ташлап китәләр бит. Алар яшь кызларны да көтү-көтү итеп коллыкка алып китми, монда гына әтәчтәй таптыйлар да, эсселәре басылгач, барыбер югалалар. Ә менә шулар эзеннән килеп җиткән кенәз алайлары каза да каза инде. Алары сыңар көбә белән калканны да, ат вә сарыкны да калдырмый. Өстәвенә, җария итеп тоту өчен меңәрләгән безнең чибәрләрне үзләренә алып китмичә калмый бит шулар. Каладан чыккан чакта ут ташлап калдырырга да онытмыйлар. Интек аннан ел буена яңа бура бурап, дивар корып. Аякка бастырдык бугай дип, тураеп, маңгай тиреңне сөртергә өлгермисең, икенче бер кенәз килеп җитә. Шуннан, менә, тернәкләнеп кара.

– Урысларны Болгарга кертми калган, куып җибәргән чакларыгыз да булды лабаса инде. Кырымда яшәсәк тә, без дә ишеттек бит, – дип Карабәкнең куз ташлавына, әлбәттә инде, Җәүдәт яугир кабынып китми калмый.

– Шулай шул, алты ел элек кыш башында урысларның берьюлы өч кенәзләре ияртеп килгән гаскәрен Болгарга да, Казан эченә дә якын җибәрмәдек. Юкса, Болгар каласы өстенә бик шәпләнеп ташланганнар иде. Уен-муен түгел, Чулман яклап, козгын өере сыман, берьюлы егерме мең ирләре диварга ябырылды. Өсләренә кайнап торган сумала, мичкә-мичкә сулар, арбасы белән таш коябыз, юк, күзләре тонган үгез шикелле һаман үрли болар. Янгын элгән бүрәнәләр тәгәрәтә башлагач кына беркадәр чигенделәр, мәгәр барыбер дә яуга ыргылу бит исәпләре. Шуннан Хәсән бәгебез туплардан ядрә очырырга әмер бирде инде...

Хәсән исемен ишетеп алуга ук, Карабәк капылт әсәренде, читтән күз ташласаң, бу мизгелдә ул үзе дә чукышырга әзерләнгән әтәч төсле иңбашларын кабарткан, сулыш алулары да кайнарланган иде, әмма моны яугир Җәүдәткә генә бик үк сиздермәде.

– ...Ун туп берьюлы ут бөркегәч, һәммәбезнең колаклары тонды, диварларга чаклы дер-дер килде. Урысларның да коты алынды шул. «Кыямәт, кыямәт! Шайтан, шайтан!» – дип үкерә-үкерә кирегә сикерделәр. Өнсез калган атлары, котырынып, җайдакларын җир өстенә койды. Ул гына җитмәгән, Хәсән бәк капкаларны ачты да дөяләргә атланган аерым бер алайны яу кырына ташлады. Акыра-акыра, ике өркәч арасына таккан бакыр табак-комганнары белән ду куптарып өсләренә килгән дөяләрне күргәч, ат-бичаракайлары тәмам шашты. Җайдакларын коеп төшерү генә түгел, аларның йөгәнен җибәрми йә авызлыкларыннан эләктерергә маташкан урысларны да таптап бетерделәр. Аннары барысы да, бүре өере куа килгән сыман, ачык дала ягына торып качты. Шуннан яу тукталды. Урыс кенәзләре безнең янә туплардан ут ачудан шүрләп тора. Ә чынында бездә уч төбенә кырып салырлык та дары калмаган шул. Иллә мәгәр Хәсән бәк моны сиздерми, ул безнең өчен отышлы солых төземәкче...

– Ә ни өчен солых? Хәсән бәккә анысы ник кирәккән? Сез инде тулы җиңүгә дә ирешә алырлык хәлдә булгансыз бит, – дип Карабәк ярсый-ярсый бүлдерсә дә, Җәүдәт бирешмәде.

– Урыслар ниндидер качак соран аша бездә дары юклыкны да, каладан тышка чыгып яуга ташланырдай чирү калмавын да белеп өлгергәннәр. Кенәзләр, этәчләнеп, ун мең тәңкә йолым сорый башлады. Безгә ярдәмгә Казаннан Мәхмүт солтан атлы әмир килгән иде. Ул дивар эчендә җыелган меңбашларга «йолым түләмибез, яуга керәбез, шәһид булсак та, Ходай Тәгалә каршына чиста намус белән китәбез», ди. Ә Хәсән бәк каршы. «Йолым өчен без соңыннан йөз мең тәңкә дә, ике йөз меңне дә табарбыз, ә ирләребез яуда кырылып бетсә, хатыннар ялгыз, ил баласыз калыр, Болгар үләр», – дип һич чигенми. Меңбашлар шаулаша, моны тыңламыйлар, һәркайсының лачын, бөркет булып таныласы килә. Ахыр чиктә шул Хәсән бәк урыс кенәзләренең һәркайсына берешәр мең тәңкә чыгарып бирергә үгетләде. Кенәзләрнең шундый сәдака күргәч тә өннәре тыгылды, ахрысы, күлнең төбен күккә аскан кебек, шундук борылдылар. Меңбашлар һаман тынмый, әмирлеккә Мәхмүт солтанны таләп итәләр, Хәсән бәкне җебегәнлектә, соранлыкта гаепли башладылар. Ә Хәсән бәк түзә алмады, бер атнадан соң җыенды да Казан каласына китте. Шулай итеп, без акыллы бәксез торып калдык ул чак...

– Имәндә икән чикләвек, – дип үзалдына сөйләнеп куйды Карабәк. – Ә мин аны икейөзлелектә, Болгар-йортны сатып, Туктамыш арбасына күчеп утыруда гаепләгән булам...

## 13

Кайвакытта ник туганыңа үкенүдән бәкегә чумардай хәлгә килсәң дә, бәхет атлы кояшның болыт ертыгыннан елмайган чаклары да булгалый икән ул.

Туктамыш Мәскәү өстенә яу белән барган чакта Карабәк барыбер дә аңа җигәне Көңгер кул астына баскан бер мең җайдакны кушып озаткан иде. Орыш-бәрелешләргә керергә насыйп булмагач, болгарлылар анда сынаулар үтәргә дә, үзләрен күрсәтергә дә өлгерә алмаган. Әмма, ни әкәмәт, буш кул белән генә кайтмаганнар. Көңгер энекәше Болгардагы кәрвансарайга йөздән артык япь-яшь кызны кертеп бастыргач, Карабәк әүвәл үз күзләренә үзе ышанмыйча торды. Боларның күбесенә унөч-ундүрт яшьтән артык түгел, ләкин берсеннән-берсе чибәр, һәркайсы да чия кебек пешеп җиткән инде.

Карабәк аеруча җитен төсле аксыл-саргылт чәчлесеннән күзен аера

алмый торды. Чибәрлекне бирсә дә биргән Ходай бу марҗага! Иртәнге кояш нурыннан керфекләрен ачкан чәчәк-гөлләр кебек керсез һәм гүзәл бит бу! Гаярь ирләрнекенә тиң озын, зифа гәүдә. Күк йөзедәй ачык-зәңгәр күзләр. Пешкән алма төсле алсу яңак. Коллыкка төшү бәхетсезлегеннән усал кысып басса да, хәтфәлеген һич тә яшереп булмаслык күпереп торган, йомшак, сусыл иреннәр. Ә алга чыгарып салган озын толымнары астыннан төртеп торучы ике дәү алманы соклanудан карап туймаслык шул. Алар ике йомарлам камырдан әвәләп куйган шикелле түм-түгәрәк, өстәвенә песи балалары кебек җанлылар да сыман. Әнә, кызый сулыш алган саен, түшенә салган толымнар да кар астыннан типкән чишмәләрдәй уянып сулкылдыйлар...

Түзде, тешен кысып түзә белде Карабәк, кичке караңгылык төшкәнче сылу кызның тәненә бармак та тидермәде. Ә мунчага кергәч, җиткән тай йә кыргый җәйрән белән сокланган шикелле, кызның гәүдәсеннән күзләрен аера алмады. Озын, нәфис ботлар. Ике учка сыеп бетәрдәй неп-нечкә бил. Аккош канатыдай йомшак куллар. Һәм, әлбәттә, һаман-һаман үзләренә тартып тора торган, сихерле һәм тылсымлы ике гүзәл күкрәк. Ә ул – ике шома бот тәхетендәге җәннәт пәрдәләре!

– Исемең ничек? – дип эндәште аңа Карабәк, кайнар һава белән кипшенеп беткән иреннәрен ялмап. Әмма дәртләнүдән тамак төбе дә кибеп беткән икән, сылу кызкай аны аңламады. Карабәк, тамак төбен кыра-кыра, ләкин мөмкин кадәр ягымлырак булырга тырышып, янә дәште:

– Атың нинди, җаным?

Сылукай Карабәкнең саф рус телендә сүз кушуына гаҗәпләнде бугай, күл суыдай зәңгәр күзләре җил исеп уяткан чәчәк таҗыдай ачылып төбәлде.

– Анфиса мин, Анфиса атлы булам.

– Матур исем, сиңа бик килешә, үзең дә бик чибәр, – дип, Карабәк теленә беренче килгән сүзләрне тезгән булды, үзе яшь кызыйның аккошныкыдай ап-ак муеныннан, шуның аша очлы, тыгыз имчәкләр өстенә таралышкан аксыл чәчләреннән күзен аера алмады.

– Аһ, чәчләрең бигрәкләр дә хәтфә, бигрәк матур! – дип пышылдый-пышылдый, Карабәк аның чәчләрен сыйпады, әүвәл шуларга, аннары ап-ак иңбашына иреннәрен тидереп алды.

Кыз олыс хуҗасының инде талый, көчле башлавын көтә иде сыман, кул очлары, чияле имчәкләре дер-дер килеп алды. Ә Карабәк бер генә тамчы да кыргыйлык һәм әрсезлек күрсәтмәде, үзен тыя белде.

– Чәчләрең, валлаһидыр, алтын кебек синең, алтын чәчләр... Тукта, ә нигә сиңа Алтынчәч дигән исем кушмаска соң?

Кыз, ниндидер хәвефтән саклангандай, ике кулын да күкрәк турысына кысып баскач, Карабәк элеккечә үк йомшак, назлы тавыш белән аңлаткандай итте.

– Соң, җаныем, син барыбер монда каласың бит. Сине хәзер кайсы яугир генә кире үз илеңә кайтарып җибәрсен соң? Сездәге кенәзләр дә бер генә тотакны да кире кайтармый, җария итеп тота, ә аннары, инде чукындыргач, хатыннары итеп алалар бит. Сине дә әллә кемнәр түгел, ә үз туганнарың шундый ук язмышка ташлады. Алар урынына безне сүгәргәме?

– Әйе шул, атаем да, агаларым да яклап кала алмады. Үзләре урманнарга кереп качты, ә безне урам уртасында зәгыйфь бәбкәләр сыман ташлап калдырдылар. Әйләнеп кайтулар язмас, язмас инде.

Кызның күзләреннән ике тамчы яшь сытылып чыгуын шәйләп, Карабәк кул очлары белән генә аның ияген күтәрде дә юешләнгән яңакларын үпте.

– Кайгырма, җаныкаем, сине монда да рәнҗетүче булмас. Бигрәк чибәр бит син, бик кадерле, түрдә генә утыра торган хатын булачаксың.

Кыз сагаеп калды, янә аккош канатыдай ике кулын күкрәгенә кысты.

– Мине җарияң итеп тотарга исәбең юк, берәр хезмәтчеңә кияүгә бирергә җыенасыңмы әллә?

– Юк, – дип кайнар пышылдап, аның керәчтәй ак иңбашларын үбеп алды Карабәк. – Мин сине үземә хатын итеп алам.

Әмирнең иреннәре, акрын гына шуа-шуа, имчәк очларына, ике кызгылт чияләргә күчте. Кызыйда да дәрт кузгалды, ахры, Карабәкнең башы аның ике канаттай кулларына, алтын-җитен чәчләренә күмелеп юкка чыкты.

## 14

Ай артыннан айлар киек казлар кебек үтә торды, ә Карабәк Болгар каласы белән, барыбер дә, сокланып туя алмый йөрде. Ушкуйлар һәм кенәзләр никадәрле генә килеп җимермәсен, аның тамырын да, үзәген дә корыта алмаганнар. Әнә, шәһәр уртасында Ходай Тәгалә тарафыннан кадап куелган ике калкан, ике маяк төсле, Зур һәм Кече манаралар калага дан һәм шөһрәт өстәп утыра. Алар шулчаклы да төз һәм мәһабәт ки, гүя күк йөзенә очып китәргә җыенган аксыл-соры ике каләм сыман. Шәрык ягына келәмдәй сузылган хәтфә ялан буйлап Ак пулат, Кара пулат, Кәрвансарай, Ак мунча, Казый һәм Хөкем сарайлары тезелешеп киткән. Карабәк, беренче эше итеп, Зур һәм Кече манаралар янәшәсендә Ак мәчет күтәрде, гөмбәзләре өстенә көмеш йөгерттерде. Мәчет хозурында даны борынгы чорлардан ук килгән зур мәдрәсә булган, аның бинасын ак ташлардан кабат тергезделәр. Инде хаким йорты, әмир йорты турында да уйларга вакыт иде. Карабәк үзе дәшми йөрсә дә, башкалар аның аяк табаннарына ут үрләтте.

– Әмир сарае, таш кирмәннән гайре яшәп буламыни? Һәр каланың йөзек кашы – әмир йорты лабаса!

Ниһаять, кала уртасында Чулман ярындагы ак ташлардан яңа, калын диварлы кирмән төзү эшләре канат җәйгәч, Карабәк Сөн белән Ык арасында калган гәрәйлеләр янына барырга ниятләде.

– Сез монда кирмәнне миннән башка да төзеп бетерәсез инде, ә минем үз туганнарымны ничә айлар буе күргәнем юк. Алып килде дә ачык кыр уртасында ташлап калдырды бу, дип сүгеп ятмасыннар...

Ык ярларына якынлашкан саен, Карабәкнең күңелендә соклану һәм горурлану хисләре көчәя генә барды. Үзе сәер, үзе матур бу Ык. Урыны-урыны белән ике яктан табигать терсәкләре белән төртеп уяткан төсле тарая да тау елгасы кебек күбекләнеп, котырып ага ул. Аннары бу коллык аранын ерып чыгуына сөенгән шикелле берәр үзәнлек табып тынычлана, йөгереп йөреп арган сабый баладай йокымсырый сыман. Елганың менә шулай җәелгән төшләрендә яр буйларын баскан камышлыклар бар, ә алар арасында җәен, шамбы, чуртан, кызылканат, алабуга, табан балыкларының иренеп кенә йөзеп йөрүенә һичбер шик юк. Ыкның колга шикелле йә җәядән ычкынган ук шикелле туп-туры булып аккан урынын эзләп табу кыен. Ык, кышкы юлда салулаган чана сыман, әле бер, әле икенче якка боргаланып килә дә, кайчакларда, арттан куа килүче кансыз сунарчылардан койрык чәнчеп качкан төлке төсле, капылт читкә ыргыла, ә урыны-урыны белән хәтта эздән җуйдырырга тырышкан шикелле, бөтенләй кире якка борылып та ага. Кем белә, шул урындагы сихри

дөньядан аерыласы килмәгәнгә шулай кабат кайта-кайта хозурланадыр ул. Ике як ярдагы шау чәчәккә чумган шомыртларны, алар артыннан сузылган әрәмәлекләрдәге камырлык, гөлҗимеш, чия куакларын ташлап китүләре ансатмыни?!

Ык турында риваять тә яши. Имеш, Таш Билбауга хуҗа булып утырган бер албасты аны сылу кызлар урынына гел мәгарәдә генә бикләп тоткан, матурлыгы белән фәкать үзе генә сокланган, ди. Болыннар өстендә колыннар, җәйрәннәр шикелле сикергәләп-тилереп уйнарга тилмергәч, албасты гырлап йоклаган бер төндә чыгып качкан икән бу матур кыз. Аны куып тотмакчы булып, Билбаудагы албасты аның артыннан улын җибәргән, ди. Елга яры буйлап сибелгән күлкәйләр әнә шул албасты малаеның куа барганда салган, йә күсәген тидереп алган кайнар эзләр ди бит. Куып тота алмаган аны яшь албасты. Ык-сылукай Чулман елгасына чумып югалган, ди.

Асылда да, елга яры буйлап сибелгән эреле-ваклы күлләрне яшь кияү кыз алырга килгәч чәчеп җибәргән көмеш тәңкәләргә дә охшаталар бит бу якларда. Көзгедәй су өсләрендә – төнбоек, ярларында – камыш, ә ул камышлар арасында, һичбер шиксез, кондыз, көзән, сусар. Күлләр чәчелгән үзәнлекләрдә түбәтәй-түбәтәй булып утырган күкчәчәк, тукранбаш, зәңгәр чәчәк, кыңгырау утраулары, яр буйларында бәбкә үләне, бака яфрагы, аксыргак, сарут, кылган... Иң мөһиме – бу якларда төмән-төмән атлар изеп киткән ялан-үзәнлек юк, ошбу тарафның кылыч орышларын да, уклар болытын да күргәне юк сыман. Кыргый, садә, керсез табигать. Мондагы алкалы каеннар, ак чәчәккә күмелгән юкә агачлары – үбелмәгән кызлар, кочылмаган яшь кәләшләр сыман. Аһ, гүзәл соң, әй, тылсымлы, оҗмахтай бу яклар!..

Карабәк үзе белән бер йөз җайдак кына алып чыккан, ә сәфәре хакында һичбер кемне кисәтмәгән иде. Ык ярында үзен Кормаш, Балтач, Уразай бәкләр иярләреннән төшеп каршы алгач, гаҗәпләнүдән баш чайкарга гына мәҗбүр булды.

– Миңа хәзер ауга чыгу да өметсез, сез анысын да белеп, киекләрне миннән алда урачаксыз икән, – дигән шаяртуына каршы көлеп кенә җавап кайтардылар.

– Кунакка кисәтмичә килеп төшкән кода-кодагыйлар бик тиз бозылыша, дигән сүзне ишеткәнең юкмы әллә, Карабәк әмиребез? Алар килгәч кенә чәкчәк ясый йә токмач баса башлаган кодагыйны ялкауга чыгаралар, ә хатыннар аркасында аннары кодалар да бер-берсенә сыртын куешалар.

– Ау димәктән, түрәләрнең авы да кешенеке төсле булмый икән лә ул, – дип, Карабәк чаптарының йөгәнен эләктергән Балтач авыз ачты. – Олы түрә кисәтеп килә торган булса, вак түрәләр киекләрне бауга бәйләп йә элмәккә үк утыртып чыга икән. Шуннан олы хаким үзен мәргән дип шапыра да инде. Нәкъ төртмә әйтемдәгечә. «Карт алаша үз койрыгын күргәч, мин колын дип, и-и, масая икән».

– Оһо, мине карт алашага да чыгара башлады бу Балтач, – дип, Карабәк бер үпкәсез рәхәтләнеп көлде. – Алай алаша икән, хатыннарың белән бер мунчага җибәр.

Айгырлар шикелле кешнәп көлешкәннән соң, төтен сызып утырган казаннар һәм ашъяулыклар янына барып тезләнделәр. Хатыннар уртага зур-зур җамаяклар белән ит калҗалары, карта-эчәгеләр китереп тезгән арада Карабәк тирә-якка күз йөгертеп алды. Бик күп ябалдашлы, матур гына тирәк ышыгы бу. Яр астында гына Ык челтери. Кул сузымында бер күл. Әйләнәсе ике чакрымга сузылган тип-тигез үзәнлек, аны ике ягыннан иң мәгъруր

наратлардан да биегрәк тау уратып алган. Бер уйласаң, бу иңкүлек үзе – олы таба, ә җайдаклар һәм бәкләр шуның бер читендә утыралар сыман. Авыл кору өчен менә дигән урын.

– Бу төбәккә килеп төпләнгәнгә биш ел үтеп китте. Инде ничә авыл калкып чыкты икән? – дип сорады ул, аерым гына беркемнең дә йөзенә текәлмичә.

– Һи, кем санаган аны! – дигән җаваптан шундук чамалады. Әһә, Кормаш телгә килде, күрәсең, калган ике бәк алдында абруе төплерәктер.

– Үзебезнең түбәдә генә дә җиде авыл булдык, – дип һаман да шул Кормаш дәвам итте. – Шуларын әйләнеп чыгарга да вакыт җитми әле. Былтыр гына, менә, көз ахырында, кар тирән ятканчы дип, Сөн буйларын айкап кайтканыем. Күршеләр ни кыйлана икән, алардан артта калып адәм хуры булып йөрергә язмасын дип.

– Ни җитмәсә, артта калган, тар маңгайлы булып саналасыз? – дигән Карабәкнең соравыннан да мәлҗерәп төшмәде ул.

– Һе, ни дип, авылда шул инде. Мәчетең юк, тегермәнең аякка басмаган, аннан килеп, арба-чана ясый торган осталарыңа, тимерчеләреңә алачык юк икән – син үзеңне Аллаһның кашка тәкәсенә санап, күкрәк киереп йөрмә инде, туган.

– Менә сиңа иске авыздан яңа сүз, – дип, Карабәк баш чайкады. – Ә мин әле авылларга тимерче дә кирәклеген күз чалымына да китереп карамадым.

– И, апаем, тимерче дә, аннан килеп, ияр тегә, камыт вә ыңгырчак ясый белә торган осталары да күче-күче белән кирәк инде. Атларның урманнан агач ташымый, кибән тарттырмый торган чагы юк та бит ул, бичаракайларның. Өстәвенә, ара ерак дими, унар-унбишәр чакрымга кунакка йөрешәбез. Анда да, Аллаһның кашка тәкәсе сымак, гел атларда инде. Менә шуңа күрә дирбия-камыт ясаучыларыннан тыш, каз каклый, чәкчәк-гөбәдияләрен телеңне йотардай итеп пешерә, килешле итеп күлмәк тегә белә торган алтын куллы хатыннарыбыз да, ай-яй, бик кадерле безгә!

– Ә шулай да, Сөн ярында ничәләп чамасы авыл санап кайттың? – дип Карабәк янә иске эзгә кайтты.

– Сикиядан Сөнгә төшә-төшә, уннан артык авыл санадым бугай инде. Беренче чиратта, мәчетләре, базарлары булган олырак авылларга исләр китте. Яхшый, Үрәзмәт, Әмәкәй, Күбәк, Гайсар, Аккүз, Исәммәт, Яркәй, тагын... э-э-э, Шәммәт, Кадермәт, Аеш, Кыргыз, Ябалак... Менә шушыларын башыннан ахырына чаклы урап чыктым, мәчет төзеп өлгермәгәннәренә кереп вакланмадым.

– Нинди Яхшый, каян килеп төшкән Исәммәт, Кадермәт ул? – дип күкерттәй кабынды Карабәк. – Исемнәрен һич кенә дә аңлап бетермәдем.

– Һе, безнең татар менә шулай кисек телле инде, мин нишләтим? – дип Кормаш иңбашларын сикертте. – Яхшый дигәнен Яхшыбай бәк кора башлады да аннары үзе Сарман бәк янына китеп барды. Тегесе моңа кызын биргән дә Зәңгәр тау итәгенә сарай салган икән. Ул югалып бер кыш үтүгә үк, авыл исеменең койрыгын кыскарттылар. Аннары шундый ук очкылык чиреннән Әлмөхәммәт урынына Әмәкәй, Кадыйрмөхәммәт урынына Кадермәт торып калды. Тегеләрдән күрмеш, Уразмөхәммәт, Ярмөхәммәт белән Шәймөхәммәтне дә тач шул рәвешчә сөннәткә утырттылар.

– И-и, болай барса, без үзебезнең әткәйләрнең исемнәрен дә онытачакбыз икән! Әйтергә шулай ансат дип, иртәгә сабыйларны Мөхәммәт урынына Мәмәт, Габдулла урынына Апуш, тагын да яманрагы, урыслардан күрмеш, Нәчтүк, Ләксәй, Ибан дип йөртә башлаулардан Ходай саклый күрсен!

– Әстәгъфирулла! – дип һәммәсе төкеренде, Карабәккә каршы төшмәделәр...

Кормаш, Балтач авылларын карап чыкканнан соң, Уразай бәк Ак Идел ягына таба алып китте. Сүзсез дә аңлашыла, бер җилләндереп кайтуда гына түгел моның исәп. Әллә чит-ят колаклардан яшереп чишәсе сере бар, әллә нинди дә булса сабак бирергә җыена микән картлач?..

Бер-ике фәрсәх чамасы ара узгач, алда искиткеч табигать хозурлыгы күреп, әмир хәйран калды. Көнчыгыш тарафтан сихри тасма төсле ике олы елга боргаланып, уйнап килгәннәр дә, калкан булып баскан мәһабәт тауны ярып, бергә кушылганнар. Бер карасаң, алар берсен-берсе табышып кавышкан япь-яшь парлар кебек, бер карасаң, дошман кулыннан качып котылган җиткән кызый чал чәчле әнкәсенең кочагына атылып чумган сыман. Хәер, ике елга да искиткеч гайрәтле һәм җитез, аларны әбәкле уйнап куышкан шук малайлар белән чагыштырсаң да артык түгел бугай. Ике елга да, йөзәрләгән чишмә һәм инеш суларын җыя-җыя, гасырлар буена челтерәгән, мең чакрым юл узгандыр, аларны чал сакаллы картлар итеп күз алдына китереп карау да, бәлки, урынлыдыр. Ләкин юк, бигрәк гаярь, үтә мәһабәтләр, аларга картлар төсе мәңге кермәстер, шәт.

– Чулман белән Ак Идел кушылган урын менә шушы инде, – дип, янда талгын тавыш белән Уразай телгә килде. – Җәннәт кайда, дип эзләп йөрисе юк, Ходай Тәгалә аның бер кисәген шушы җиргә бүләк иткән бугай.

Карабәк елгалар ярына күз йөгертеп чыкты. Ак Иделнең бер як ярын ак чәчәккә күмелгән шомырт куаклары каплап киткән. Арада сарырак йә шәмәхә төстәрәк чәчәкле куаклар да очрый. Бу яктагы халык «камырлык» дип йөрткән куаклармы, «эт шомырты» дигәннәре шулай нык үзгәме? Алай дисәң, бу якларда гөлҗимеш агачлары хәйран үсә, диләр.

– Бу ике елга турында сәер бер бәян бар. Әле бәләкәй чагымда ук карт агайлар авызыннан ишетеп үскән идем, инде үзем дә кәкре таякны юлдаш итә башладым, ә шул бәянның серен чишкәнем юк.

Уразай бәк ике елга кушылган төштәге биек тау өркәчләренә текәлеп баскан, карашында уйчанлык, ул моңсулык теленә дә күчә бара сыман.

– Чулман елгасы да, Ак Идел дә Таш Билбауда чишмә ярган, диләр. Ул олуг тау инде мең-мең еллар элек үк бар җиһанның умыртка баганасын хасил иткән, аңа ул заманда бер дәү дию хуҗа булган, имеш. Чулман – тауның гареб кыйсемендә, Ак Иделкәй гареб тарафында түгәрәк күл хасил итеп яткан. Әүвәл бүре, төлке, куян, бурсык, болан, поши, җәйрән, суар – һәммә җәнлек шушы күлләр тирәсендә истирәхәт кичкән. Мәгәр берзаманны Таш Билбауга җирән җонлы аю үз балалары белән адашып килеп кергән дә, гоҗлык өянәге кузгалган саен, ул бурсык, куян, поши балаларын буа башлаган, ди. Моңа үзенең бер дистәләп баласы белән ана бүре чәчрәп каршы чыккан. Җирән аю кайсы тарафка гына ауга кузгалмасын, бүре балалары моның артыннан калмый, хәвеф тудымы, башка җәнлекләрне кисәтәләр икән. Берсен-берсе саклап тора-тора, кайвакытта җирән аю бүре балаларын буып ташлый, моңа җавап итеп, ана бүре дә аю балаларының бугазларын чәйнәп өзә икән. Таш Билбауда шулай тәмуг туган, аю белән бүре балалары олуг тау өркәчләренә дә сыймый башлаганнар. Аюда нәфес котсыз, Чулман суын тик үзенеке генә итмәкче булып, күлнең бер як ярын ишеп җибәргән бу. Ireккә чыккан Чулман Таш Билбаудан аска томырылган да, үзенә өркәчләр арасыннан юл яра-яра, гөрелдәтеп ага башлаган, ди. Үзенең олы күлдән мәхрүм калуын күргәч, дәү карт дию бүре көтүенә фәрман биргән.

– Ак Идел күленең читен ерып торам, шуның дулкыннары өстенә көймәсал тезегез дә бичара Чулманны куа чыгыгыз сез. Мин зур бер ялан уртасына балчыктан тау өеп, киртә корып торырмын. Сез тиз арада төшеп җитегез дә, Чулман суын борып, Таш Билбауга кире кайтарырбыз. Тик карагыз аны, юлда сезнең берегез дә аерылып китәргә тиеш түгел. Фәкать бергә булсагыз гына, сез карак аюны да, Чулманны да җиңә алачаксыз...

Карабәк сиздермичә генә күз уңын Уразай бәккә таба төбәп ала. Карашын ике елга тарафыннан гел алмыйча сөйли, йөзе җитди, иреннәренә тикле усал кысып куйган. Ул үзе ишетеп үскән бәянга сабый чагында ук ышанган һәм шул хисне кунак әмир күңеленә дә түкми-чәчми күчерәсе килә.

– Менә шушы биек, тоташ тауны Таш Билбаудан төшкән дию өеп куйган. Тизрәк куып җитик, дип ашыга торгач, бүре гаиләсе утырган сал менә шуның бер сыртына бәрелеп чәлпәрәмә килгән. Ана бүре үзе, Чулманны бору өчен юл ярыйм дип, тау итәген икегә телергә тотынган. Ә бүренең ике җиткән улы ике як ярга йөзеп чыкканнар, ди. Шулвакытны биек тау өстеннән күк күкрәгәндәй тавыш ишетелгән:

– Мин сезне бер-берегездән һич тә аерылмагыз, аерыласыз икән, бер-бер артлы барыбер бетәчәксез, дип каты кисәттем бит. Нигә минем гозеремне аяк астына салып таптадыгыз? Аерым көе михнәт чигеп яшәү юлын сайлагансыз икән, интегегез инде...

Шул мизгелдә үк диярлек дию юкка чыккан. Ә бүренең ике улы Ак Идел сулары аша ике ярда ята. Берсен – татар, икенчесен инде башкорт, диләр...

– Үзе кызганыч, үзе яралы булды синең бу бәяның, – дип, Карабәк тик бераздан гына җавап бирде. Ул һаман карашын Ак Иделне буып утырган ике тау өркәченнән аера алмый, йөзе-кыяфәте таш балбалдай иде.

Уразай бәк Ак Идел ярына сыенып утырган йортлар тарафына бармак төртте.

– Өшәр[35] авылы бу. Шул яралы бәян сакчылары. Ә без үз ихатабызга кайтыйк, син күрмәгәндә калыккан яңа авылларга бер күз салыйк әле.

Ак Идел яры буйлап кирегә юырттылар. Карабәк әле һаман гыйбрәтле бәян уйларыннан арына алмый бара, Уразай бәй, яучы карт шикелле, һаман саен алда.

Дистәләп күл ялтыраган үзәнлектә йә иңкүлек, йә тау итәкләренә сузылып яткан дүрт авылга, артыгын түзә алмыйча, камчы очы белән төртеп күрсәтте ул.

– Менә, соклан инде, Карабәк, күз уңыннан кичер. Югары Гәрәй – берсе, калганнары – Түбән, Урта, Кече Гәрәй. Сөннең аръягында тагын бер Гәрәй бар. Барысы да үзебезнең кабилә исемендә. Аксакаллары Мөхәммәт, Гайнан, Әбелшәех атлы булса да, үзләре баш тартты. Юк, безне бутамасыннар, без – Кырымнан ук канны монда алып килгән гәрәйлеләр, диләр. Ун-егерме авыл бер үк атлы булмасын дип кенә, кайберләренә Бурсык, Кабан, Әтәч, Куян дигән кушаматлар таптык, бер төрләрен үзебезчә гап-гади – Такталачык, Каентүбә, Чалманарат дип кенә атап чыктык инде...

Юл уңаендагы беренчесе – Түбән Гәрәй, урамнарына барып керүгә үк, Карабәкнең күзләрендә якты ут кабынды. Матур, төзек, килешле бит, шайтан, күз тимәсен! Урамнарның киңлеген йөзәр адым чамасы корып куйган болар. Димәк, янгын дигән хәвеф туа калса, очкын йорттан-йортка әтәч сыман гына сикерә алмаячак. Капкалары – такта, коймалары – читән. Йортлары йә нарат, йә усактан. Ихата түрендә мунча, келәт, лапас тезелешеп киткән. Байтак

[35] Өшәр – баскыннар килгәч, ул Семиостров атамасы белән йөрде, хәзер бөтенләй юкка чыкты инде.

гомерләрен сәфәрдә йөрсәләр дә, алдан күрүчән, бик нык әзерлекле бит ул гәрәйлеләр. Келәт идәне астында, һичбер шиксез, кар базлары да бардыр.

Урамнарында бер җан иясе дә күренмәгәнгә генә, як-ягына, хәтта ихаталарга да күз йөгертеп барырга мәҗбүр булды. Әй, юк, җансыз түгел, бер капкадан җиткән буйлы ялгыз кыз чыкты бит, әнә. Иңнәрендә – көянтәгә аскан ике чиләк. Җайдакларны күрүгә үк, мәче җитезлеге белән ихатага кире чумган иде, Карабәк аваз салды.

– Без шулай ук өркеп качардай котсызмыни, сылу?

Яртылаш ачылган капкадан үрелеп, кызый сүз ыргытты.

– Юк ла инде, абый, котсыз түгел лә сез. Каршыга буш чиләкле кеше очраса, юл уңмый дигән ырым бар бит. Мин шуңа гына качтым.

– Ә минем барасы җирем шушы авыл иде, мин килеп җиттем бит инде, сылукай. Әйдә, чыгып күрен. Мин ырымнар белән баш катыра торган кеше түгел. Аның каравы, бер канунны гомерлеккә ятлап куйдым, менә. Бүредән курыксаң, урманнарга йөрмә... Әйдә, чык, дим, ичмаса, су эчер син безгә.

Ниһаять, кыз тәвәккәлләде, ахрысы, чиләкләрен алъяпкычы белән каплый-каплый, кабат пәйда булды. Карабәк күз йөгертте: агайлар әйтмешли, авызыңда эреп китәрдәй җиләк төсле пешеп җиткән сылу бала бит бу! Яше, мөгаен дә, ундүрт-унбиштәдер, әмма үзе төлке-сыртланнар да куып тота алмас җитез җәйрән сыман. Алъяпкыч канатлары астыннан ике алма төрткән. Алъяпкычны буып куйган биле бер уч көлтә төсле. Озын итәкләре аякларын каплый, тик зеңгелдәп барган тәңкәле толымнар астына күз текәсәң, тиз-тиз уйнаклаган тыгыз таучыклары аның төз, көчле аяклы икәнлеген ассызыклап тора. Аз да түгел, күп тә түгел, бүген үк яучы җибәрерлек килен ләбаса бу сылу-җанашкаем!

Урам уртасында сиртмәле коены чаптар да инде күптән сизенгәндер, түземлеген җуеп, ул да шунда тартты. Бура янына килеп җитүгә үк, Карабәк ияреннән сикереп төшкән иде дә, кыз бик җитез икән, сиртмә бавын эләктерергә өлгерә алмый калды. Ә кызыкай, кулларын тиен шикелле җитез биетә-биетә, кое сиртмәсен әүвәл торна борыныдай аска таба иде, аннары күз ачып йомарлык арада бура авызында ялык-йолык килеп, комнар белән ышкып чистартылган бакыр чиләк калкып чыкты. Аны бура почмагына җайлап утыртты да телгә килде сылу:

– Рәхим итегез, әйдә, эчегез соң!

Карабәк, сихерләнгән сыман, аңа текәлеп тик торуын белде. Кеш тиреседәй елкылдап торган чем-кара, хәтфә, йомшак чәчләр. Карлыгачның ике канатыдай кыйгач кара кашлар. Озын, куе керфек. Шомырт төсле чем-кара күзләр. Бер генә сыры да булмаган алсу, сусыл иреннәр. Нәни, йомры ияк. Оялудан, тарсынуданмы икән, кызарып чыккан ике матур яңак.

– Үзегез су сораган идегез ләбаса, йә, эчегез инде, – дип кызның елмаюын да күргәч, Карабәк, әйтерсең лә, телен үк йотты.

Менә сиңа гап-гади бер авыл уртасында иң беренче булып очраган татар кызы! Син шушыңа гашыйк булмый йә, хәвеф-мазар туса, якламыйча, коткармыйча кара!..

Карабәк иреннәре белән көмеш суга чумды. И-и, бу суның keләм кебек йомшак, нәфислеге, әй, аның тешләреңне чымырдатырдай хәтфә суыклыгы! Шушы таныш түгел сылу кулыннан алып эчкәнгә генә шулай татлымы соң бу, әллә туган якның тәгәрмәч эзенә җыелган сулары да зәмзәм буламы ул?..

– Атың кемдер, сылу? – дип аваз бирде Карабәк тик бераздан гына.

– Айзирәк мин, – дигән җавап Карабәккә болытлар өстеннән төшкәндәй талгын ишетелде.

– Ә нишләп япа-ялгызың син? Авылыгызда нигә берәү дә юк?

– Ялгыз түгел, өйдә инәкәй бар. Күрше карчыклары, бала-чага монда бик күп әле.

– Ә өлкәннәр? Мин ирләрне, хатын-кызны әйтәм.

– Һи, абый, мәзәк тә инде син. Гәрәйләрнең хәзер кул арасына керердәй барча малай-шалаена, кыз-кыркынга тикле болында бит. Инде атна буе Ак Идел буендагы тугайлыкта печән чабып, печән җыеп ята барча халык.

– Ә син нишләп монда? Нигә анда түгел?

– Андагылар көн кызуында ял итеп алырга туктады, мин авылга чаптым. Инәкәй чирләп егылды, мин аның хәлен белергә дип кайттым. Чәй генә эчерәм дә тагын шунда торып йөгерәм мин.

– Алай икән, алай, – дип маңгаен һәм чигәләрен уып торды Карабәк. Аннан барыбер дә тагын сорау бирде. – Әтиең дә болындадыр инде?

– Минем әткәй юк бит, – дип юаш тавыш белән җавап тотты сылу. – Өч кыш элек Ак Иделгә батып харап булды.

– Нишләп инде?

– Сусарларга куйган җәтмәләрне тикшерергә дип җыенып киткән иде, Ак Идел өстендә боз ярылган да, әткәй, мәрхүм, су төбенә чумган. Безнекеләр өч көн буе ыргаклар белән дә эзләп карадылар, таба алмадылар. Идел аңа кушылган Шәбез төсле, Бәҗәнә шикелле вак-төяк инеш түгел, ул бит диңгез сымак. Колга буе гына ярык эченә ыргак ташлап, минем әткәйне ничек итеп таба алсыннар ди?

– Үлгән артыннан үлеп булмый, сеңел, җаны оҗмахтадыр, син кайгырма бик үк, – дип юатырга мәҗбүр булды Карабәк. Аннары үзен тортkәләүгә сискәнеп, башын борса, чаптары чиләктәге суны төбенә кадәр эчеп бетергән дә тагын сорый, ахры.

– Җитте, җитте, наный, – дип, хәзер инде атны юатты ул, муеныннан шап-шоп сөеп алды. – Без өебезгә кайтып җитмәдек бит, тагын юл чыгасы.

Карабәк Айзирәкнең кулларыннан алды, кыюланып дәште.

– Син тагын болынга төшәм, дигән идең. Әйдә, алып төшеп, ул тугайлыкны миңа да күрсәт әле. Мин печән чабып кәҗә маемны чыгарган оста түгел-түгелен, шулай да сәнәк тоту, кибән куюларны гына булдыра алырмын сыман.

– Ай-һай, абый! Кибән түбәсендә печән алып тору өчен минем Саттар абый кебек булу кирәк. Менә ул, ичмаса, булдыра да инде. Кулларына карап өлгереп тә булмый, бер уч печәнне дә кире төшермичә җыеп бара белә. Үзе тиен кебек боргалана, әле шунда тузан болыты күтәрердәй итеп биергә дә өлгерә.

– Ярар, укам коелмас, кирәк булса, мине дә мендерерсез. Алай-болай синең арттан яучы җибәрергә кирәк булса, миңа Саттар абыең белән дуслашып кую да артык булмас.

– Әй-лә, абый, тиктомалдан нигә шаяртасың? Синең кебек ай-кояшлар безнең ише хәерче ихатасына нурын ташлый димени инде? – дип, Айзирәк асылда да нык кына үпкәләде, яулыгының бер очын авызына кабып, борылып ук китте.

– Сылуым, сылуым, – дип, артыннан юыртырга мәҗбүр булды әмир. – Серкәң бөтенләй дә су күтәрми икән, миңа шаяртып сүз кушарга да ярамый микәнни соң?

– Ярамый! – дигән коры гына җавап ишетелде, әмма ни хикмәттер, сылу кызыкай адымнарын барыбер сүлпәнәйтте.

– Мине болынга алып бар, дип сорадым бит. Әйдә, җыен да чык. Тугайлыкка аптөш инде мине.

– Ярар, ярар...

Күз ачып йомган арада Карабәк эргәсенә алмаш чаптар китереп җиткерделәр. Айзирәк иңгә-иң басып бара башлагач, Карабәк аны кысып кочаклап алудан үз-үзен көч-хәл белән тыйды. Ут кебек янган тәннәрен бер-берсенә тидерергә дә шүрләп, юл буена талгын юырттылар. Биек тау өстеннән ачылган искиткеч манзараны күреп алгач кына, Карабәк капылт чаптарының йөгәненнән тартты.

– Тыр-р-р, малкаем. Тик кенә тор берүк. Мин мондый матурлыкны кабат кайчан күрәм әле.

Тау астында, тиңсез дәрья булып, Ак Идел-сылукай талгын гына ага. Карабәкнең чал Иделне, Чулман-Нократларны, Тын елганы, Җаек-Сакмар буйларын, Кондырча, Ык, Сөн, Нокыш суларын, хәтта Җидесу төбәгендәге Ак-су белән Күк-су атлы дәрьяларны да барып күргәне бар. Һәммә елга, һәрбер чишмә, пыскып янган учак шикелле үк, гомер бакый карап туймаслык ул. Ләкин кайсысы гына шуларның Ак Идел атлы сылу елга белән тиңләшә ала икән?

Әнә, тау астында нинди хәтфә болын! Үләннәре талгын искән җилдә дә диңгез дулкыннары төсле берсе артыннан берсе куышып йөгерешә. Бу үлән диңгезенең чиге-чамасы юк, ул яр буйлап офыкларга кадәр сузылып юкка чыга. Тугайлыкта, түмгәк-түмгәк ясап, куе әрәмәлек үсеп чыккан. Агачлар арасында кәккүк кычкыруы, былбыл белән тургай сайраулары. Әрәмәлекләр артындагы сай сулыкта аккош, чеpлән, ләкләк, торна аваз сала. Барысы да – хыялларда күреп иләсләнгән җәннәт бакчасыдай, монда тутый кошлар һәм тәвис-ханбикә үзе генә җитми.

– Ныклап кара, хәтереңә салып куй, синең гыйшкың менә шунда кала, – дигән сәер җөмлә колакларына килеп ишетелде. Үз-үзенә ышанмыйча, Карабәк ияреңдә утырган Айзирәкнең иреннәренә күз ташлады. Юк, ул түгелдер, аның иреннәре нык кысылган. Алай булгач, әллә Ходай үзе, әллә йөрәге эндәштеме соң аңа?

– Һай, безнекеләр эшкә кузгала бит! – дип аваз бирде сылу. – Сүзләүләре мөмкин, яннарына ашыгырга кирәк.

Карабәк чаптарының касыгына үкчәләрен тидереп алды, ике янган йөрәк тау өстеннән аска томырылды. Уразай бәк күптән инде бирегә төшеп җиткән, колачын киң ачып каршылады.

– Җаны теләгән – җылан ите ашаган, ди. Печәнчеләргә ярдәм кулы сузарга ниятләгәнсең икән, рәхим ит тә уртасында бул, кунак түрә.

Карабәккә әүвәл чалгы, шабыр тиргә баткач, сәнәк тоттырдылар. Кибән куючы яшь-җилкенчәкне күргәч, шулар янына чапты. Анда килсә, сүз берләшкән сыман, һәммәсе дә кибән түбәсенә төртеп күрсәтәләр.

– Май ягылган күмәчне ялкау да ярата ул. Син, әйдә, шул күмәчнең тәмен татып кара әле.

Югарыда унтугыз-егерме яшьләрдәге, Карабәкнең үзе шикелле үк, карачутыр егет. Качышлы уйнап та маташмады үзе.

– Сиңа су эчергән Айзирәкнең абыйсы инде мин. Саттар атлы булам. Минем белән рәттән һич югы тирләгәнче басып тора алсаң, бер атна буена ашаудан баш тартам, – дип рәхәтләнеп көлә.

Өчме-дүртме егет берьюлы чүмәлә чаклы печән ыргытуга, Карабәк кибән өстеннән мәтәлде дә төште. Гарьлегеннән тагын өскә таба ыргылган иде дә, итәгеннән тартып, ирек бирмәделәр.

– Кетәклектә һәр тавыкның үз урыны мәгълүм. Каш ясыйм дип күзеңне чыгарырсың. Безгә син печән чүмәләләрен ташып өлгертсәң дә җитә.

Кичке эңгер-меңгердә күз бәйләнә башлаганчы печән ташый-ташый, Карабәкнең ике кулы өзелеп төшә язды. Аякларын да көч-хәл белән генә сөйри иде инде, Аллаһның рәхмәте, «ярхәмкалла, тәмам», дип кычкырып, эшне туктаттылар. Карабәк чүмәлә төбенә чүгүгә үк йоклап китәр сыман иде, яшьләрнең тугайлык уртасында учак кабызуын күреп әсәренде. Монысы ни тагын да, болар ни кылмакчы?

Учак өстеннән сикереп уйнаулар да, әйлән-бәйлән килеп биюләр дә, учка йөзек салып җәза бирүләр дә – берсе-бер калмады. Карабәк өчен болар, әлбәттә инде, чит-ят, ул аларның бер бөртеге турында да ишетеп белми иде. Хәйран калып, күзәтеп тик утырды. Инде аның күз кабаклары йомыла башлавын шәйләделәр бугай, Уразай бәк чышан-пышан килде.

– Тал белән печәннән әвәләп куйган чатырларның иң кырыйдагысы, әнә тегесе – ул синеке булыр. Кер дә ят, Карабәк. Иртән йоклап калсаң, хурлыгын соңыннан Ак Идел суы белән дә юып бетерә алмассың...

Иртән төш күрдеме ул, саташтымы – яшерен бер фәрештә аның борынын, колакларын хәтфә үлән белән кытыклап уяткандай булды. Баш астына салынган иярдән калкынып як-ягын карманса, бернинди фәрештә дә, хәтфә үлән дә юк. Чатырдан баш сузса, болынлыкта да бер җан иясе дә күренми бит әле. Таң атмаган дияр идең, әнә, Ак Иделнең үр ягыннан офыкны кызартып, кояш чыгып килә. Димәк, йоклап калмаган, Ходайга мең шөкер, аны хурлыклардан йолып алган бит ул. Ул дигәне тагын фәрештә бит, кайда икән үзе?

Карабәк чишмә урынын кичә кич үк ятлап калган иде. Гер таккандай кулларын яман болгый-болгый, тәнен яза-яза, су янына килсә, чишмә улагы янында Айзирәк елмаеп утыра.

– Уяндыңмы, түрәм? – дип эндәшкән тавышына кадәр газиз, кайнар.

– Мине син уяттың бит, әйт, шулаймы? – дип сүз кушты Карабәк тә, артык түзалмыйча.

– Юк, мин түгел, ә фәрештәң, – дип елмайды таң сылуы.

– Синең кебек фәрештәне көтеп күпме хыялландым! – дип пышылдады әмир, таң сылуын кочагына алып.

– Мин дә, түрәм! – дип җаваплады әллә таң сылуы, әллә барча җиһан...

Карабәк Айзирәкне җитәкләде дә печәнчеләр ыстаныннан читкә торып йөгерде. Аякларга урыны-урыны белән аксыргаклар, сарут, кандала үләннәре тешләк ата каз шикелле ябышмакчы була, яшүсмердәй кызган Карабәкне генә һич туктата алмый. Уразайлыларның ботаклардан корган чатырлары тәмам күз алдыннан югалганчы, Агыйдел ярына килеп төртелгәнче йөгерде алар. Яр буенда Айзирәк, артта калган чатырларга төртеп, искә-аңга чакырмакчы иде, яргаланып беткән иреннәре белән әмир аның сабый баланыкыдай үпкәләп бөрешкән нәни генә авызын томалады.

– Син хәзер мәңгегә минеке, тик минеке инде! – дип пышылдады ул, ут капкандай тиз-тиз сулыш ала-ала.

Аннары әмирнең иреннәре колак очларына, иңбашларга, муенына, ике пөхтә ими арасына очып күчте. Җиргә тезләнделәр. Зәңгәрсу алъяпкыч, яшькелт күлмәк, аксыл итәкләрнең җиргә шуышып төшүен дә һичкем шәйләмәде. Тездән узган үлән искиткеч тә хәтфә, шундый кайнар иде, ул ике ярны юрган-ястыклар шикелле җәелеп кочагына алды. Кызның аккош канатыдай аксыл,

шома тәненә, дәрттән ташып тулган күкрәкләренә күз салуга, яр буендагы таллар да көнләшүдән түбән иелде, ә җир җиләкләрнең яңаклары оялудан кызарып чыкты сыман.

Айзирәкнең имиләре ике алма зурлыгыннан артмыйдыр да әле. Очларын да пешкән чия дип кычкырырлык түгел. Ләкин нишләп бу кадәрле нәфис, татлы, үзләре йомшак та, тыгыз да һәм сихерле соң алар! Карабәк онытылыбрак үпкән чакта чия төше чаклы ими очларыннан ике тамчы сөт тә сытылып чыкты бугай. Сөбханалла, җир йөзендә кырыкка хәтле яшәп, үз гомерендә мондый да татлы, бу чаклы да исерткеч сыеклыкка телен тидереп караганы да булмады бит аның!

Айзирәкнең ими башлары, кендеге, беләкләре әүвәл Карабәкне яшь кычыткан шикелле өтеп алган иде, аннары рәхәтлегә, кырмыска өере төсле, бөтен тәне, иңбашлары, аяклары буйлап таралды. Ә бераздан, Айзирәк тәненең кайнарлыгын, керсезлеген, кадерен тоя барган саен, Карабәк үзен әле кычыткан, әле ябь-яшь, хәтфә, куе чыршы миллеге белән чабынгандай тойды. Рәхәтлек мизгелләре чыршының йомшак ылыслары кебек тә кадый, кычыткан кармагы төсле чеметә, яндыра, кыздыра гына бара, ләкин мондый ләззәттән аерылып булмый, ул бу чаклы бәхетне һичбер кайчан татымаган сыман, кайнар мунча ләүкәсендәге шикелле, кабат-кабат чабынасы килә!

Айзирәк тә назлы аваз белән, истирәхәт кичереп ыңгыраша. Ул су эчәргә сусап нәни инеш буена төшкән тай шикелле. Карабәк белеп тора бит, ябь-яшь тайны елга янына йөгәнләп тә, хәйләләп тә китерергә була, әмма муенына менеп атлансаң да, ул иренен су өстенә тидерәчәк түгел! Ләззәт, шифа, рәхәт, бәхет, оҗмах Карабәккә!..

**15**

Бер атна буе бөтен шартын китереп туй иткәннән соң гына кайтыр юлга чыкты яңа, яшь пар. Саттар аларны Ык елгасындагы Мирза кичүенә чаклы озата килгән иде, аерылышканда Карабәккә туры карап дәште.

– Айзирәк өчен калкан булып яши белсәң иде, җизни түрә. Без, аның борадәрләре, берни сорамыйбыз, кара гавам кызы, ятимә дип, аны гына син рәнҗетә күрмә.

Инде кочаклашулар бетеп, иярләргә менгәч, Карабәк сорап куйды.

– Карале, кем, каениш, Мирза кичүе дигән атама монда ничек килеп эләккән?

– Аны беркем дә анык кына белми. Тимер-Булат атлы әмирне тез чүктерү өчен бу төбәккә Мамай мирза да килеп җиткән, дигән имеш-мимешләр бар. Ә чынлыкта, ай-һай, килде микән? Ул һич югы бер төмән белән ябырылган булса да, Ык буен да, Ак Идел тирәсен дә айкамый вә измичә генә кайта белмәс иде. Бу якларда түмгәк хәтле вак-төяк түрәләргә дә кибән чаклы олы исем тагу кебек сәер гадәтләр бар. Сарман янындагы Зәңгәр тауда Майкы би атлы бер меңбаш та гомер иткән булган, мәгәр үзен һаман онытмыйлар. Ул Бату хан гаскәрендә, хактан да, бик абруйлы меңбаш булып йөргән, ә Биләр каласын яулап алганнан соң, бер болгар кызына гыйшык атып, шушы якта торып калган икән. Шул Майкы бине ошбу төбәк халкы кайчакларда әмир йә хан дип тә җибәргәли. Әнә, Ык буендагы Тәмьян авылы янәшәсендә Тугаш атлы бер бәк алагаем утар корып яши. Чулманга коя торган бер инеш янәшәсендәге тау башында Бигеш атлы түрә зур йорт салып куйган. Нинди галәмәттер, халык аларның икесен дә,

бер чыбыктан сөреп, хан дип атап йөри. Һәр бәндәнең авызына сугып йөреп булмый, ә алар юк кешене дә күккә чөя шулай. Инде аптыраганнан, үзебез дә, торып-торып, һаман баш ватабыз. Шул Мамай мирза чирүендә яу кылып йөргән өчен генә кичүне дә мирзаныкы дип атамадымы икән ул түрәләр?..

«Сәер, гаҗәеп кыргый хәл бу, – дип, үз эченнән генә уйга чума-чума, кайту юлына чыкты Карабәк. – Мамай хөрмәтенә кушкан булсалар, алар шул мирзаны сагыналар, димәк. Ә ни өчен? Мамайның аларга нинди изгелеге тиде икән? Каты, корыч куллы булганы өчен кадерлеме шулай? Итек ыштыры, аяк чолгавы сыман, туктаусыз алышынып торган хан аламаларыннан туеп беткәннәрме? Менә, баш ват.

Һичбер шик юк, әлбәттә, халык бу Сарайның таган сыман әрле-бирле уйнаган түнтәреш-суешларыннан да, тотрыксыз заманадан да туеп беткән инде. Бозау сыман юаш ирне, үшән алашаны, чи утынны да өнәмиләр, куралмыйлар хәтта. Халыкка тыныч кына, кайгы-хәсрәтләрсез гомер итү өчен ил сагына кыя-калкан булып баса алырдай гаярь ханнар, күмәк гаскәр кирәк бит ул. Әнә, теге чакта Болгарда зар елаган Низамины гына искә төшер. «Без урыс ушкуйларыннан, урыс баскыннарыннан арына алмыйча, канга батып яттык, шул көннәрдә Сарайдагы ханнар безне яклау өчен бармакка-бармак та сугып карамады, Болгар олысын да үзләренә ясак түләргә вакыт җиткән чакта гына искә төшерәләр». Анысы шул чамарак тетеп салган иде, ә гади яугир булып йөргән Җәүдәтне генә кара, ул да үз йортын, үз илен билбирмәс баһадир итеп күрергә хыяллана ласа!

Менә шундый ул хакыйкать, кичәге Габдулла хан һәм бүген йорт хуҗасы булып күтәрелгән Карабәк әмир! Син юкка гына Болгар олысын Урдадан аерып алу яисә халкын үз артыңнан ияртеп кайсыдыр кыйтгага алып китү, аерым ханлык төзеп гомер итү турында хыялланасың. Син йөзәрләгән авылны, йөз меңләгән ир вә хатыннарны күк йөзенә иңдерә дә, аларны җиде кат болытлар өстендә яшәтә дә алмыйсың бит. Халыкның туган-үскән нигезе дә, кендек каны тамган туфрагы, туганы-тумачасы, кода-кодагые, хәтта чикне бозган өчен тибешеп-төрткәләшеп яшәгән күрше-күләне дә бары шушында, Болгар атлы бер олыста гына. Хәтта тирес өемендә тибенгән тавыклар да үзенең ихатасын ташлап китә белми, ызан аша яткан күршеләр бакчасына кереп суалчан каптырса да, кабат үзе ияләшкән ихатага йөгерә дә кайта. Туган җир – ул иңгә элгән йә аякка кигән кәвеш белән җилән генә түгел, аны монысы ертылды йә тишелде дип кенә алыштырып һәм яңартып булмый. Менә шушы яшәгән җиреңне гөлбакчага әйләндерә белергә, ә аны куян-төлке түгел, аю-бүреләр дә үтеп керә алмас кирмәннәргә төреп куярга кирәк.

Әнә, Кормаш, Балтач, Гәрәй авылларын күреп, мең сокланып киттең. Гөлбакчадай авыллар кору, гаиләләр ишәйтү, мал үрчетү, һөнәр алачыклары төзеп кую өчен Кырым хәтле Кырымнан кузгалып килгән халыкка да кан коюсыз, сугышларсыз үткән биш ел вакыт җитте. Ипле-имин биш ел дәверендә Болгар белән Казан калаларың да, Җүкәтау белән Кашан кирмәннәре дә диварларга төренеп, аякка күтәрелде. Әгәр Туктамыш хан Мәскәү кенәзләрен тез чүктереп, арт сабакларын укытып кайтмаган булса, синең Болгарыңа ул ушкуйлар, ул ачәрвах урыслар ирек куеп, ярхәмкалла дип кенә торыр идемени? Димәк, син Болгарыңның култык таякларын ташлап, тураеп һәм көрәеп басуы өчен дә, иң беренче чиратта, Туктамышка гына бурычлысың. Кабык эченә йомарланган әкәм-төкәм сыман, үз йортың, үз гаиләң иминлеге өчен генә янып-көеп яшәү оят, гарьлек! Урда куәте дә, бер йодрыкка укмашкан

бармаклар шикелле, Болгар, Хаҗитархан, Кырым, Сарай, Актүбә кебек аерым-аерым йортлардан туплана ул. Берең аксый икән, күршеләр кул сузар. Икенчең егылса, дошман таптамасын өчен башкалары каплар. Хаҗитархан, Кырым, Актүбәләрдә дә – синең татарларың! Җучи хан төзеп һәм васыять итеп калдырган олуг илне саклау – безнең бурыч. Их, аны көчәйтер һәм үгез шикелле гаярь итү өчен тәкъдир аларга тагын биш-алты ел сугышларсыз гына гомер бирсә икән!..

Карабәк янәшәсендә күләгә шикелле беркеп барган Айзирәкне кочагына кысты.

– Шуны уйлап кайтам, көзге айлар якынаеп килсә дә, быел кичекмәстән Ага-Базарда зур ярминкә уздырырга кирәк. Ике йөз, өч йөз еллар элек үк безнең Болгар нәкъ менә Ага-Базары белән бар җиһанда бик зур шөһрәт тоткан. Каф таудан төшеп тә сәүдәгәрләр килеп җиткән монда, Үргәнеч ягыннан кыргыз-кайсаклар, мангытлар, калмык-ойротлар зур кәрваннар куган. Ни әкәмәт, хәтта гареб ягындагы варяглар да кораб-кораб булып килгәннәр бит. Яшь хатын алды да сараена кереп бикләнде бу, димәсеннәр әле. Яшь хатынлы булган сөенечтән Ага-Базар ярминкәсен дә дошманнарның эче янарлык итеп үткәрергә кирәк. Кайтуга ук һәр тарафка елгыр чапкын юллыйм. Үргәнече, Каф тавы, варяглары, мадьярлары – һәммәсе дә килсен. Минем күңел иркен, бүген арт якларыннан тын алып яшәгән Мәскәү белән Рәзәненә дә чапкын җибәрттерәм, эчләре янсын ла, чукынып китмәгәе!

**16**

Ага-Базар ярминкәсе генә үтеп киткән иде, Туктамыш хан чакыру юллаган.

– Сарайда туй! Туктамыш хан үзенең Нәкыя атлы кызын мангыт кабиләсенең олугбәге булган Балтыкчы бәк угылы Идегәйгә бирә. Бөек ханымыз барлык олыс бәкләрен, кала әмирләрен, сәедләрен вә юлтотмыш сәүдәгәрләрне олы туйга дәшә!

Туй икән, туй. Олыс әмире генә булган Карабәк, билгеле ки, мәшһүр хан ук түгел, Айзирәк белән аңа мәркәз үзәгендә, таҗдар сараенда меңәрләгән кунак чакырып туй гөрләтү кебек бәхет елмая алмый. Карабәк, гомумән, өч туен да артык тыйнак кыйланып, түрәләр күзеннән качып бәйрәм итте. Үзенә калса, туйның теләсә кайсысы да, беренче нәүбәттә, гаилә шатлыгы ул. Ә шатлыктан, зур кыңгырау тагып йөрмәсәң дә, бик тиз көнләшәләр. Әмма бүтән бер чараң юк, илтотмыш хан олугбәккә санап туйга дәшә икән, син арба артына тагылган дегет чиләге түгел дигән сүз бу, юлга җыен инде, Карабәк-Габдулла хан...

Карабәк ун-унбиш олаулык бүләк әзерләтте, үзе белән улы Солтанны, җигәне Көңгерне, ике йөз җайдаклы сак нөгәре алды. Кияү буласы Идегәйдән бигрәк ханның үзенә дип әзерләнгән ун чабышкы тайны олау уртасына бәйләп куйганнан соң гына, таштан салган сараеның ишегенә килеп, Айзирәккә дә, ниһаять, аваз салды.

– Олау әзер, сине генә көтәбез, җаныкаем...

Идел яры буйлап төшә башлагач та, Карабәк һәр тарафны мыегына чорнарга онытмады. Сәмәр кирмәнен, Җигүлат тауларын, алардан соң Караяр, Мәчетле, Кайтарма салаларын үттеләр, һәммәсе дә коры-сарылардан арынган яшь таллык шикелле кабаттан күтәрелгән, куәт-сүл җыйганнар. Үзәнлекләр саен сыер, сарык, кәҗә, елкы көтүләре утлый, арпа, солы, арыш басулары тезелешеп кала. Бер генә татар авылында да җимерек келәт-сарай, сугым малы төсле җиргә тезләнгән мунча, янгыннан соң кара кисәүләре белән чулак-гарип сыман кызгандырып утырган хәрабә юк. Яши, гөрли, тернәкләнә бара Алтын Урда!..

Сарай каласы да арасына балчык һәм таш тутырылган икешәр катлы имән диварга төренгән. Идел ягыннан бөтенләе белән ак таш. Капкалары биек, тимердән тышлаганнар. Дивар артларында зур басмалар, алар түбәләнгән. Почмак саен биек манаралар. Һәркайсында көбә, калкан, сөңге, айбалталар белән коралланган сакчы.

Мәркәз урамнарын санап кына бетермәле түгел. Үзәктәгеләрнең юлына таш түшәлгән. Таш диварлар белән уратылган сарай чаклы йортлар. Боларның һәркайсы аерым кирмән төсле, дошман урамнарга бәреп керсә дә, бу йортларны кан түкмичә генә яулый алмаячак. Мәчетләр күп. Хан сараена җиткәнче үк Карабәк утыздан артык Аллаһ йортын санап үтте инде. Әле күрше урамнарда, шәрык, шималь якларында да манаралар, гөмбәзләр, ярымайлар ялтырап күренә бит, гомум алсаң, бер йөз генә бардыр. Алардан тыш, Сарайда икеме-өчме нәсарә чиркәве дә яшәп килә иде, Туктамыш та аларга зыян-зәүрәт салырга җөрьәт итмәгәндер. Мәскәү-Сүздәлдәге Митрәй, Константин, Олег кенәзләрнең барчасы да хәзер, каз-үрдәкләр төсле, тәпиләрен ашереп, шуышып кына, ярлык өчен һәр ел саен Туктамыш каршына килеп йөри диләр. Аларда, күркә сыман кабарып, үз-үзләре белән хозурлану тузганак мамыгы шикелле җилгә очты инде...

Карабәк хан сараена кергәнче үк, бәкләр бәге Хәсәнне күреп сораштырырга карар итте. Хәзер аңа томаннар артындагы кара көннәр өчен теш кайрап йөрүдән бер файда да юк бит. Син – кайчандыр ярты җиһанны дер селкетеп торган Болгар бәге, йортың яшәеше хакына тез чүгә бел...

– Ә мин, колакларны ябалакныкыдай тырпайтып, Болгар хакында адым саен сораштырып торам. Үзең Сарай тарафын бөтенләй ташладың бит, – дип, Хәсән аны колач җәеп, кочып каршы алды.

Карабәк төче камыр төсле җәелеп сөйләшүне бик өнәми иде. Ләкин ул туй түрендә утырырга, күңел ачарга дип чакырылган олы кунак лабаса, чамадан тыш җитди булып кыйлануны да артык күрде.

– Синең өчен Болгар юлына киртә корылмаган, гайбәтче хатыннар төсле читтән генә төпченеп ятканчы, кайт та күрен идең, – дип, сүзләрен бик иләп тормыйча гына авыз ачкан иде, Хәсәннең урт кысуын шәйләгәч, шып туктады.

«Әһә, синең Болгарга булган үпкәң һич үтмәгән икән», – дип нәтиҗә ясады ул күңеленнән һәм бәйләрбәге көтмәгән сүз кузгатты.

– Карале, бәк, туйга килгән булдык инде без килүен, мәгәр Идегәй хакында бөтенләй дә ишеткәнебез юк бит. Мин сарайда утырган чагында нindидер Балтыкчы бәк исеме колакка чалынды анысы. Әмма кабилә башлыгы идеме ул аксакал, әллә мангыт олысының бәге идеме, анықларга вакыт эләкмәде. Ә хәзер үзең туйга кил, үзең кияүнең кем икәнен дә белмә, болай әллә ничек, караңгы төн уртасында күзеңә яулык бәйләп, әбәкле уйнаган сыман.

– Һо, гаять катлаулы туй бу, аның бөтен серләрен белмичә килүең отышлырак түгелме икән әле, – дип Хәсән үзе үк баш чайкады. – Син исемен ишетеп кенә калган Балтыкчы бәк күптән юк инде ул. Моннан җиде ел элек безнең Туктамыш хан аны үз куллары белән тотып чапты.

Карабәк, корт чаккандай, үзенең кәнәфидән сикереп торуын да шәйләмичә калды.

– Ничек инде, ничек?

– Тарихы бик озын. – Хәсән янә башын чайкап куйды. – Аксак Тимердән өч төмән чиру алгач, Туктамыш Күк Урда өстенә тәүге тапкыр җитмеш алтынчы

санәдә[36] үк килеп җиткән иде. Сауран каласы тышында без аны пыран-заран китереп тар-мар иттек, Туктамыш үзе көч-хәл белән генә качып котыла алды. Аксак әмир ягындагы нәүкәрләр – умарта оясында бал кортлары сыман. Аксак моңа янә өч төмән җайдак биргән. Тагын шул ук Сауран кирмәне янында каршы алдык инде Туктамышны. Бу юлы Күк Урда чирүен Ырыс ханның икенче угылы Токтагый җитәкләде. Туктамышның үз нәүкәрләрен кирмән диварларына ташлавын гына көтеп җиткердек тә, поскындагы төмәннәр белән арттан томырылып, Аксак Тимер озаткан икенче чирүне дә тоташ кырып салдык. Туктамыш Ак-су аша йөзеп кенә үлемнән ычкынды ул чакта да.

– Бәрәч, бәрәч, Туктамыш хан, шулай итеп, үз хакына алты төмән яугирне кырып бетерттеме? – дип, Карабәк кабат күзен акайтырга мәҗбүр булды.

– Алай гына да түгел, – дип кул селтәде Хәсән, аннары элеккечә үк, җитди дәвам итте. – Бу юлы да гаскәр югалтып кайткач, Аксак инде үзе әллә туксан, әллә бер йөз меңлек гаскәр белән, мәркәзебез Сыгнакка төбәп, юлга чыга. Ырыс хан да аны ярты юлда тугыз төмән белән каршы алды. Иллә мәгәр орышка керергә өлгерә алмадылар. Әллә кайдан гына давыл килеп чыкты. Карлы яңгыр атна буе койды. Шуның артыннан ук кисәк салкын бәрде, җир өстен тоташ боз катламы сарды. Хакмы-юкмы, төгәл әйтә алмыйм, мәгәр Аксакның шул яланда бер атна эчендә унбиш мең баш аты әрәм булган, диделәр. Ырыс хан, Туктамышны кайтарып бирүен таләп итеп, Аксак янына илче дә юллап карады, мәгәр теге барыбер тыңламады. Ахырда инде, яуны башлый да алмыйча, кире чигенделәр.

– Ниндидер «Тайгак орыш», «Пычрак орыш» дигән яулар турында хәбәр Кырымга да килеп җиткән иде, бактың исә, гел булмаган икән, – дип Карабәк сүз кыстырды.

– Җитмеш сигезенче санәгә аяк баскач, Аксак әмир янә ияргә күтәрелгән. Нәкъ шул көннәрдә, һич тә көтмәгәндә, Ырыс ханыбыз китте дә барды, туган. Нишләп, ни сәбәптән – һичкем белә алмады. Тәхетне Токтагыйдан да кечерәк Тимер-Мәлик эләктергәч кенә, күңелгә корт төште. Шушы сәрхуш кулы уйнамадымы икән? Бу озак вакыт буе хан булып утырса, безнең эшләр харап, дибез. Менә шундый уйлар белән пошаманга калдык. Ә бу ике дә уйламый, төш җиткәнче түшәктә гырылдый, аннары кич буена, төн буена эчә. Хәтта Аксак әмир дә сәрхуш Тимергә каршы яу кылып йөрүдән хурланган, дүрт төмән гаскәрен Туктамыш кулына ташлап киткән. Ни галәмәт, исерек хан кул астында яуга ташланып, бу бәрелештә дә җиңүгә ирештек әле без. Туктамыш нибары иллеләп нәүкәре белән генә яуны ташлап качты. Тимер-Мәлик Туктамышның башы өчен бер мең елкы вәгъдә иткән иде. Җайдакларыбыз аны илле чакрым куды. Ләкин Аксак әмир Туктамышка гарәп чаптары бүләк иткән булган, безнекеләр андый аргамакны тота алмый кайтты.

– Могҗиза, әкәмәт бу, – дип, учы белән тезләренә суга-суга гаҗәпләнде Карабәк. – Туктамышка нинди генә фәрештә шулай ярдәм итте икән?

Хәсән дә кул селтәде.

– Белмим инде, белмим. Мәгәр моны саклап йөртүче фәрештә, асылда да, бардыр. Өч тапкыр гаскәр туздырып кайткан Туктамышка Аксак әмир дүртенче кат чирү бирсен әле! Могҗиза инде, валлаһи, могҗиза, син хак әйтәсең. Күз алдыңа китер. Җитмеш сигезенче елның азагында Туктамыш Күк Урда өстенә дүртенче кат килгәч, түземе коргаксыган Сауран кирмәне ак әләм күтәрде бит! Каладагылар, кырга чыгып, Туктамышка бигать китерде. Аксак әмир гаскәренә Сауран чирүе дә кушылгач, Сыгнак каласы да озак һөҗүмнәргә түзә алмады.

[36] 1376 ел.

Каладагы бәкләр Тимер-Мәликне, арканнарга бәйләп, Туктамыш кулына чыгарып бирде, ә ул аны ике дә уйламыйча бүкәнгә озаттырды. Тимер-Мәлик Балтыкчы бәкнең кызын хатынлыкка алган, шуңа күрә кияү-хан бабасын бәйләрбәк итеп тә куйган иде. Мондый абруй күргәч, билгеле ки, Тимер-Мәлик янында аңа бабасы тиеш булган Балтыкчы бәк тә сугышларга керде. Туктамыш каршына бауларга чорнап китергәч, Балтыкчы би, газиз кызы белән киявенең абруйларын саклап, яңа табылдык хан алдына тезләнеп бигать китерүдән бөтенләй баш тартты. Меңәрләгән инсаннар каршында, үзәк мәйданда бит. Шуннан Туктамыш, котырынып, ятаганын суырып чыгарды да Балтыкчы бәкне икегә телеп атты. Булачак кияве Идегәйнең этисе менә шул инде ул... Һәм иң гаҗәбе – Идегәй шунда, дилбегә буе аралыкта гына басып тора иде... Үз күзләре, үз күзләре белән күрде барысын да...

Карабәк озак вакыт буе башын кочып утырганнан соң гына телгә килә алды.

– Минем башыма сыймый. Үзенең этисен кылыч белән чапкалап үтергән катыйльнең кияве булырга ризалык бирү өчен нинди соран, нинди җансыз бүкән булырга кирәк икән? Шул катыйльнең кызын ничек кенә назлап, сөеп булсын? Минем өчен коточкыч кыргыйлык, монафыйклык бит бу! Үз атаңны ничек сату, аяк астына салып таптау мөмкин?

– Күреп торасың бит, сата да, таптый да аның ише җаннар, – дип уртаклашты Хәсән, ә үзенең тавышы сүнеп торган учак өстендәге казанныкы төсле тонык кына чыкты. – Ләкин Идегәйгә үз җаны кадерлерәк дигән сүз генә түгел бу. Уйлавымча, аста соранлык, мәкер һәм дә зәһәр утлы өмет яшеренеп ята.

– Бабасы, ягъни Туктамыш урынына үрмәләргә ният итүен күз алдында тотып әйтүеңме?

– Әйе, тәхеткә дә өмет итүе бар.

– Анысы барып чыкмас. Идегәй – ул Чыңгызыйлар нәселеннән түгел.

– Шуңа карамастан, Ногай мирза белән Мамай мирза егермешәр ел буе Сарай хакимнәрен уч төбендә биеттеләр, әнә.

Тагын уйга калдылар. Карабәк умарта күче эченә чумган кебек булды. Сәер, сәер кабатлану бу. Мамай мирза, Бирдебәк кызына өйләнеп, хан киявенә һәм иң төп сәрдәренә әверелгән, чынлыкта исә бабасын да, гомумән, Урданы да үзенең уч төбендә биеткән. Хәзер Идегәй Туктамышның кияве булып килә, ул да, мөгаен, гаскәрнең бер өлешен үз кулына эләктермичә калмас. Чишмә шулай акса, иртәгә Туктамышның да Идегәй кулында уенчык хан гына булып калуы бар. Идегәй ни кыйланыр аннары, ни күрсәтер?.. Янә дә килеп, болар икесе дә бер үк сират күпере аша үткән, бер үк тәкъдир кубызына биеп йөриләр бит. Туктамышның этисе Туйхуҗаны Күк Урдага атланып алган Ырыс хан ботарлаткан. Идегәйнең этисе Балтыкчыны инде үзе үк шундый канлы язмыш кичергән Туктамыш хан, тагын шул ук Күк Урдага хуҗа булып алган явыз, телеп аткан. Туктамыш хан, ярлыкау һәм яклау эзләп, Аксак Тимер янына чыгып качкан, шуннан чит гаскәр, дошманнар чирүен алып килеп, ханга әверелгән. Тәкъдир дигәннәре бу юлы да кабатлана калса, Идегәй кайсы таҗдар ышыгына барып борын төртергә мәҗбүр булачак соң? Әгәр Идегәй Туктамыш мәктәбен, аның язмышын өлге иткән икән, димәк, кабатланачак бит, аһ, якынлаша бит бу канлы һәм аяныч язмыш! Моннан ничек, ничек котылырга?..

Тынлыкны янә Карабәк башлап бозды.

– Ә син ничек Туктамыш кылычыннан исән кала алдың? Аның Сыгнакны яулап алган чагын күз алдымда тотам. Син Ырыс хан янында да олугбәк булып, диван хәтле диванны да үз кулыңда биетеп утыргансың. Ни галәмәт,

Туктамыш сараенда да син – ханның уң кулы. Кайсы җайдакка да яраган чаптар шикеллерәк.

Хәсән кырыс тавыш белән, кистереп һәм катгый итеп дәште.

– Менә монысын мин сиңа чәйнәп каптыра алмыйм. Чөнки чәйнәп биргән икмәк катысы хәтта сабый өчен дә тансык ризык түгел, дигән сүзне ишеткәнең бардыр, үзеңә уйларга да урын калсын. Ходай насыйп итсә, бермәлне синең башыңа да шул ук кайгы төшәр, шулчак ни өчен минем әүвәл Ырыс, аннары Туктамыш ыстанын сайлап туктаганны үзең чамаларсың. Ханнар килә дә китә ул, икебез дә үз башыбыз белән сынап карадык бит. Ә минем өчен бер кыйбла гына изге һәм кадерле. Нинди генә адым ясасам да, мин иң элек үзем түгел, бәлки бердәм Урда, бердәм татар иленең бөтенлеге, иминлеге өчен көеп йөрдем. Шуның хакына мин шайтан алдында да бил бөгәргә әзер. Бер генә теләк яндыра – татар, татар гына яшәүдән туктамасын, илем таркалмасын! Сүзләремдә бер мыскал ялган да юк, моңа Ходай шаһит!..

Хәсәнне ул яңадан туйда гына күрде. Ләкин инде Карабәкнең анда бер гаме юк, аны Идегәйнең кыяфәте җәлеп иткән иде. Нинди галәмәттер, утыз яшен тутырып килгән Идегәйдә моннан биш ел элек югалган Мамай мирза чалымнарын шәйләп шаккатты ул. Карабәкнең күңел көзгесе генә шулай, анда үч бар, дип кенә нәтиҗә ясар идең дә бит, юк, әйгенәм, әнә, бер үк төрле гәүдә, бер үк буйлар. Тегесе дә базыграк гәүдәле иде, әмма төптән юан. Бу да нәкъ шул. Мамайның соңгы елларда чәче сирәкләнеп, баш түбәсе пеләшләнеп бетте. Идегәй яшь әле, аның чәчләре сагыз кебек ялтырап, бөдрәләнеп тора. Моның йодрыклары бала башы чаклы, беләкләре имән кәүсәсе сыман. Хәер, Мамай мирза да алышларда, орышларда бер дә сынатмады. Күз кабаклары, мөгаен, беркадәр аерылгандыр. Мамай кабаклары каш астыннан ук шешеп, керфекләре өстенә төшеп яткан иде. Идегәйдә дә кысык күзләр, юкса, әмма каш астыннан төбәлгән карашында – яшен, очкын, ялкын, ут бураны. Юк, бу бер сайлаган юлыннан чигенә йә төлке сымак койрык болгап йөри торган аумакай бәндә түгел. Туктамыш моннан ни өчен кияү ясарга омтылуы җиңел аңлашыла. Әйе, ул Балтыкчының җанын кыйган өчен нык үкенгән һәм гөнаһын юмакчы булып кыйланадыр инде. Идегәйне үз ягына аударса, аңа ияреп, барча мангыт кабиләсе, мал көтүе төсле, Туктамыш хан чатыры астына кереп баса. Ләкин менә Идегәйнең үзенә хан кияве булу ниләр өчен хаҗәт? Ул ни ота?..

Туй шәп итеп ягылган мунча төсле кыза-җанлана башлагач, бары да аңлашылды. Төп «туй бүләге» хакында Туктамыш хан үзе торып әйтте.

– Мин Идегәй киявемне үземнең угылым дип игълан итәм һәм дә ки ул олуг хан чирүендәге сул канатның башлыгы итеп билгеләнә!

– Афәрин! Машалла! – дип үкерде барча ялагай, соран яраннар.

– Хурлык, оят! – дип төзәтте күңеленнән генә зиһене булганнары.

Билгеле ки, алар берсен-берсе, гомумән, ишетмәде.

## 17

Олыс чигенә аяк басканнар гына иде, атын сары күбеккә батырган чапкын каршы алды.

– Сөенче, сөенче, олуг әмиремез, синең угылың бар! Алтынчәч бикәмез сине таза, бөтен бәби илә көтә!

– Әттәгенәсе! Мәгыйшәтнең иңгә канат куя торган мондый сәгадәт чаклары да була икән! – дип, ияреннән сикереп, Карабәк бәхет китергән чапкынны кочагына алды. – Менә мондый сөенеч хакына яшәсәң дә була!

Олаулар ягына борылып күз салса, Айзирәкнең иреннәре кыстыбый чите шикелле бүлтәйгән шул.

– Көнләшмә син, көнләшмә, җанкисәгем! – дип, Карабәк инде Айзирәкне арба өстеннән төшереп һәм кулларыннан тотып әйләндерде. – Синең дә менә шушылай сөендерер чакларыңны көтәм!

Ә ияргә менгәч, барыбер түзә алмады. Айзирәкне иелеп кенә яңагыннан бер үпте дә чаптарының касыгына төртте.

– Мин китим, кулларыма алып багыйм инде тизрәк!..

Болгарның диварлары күптән сукыр түгел, яннан куян йөгереп узганны да ярканатлар төсле шәйләп тора. Карабәк ташкирмән эченә аяк баскан иде, Алтынчәч тә, кырнак кызлар белән ясавыллар да ихатага тезелеп каршылады. Алтынчәчнең кулларында ефәк биләүгә төргән тиңсез бүләк. Актарып интекмәсен, җайсыз тиюе бар, дигәннәрдер инде, сабый йөзен ачык калдырганнар. Биләү авызында кызгылт яңак, почык борын, бармак башыннан да бәләкәйрәк ике сызык ирен. Карабәкнең каткан уч төпләрен, кайнар сулышын да сизенгәндер инде, һич тә көтмәгәндә ул күзләрен ачты. Нигә мине хуҗабызга кисәтми күрсәтәсез, дип рәнҗүдәнме икән, шактый яңгыравык тавыш белән аваз салды.

– Ү-у-ә-ә, ү-у-ә-ә!

Сабый тибенүгә, ефәк биләү астыннан арыш саламыдай сары чәчле нәни баш ачылды. Үзен тыеп тора алмыйча, Карабәк таш кирмәнне тутырып шатлык чәчте.

– Минем малай туды, минем угылым бар! Үзем кебек каралар рәтендә йөрмәсен дип, мин аңа Алтынбәк атлы шанлы исем кушам!

– Сугыш-казалар күрмәсен, бәхет-сәгадәт эчендә гомер кичерергә язсын бу нарасыйга, – дип артта кайсыдыр бер ясавыл пышылдады.

– Улыма орыш-афәтләрсез, түбәнлек-хурлыкларсыз гомер язса иде! – дип Карабәк кабатлады...

Теләкләре Ходай Тәгаләнең «амин» дигән чагына туры килмәгәндер, ике ай чамасы вакыт узуга, Сарайдан күңелгә ук булып кадалырдай хәбәр җибәрделәр.

– Аксак Тимер әмир миңа бигать китергән, алай гына да түгел, хәтта аркадаш булырга ант сулары эчкән Харәзем мәмләкәтенә бәреп кергән. Аның мәркәзе Үргәнечне яуламакчы булып, бер ай буе камап интеккән дә, теше үтмәгәч, кире борылган, ди. Иллә мәгәр Кабул ягындагы пуштуннар илә әфганнарның фетнәсен бастыруга, кабат Үргәнечне тезләндерергә ният кора икән. Үргәнечтәге Сөләйман суфига ярдәмгә бер-ике төмән чирү җибәрмичә булмас. Күмәк карар өчен мин диванга дәшәм.

Менә сиңа угыл өстәлү, менә сиңа ять-яшь ата булу шатлыклары! Барысы – чәлпәрәмә! Юкка гына яу-орышсыз тормыш ялварып догалар укымаган, саф сулы чишмә төбенә караган шикелле, Карабәк барысын да үтәли күреп торган, һәр тарафны дөрес гөманлаган. Болай булгач, чиксез тетрәнүләр кичерәсе, канлы елгаларга да чумасы бар икән! Их, ул Үргәнечләргә, ул Аксак Тимергә теш күрсәтеп, үз Урдабызга дошман чирүләре чакырмаска иде дә бит, тик Сарай хакимнәре кара гавам ризалыгын сорап торамыни?!.

*(Дәвамы алдагы саннарда)*

# ХӨРМӘТЛЕ КОЛЛЕГАЛАР!



Сезне «Казан утлары» журналы нәшер ителә башлауга 95 ел тулу уңаеннан ихлас күңелдән тәбрик итәм.


Татарстанда, гомумән, татар халкы гомер иткән һәрбер тарафта «Казан утлары» журналы зур абруйга ия. «Казан утлары» исеменә тугры калып, журнал халкыбызның җанына җылылык бирә, рухын ныгыта, әдәби һәм мәдәни тормышын яктыртуга хезмәт итә. Аның сәхифәләрендә халкыбызның бай тарихы, кайвакытта фаҗигале тормышы чагыла.

«Казан утлары» яңадан-яңа талантлар ача, әдәби әсәрләрне беренчеләрдән булып укучыларга ирештерә. Журнал редакциясендә талантлы әдипләр, иҗат әһелләре эшли, аның тирәсенә милләтебез язмышына битараф булмаган әдәбият сөючеләр туплана. Инде бер гасырга якын дәвердә «Казан утлары» меңләгән татар йортына якын дус, киңәшче булып килә.

Хөрмәтле коллегалар! Гадәттә, юбилей көннәрендә үткәннәргә нәтиҗә ясыйлар. Әмма бу – яңа эшләр башлау өчен дә бик кулай вакыт. Журналыбызның туган көнендә башкарган эшләр белән горурланып кына калмыйча, яңа кызыклы проектлар башлап җибәрик. «Казан утлары» гомер буе юлларыбызны якты итсен! Барлык хезмәткәрләргә нык сәламәтлек, бетмәс көч-куәт, иҗат уңышлары һәм укучыларыгызның арта баруын телим!

**Хөрмәт белән,**
**Римма РАТНИКОВА,**
*ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары,*
*ТР Журналистлар берлеге рәисе*

# УТЛАРЫ ДӨНЬЯГА НУР ЧӘЧӘ



Миңа татарчаны өйрәтә торган ике зур хәлфә булды. Берсе кечкенә вакытыннан татарның зур улына әверелгән Габдулла Тукай иде. Ул 27 яшендә үлмәсләр дөньясына күчте. Зур иҗаты бу көндә дә сау-сәламәт. Икенче хәлфәм – «Казан утлары» журналы. «Казан утлары» – бер мәктәптер. Татарчаның һәм татарлыкның мәктәбе. Бу мәктәп иң авыр вакытларда да Казаннан Америкага, Финляндиягә, Германиягә, Япониягә, Төркиягә, Полониягә, Австралиягә, Кытайга, Себергә, Питерга, димәк, әйтергә мөмкин, бөтен дөньяга бер ишек ачты. Татарның, татарчаның уты җитмәгән урыннарга Казанның утларын җибәрде. Татарның тормышын балкытып торды. Анда нәрсә генә язылса да, ул татарчаны яшәтте. Алга таба да шулай булсын иде. Без – Төркия төрекләре, төрки халыкларның, туганнарыбызның дуслык дөньясында күп еллар бер генә ирекле җөмһүрият булып калган Төркиядә шул өметтә торабыз. Татарлар, үз рухи байлыкларын саклаган хәлдә, мәңгегә яшәсеннәр! «Казан утлары»н күбрәк санда бастырып дөньяга тарату мөмкинлеге артсын. Таралган һәм таратылган һәр татарга Казанның якты утлары сибелсен. Татар әдәбияты – зур әдәбият. Аның бүгенге галимнәре, язучылары, шагыйрьләре дөнья әдәбиятын баетуда үзләреннән лаеклы өлеш кертәләр.

**Мостафа ӨНӘР,**
*Төркиянең Мәрмәрә университеты профессоры*

# «КАЗАН УТЛАРЫ» – ТАРИХИ ЕЛЪЯЗМА УЛ



«Казан утлары»на – 95 ел! Бу бер кеше гомере озынлыгына тиң вакыт аралыгы гына. Ләкин шул чор эчендә иҗтимагый хәятебездә нинди генә вакыйгалар булып узмады: көтелмәгән тетрәнүләр дә, зур табыш-югалтулар да, бөек ачышлар да. Нинди генә чор булмасын, «Казан утлары» һәрвакыт заман белән иңгә-иң атлады, милләтнең йөз аклыгы, намус көзгесе булып калды.

95 ел буена журнал бер генә көн дә эшчәнлеген туктатмады. Хәтта Бөек Ватан сугышы елларында күп кенә басмалар ябылганда да, «Казан утлары» үзенең утын сүндермәде. Ул да көрәшнең иң алдынгы сызыгында баручы татар язучыларына рухи таяныч, өмет, ышаныч булып торды. Журнал авторларының күбесе яу кырында ятып калды. Муса Җәлил, Фатих Кәрим, Абдулла Алиш, Гадел Кутуй кебек каһарман әдипләребез милләтнең горурлыгы, батырлык символы булып калдылар.

Бүген татар әдәбиятының классикасына әверелгән әсәрләр тәүге тапкыр «Казан утлары»нда дөнья күрде, укучыларга шушы басма аша барып ирешә. «Казан утлары» сынавы аша узмыйча, кем дә булса зур иҗат мәйданында танылу алдымы икән?! Юктыр, мөгаен.

Әдәби-нәфис һәм иҗтимагый-сәяси журнал буларак, «Казан утлары» туган телне, рухи мирасыбызны саклау һәм пропагандалауда, каләм әһелләренең профессиональ осталыгын үстерүдә, төрле милләтләр белән мәдәни бәйләнешләрне ныгытуда зур һәм нәтиҗәле эш башкарды һәм әлеге изге гамәлләрне бүген дә лаеклы дәвам итә.

Журнал татарны дәүләтле, телле, мәгърифәтле итү юлында авыр йөкне төпкә җигелеп тарта. Халкыбызның тарихын, гореф-гадәтләрен, әхлакый кануннарын әсәрләр аша укучыларга җиткерергә тырыша. Үсеп килүче яшь буынны ватанпәрвәрлек рухында һәм әхлакый тәрбияләүдә, аларның шәхес булып формалашуында журналда дөнья күргән әсәрләрнең роле биниһая зур.

95 ел – әдәби мохит өчен яшьлек әле ул. Ул үзенең авторлары белән яшәргәннән яшәрә бара. Журнал яшь каләм ияләренә дә киң мәйдан бирә. Әдәбиятыбызның киләчәге зур, өметле. «Казан утлары» – әдәби мирасны буыннан-буынга тапшыручы, безне берләштерүче байрак ул.

«Казан утлары» киләчәктә шушы олы миссиясен дәвам итеп, туган телнең сафлыгын саклар, яшь буынны галиҗәнап китап дөньясына тагын да якынайтыр, татар халкын дөньяга танытуда армый-талмый хезмәт итәр, әдәбиятыбыз офыкларын киңәйтер дип ышанабыз.

**Данил САЛИХОВ,**
*Татарстан Язучылар берлеге рәисе*

# «АҒИҘЕЛ» ТӘБРИКНАМӘҺЕ



«Ҡазан утлары»…Ошо ике мәғрүр һүҙгә күпме балҡыш, күпме нағыш, илаһи йыр-моң һыйған! Ошо ике ғәзиз һүҙҙән боронғолоҡ та, заман һулышы ла, татар хәтере лә, ил-йорт ғәме лә бөркөлгәндәй. Ошо ике һүҙҙән хеҙмәткә илһам, ижад сәме, яу ораны уянғандай, ғорурлыҡ, ватансылыҡ тойғоһо ла зиһендәрҙе яҡтыртып ебәргәндәй.

Ҡәҙерле ҡәрҙәштәр! Абруйлы журнал, әүәл төрлө исемдәр менән аталып сыҡта ла, тәүге һандарынан уҡ татар халҡының мәшһүр әҙәбиәтен туғандаш телле, уртаҡ динле халыҡтар, шул иҫәптән башҡорт милләтенә лә ихлас еткереп тора. Хатта ки был үҙенсәлекле, йәшәйеш ҡиблаһылай баҫма, гүзәл Ағиҙел – Камаға, Кама – Волгаға, Волга Каспийға ҡойғандай, алҡын дарья булып алыҫ-алыҫ ерҙәргә шифалы рухиәт һирпте һәм һирпә. Беҙҙе «Ҡаҙан утлары»ның бөгөн дә әүәлге традицияларҙы һаҡлап, лөғәт нәфислеген, әҙәби-мәҙәни ҡаҙаныштарҙы нығытыуға индергән өлөштөң һәлмәклеге һоҡландыра.

Башҡорт таҡмағын икенсегә бороборaҡ, һеҙгә, хөрмәтле ҡәләмдәштәр, түбәндәге теләкте еткерәбеҙ:

*Һиңә әле 95 кенә*
*100-өң дә бит тулмаған.*
*Йөҙөң тулһын, меңең тулһын –*
*Иртәгәң сағыу булһын!*

Ошоғаса тарих арбаһында бергә елдек, киләсәктә лә бергә еләйек!



*«Ағиҙел» редакцияһы һәм мөхәрриәте,*
*бихисап уҡыусылары исеменән журналдың*
*баш мөхәррире* **Рәлиф КИНЙӘБАЕВ.**
*Башҡортостан, Өфө*


# ТАТАР ДӨНЬЯСЫНЫҢ ОЛУГ БӘЙРӘМЕ



Узган ел «Йолдыз» журналының 40 еллыгы булды. Ул 1976 елда Ташкентта чыга башлады. Быел исә «Казан утлары»на – 95 ел. Шуны әйтергә кирәк: бу ике журнал – татар дөньясының журналлары – гомер-гомергә язучылар арасында хезмәттәшлектә булды. 1929 елда «Безнең юл» журналында латин хәрефләрендә кырымтатар язучылар җитәкчесе Җәмил Сәйдәмитевнең «Ике арада тәрҗемә эшләрен башларга кирәк» дип исемләнгән мәкаләсе чыга. Димәк, хезмәттәшлек ул вакытта ук башланган. Бу – зур әһәмияткә ия. Ул чорда башланган хезмәттәшлек бүген дә дәвам итә. «Казан утлары»нда 1991 елда кырымтатар язучыларының иҗатларын яктырткан туплама чыкты. «Йолдыз»да 2015 елда татар әдәбиятына багышланган «Татар язучылары милләткә хезмәт итә» дип исемләнгән язма һәм бүгенге көннең күренекле шагыйрьләре – Р.Фәйзуллин, З.Мансуров, М.Мирза, Г.Морат, Р.Зәйдулла һ.б. иҗатлары дөнья күрде. Шулай ук кырымтатар шагыйрьләренең Тукайга багышланган шигырьләре дә басылды. Дустанә мөнәсәбәтләр дәвам итсен иде. Без – бердәм татар дөньясы. Кырым татарымы ул, Казан татарымы – без бер дөнья. Төрки дөньяның эчендә иң зур дөнья – ул татар дөньясы. Олуг бәйрәм белән!


**Диләвер ОСМАН,**
*шагыйрь, «Йолдыз» журналының баш мөхәррире,*
*Кырымтатар Язучылар берлегенең җаваплы сәркатибе*



Рәшит
Бәшәр

# И ҖАНЫМНЫҢ САДӘ ЧАКЛАРЫ

## Сафлану

Төбенәчә киереп
Ачтым ил ишекләрен:
Керләнеп каткан илне
Җилләтеп алыйм әле.
Саф һаваны иркенләп
Бер сулап калыйм әле.
Җиһан каршында җаным
Япа-ялгыз калганда,
Җиденче кат күкләрдән
Сыныма нур тамганда,
Бер гөнаһсыз сабыйдай
Басып торам яланда.
Кыр казының каурые
Ята яшел аланда.

Тирә-ягым чип-чиста,
Бер тузан юк, кер дә юк.
Бөтен җаннар шыр ачык:
Үч тә юк, мәкер дә юк.
Һәр күзәнәктә сафлык,
Ачык күңел ишегем.
Көнем – кояш, төнем – ай,
Хөсетлек юк, юк шигем.

Азга гына булса да
Пәйгамбәр бул! Оҗмахта
Яшәп алчы, и кешем!

---

Рәшит БӘШӘР (1949) – *шагыйрь һәм прозаик; «Сандугачлы бишек», «Ачык капка», «Былбыл оясы» һ.б. китаплар авторы. А.Алиш исемендәге әдәби премия лауреаты. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.Чаллыда яши.*

* * *

*Илдә ниләр бар икән?*

Х.Туфан

Илдә җил исә микән,
Болытлы микән илдә?
Чишмәләр кипми микән,
Таллар шаулыймы җилдә?

Оныклар кем телендә
Сөйләшә икән илдә?
Өй саламы ир-атлар?
Караламы зиратлар?

Әле аязып китә,
Әле болытлый күңел...
Көннәр көнгә бәйләнә,
Көннәр төнгә әйләнә,
Җаваплар анык түгел.

## Төн

Татлы төшем бүлдереп
Уятты мине бу төн.
Сискәндереп, сагайтып,
Уйлатты мине бу төн.

Кан-яшь юа җир йөзен,
Шашынып Иблис йөри.
И кешеләр, үзгәртеп
Булмас микәнни берни?

Төшләрдә генә яшәп
Калыплар булмый шул ул.
Сугыш, көчләүдән азат
Халыклар булмый шул ул...

## Ак чатыр

Киң далада җилли ак чатыр,
Чатыр тирәсендә кылгандыр.
Иртән ире ауга киткәндә,
Яшь-яшь хатын дога кылгандыр.

Кылганнарны йомшак тирбәтеп
Агып китте җыру тавышы.
Хатын җырлый... Җитез лачынның
Әкренәйде канат кагышы.

Ташка менеп баскан яшь җәйран
Кымшанмый да... Оеп тын тора.
Яшь җәйранны җилләр иркәли,
Урман өсләрендә моң тора.

Казан тирәсендә кайнаша
Ак яулыклы гүзәл Сөмбелә.
Куян шулпасына хуш исле
Төрле тәмләткечләр сибелә.

Чибәркәйнең читек астыннан
Чишмә тибеп чыгар шикелле.
Алкасына кунган пәрәвез,
Борын очы чак-чак сипкелле.

Ауда йөргән чибәр яшь ирне
Яшь хатынның җыры чакыра.

Кайтыр аучы... Атын тышаулар,
Гөрләшерләр ап-ак чатырда.

...Алар, бәлки, минем бик ерак
Әбием һәм бабам булгандыр.
Төшләремә кергән чатырга
Җир җиләге исе тулгандыр.

## Төн авазы

Сокландым бүген төн белән
Гаҗәеп күренешкә:
Ак бәтиләр сикерешкән
Ялан-кыр керде төшкә.

Кемдер дәште: – Кузгал, бәндә,
Бәхет капкасы ачык.
Төн авазын тыңларга син
Гөлле бакчаңа ашык!

Чыклы үлән... Гөлләр исе...
Көмеш нурга төренеп
Басып торам ай астында,
Ак сынга әверелеп.

Каядыр чишмә челтери,
Ат кешнәвен ишетәм.
Сузылып ак песи чыга
Ачык калган ишектән.

Бакча башына чаба ул,
Ай нурын ера-ера.
Чык коела таң гөленнән,
Сукмак җемелдәп тора.

Шадра айдан кемдер мине
Җентекләп күзли кебек.
– Син дә ялгыз, мин дә ялгыз,
Кил! – дип кул изи кебек.

Сәер бер хис җилкендерә:
Нурга төренгән көйгә
Ашасы килә күкләргә...
Кирәсе килми өйгә.

## Тургай

Тургайларны тыңлап саташтым,
Истирәхәт иттем төшемдә.
Йомшак йомгак тургай баласы
Килеп-килеп кунды түшемә.

Томшыгында көмеш тамчыдыр,
Каурыйларын җылы җил тарый.
Чабып киттем, очты тургай да,
Бигрәк нәни инде, и наный.

И җиһанның моңлы мәлләре,
И җанымның садә чаклары.
Сайрый галәм, юллар читендә
Җилбер-җилбер каен чуклары!

Эсселектән көйгән гөлләрнең
Балтырларга куна тузаны.
Күк читләре сары, сап-сары,
Саргайткан ла бугай көз аны.

Үзәгемне өзеп сайрады
Галәм бишегендә атынып.
Туган җирнең даһи җырчысы
Йөрәгемә керде атылып.

Сайрап чыгар тургай төн буе,
Тыпырчыныр җылы түшемдә.
Иртәгә дә сайрар, йөрәгем
Ярылмаса бүген төшемдә.

***

Таң чыкларын киптерәм,
Болында учак яктым.
Учларымда эретәм
Томанын туган якның.

Чишмә янында күрәм
Көянтәле бер кызны.
Чылтыратып чиләген,
Кулларын күккә сузды.

Ак шәл сыман ак томан
Шуып төште иңеннән.
Нур чәчелде ирене
Читендәге миңеннән.

## Яңа ай туган мәлләр

Яңа ай туган мәлләр...

Буранлар, җилләр инде,
Сукмак читендә үскән
Агачны ияр инде,
Юлларга сыртлап-сыртлап
Ак көртләр өяр инде.

Яңа ай туган мәлләр...


Җаныем килә инде,
Битемне сыйпый-сыйпый:
«Сагындым!» – дия инде.
Һәм башын оялчан гына
Аскарак ия инде.
Без – гашыйклар. Ходайның
Бер гөнаһсыз бәндәсе!
Кочагымнан чибәрнең
Шуып чыга гәүдәсе.
Чыркылдап бер көлә дә
Читкәрәк мине этә.
Бияләйләре карлы
Сукмакка төшеп китә.
Көлтә-көлтә нурларда
Югала кинәт кенә.
Диярсез: «Һәммәсе
Матур әкият кенә!»

Яңа ай туган мәлдә
Яшьлеккә кайтып киләм.
Ул чакларны бүгенгә
Кайтарып булмый, беләм.
Күрешеп яшим көн дә
Ерак яшьлегем белән.

Ак мәрҗәннәр коела
Таңда ачылган гөлдән.
Баллы чәчәк исләрен
Сузылып сулый үлән,
Сулыгып сулый үлән...

Туып килә яңа ай...

Элекке аем түгел,
Ул да үзгәргән бугай?!



Вакыйф
Нуриев

# МӘҺДИЕВ ҺӘМ...

БӘЯН-ХАТИРӘ

**...ИПИ**

МӨХӘММӘТ МӘҺДИЕВ ЯЗА: «Бар шундый малайлар – атна буе юкбарны ашап яшиләр дә, шимбә көнне авылларына бер кирпеч ипи алып кайталар. Сугыш вакытында авылга атна саен бер кирпеч ипи кайтарып кара әле син! Дөньяда шуннан да зур байлык булырмы?» («Без – кырык беренче ел балалары» әсәреннән.)

ӘНИ СӨЙЛИ: «1943 елның җәй ахыры. Без Мөхәммәт Мәһдиев, Зөлхия Миңнекәева һәм мин (Арча районы Сеҗе авылына кияүгә чыгып, шунда кырык биш ел балалар укыткан әнием Нәкыя Абдуллина. – *В.Н.*) Яңа Чүриле районы Сикертән җидееллык мәктәбен «5»легә генә тәмамладык. Сүз куештык: Арча педагогия училищесына китәргә! Ул урман артындагы Үрнәк бистәсендә. Документларыбызны тапшырдык. Хыялыбыз – укытучы булу! Әнинең мине җибәрәсе килми. Ничек җибәрәсе килсен, әти, абый – сугышта, мин – әни белән калган дүрт баланың кул арасына керә башлаган бердәнбере. Колхозда «помбригадир» булып эшлим. Укырга теләк шулкадәр зур ки, китәргә әзерләнәм, лапаста кача-поса чемодан ясыйм. Тактадан. Өйдә вак кадак таба алмадым. Йөзлене җибәрәм. Кадак тышкы якка чыкмасын дип, эчке якка авыштырыбрак кагам. Эш беткәч, чемоданны ачып карасам, бөтен кадак эчкә чыгып тырпаеп тора. Үзләрен бөгеп тә булмый.

Кичкә таба Гөберчәктән Мөхәммәт килде. Бер җәйдә буйга үсеп киткән, каралган. Үгез җигеп көлтә ташыган, җир сөргән. Шуларны сөйләде.

Иртәгесен әни басуга киткәч, эчен кадак камап алган чемоданымны алдым да Зөлхияләргә чаптым. Аннары ике кыз Гөберчәккә юл алдык. Анда безгә Мөхәммәт кушылды. Шулай итеп, өчәү юлга чыктык. Зур юлга! Белем юлына! Алда күпме михнәт, газап күрәсебезне без әле белмибез.

Өч классташ. Тактадан ясалган өч чемодан. Тузанлы юл...

Тирә-якта ни кычыткан, ни алабута калмаган. Барысын да ашап бетергәннәр.

---

Вакыйф НУРИЕВ (1958*) – язучы. «Бүре кадәр бүрек», «Җиденче палата», «Ана догасы» китаплары авторы. ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре. Абдулла Алиш исемендәге әдәби премия лауреаты. Казанда яши.*

И ул елларда... Үзәккә үтте ачлык. Әнинең: «Һай балалар, балалар... Сезгә нәрсә ашатыйм инде мин», – дип, безне кочаклап елаганы хәтердә. Мөхәммәтләр дә ач. Әнисе каяндыр аз гына он юнәтеп, кычыткан ашына умач салган көн өйдә зур бәйрәмгә әверелә.

Май аенда шимбә көнне укудан кайтышлый Мөхәммәт, Зөлхия һәм мин Күчтем авылының бәрәңге басуына китәбез. Җилләнгән басуда кар астыннан чыккан, яңгыр, кар сулары юган бәрәңгеләр була. Шуннан әниләр күмәч пешереп бирә иде. Без аны дүшәмбе көнне үзебез белән алып китәбез һәм алты көнгә тигезләп бүләбез. Безгә аз гына эләккән шул черек бәрәңге кәлҗемәсе дә ярап торды ул чакта.

Берсендә шулай, Чөмә-Елгадан Рафаэль Кадыйров (аның апасы Курса разъездында пекарняда эшли иде) дәрес вакытында Мөхәммәткә аз гына ипи сындырып бирде. Мөхәммәт аны шунда ук капты һәм, укытучыга сиздермәскә тырышып, чәйни дә башлады. Бәнәнә апа дәресе иде. Ул сизми каламы соң инде?! Безгә биргән сорауның җавабын Мөхәммәттән сорады. Мөхәммәт авызындагы ипиен чәйнәми генә йотарга мәҗбүр булды.

– Йоттыңмы инде? – дип сорады укытучы.

– Йоттым, апа, тик ипинең тәмен белмичә калдым, – диде Мөхәммәт, авыр сулап.

Училищеда безгә карточкага ипи бирәләр бит әле. Өйдәгеләр аны бөтенләй күрми ләбаса. Шуңа күрә безгә бирелгән ипине, ач булсак та, ашамаска тырышабыз. Аны каядыр ераккарак яшерәбез. Югыйсә, нәфесебезне тыя алмыйча, ашап бетерүебез бар.

Беркөнне бүлмәгә Мөхәммәт килеп керде. Миңа үзенең ипиен бирә.

– Нәкыя, чемоданыңа салып куй әле, – ди.

– Юк, юк, Мөхәммәт, салып куя алмыйм, – дим.

– Нигә салмыйсың?

– Чемоданымның биге начар. Ипиеңне урласалар... Сиңа ни дип җавап бирермен?!.

– И-и-и... Нәкыя, Нәкыя!.. Син кешенең башы ике дип беләсеңме әллә? Синең ул кадаклы чемоданыңа курыкмыйча кем кулын тыксын инде?!

1947 елның 20 августы. Яңа Чүриле районы үзәгенә конференциягә җыелдык. Мөхәммәт тә шунда. Мин, кечкенә гәүдәле, колакка да катырак булгач, алгарак утырдым. Зал тып-тын. Кемдер аркама кагылып алды. Ап-ак чәчле бер апа миңа мәктүп бирә. Борылуга берничә рәт арттарак утыручы Мөхәммәтнең миңа туп-туры карап торуын сиздем. «Записка»ның аныкы икәнен шунда ук белдем. «Нәкыя, буфетта ипи саталар. Күпме алсаң да, бирәләр», дип язган ул. Эчемә шатлык сыймады. Тәнәфестә чиратка басып, ике ипи алдым. Димәк, өйгә энем һәм сеңелкәшләрем янына күчтәнәч белән кайтачакмын.

ХӘТЕРЕМ ДӘФТӘРЕННӘН: «Бер елны безне – бер төркем язучыларны Арчага чакырдылар. Уракның иң кызган вакыты иде. Безне басуларга алып чыгачаклар. Маршрут билгеле: Курса, Курса Почмак, Масра, Казанбаш, Гөберчәк, Сикертән... Юлыбыз туган авылым Сеҗе аша үтмәсә дә сөендем. Күрше авыллар да минем туган як түгелмени?! Минем туган як түгелмени аларның басу-кырлары, урман-чытырманнары?! Атаклы Курсави, Ахун, Мәһдиевләрне биргән якка кайтабыз. Менә Мәһдиев язган «Пауал тегермәне» турысын, «торналар төшкән җир»не үтеп, «Масра басу»га күтәреләбез, аннары Гөберчәк урманына төбәп юл тотабыз. Якташ язучыбыз «дөньяның

зыңлаганын» тыңлап торганда, «тын, бик тын» булган басуларда бүген «сабырлык, акыл чәчү» турында уйлап та булмый. Монда көрәш бара. «Ак барс» дип аталган хуҗалыгыбыз игенчеләре кырны штурмлый. Дөресен әйтим, мондый уңышны беркайда да күргәнем юк иде. Хикмәти хода, шушы галәмәт минем туган ягымда бит әле. Җирне әйбәтләп эшкәртү, тиешенчә ашлау, сортлы орлык чәчүнең хикмәте икән. Ярый әле комбайннар зәһәр. Барысы да чит илнеке. Без белгән «СК»лар бу кырга керсә, икмәкне йота алмыйча, шунда ук тончыгачак ди. «Һоланд»лар артыннан сузылып калган пакусларны гына күр әле. Алар шундый калын, шундый биек ки, без утырган машина килеп бәрелер кебек.

Икмәк ташый торган «КамАЗ»лар берсе артыннан берсе китеп кенә тора. Башта алар кыр буйлап урманга менә. Аннары урман кырыеннан Гөберчәккә юл ала.

Алар нәкъ менә Мөхәммәт абый, Зөлхия апа, әниләрне ачка интектергән юлдан гәрәбәдәй сап-сары ашлык – ипи төяп чаба...»

## ...бүреләр

МӨХӘММӘТ МӘҺДИЕВ ЯЗА: «Безнең бабаларыбыз мәҗүсилек заманында бүре культына табынган булу ихтималын фольклорчылар еш әйтә. Шулайдыр, шулай булгандыр. Бүредән курку белән бергә халык күңеленең бик тирән төбендә бу хайванга курку катыш яшерен ихтирам, олылау хисе ятканын белмибезмени?

– Кичә төнлә бүре килгән, – дип иртәгесен сөйләнгән хәбәр шом катыш серлелек, зурлык, әһәмиятлелек белән йорттан йортка йөри иде. Бүре килгән... Әйтерсең, кабереннән торып борынгы баба, изге ата килеп киткән, ә без берни белмичә йоклап ятканбыз». («Торналар төшкән җирдә»)

ӘНИ СӨЙЛИ: «Ах ул бүреләр!.. Дүшәмбе укырга барганда, еш чыгалар иде. Таң сызылып кына килә, бүреләр инде ауда. Әтидән ишеткәнем бар иде, имеш, бүре сыбызгы тавышыннан курка. Авыл малайларыннан бер сыбызгы юнәткән идем. Берсендә шулай бүре чыккач, битемне кабарта-кабарта шуңа өрә башладым. Сыбызгымның сызгыруына бүренең койрыгы да селкенмәде. Мөхәммәт кенә миңа гаҗәпләнеп карап куйды:

– Нишлисең син, Нәкыя?

– Бүре куркытам.

– И-и-и... Нәкыя, Нәкыя!.. Болар бит – сугыш ягыннан качып килгән бүреләр. Болармы?.. Болар – «зениткалар», «артиллерия» һөҗүмнәрен күргән бүреләр. Снарядлар шартлавын ишеткән, пуля яңгырын кичкән бүреләр. Исләре китә синең сыбызгы сызгыртуыңа.

Бүре чыккач, Мөхәммәтнең безгә куйган таләбе – ерткычның күзенә карамаска, аңа арка белән басмаска. Иң шәбе – аңа ян белән тору. Кемдер, хәтерем ялгышмаса, Марсель Галиев бугай, язып та чыкты әле. Мәһдиев сөйләшкәндә әңгәмәдәшенә ян белән торуны кулай күрә, чөнки безнең татар сүзен тыныч кына әйтә алмый, корсакка, күкрәккә төртә башлый, дип. Бу сүзләр хактырмы, юктырмы? Хак икән, димәк, сабакташымны саклану чараларына бүреләр өйрәткән булып чыга түгелме?

Бүреләр, бүреләр. Ах ул бүреләр!..

Берсендә шулай карточкага ипи бирделәр. Бер атналык кирпеч ипи. Шуны тизрәк алып кайтып бирәсе, өйдәгеләрне сөендерәсе килә. Ачлар бит инде.

Уйлаштык та авылга атна уртасында кайтып килергә булдык. Хәзергә әле юл да бар. Аннары кар явачак, бураннар башланачак. Мөхәммәт кайта алмады, ул – «дежурный». Аның безне җибәрәсе килмәде. Ни үгетләде, ни ялынды. Тыңламадык. Зөлхия белән кайтып киттек. Исән-имин кайтып җиттек. Сеңелкәшләрне, энекәшләрне сөендердек. Төнге өчтә китәргә чыктык. Дәрескә өлгерәсе бар. Училищеда тәртип кырыс. Биш минутка гына соңа калсаң да – куалар! Гөберчәкне үттек, урманга җиттек. Уңда – урман, сулда – кыр. Сулыш алырга да куркып барабыз. Отыры таң беленә башлады. Төнлә кырпак кар яуган. Кыр ала-кола булып ята. Басуга түгелгән тирес өемнәре дә ала-тилә. Чү! Шул өемнәрнең берсе селкенә башлады. Икенчесе дә, өченчесе дә шуып барган кебек. Минем күземә генә шулай күренәме соң? Зөлхиядән сорыйм. Ул җан ачысы белән кычкырып җибәрде:

– Нәкыя! Бүреләр!!!

– Бүреләр?!.

Әнә, тезелешеп, кырны ярып, урманга таба менеп баралар. Нәкъ безнең каршыга чыгарга чамалый болар. Баш бетте болай булгач.

Мөхәммәт!.. Зөлхия белән икебез дә берьюлы әйттек бу исемне. Их, Мөхәммәт! Кичә сүзеңне нигә җиргә салдык икән?! Күңелдә – үкенү, үкенү, үкенү...順ыбызда син булсаң иде хәзер. Ерткычлар белән дә уртак тел таба белә идең бит син.

Күңелнең бик тирән бер почмагында «бәлки, бүреләр юл аша чыгарлар да урманга кереп китәрләр», дигән өметле уй да бар иде әле. Аларның юл буенда түгәрәкләнеп утыруларын күргәч, ул өмет тә киселде. Ерткычлар урманга да кереп китмәде, безгә дә карамады. Гамьсез генә оеп утыра бирделәр. Без ни алга, ни артка бара алмыйбыз. Елыйбыз. Безне бүреләрдән куркып елыйлар, дип уйлыйсызмы? Куркабыз инде. Сүз дә юк. Юлдан каршыбызга бер хатын-кыз килүен күргәч, бүреләрдән курку хисе бераз басылгандай булды. Әмма ул хатынны күреп, сөенергә дә, сөенмәскә дә белмәдек. Алда безгә дәһшәтлерәк куркыныч яный бит әле – без дәрескә соңга калачакбыз. Безне училищедан куачаклар!

Озак утырды бүреләр. Тирләгәннәр, пешкәннәр. Сыртларыннан пар күтәрелә Яктыргач кына берсе – араларында иң зурысы, торып басты. Вожактыр инде ул. Биек чыршыларга карап, ым какты. Бүре көтүе ашыкмый, акрын гына, дәрәҗәсен белеп кенә шомлы урман куелыгына кереп югалды. Алар утырган урында, кар эреп, кучкыл түгәрәкләр хасил булган иде. Ә теге хатын Тылаңгырныкы булып чыкты. Гөберчәккә барышы икән.

Хәлбуки, без училищега килеп кергәндә, дәресләр башланган иде инде. Язмышыбыз бик тиз хәл ителде. Бусаганы атлап керүебез булды, директор үзе басып тора инде. Ул: «Хәзер үк күземнән югалыгыз! Ычкыныгыз моннан! Приказ чыгар!» – дип кычкырды да китеп барды.

Без тулай торакка кайтып елашып утырганда Мөхәммәт килеп керде. Беренче тәнәфескә чыгуга, безнең янга йөгергән. Борчылуы йөзенә чыккан. Аңаниләр булганын сөйләдек. Ул: «Беркая китмәгез! Бүлмәгездә генә утырыгыз», – диде дә икенче дәрескә йөгерде. Кичкә таба Мөхәммәт бүлмәбезгә балкып-сөенеп килеп керде. «Кызлар! Борчылмагыз. Училищеда каласыз. Приказ булмаячак!» – диде ул. Шатлыгыбыздан нишләргә белмәдек. Укудан соң Мөхәммәт Тылаңгырга барган. Теге хатынны эзләп тапкан. Аны директорга алып килгән. Безгә очраган юлчы иртәнге вакыйганы түкми-чәчми сөйләп биргән. Шул төнне бүреләрнең Төрнәледәге фермага кереп бөтен сарыкны

буып чыгулары турында хәбәр таралган. Аны директор да ишеткән. Шушы, иртән без күргән бүреләр җиткән бит инде ул бичара сарыкларның башына. Төрнәле ягыннан менделәр дә шул. Корсакларын кан белән тутырган тук бүреләр булган алар. Әйтәм аны, безгә борылып та карамадылар. Аларның безгә – яшь кызларга карата булган битарафлыгына ачуыбыз да килмәде микән әле».

ХӘТЕРЕМ ДӘФТӘРЕННӘН: «Казанда, университетта беренче курста укып йөргән чагым. Беренче сессия. Беренче имтихан. Мин авылда әзерләнәм. Өйдә үзем генә. Әти-әни эштә. Укып ятам. Башым революцияләр, съездлар, сугышлар белән тулы. Күз алдымда саннар биешә. Ул даталарны ничек хәтердә калдырып бетермәк кирәк. Укыдым-укыдым да урам әйләнеп кайтырга булдым. Төтен баганалары белән күкне терәтеп торган ак авыл. Ак дөнья. Һаваның сафлыгыннан баш әйләнә. Клуб тәрәзәсендә ут бар. Сугылып чыгасы иттем. Керсәм... университетта безне татар теленең нечкәлекләренә өйрәтүче укытучыбыз Хәлил Сәлимов елмаеп басып тора:

– Син бу авылданмыни?

– Әйе, минем туган авылым. Сезне нинди җилләр ташлады?

– Без концерт белән кайттык. Таһир Якупов, Нәфисә Василова.

Миндә имтихан кайгысы бетте. Нигә кирәк Керенский-Меринскийлар, Капланнар-Мапланнар... Таһир, Нәфисә кебек халык бәгыреннән чыккан җырчылар авылга көн саен килеп тормый.

Концерт шәп булды. Халык клубка чак сыйды. Мәшһүрләр кич буена моң сипте. Хәлил Сәлимов университетның журналистика бүлегендә укучы Альберт Һадиев язган, бер абзыйның фронтта һәм мунчада күргәннәре турындагы хикәяләрне сөйләп эч катканчы көлдерде. Концерт барганда, клубның ишегеннән, бүрәнә ярыкларыннан пар чыгып торды.

Иртәгесен буран башланды. Юлларны кар күмде. Имтиханга әзерләнү турында уйлыйсы да юк. Казанга ничек китәргә? Башта шул кайгы. Артистлар да китә алмады. Хәер, аларга борчыласы юк. Хәлил абыйны кунарга үзебезгә алып кайткан идем. Таһир Якуповны да чакырдык. Ашарга-эчәргә бар. Әни коштабак тутырып ит пешерде. Сыйланып тик ят. Иртәгесен клуб көн буена ачык булды. Халык яраткан артистларыннан аерыла алмады. Авылдашларым өчен бер бәйрәм булды бу буран. Минем генә кәеф юк. Имтиханга барып җитә алмасам, университеттан куарлар дип куркам.

Бер тәүлек дулаганнан соң буран тынды. Мин, төнге өчтә торып, юлга чыктым. Артистлар йоклап калды. Бүген имтихан. Авылдан сигез чакрым ераклыктагы Мөндешкә карга бата-бата менәсе. Стансага җитәрәк, кечкенә генә Либәдән дип аталган зиреклекне үтәсе. Аны үткәндә, таң билгеләре беленә башлаган иде инде. Шулвакыт зиреклектән бүре атылып чыкты. Үзе бозау кадәр, башы атныкы кадәр. Хәл китте. Кулда таяк бар-барын. Өскә ташланса, ул таяк белән генә нишли алам мин?! Зиреклектән кинәт чыккан бүре кинәт кереп тә китте. Стансага килеп җиткәнче адым саен артыма борылып карадым. Бүре бүтән күренмәде. Поездга кереп утырганда, хәлем тәмам беткән иде. Казанга килеп җиткәч, вокзал янында җиденче троллейбусны көтеп иза чиктем. Ул килмәгәч, университетка җәяү чаптым, югыйсә, имтиханга өлгермәячәкмен. Бураннан соң җылытты. Казанда кар эри. Тау менгәндә тирләдем-яндым. Авылдашым, ак тегүче Ибрай бабайның калын сарык тиресеннән тегеп биргән тунын салып ташлардай булдым. Мин килеп кергәндә, профессор Субич аудиториядә үзе генә иде.

Ведомостьларны портфеленә салып маташа. Ни өчен соңга калуымны аңлата алган кадәр аңлатып бирдем. Ул миңа гаҗәпләнеп карап торды да билет алырга кушты. Алдым. Беренче сорау: «Думская тактика большевиков». Большевикларның Думада күбрәк урын алырга теләүләрен генә беләм. Шуннан артыгын әйтә алмыйм. Гомумән, мин нидер әйтерлек, сөйләрлек хәлдә түгел идем. Беренче имтиханда ук – «провал». Университеттагы соңгы имтиханым да шушы булыр. Хәзер тулай торакка кайтып әйберләремне җыям да авылга китәм. Фермада яки конюшнидә эшләмәслек егетме мин?! Мәктәпнең завучы Тәлгать абый: «Университетны тәмамлагач, авылга кайтырсың. Мәктәпнең стена гәҗитенә баш мөхәррир итеп куярбыз сине», – дип тә ышандырган иде. Бәлки, хәзер үк куярлар. Җитмәсә иртәнге бүре күз алдымда тора. Казанда, университетта калган тәкъдирдә ул минем каршыга тагын чыгачак. Төштән соң укыгач, мин авылдан дүшәмбе китәм. Бер төн булса да өйдә кунасы килә. Юлда үзем генә. Кемнең төнге өчтә торып китәсе килсен.

Тулай торакка кайтып әйберләремне тутыра башладым. Кулыма Мөхәммәт Мәһдиевнең «Фронтовиклар» китабын алгач, әллә нишләп киттем. Педучилищеда нинди михнәтләр күреп укыганнарын әни миңа сөйләгән иде инде. Ач булганнар – укуны ташламаганнар. Юлсызлыктан интеккәннәр – укуны ташламаганнар. Каршыларына бүреләр өере чыккан – укуны ташламаганнар. Син?.. Караватка утырдым да үз-үземне эттән алып эткә салдым. Мөхәммәт абыйның: «Имтиханны бер бирмәсәң, тагын кереп була бит аңа», – дип әйткән сүзе дә искә төште. Авылда минем турында, Мәһдиев аны университетка «по блату» кертте, дигән сүзләр дә йөри бит әле. Хәзер әйтәчәкләр: «Әһә, по блату» кергән иде, укый алмады. 1981 елда журналистика кафедрасы мөдире Флорид Әгъзәмов «Социалистик Татарстан» (хәзер – «Ватаным Татарстан») газетасының 19 ноябрь санында минем турында язып чыккач, «по блату»ны авыл бүтән әйтмәде. Язмада мондый юллар бар иде: «Туган төбәгендә борын төрткән һәр сәләтле егет-кызга үтә игътибарлы, журналист җанлы Мөхәммәт Мәһдиев тә әлеге абитуриентка «өметле, тырыш егет» дигән бәя бирде.

«Фронтовиклар»ны «Казан утлары» журналыннан укыган идем инде. Хәзер китабын укыйм. Аны, портфелемә салмыйча, кире шүрлеккә куйдым. Мин университетта калырга булдым. Дүрт көннән соң Субичка имтиханны тапшырдым. «Бишле»лек сөйләдең, «дүртле» куям, чөнки «пересдача» бит, үзең беләсең», – диде профессор.

Либәдән зиреклегеннән чыккан теге бүре исә станса миченә ягучы Галимҗан абзыйның эте булып чыкты».

### ...мода

МӨХӘММӘТ МӘҺДИЕВ ЯЗА: «Арткы рәтләрнең берсендә ялт та йолт килеп Әнвәр Ахунҗанов утыра – монысы факультетта киенү моделе. Аның өстендә иң затлы костюм, йә Польшаныкы, йә Югославиянеке. Ул безнең шикелле Казанның дүртенче фабрикасыныкын беркайчан да кимәс. Аның костюмына карата галстугы, галстугына карата күкрәк кесәсеннән күренеп торган бер кисәк тукыма булыр. Штиблетларын буямас өчен ул трамвайга кермәс, гел такси белән генә йөрер. Баскычтан – баскычка. Көненә ничә тапкыр очрашсаң да, өр-яңадан кул биреп күрешер һәм әйтер:

– Мәһди, бу галстугың килешми. Иртәгә мин сиңа икенче галстук алып киләм.

Ләкин икенче көнне син аны күрә алмыйсың – Әнвәр абый ул көнне, һичшиксез, комиссионкада була, югославский костюмын шунда тапшырып, япон материалыннан яңа костюм тектерергә ательега йөгергән була. Факультетта мода ягыннан ул бер генә ирне дә үзеннән уздырмады, без мокытларга һәрвакыт үрнәк булып, модель булып торды». ( «Ачы тәҗрибә»)

ӘНИ СӨЙЛИ: «Абыем Нигъмәт сугышта яраланып кайтты да Казанда тимер юлга эшкә урнашты. Бервакыт киндер капчыклар кайтарып атты ул. Шул капчыклардан әни миңа бишмәт тектерде. Фасунлы бишмәт килеп чыкты. Иңсәләре күпертмәле, җиңнәре манжетлы. Гәүдәгә дә ятышлы. Бер атна киеп йөргәннән соң, әни аны, Чүрилегә алып менеп, урыслардан мандырып алып төште. Тик буявы тигез сеңмәгән. Әллә ничек ала-кола булып калган. Шулай да училищеда тагын бер атна киеп йөрдем әле мин аны. Әни тагын Чүрилегә алып менеп мандырып алып төште. Шәп манганнар бу юлы. Ялык-йолык итеп тора. Киеп киттем училищега. Мөрәләнең Әлтафи яныма килде дә: «Нәкыя, киемнәрең бигрәк күп синең», – дип әйтеп куйды. Мөхәммәт тә шунда басып тора. Әлтафиның сүзләрен ул да ишетте. «Өч атна рәттән өч төстәге бишмәт киеп килгәч, Әлтафи миндә өч бишмәт бар дип белә икән», дип уйлап куйдым эчтән генә. «Каян килеп күп булсын инде ул кием миндә, Әлтафи. Шул бер бишмәт инде ул. Башта мандырмыйча кидем. Аннары ике тапкыр мандырып алдык», – дидем. «И-и-и... Нәкыя! Нәкыя! Нигә инде шунда, әйе шул, өч бишмәтем бар, дип әйтмисең», – диде Мөхәммәт. «Мокыт», – дип тә өстәп куйды.

Еллар узгач, әдип Мөхәммәт Мәһдиев үзенең бер әсәрендә Закәрҗанның бер пәлтәне өч тапкыр мандырып туган авылында зур «эффект» тудыруын язды».

ХӘТЕРЕМ ДӘФТӘРЕННӘН: «Җитмешенче елларда джинсы чалбар модага керде. Аның да «американские», кыршыла торганы. Аны Сорочи базарыннан гына табып була. Анда да кемнәрдер киеп туздырып бетергән ыштан гына. Иң арзаны – йөз-йөз егерме сум. Яңасын табу турында уйлыйсы да юк. Мин дә алдым бу чалбарны. Җәен Арча район газетасы редакциясенә практика үтәргә кайткач, рәхмәт төшкере, мөхәррир Ренат Таҗиев мине штатка алды. Шунда эшләп алган бер айлык хезмәт хакын Сорочида чыгарып салдым. Тулай торакка кош тоткан кебек кайттым. «Авыл гыйбады» дигәч тә, без дә төшеп калганнардан түгел. Бездә дә бар «американский ыштан!» Шул көнне Мөхәммәт Мәһдиевнең пләмәше Җәүһәрнең туган көне икән. Без бер «общага»да торабыз. Якташым мине дә чакырды. Кердем. Хәлбуки, «фирменный штан» киеп инде. Мөхәммәт абый да килгән. Табынга утырганчы фотога төшү китте. Мәһдиев кадәр Мәһдиев белән ничек төшмисең ди. Чиратлап төшәбез, чиратлап төшерәбез. Мин төшергәндә Мөхәммәт абый әйтеп куйды: «Ну, Вакыйф, синең ыштан! Американскийдыр инде бу, име!» Американскиен американскийдыр да, тик менә туган көннән чыкканда, чалбарым тетелә башлаган иде инде. Иртәгесен аны тизрәк Ленин урамындагы «Комиссионка»га тапшырдым. Аны шул көнне үк алдылар. Дөрес, биш сум өстән чыкты чыгуын. Аның каравы котылдым.

Чалбарымны кеше күрми калды дип тә уфтанмыйм.

Мәһдиев күрде.

Мөхәммәт абый моданы аңлый һәм үзе дә заманча киенә белә иде».

**...ЮЛ**

МӨХӘММӘТ МӘҺДИЕВ ЯЗА: «Авыр, кырыс юллар үтелгән. Ничек үтә алганбыз, аңа каян көч килгән? Әйе, әйе, хәтерлим. Левинсон ни өчен алга барган? Отряды тар-мар килгәч тә, өметен җуймаган. Урман караңгылыгыннан чыккач, ул алдында якты дөнья күргән. Елаудан туктаган. «Нужно было жить и исполнять свои обязанности».

Шулай. Безгә дә яшәргә һәм үз бурычыңны үтәргә кирәк иде». («Без – кырык беренче ел балалары»)

ӘНИ СӨЙЛИ: «Юлга чыкканда юлдашың үзеңнән яхшырак булсын, диләр. Мин болай дип тә әйтер идем: «Юлга чыкканда юлдашың Мөхәммәт Мәһдиев булсын!»

Һәр дүшәмбе Зөлхия белән төнге өчтә кузгалабыз. Тау менәбез дә авылга карап торабыз. Ут әсәре юк. Сикертән рәхәтләнеп йоклый. Без, ике кычыткан чыпчыгы, ике юләр, белем алабыз дип черәшәбез. Башта Сикертәннән Гөберчәккә менәбез. Бу араны курка-курка узабыз. Һәр маяк бүре булып күренә. Гөберчәк тә йоклый. Авылга кереп байтак җир баргач, Мөхәммәтләрнең капкасына киләбез. Өйләрендә ут бар. Димәк, торганнар. Сукыр лампадагы шушы тычкан уты – бөтен Гөберчәккә бердәнбер ут. Йорт эчтә. Капкадан кергәч тә, өйгә кадәр шактый ара узасы. Тәрәз шакыйбыз. Ишекне Мөхәммәтнең әнисе ача һәм болай ди:

– И- и-и... Кызларым килгән икән. Әйдүк, өйгә керегез!

– Керәбез! Керәбез!

Кермибезме соң инде?! Сөенешә-сөенешә узабыз. Туңдык. Аз гына булса да җылынып чыгарбыз.

Мөхәммәт тә торган. Ишек бусагасында бүген төнлә үргән чабатасын киеп утыра. Киде дә безнең алда ишектән түргә, түрдән ишеккә йөреп, чабатасының аякка иплеме-җайлымы икәнлеген тикшереп карады.

Аннары юлга өчәү чыгабыз. Гадәттәгечә, фермалар тирәсендә урманга юл таба алмыйча бераз адашып йөрисе. Яхшымы-начармы, Гөберчәктән урманга юл бар әле. Буран булса, анысын да таба алмыйсың. Урманга җиткәч, өчебез дә кесәсеннән бау чыгара. Шуның белән бишмәт итәкләрен күтәртеп бәйлибез. Урман кырыеннан сигез-тугыз чакрым тирән көрт ерып барасы. Елның-елында шәп монда кар. Җил аны кырдан ташый һәм урманга терәп сала.

Юлны Мөхәммәт ярып бара. Без аның эзеннән. Беребез карга кереп чумса, аны тартып чыгармакчы булып, өчебез дә чумабыз. Зәмһәрир суыкларда туңабыз. Мөхәммәткә дәшәбез: «Каттык!» Әйтүебез була, ул кычкырып җибәрә:

– Әнә бүре!

– Кайда?

– Әнә! Безгә таба килә!

Эзләр бутала. Мөхәммәтнекен югалтабыз. Бәрелешәбез. Беребез өстенә икенчебез килеп каплана. Безне кар чоңгылы суырып ала. Күзләребез тирә-яктан бүре эзли. Аннары чоңгылдан көчкә-көчкә чыгабыз. Шулай бер аунап алгач, тән җылынып китә. Бактың исә Мөхәммәт бүрене дә безне җылытыр өчен «чыгара» икән. Керфекләребез бәс белән капланган салкын төннәрдә бу «аварияләр» аның «гаебе» белән еш була иде. Аннары җаен табып, юлны дәвам иттерәбез.

Мөхәммәт – алда, тагын юл яра.

Берсендә, шулай тирән көрткә бата-бата байтак баргач, Мөхәммәткә дәшәм, ял ит бераз, дигән булам һәм алга үзем чыгам.

Хәзер юлны мин ярам, имеш. Ярырсың, бар. Аяк кечкенә, чабата кечкенә. Димәк, эз дә кечкенә. Мөхәммәткә шул эзгә басасы, шуны киңәйтәсе. Алдан барды ни, минем арттан барды ни! Мөхәммәтне «ял иттергән» арада чабатам да сүтелде. Командирыбыз рәтләп бирде. Нәкыя, чабатаңны үрәсең икән, калыбында ныграк тарт! Тыгыз булсын, диде.

Мөхәммәт безнең өчен юл яручы гына түгел, юл күрсәтүче дә иде. Кышын без торган бүлмәдә котып салкыны. Туңабыз-катабыз. Өстебезгә урман аварга тора, ә ягарга утын юк. Училищеда тәртип шундый: бүлмәне «дежурный» җылытырга тиеш. Ничек җылытырга тиештер инде ул аны. Урмандагы корысарыны күздән үк җыеп бетердек. Анда бер ботак та таба алмыйсың.

Кайсыбыз гына кизү тормасын, бүлмәләребезне җылыту хәстәрен без – Мөхәммәт, Зөлхия һәм мин бергә күрәбез. Ул көнне дә урманда берни тапмыйча озак каңгырап йөрдек. Мөхәммәт бер каенда корган ботак күреп алды. Ничек итсә итте, агачка менде, теге ботакка ике куллап асылынды. Сындырмакчы була. Ботак бирешми. Аны сындырырга юньле ризык күрмәгән Мөхәммәтнең арык гәүдәсенең авырлыгы җитми. Без Зөлхия белән, үрелеп, аның ике аягын кочаклап алабыз да сабакташыбызны селкетә башлыйбыз, аска тартабыз. Маташа торгач, Мөхәммәтнең ике аягыннан ике итеген тартып алуыбызны сизми дә калдык. Егетебез ботакның очына килеп селкенә башлый. Хәзер инде без аның ялан тәпиләреннән тартабыз. Төшәргә йомшак булсын дип, җиргә киемнәребезне җәйдек. Ниһаять, ботак шартлап сынды. Ялан аяклы Мөхәммәт җиргә гөрселдәде. Без – ике кыз, көлешә-көлешә, итекләрен кидерәбез. Итек – чепуха, ди Мөхәммәт, сез әле чалбарны тартып төшерә яздыгыз...

Мичкә ягарга урманнан ботак-сатак җыюның Мөхәммәт уйлап тапкан юлы безне коткарды. Ул көнне бүлмәбезгә азмы-күпме җылы кунды.

ХӘТЕРЕМ ДӘФТӘРЕННӘН: «Узган гасырның 70нче елларында университетның тарих-филология факультетында татар телендә «Әдәби сүз» дигән стенгазета чыгарыла иде. Коридор паласы хәтле бу газетаны диварның буеннан-буена элеп куялар иде. Гадәттә, аның баш мөхәррире укытучылар арасыннан билгеләнә. Шактый еллар бу йөкне Марсель Бакиров тартты. Бер елны Мөхәммәт Мәһдиевне куйдылар. Аның урынбасары итеп мине тәгаенләгәннәр. Мөхәммәт абый: «Сине үзем тәкъдим иттем, Әгъзәмов хуплады. Син ризамы?» – диде. Мин Мәһдиев тәкъдименнән баш тарта алмыйм, риза, дидем. Ризалык бирүен бирдем дә, эшне нидән башларга, унбиш-егерме метрлы газетаны ничек тутырып бетерергә? Журналистикада укучы бер мишәр егетенә «заказ» биргән идем, «Гонорар түлисезме?» – дип сорады. «Юк!» дигәч, язудан баш тартты. Стенгазетада нинди гонорар инде ул?!

Шулай баш кашып йөргән көннәрдә Мәһдиев безгә дә юл күрсәтте. Башта алдыбызга бер язма китереп салды ул: «Былтырның хисабы». Тукайның шундый мәкаләсе бар бит. Мәһдиев язманың өстенә «Тукайдан түгел» дип тә куйган. Укыдык та шаккаттык. Мөхәммәт абый факультетыбызның кайнап торган тормышын яктырткан. Күпме яңалык, күпме мәгълүмат бу язмада. Автор аларны Г.Тукай калыбына дыңгычлап тутырган. Укырга да кызыклы. Мәсәлән, мондый юллар: «Былтыр татар теле һәм әдәбияты бүлеге студенты Нәҗип Исмәгыйлев (сүз киләчәктә галим, хаттат булачак, Г.Тукай бүләген алачак Нәҗип Нәккаш турында бара) тәүлектә 24 урынына 26 сәгать булуын исбатлады. Аның яхшы укуы, һәр эшкә өлгерүе менә шуның белән бәйле. Әйе, тәүлектә 26 сәгать. Нәҗип шулай ди. Моны исбатлар өчен иртән ике сәгатькә иртәрәк торырга гына кирәк икән».

Иртәгесен М.Мәһдиев безгә юлны Тау ягына күрсәтте. Фотожурналистика серләренә өйрәнүче Таһир Мәхмүтов белән Апаска киттек. Студентларыбыз – бу районда бәрәңгедә. Алар янында өч көн булып, колхоз кырларыннан, ындыр табакларыннан репортажлар алып кайттык. Мәһдиевтән үрнәк алып эшкә тотынган редколлегия әгъзасы Мансур Шәяхмәтовның да язмалары әзер. Мәһдиевнең кызы Гәүһәр аларны машинкада җыйды. Гөлнур Айзатуллова белән Гөлшат Салихҗанова (икесе дә шигырь яза) аларны кисеп ватман кәгазенә ябыштырып тордылар. Рәссамнарыбыз Нәҗип Исмәгыйлев белән аның бертуган энесе Әмир газетаны бизәү белән мәшгуль булдылар.

Студентлар колхоздан кайтканда, газета диварда эленеп тора иде инде! Укырга килгәч, егетләр-кызлар аңа ябырылды.

«Әдәби сүз» Казан вузлары стенгазеталары арасында үткәрелә торган конкурста һәр елны беренче урынны алды».

### ...күңел

МӨХӘММӘТ МӘҺДИЕВ ЯЗА: «Күңелдә җылылык, яхшылык, юньлелек». («Ачы тәҗрибә»)

ӘНИ СӨЙЛИ: «Шимбә төштән соң авылга кайтырга чыктык. Урта авылда этләр өрә – тамак ач. Хәл юк. Көчкә-көчкә атлыйбыз. Җитмәсә, буран, каршыга салкын-ачы җил исә. Сабакташыбыз Салихжан Шәмәтов ярты юлда егылды. Аны нишләтергә белмибез. Дәшеп карыйбыз, битләреннән сыпырабыз. Ул күзен йомган, йөзе ап-ак. Зөлхия белән икебез бер Шәмәтовка, бер Мөхәммәткә карыйбыз. Мөхәммәт тә аптырашта: «Бу ни хәл инде бу?» – дип куйды. Аннары нишләде – тиз-тиз генә капчыгын чиште, аннан ипи чыгарды. Әнисенә күчтәнәчкә дигән ипи. Ул аннан бер кисәкне сындырып алды да Шәмәтовка бирде. Безне җилгә арт белән бастырып, Салихҗанны ышыклап торырга кушты. Шәмәтов башта ипине чемченеп кенә капты, аннары йотлыга-йотлыга ашый башлады. Аның күзләре ачылды, маңгаеннан тир тамчылары тибеп чыкты. Җилдә торып, тирләгән тәнебездәге бишмәт шыгырдап катты. Тукайның «Таз» шигырендәге малай кебек булдык. Аркага ни белән генә суксалар да, авыртуны тоймаячакбыз.

Бераздан Салихҗан аякка басты. «Кинәт башым әйләнеп китте», – диде ул. Баш нигә әйләнә? Шул ашамаганга, ач булганга әйләнә инде! Мөхәммәт таш кебек каткан бишмәтләребезне күрде дә безне тизрәк Сикертәнгә кайтарып җибәрде, Салихҗанны авылына кадәр озатып куярга булды.

Кем белә, юлда тагын ни буласын?!»

ХӘТЕРЕМ ДӘФТӘРЕННӘН: «Тәнәфес иде. Университет коридорында ыгы-зыгы. Мәһдиев очрады. Хәл-әхвәл сорашты. Үзе бүген генә авылдан килгән. Авария күреп килдем, шуңа кәефем төште, ди. Бер егетнең хәле бик авыр икән. Мөрәленеке, диделәр. Каты эләккән. Аягы сынган. Бер генә җирдән сынды микән әле. Башка төшләре дә имгәнгән булуы ихтимал. Хәл кадәри ярдәм күрсәттек инде үзенә. Яраларын бәйләдек. Аннары бер машинага салып Арчага озаттык. Үз кулларым белән күтәреп салдым. Яшькә синең чамадарак ул. Сеҗедә бер тирәдә укымадыгыз микән әле, ди.

Мәктәпне миннән бер ел алданрак тәмамлаган Рашат булып чыкты ул. Яхшы укыды. Мәктәпнең бер дигән чаңгычысы иде. Нишлисең, күрәсең булгач... Мөхәммәт абый аның хәлен гел сорашып торды.

Аллага шөкер, егет аякка басты. Мөхәммәт абыйның игелекле күңеле дә, шифалы куллары да аңа тәэсир итми калмагандыр, дип уйлыйм...»

**...мәхәббәт**

МӨХӘММӘТ МӘҺДИЕВ ЯЗА: «Фет кыйммәткә төште Зарифуллинга. Зоолог Исмәгыйль абзый иртәгесен директор янына кереп тавыш чыгарган, имеш.

– Без кемнәрне тәрбиялибез, – дип бәйләнгән, имеш. – Мәхәббәт турында шигырь сөйләргә аның ни хакы бар? Рус әдәбияты укытучысы нәрсә карый?

Зоолог бу уңай белән Нина Комиссарова җырлаган җырны да телгә алган. Шуннан китте тавыш, китте тикшеренү. Кемдер бер хәбәр тараткан: имеш, колхозда вакытта Зарифуллин кичләрен Комиссарованы озаткалаган. Фет шигыре шуның нәтиҗәсе икән...

Ашыгыч рәвештә өлкән курсларның җыелышы җыелды. Директор, «ёжик» чәчле, кечкенә башлы, озын төз гәүдәле, коры кеше Зарифуллинны алга чыгарып бастырды. Бер-бер артлы сораулар бирде:

– Колхозда вакытта син рус группасындагы Комиссарова белән кич очраштыңмы?

– Кич клубтан бергә кайттык.

– Барлыгы ничә тапкыр?

Зарифуллин моны күңелдән белә.

– Өч тапкыр.

– Нәрсәләр турында сөйләштегез?

Зарифуллин монысын да күңелдән белә.

– Ушинскийның дидактикасы турында. Педология турында. Дүртенче курста географиядән экскурсия уздыру методикасы турында.

Директорның кечкенә башы югарыдан торып нәгъруә орды:

– Ялганлама, Зарифуллин! География методикасы турында сөйләшү өчен кичен кызлар белән очрашмыйлар!

Зарифуллин бер мәлгә аптырап калды. Ә башка максат белән очрашу ничек була икән?»(«Без – кырык беренче ел балалары»)

ӘНИ СӨЙЛИ: «Апаз кызы Өрфия укыды безнең белән. Аның матурлыгына бер дә чик-чама юк иде. Бите алсу, кашы кап-кара, буй-сыны төз, киемнәре гәүдәсенә килешле. Ул сөйләгәндә, күзеннән очкын сибелә, кайнарлык бөркелә. Үзе үткен. Бик яхшы укый. Мөхәммәтнең аңа күзе төште. Ләкин сиздермәгән була. Без – кызлар, сизмибезме соң инде?! Күзләре очрашканда, икесе дә кызарып чыга. Мөхәммәтнең колакларына кадәр кызара. Моны безнең белән укыган Гариф та, Яхъя да (Татарстанның халык язучысы Гариф Ахунов, тәрҗемәче, мөхәррир Яхъя Халит. – *В.Н.*) сизделәр. Әмма бу турыда бернинди сөйләшү дә, төрттерү дә булмады.

Мөхәммәт Өрфиядән еш кына йә китап, йә конспект алып тора иде. Ала, тиз генә кайтарып та бирә. Кыз егет биргән китапны беравык күкрәгенә кысып тора. Беләбез бит инде, китап, конспект эчендә «записка» бар. Белмәмешкә-күрмәмешкә салышабыз. Ике саф йөрәк үзләре генә белгән тыйнак та, серле дә мәхәббәт иде бу. Беренче мәхәббәт! Мөхәммәтнең исә тәүге иҗаты, беренче әсәрләре әнә шул гыйшык-мыйшык мәктүп-хатлары булмады микән әле?!

Укуны тәмамлагач, Мөхәммәт армиягә китте. Флотта хезмәт итте. Өрфия икенче кешегә кияүгә чыкты.

Яшьли сөйгән ярлар ятка кала, дип юкка гына әйтмәгәннәр шул...»

ХӘТЕРЕМ ДӘФТӘРЕННӘН: «Элек безнең Сеҗе авылы халкы малга кышка печәнне урманда чапты. Гөберчәк тә гомер-гомергә урман белән яшәде. Анда һәркемнең үз кишәрлеге. Тик печән чаба торган җир авылдан ерак. Урман кергәч тә җиде-сигез чакрым барасы.

Уттай кызу печән өстендә урманда иң кадерлесе – су. Ул җитми, ул тиз бетә. Аны күп алып та булмый, чөнки җәяү барасы. Төштән соң суга Урман артындагы Гәр-Хуторга чыгабыз. Электр кермәгән, радио-телевизор күрмәгән, җиде-сигез йортлы кечкенә генә авыл бу. Мөхәммәт Мәһдиевнең «Исәнме, Кәшфи абый» бәянына да керде ул авыл.

Суны Гәрәй атлы бер абзыйның бакча эчендәге коесыннан аласы. Бакчада умарта оялары. Кортлары бик әшәке. Шуңа күрә мин кермим, өйдән кемнең дә булса чыкканын көтәм. Бервакыт күз алдымда бер кыз пәйда булды. Каяндыр урман эченнән килеп чыкты ул.

– Сиңа су кирәкме? – диде ул, елмаеп.

– Кирәк иде шул.

Кызчык кулымдагы чәйнекне алып кереп тә китте. Мин кортлар гөжләвен, күке тавышын тыңлап торган арада чыгып та җитте.

– Мә эч!.. – үзе йөгереп китеп тә барды.

Су да, сусау да онытылды. Әлеге кызның якты күзләре, елмаю өчен генә яратылган иреннәре, чәчәкле юка күлмәге, ромашкалардан үрелгән такыясы күз алдымнан китмәде. Гәр-Хуторга ничә тапкыр суга чыктым. Ничә тапкыр болай гына чыктым, ул кызны бүтән очрата алмадым. Гәр-Хутор күптән юк инде. Хәзер урманга да кереп булмый. Күңелдә ниндидер бер могҗиза, мәңге онытылмаслык мизгел булып шул кызчык кына калды.

«Кечкенә авылның кызлары матур була», дип язды М.Мәһдиев. Син хаклы, Мөхәммәт абый!»

### ...поезд

МӨХӘММӘТ МӘҺДИЕВ ЯЗА: «Казан – Шәмәрдән поезды» дигән игелекле бер поезд барлыкка килде. Иллә дә кайчак акыллы, игелекле эшләр эшләнеп куя. Элеккеге елларда Арчада, Курса разъездында пассажир поездларының баскычларына асылынып, товар составының тормоз баскычларында туңып-өшеп, ревизорлардан тотылып, штрафлар түләп, шпаналардан таланып, алардан куркып сикереп, шлаклы откосларда авыз-борын канатып, тез башларын суйдырып, кулларны каймыктырып йөргән көннәремне искә төшердем дә – җәйнең болыт арасыннан кояш караштыргалаган, җылы, парлы бер көнендә шул поездга утырып Шәмәрдәнгә киттем. Исәбем – вагоннан чыгып тормыйча шул ук поезд белән кире кайту иде». («Бәхилләшү»)

ӘНИ СӨЙЛИ: «Сугыштан соң училищены яңадан Арчага күчерделәр. Юлыбыз тагын да кыенлашты. Арча Үрнәк кенә түгел. Ике тапкыр ераграк. Ул юлны җәяүләп үтәргә көчебез юк. Нишләргә? Өйгә ничек кайтырга? Коткаручыбыз тагын шул Мөхәммәт инде. Стансага төшеп, төнлә безнең якка китәчәк эшелонны белешеп менә. Төнлә бергә төшәбез һәм тимер юл буена өчебез өч җиргә чүмәшәбез. Кеше күзенә күренәсе түгел. Хәрби эшелонның калын тун кигән, автомат аскан сакчылары безгә атарга да күп сорамас. Состав кузгалган шәпкә, йөгереп чыгып, өчебез өч вагонның ишегенә кунакларга тиеш. Аннары тәртип болай: Курсага җитәрәк, башта Мөхәммәт сикерә, аннары – мин, мине күреп – Зөлхия, чөнки поезд туктамый. Мин – Мөхәммәтнең, Зөлхия минем сикергәнне күрергә тиеш. Мөхәммәтнең тагын бер шарты бар: Курсада җиргә килеп төшкәч, поезд үтеп китүгә, сикереп торырга. Безнең исән-имин калуыбызны аның шунда ук күрәсе-беләсе килә.

Берсендә шулай буранда кайттык. Биткә кар сибелә. Ул муенга, бишмәт

җиңнәренә кереп тула. Поезд җиле буранны тагын да көчәйтә. Курсада коелышкач, Зөлхияне югалттык. Мөхәммәт, мин торып бастык. Зөлхия юк. Мөхәммәт нишләргә белми. Мин дә курыктым. Төшеп калганмы? Безне күрмичә үтеп киткәнме? Шушы хәтәр юлда харап булырга, имгәнергә мөмкин. Безгә нишләргә? Авылга Зөлхиясез кайтып керә алмыйбыз бит инде! Шулай кайгыга батып торганда, кар өстендә нидер селкенеп куйды. Карасак – ике итек. Зөлхия! Тартып чыгардык. Сикергән шәпкә башы белән кар көртенә кадалган да чыгалмый яткан икән.

И шул вакытта Мөхәммәт белән сөенүебезне күрсәгез!..»

ХӘТЕРЕМ ДӘФТӘРЕННӘН: «Хатыным Ләйлә белән минем туган якка – Арча районы Сеҗе авылына Сабантуйга кайтышыбыз. Компрессорныйда электричкага утырдык. Утырдык димәсәң, хәтере калыр, этешә-төртешә тамбурга кереп бастык. Кеше өстендә – кеше! Юл газабының баласы гына әле бу. Арчада өч вагонлы дизель-поездга күченеп утырасы. Менә анда булачак мәхшәрнең дә мәхшәре! Уйлап карагыз, унике вагон халык өч вагонга сыеп бетәргә тиеш! Арчаның үзендә һәм тимер юлдан читтә яшәүчеләр генә аңа утырмый. Өч вагонны штурмлау өчен башта биек платформадан сикерәсе, аннары рельслар, шпаллар аша җан-фәрманга чабасы!.. Мин чабармын анысы, студент булып йөргән елларда бу тәмугны күп кичтек инде. Хатыным өчен борчылам. Ләйлә – Казан кызы. Мондый юлларда йөрергә күнекмәгән. Авыл Сабан туена да беренче кайтуы. Бу сынауларны үтә алырмы? Бу юлдан гайрәте чигеп, җаны бизеп калмасмы?! Түрәләрнең Казаннан Арча, Шәмәрдән, Балтач, Саба, Кукмара, Нократ Аланы якларына кайтучыларның юл мәсьәләсен унике вагонны өч вагонга тутыру юлы белән хәл итүләре гаҗәпкә калдыра. Мине гаҗәпләндергәне тагын шул: багана саен туктап кайткан өч вагон кайчандыр район үзәге булган, базары белән дан тоткан, бүген республика психоневрология диспансерын, участок хастаханәсен, амбулаторияне үзенә сыйдырган, почтасы, мәктәбе эшләп торган Яңа Чүриледә туктамый! Өч чакрым ары китеп, өч-дүрт өйле Мөндештә туктый. Шулай итеп, Чүриледән безнең авылга кадәр кайтасы дүрт-биш чакрым юл сигез чакрымга озына.

Дәрвишләр бистәсенә җитәрәк, вагонга үтә алдык. Шулвакыт кемдер эндәште:

– Вакыйф! Кил монда!

Карасам – Мөхәммәт Мәһдиев! Ул Сабантуйны калдырамы соң инде?! Мөхәммәт абый үзе дә кысылып, янәшәдәгеләрне дә җайлап-көйләп, хатынны да утыртты. Аннары миңа карап болай диде:

– Арчада каршы алалар. Машина була. Бергә кайтырбыз, яме.

Эчкә җылы йөгерде. Болай булгач, мәхшәр-һөҗүмнәрдән, сигез чакрым җәяү кайтудан котылабыз.

Арчада поезддан төшкәч, стансадагы чатыр чапкан халыкка кызганулы караш ташлап, тимер юлларны биек баскычтан ашыкмый-кабаланмый кеше төсле үттек. Мөхәммәт абыйның машина дигәне автобус булып чыкты. Аңа безнең юл өстендәге авылларга кайтучылар да утырды. Курсага җиткәч, автобустан төшүчеләргә ул: «Кызганыч, быел Сабан туегыз председательсез үтә инде», – диде. Бәйрәм алдыннан гына хуҗаны моннан алып башка урынга куйганнар. Яңа рәис юк икән әле. Мөхәммәт абый шуны да белеп тора. Хуҗасыз туй – туй түгел шул инде!

Без Сикертән чатында төшеп калырга әзерләндек. Моннан Сеҗегә дүрт чакрым гына кала. Мөхәммәт абый, шофёрга әйтеп, безне авылга ук керттерде».

**...үкенеч**

МӨХӘММӘТ МӘҺДИЕВ ЯЗА: «...Мин курсларга килгәндә, остазым (Арча педагогия училищесында рус теле һәм әдәбиятын укыткан Хәлим Искәндәров – *В.Н.*) үлгән иде инде. Шунда теге «авыллык» акылым миңа болай сөйләнде: беренчедән, син – ахмак, мокыт; икенчедән, син – мәгънәсез, идиот. Имтиханыңны бирә алмасаң соң? Аны бирергә тагын кереп булмыймыни? Бу кеше сиңа бер имтиханлык кынамыни? Бәлки әле менә дигән итеп биреп чыккан булыр идең остазың белән бер сөйләшеп утырсаң!

Өченчедән, заманасы бик иркен иде бит: 1956–1958 елларда теләгән вакытыңда Казанның теләгән ресторанына кереп утырырга, борын башына биш-алты тәңкәгә ашап-эчеп чыгарга була иде. Әле 1964 еллар тирәсендә дә банкетка кеше чакырганда, җан башына сигез сумнан акча кертәсе иде. Синең, ахмак заочникның кесәсендә бит, йөз сумлап акча бар иде ул вакытта». («Ачы тәҗрибә»)

ӘНИ СӨЙЛИ: «Сеҗегә Мөхәммәт Мәһдиев кайтты. Мәктәптә укучылар белән очрашты. И күңелле дә булды соң! Мөхәммәт барысын да авызына каратып тотты. Яза да, сөйли дә белә. Рәвеш тә шәп бит инде. Очрашудан соң Мөхәммәтне өйгә чакырдым. Мәктәптә табын әзерләнгән иде. Кунак: «Сабакташым янына кереп чыгасым бар», – дип, анда озак утырмаган. Мин дә табын кору хәстәре белән йөри идем, Гатият (Гатият Хәйруллин, ул вакытта авыл Советы рәисе. – *В.Н.*) белән килеп тә керделәр. Төшке ашка ирем Вәкил дә кайткан иде. Мөхәммәт башта чабынып чыгарга булды, мунчаны алдан ук ягып куйган идем. Аннан кып-кызыл булып, тирләп-пешеп чыкты. Улым Вакыйф мәктәптә Мәһдиев белән очрашу буласын белә иде. Ялга кайткач, Мөхәммәт абыйсына бирергә бер шешә сыра калдырып киткән иде. Мунчадан чыгышына суыткычтан алып шуны бирдем. Мөхәммәт аны чоландагы кәнәфигә утырып, маңгаеннан, битеннән агып төшкән тирләрен сөлге белән сөртә-сөртә, аз-аз гына йотып, тәмләп, озаклап эчте. Көне дә бик матур иде. Дөньяның чәчәк аткан, кояшта коенган чагы. Нәкъ үзе язганча булды: «Ә шулай да авыл мунчасы шәп нәрсә инде. Сезнең җәйге эссе көндә авыл мунчасына кергәнегез бармы?»

Мөхәммәт бераз хәл алгач, кипшенгәч, өйгә кереп чәй эчтек. Аннары Гатият кунагыбызны, машинасына утыртып, Арчага алып китте. Анда Мөхәммәт поезд белән Казанга китәргә тиеш.

Мөхәммәтне озаткач, келәткә керәсе иттем. Шунда күзем матчада эленеп торган казга төште. Какланган каз. Ах, аны Мөхәммәткә бирергә оныткынмын бит. И тишек баш!.. И үкенгәннәрем шул вакытта. «Каз үстерү, каз симертү буенча иң оста булган ике хатынны беләм мин Кесмәс буенда. Аның берсе минем әни, икенчесе Нәкыя», дип язды бит югыйсә. Казны ул чоланда сыра эчеп утырганда ук кулына тоттырасы иде бит!

Мөхәммәтнең безгә соңгы кайтуы булган икән...»

ХӘТЕРЕМ ДӘФТӘРЕННӘН: «Горбачёвның «сухой закон»ыннан соң авылларда хәмер сатуны тыйдылар. Казанда, сәгать ике тулгач, кайбер кибетләрдә аз-маз чыгарып алалар. Андагы чиратны күрсәң, гүя башын кибет ишегенә тыккан озын-юан елан сузылып ята. Без, Казандагы авыл малайлары, туган якка ялга кайтканда каян да булса юнәтеп, берәр ярты кыстырып кайтырга тырышабыз. Авылда эше дә бетәмени: йә печәнне хәл итәсе, йә утын хәстәрен күрәсе... Каралты-кураны да гел карап торырга кирәк. Кеше белән эшлисе бит әле. Күп эшне ярты хәл итә. Нишлисең – заманы шундый.

Менә тагын ял җитә. Авылга кайтасы бар. Бауман урамындагы «Шәраб» кибетенә кердем. Монда да «елан» бөгәрләнеп яткан. Чиратның башын-койрыгын табарлык түгел. «Вакыйф!» – кемдер миңа дәшә түгелме? Як-ягыма каранып торганда, исемемне тагын кабатладылар. О-о-о... Мөхәммәт абый!! Күр әле, чираты җитеп килә. Ул артта торучыларга нидер әйтеп-аңлатып алды һәм миңа үзенең алдына кереп басарга ишарәләде. Кеше арасына кыл да сыярлык түгел. Мөхәммәт абый ничек итсә-итте, тәки мине алдына кертте. Курыкмыйча кертте бит әле, чөнки чиратны погоннарына «ВВ» дип язылган батальон солдатлары күзәтеп тора. Аларның берсе – буйга ике метрлысы – Кавказ халкына охшаганы бигрәк рәхимсез кылана. Чиратсыз керүчене дә, аны кертүчене дә суырып ала һәм беләгеннән тотып әйләндерә башлый. Карусель күрсәтә, имеш. Кучәре – үзе. Мәһдиев мине шундый оста бастырды ки, арттагылар да сүз әйтмәде, погонлылар да сизмәде. «Син дә, Вакыйф, авылга кайтасыңдыр инде, – диде ул, бераз тынычлангач. – Вәкилгә күчтәнәчкә аласыңдыр. Мин дә Гөберчәккә кайтам. Урам якка койма тотасы бар. Егетләр булышырга килмичә калмый. Аз гына сыйласаң да күңелләре була. Шулай инде... Нишләтәсең?!»

Икешәр ярты алып урамга чыктык. Бер кешегә шуннан артык бирмиләр. Монысы да ничек эләкте әле?!. Бауман буйлап «Кольцо»га таба барабыз. Без бәхетле! Ул чорда хәмер яки сыра эләктерә алган кеше шәһәр урамнарыннан әлләкем булып үтә иде. Мәһдиев – бишенче трамвай тукталышына, мин троллейбуска киттем.

Соңыннан минем дә акылым телгә килде һәм болай диде: «Син – ахмак. Син – мокыт. «Кольцо»га җитәрәк, «Совет» кунакханәсе яныннан узганда якташыңа, остазыңа болай дип әйтергә тиеш идең: «Бер тәкъдим бар, Мөхәммәт абый. Минем портфельдәге күчтәнәчнең берсен башлыйк. Авылга алып кайтырга берсе бик җиткән. Бая кибеттә сез булмасагыз, алар эләкми иде бит. Хәзер «Совет» буфетына керәбез. Анда һәрвакыт пешкән тавык, ит бар. Буфетчы Лилия язучы халкын бик хөрмәт итә. Аерым бүлмәгә утырта. Бер утыру – бер гомер, диләр бит».

Акылым һаман тынычлана алмады: «Мәһдиев риза буламы, юкмы – аның эше. Әмма син аны чакырырга тиеш идең. Теге вакытта авылга кайткач, Мөхәммәт абыйга мунча чабынып чыккач бирергә дип калдырып киткән бер шешә сыраңа да күңеле булган аның. Кызы Гәүһәр, кандидатлык диссертациясен яклагач, мәҗлескә сине дә чакырдылар. Табын мул иде: шәп шәраблар, затлы ризык. Шунда Мөхәммәт Мәһдиев бөтен халык алдында үзеңә генә бер шешә сыра бирде. «Вакыйф, син мине сыйладың, мин дә сине сыйлыйм әле», – диде. Улы Искәндәр: «Әти, әҗәтеңне кайтарасың мәллә?» – дип шаяртып та куйды.

Их, син!.. Син – мәгънәсез. Син – идиот.

Кесәңдә тавык алырга җитәрлек өч-дүрт сум акчаң да бар иде ул вакытта.

Акылым Мәһдиевчә битәрләп бара...»



Флёра
Тарханова

# МОҢ ТАРАЛДЫ АЧЫК ТӘРӘЗДӘН

## Капка

*I. Әби*

Дистәләгән елны алып ташлап,
Кайттым әле үсмер чагыма:
Күзгә сарган энҗе тамчыларда
Шул чакның бер көне чагыла.

Утырдым да каршыдагы йортның
Бакча буендагы тактага,
Хатирәләр эргәсеннән киттем –
Ә күзләрем безнең капкада.

Кемдер кинәт йомшак кына итеп
Капка келәсенә кагылды,
Әби икән, чыга-чыгышка ук
Озын итәгенә абынды.

Карап алды шундук як-ягына,
Догасын һәм әфсен укынып,
Китеп барды аннан түбән очка,
Җил-җил атлап, давыл, ут булып.

Кызулаган саен ак күлмәге
Өермәдәй барды артыннан,
Сихәт илтә китте булса кирәк
Бала көткән яшь бер хатынга.

Шулай йөри инде дәшкән саен,
Карамыйча җил һәм давылга,
Җиде баласына әни булса,
«Кендек әби» бит ул авылга.

Флёра ТАРХАНОВА – *шагыйрә, прозаик, тәрҗемәче; «Яшьлек эзем калган сукмаклар», «Язмышлар язылганда», «Хисләр дәрьясында» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Г.Исхакый исемендәге әдәби премия лауреаты. Казанда яши.*

Күпме бала аның кулы аша
Җиһаннарга аваз салгандыр,
Күпме парның чиксез рәхмәтләре
Савап булып өелеп калгандыр.

Әбиемнән әле үз гомерендә
Меңнәр китте арынып мең чирдән,
Сызлауларын басар өчен халык
Килә иде хәйран күп җирдән.

Ул гына да түгел: биш ятиме –
Биш оныгы булды кулында,
Хәл килгәнчә булышып, һәммәсенә
Терәк булды тормыш юлында.

Әбиемне шушы изгелеге,
Шул рәхмәтләр имин йөрткәндер.
Бу дөньяда әле мин кирәк дип,
Туксаныннан узып киткәндер…

Табигатьтән көчле иде әби
(әле безгә шактый күчкән ул):
Кайнап торган зур самавыр белән
Өй базына егылып төшкән ул.

Артык зыян күрми генә шунда
Исән калган, Хода рәхмәте.
Чирләп ятканын да беркем белми –
Китермәгән иблис зәхмәтен.

Үз җирендә урак урган чакта
Уеп алгач учының яртысын,
Бер уч тоз сипкән дә шул ярага,
Дәвам иткән эшен ярсынып.

Укымышлы иде безнең әби –
Үзе кебекләрне иш итте.
Гарәп, төрек, фарсы, рус сүзләрен
Әбиемнән әүвәл ишеттем.

Ул гынамы? Байбичәләр булып
Йөргән әби, туганнар дәшкәч,
Ике кызын утырмага йөрткән
Күрше авылдагы кардәшкә.

Баганалы авылы кыркапканы
Каерып ачкан ак пар ат күреп,
Килү белән, әби, апаларым
Авыл әйләнгәннәр иң элек.

Әби, әби! Бер дә картаймыйсың,
Югыйсә бит йөзне вакладың.
Зифа гәүдәң бераз бөкрәйсә дә,
Дәрәҗәңне һәрчак сакладың.

…Шул арада әби кайтып җитте –
Тиз беткәндер эше, күрәсең,
Тагын шулай җил-җил кереп китте,
Шалтыратып капка келәсен.

### *II. Әни белән әти*

Тукта! Кем булыр бу? Атлый-чаба
Безнең өйгә таба кем килә?
Әни ич бу: озын тәнәфестә
Бала имезергә йөгерә.

Хәле китеп, азрак тын алыйм дип,
Капка келәсенә тотынды.
Бераз басып торды тыныч кына –
Авыр сулавыннан котылды.

Ә аннары, кинәт каударланып,
Ачып керде авыр капканы,
Тизрәк-тизрәк, инде китү кирәк –
Сәгатьләп торырга кайтмады.

Тамак туйгач, тынып йоклап киткән
Баласына ябып япманы,
Чыгып чапты, тамагына үзе
Әллә капты, әллә капмады.

Очты гына күпер, сулар аша,
Соңга калмыйм, диеп, дәрескә.
Сиксән дүрт күз берни сизми калды –
Шулай өлгер иде һәр эштә.

Әни кабат киткәч мәктәбенә,
Капка торды бераз «тын алып».
Бала-чага иртүк, чыр-чу килеп,
Беткән иде инде таралып.

Көн авышты. Шалтыр-шолтыр килеп,
«Хәлдән тайды» капка келәсе,
Әле тагын әти кайтасы бар –
Гаиләнең иң зур түрәсе.

Һәм, ниһаять, салмак кына атлап
Кайтып килгән әти күренде.
Ашыкмыйча гына килде дә ул
Капка келәсенә үрелде.

Туктап калды әти, әллә инде
Минем күзәтүне сизенеп,
Борылды да миңа таба карап
Озак торды, куйды көрсенеп.

Бәлки әле аның сизгер җаны
Минем барлыгымны тойгандыр,
Киләчәктән мине күрер өчен
Озак итеп карап torгандыр?

Кереп китте. Балалары дәррәү:
«Әти кайтты, әти», – диеште,
Әни өстәл япты, әтиемә
Салып куйды иң зур өлешне.

Өй эчендә, сүзгә урын куймый,
Унбер кашык «өзелеп җырлады»,
Өй кырында үскән таллары да
Шаулавыннан озак тынмады.

Ут алдылар. Кинәт салмак кына
Моң таралды ачык тәрәздән,
Кыңгыраулы гармун башлаганны
Дәвам итте баян бераздан.

Баян тынып калгач, үзәкләрне
Скрипка кылы өздерде,
Арыса да, әни җыр башлады –
Гүя моңнар аңа көч бирде.

Без кушылдык әни җырларына,
Әти көе безне биетте –
(Киләчәктә хәтта хәсрәтләре,
Авырлыклары да үз итте...)

Мин боларны күрше эргәсеннән
Уелыплар төшеп тыңладым.
Түзалмадым: ятим өебезнең
Инде кыйшык капкасыннан кереп,
Баскычына ятып еладым.

**Редакциядән:**

*Каләмдәшебез бу айда үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*

# ҺӘР САНЫ БӘЙРӘМ

**Мәгърифәтле милләттәшләребез «Казан утлары»н халкыбызның төп журналы дип таный. Әйе, моңа ныклы нигез бар: журналның яше ягыннан да, миссиясенең тарихилыгы һәм күләме-саны ягыннан да. Әгәр татар басма матбугатына йөз ун еллар икән, «Казан утлары»ның элгәреләре дип «Шура», «Аң» басмаларын санасак, журналыбызның яшен дә шул еллар белән бәйләп карарга кирәк. Чыннан да, әдәби басмалар булмаса, XX гасыр башында татар әдәбияты яңа күтәрелеш кичерер идеме? Тукай, Исхакый, Ибраһимов кебек бөекләр балкып чыгар идеме? Журналның бу айда билгеләп үтелә торган 95 еллыгы ул инкыйлабтан соңгы совет чорын гына эченә ала...**

**Моннан ун еллар элек мең дигән сан телләрдә күп тибрәнде. Мең еллык Казан, мең еллык әдәбият, мең саны чыккан журнал... Баксаң, «Казан утлары»ның саны бүген инде мең дә бер йөз утыз бишкә җиткән икән! Бөтен Россиясендә мондый санга ирешкән әдәби журнал юк та бугай...**

**Язмыш миңа чирек гасырга якын бу олуг журналның баш мөхәррире булу дәрәҗәсен бүләк итте. Гомернең көчле, дәртле, иҗатлы, Күк белән Җирне җиңел генә тоташтырып була дип ышанып йөргән чаклар! Ә еллары бик җиңел түгел иде болай. Торгынлык, үзгәртеп кору, демократик омтылышлар, СССР таркалу, күпфиркалелек, референдумнар, финанс тотрыксызлыгы, илкүләм кризис... Шулай да, шагыйрь әйтмешли, «Әдәбиятыбызның кәрван башы – олуг журналыбыз», уңга-сулга тайпылмыйча, үсештә булды. 2013 елны «Казан утлары» журналының җитәкчесе вазифасын яңа кулларга тапшырганда (ә болай үземне журналдан киттем дип санамыйм, статусым гына үзгәрде, әлегәчә һаман шул матбугат өлкәсендә хезмәттәмен), табигый, күңелдә төрле сораулар да булмады түгел: яңа җитәкчелек ничек, ни дәрәҗәдә, нindiрәк юнәлештә дәвам итәр? Шөкер, шөбһә-борчылулар юкка булган. Журнал төп юлдан тайпылмыйча алга баруын дәвам итә. Шуңа сөенәм. Иң мөһиме – тираж кимемәде. Хәзер «Казан утлары» 5000 данә чыга. Заманасы өчен, әдәби журнал өчен яхшы сан. Үзеннән-үзе генә җыелмый бу данәләр! Журнал хезмәткәрләре көне-төне дигәндәй гел юлда, халык арасында, укучылары арасында. Яхшы күрсәткеч – әнә шул оештыру эшләре нәтиҗәсе. Рәхмәт аларга!**

**Затлы әдәби сүз һәр заманда, һәр халыкта зур хәзинә саналган. Телне халык тудыра, язучылар аны чарлый, камилләштерә... Журналның титул битендә төрле чорларда «гыйльми», «сәяси», «иҗтимагый», «сәнгати», «тәнкыйти», «тарихи» дигән сүзләр бар, әмма югарыда аталган һәр сүз янында «әдәби» сүзе янәшә тора. Әдәбият ул – бөек нәрсә! Халыкның рухи биеклеге күрсәткече. Сәнгатьнең байтак төрләре турыдан-туры әдәбиятка бәйле. Тарихи яктан бәяләгәндә, әдәбият – сакланып калган төп байлыгыбыз. Бу байлыкны барлыкка китерүдә «Казан утлары»ның өлеше гаять зур.**

**95 ел. Ярый, бу датаны да билгеләп үтү – саваплы гамәл. Ә болай төптән уйлаганда, журналның һәр елгы гомерен – вакыйга, һәр чыккан санын бәйрәм дип кабул итеп була.**

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН,**
*Татарстанның халык шагыйре,*
*«Казан утлары» журналының*
*1989-2013 елларда баш мөхәррире*



Фәнил
Гыйләҗев

# ИСКЕ КАЗАН – КИРМӘН НИГЕЗЕ

ЛИРИК ПОЭМА

*Казан – Арча тимер юлының Камай тукталышыннан ерак түгел «Иске Казан» музей тыюлыгы урнашкан. Тарихи елъязмалар һәм борынгы риваятьләр буенча биредәге шәһәрлектә – хәрби корылмада кайчандыр тулы канлы тормыш кайнаган.*

*Үзенә тартып торучы сихри табигатьле бу урында татар яшьләре 2000 еллардан башлап җыеннар үткәрә, шанлы чорларыбызны искә алып фәлсәфә кора, ял итә, агачлар утырта...*

**1**

Казансудан без дә балык тоттык,
Казан астык Кирмән буенда.
Чәй кайнаттык шифа-үләннәрдән –
Ханнар чишмәсенең суыннан.
Таңбатырлар, Таңсылулар сыман
Без дә эчтек сөю ширбәтен.
Кара яллы төнне без дә кичтек,
Ут сакладык:
«Сүнә күрмәсен!»
Учак кырыенда үтте ул төн.
Синең йөрәк янды...
Ә минем
Башмак белән чалбар очы көйде...
Кырыс иде никтер шагыйрең.
Төне суык иде.
Төн салкыны
Үзәкләргә үтте, бәгырьгә.
Ягар утын бетте...
Шушы мизгел
Күз алдымнан китми әле дә.
Кемнәр кайдан җылы эзләгәндер,
Ә син миңа килеп сарылдың.
Сүз дәшмәдең.
Тик күзләрең әйтте:
«Мин сагындым сине, сагындым!»

Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ (1987) – *шагыйрь; «Ризасызлык» исемле шигырь китабы авторы. Казанда яши.*

Кочагыма сеңдең һәм җылыттың
Таш балбалдай хиссез йөрәкне.
Учак көлгә калып сүрелгәндә,
Саф сөюең, назың кирәкте.
Иске Казан җиле учак көлен
Әфсен әйткән камдай бөтереп,
Сабантуйда беренчелек алып
Мәйдан әйләнүче ат кебек
Чирәмнәрнең башын иеп узды
Һәм бәйләде безнең чәчләрне.
Шул мизгелдә төн карасын ярып,
Күктә чатнап яшен яшьнәде.
Җир анабыз үзе түшәк булды,
Җилләр безгә юрган иде күк,
Бер-беребез өчен учак булдык,
Түшәмебез булды төнге күк.
Төн үткәрдек Кирмән нигезендә,
Казансуның борма ярында.
Бар гавамнан читтә, бер дулкында
Серләште тик ике җан гына.

**2**

Төн карасы чигенүче яудай
Офыкларга ал кан түккәндә,
Төтен исе бәгырьләрне төтеп,
Сабыр төбе чиккә җиткәндә,
Казансуны томан сарган чакта,
Бар тереклек җылы көткәндә,
Таңбатыр һәм Таңсылудай икәү
Таң аттырдык уртак тирмәдә!
Таң аттырдык чикмән уртаклашып,
Икебезгә уртак тын алдык
Һәм өздереп йөрәк җырын сузган
Тургай моңын тынып тыңладык.
Ә ул очты безгә бәхет юрап,
Фатихасын биреп, алкышлап…
Тыңладылар аны, башын иеп,
Бөдрә таллар, зифа камышлар.
Ул җырлады канат җилпи-җилпи,
Шат кайтаваз булып үткәннән:
Бу тугайда, диеп, Таңбатырлар,
Таңсылулар дөнья көткәннәр.
Бу тугайда учак тергезгәннәр,
Туй иткәннәр, казан асканнар,
Изге теләк теләп, агачларга
Бәйләгәннәр ап-ак тасмалар.
Бу тугайда Казан җайдаклары
Тулпарларга йөгән кидергән.
Сөңге аткан, җәя тарткан затлар
Гашыйк булган, сөйгән, сөелгән...
Бу тугайда чиләк-көянтәсен
Аскан көе горур иңенә
Су ташыган Казан сылулары
Текә ярдан Кирмән өенә.

Бу тугайда су төбенә киткән
Алтынбәкнең алтын казаны.
Ил өстенә яу килгәндә, халкым
Шунда кичкән бәла-казаны.
Бу тугайның имән Кирмәненнән
Уктай очып атлы батырлар
Ил өстенә килгән дошманнарны
Япанчыдай канга батырган.
...Бу тугайда әче төтен исе
Томан белән бергә тарала.
Үрләп янган кызу учакларның
Чал шаһиты – күмер-көл кала.
Шаһит булып таулар, валлар кала,
Чишмә кала, кала тугайлар...
Сызылып таңнар ата һәм күкләрдә
Сөю җырын көйли тургайлар.

**3**

Кара ялын җилдә җилфердәтеп,
Җанга кешнәп кайчак төн керә.
Шул мизгелдә иңне-иңгә терәп
Юатырдай кешем – син генә.
Шул мизгелдә мин уйларым белән
Кайтып киләм Иске Казанга:
Таңбатырлар белән Таңсылулар
Парлап дөнья көткән заманга.
Мин – Таңбатыр, син – Таңсылу булып,
Ут саклаган чакка икәүләп.
Һәм уянып китәм...
Колагыма
Син дәшәсең икән, иркәләп.
Һәм үбәсең юеш маңгаемны,
Чигә чәчем сыйпап җай гына.
«Бар да үтте», диеп пышылдыйсың,
Атмаган тик бары таң гына...
Күзләреңнән күрәм:
Сагынгансың!
Сарылгансың куздай тәнемә.
Таң атмаган, тургай моңы да юк,
Куркыныч төш үткән өнемә...
Саташылган:
Имеш, Таңбатырлар
Ауга түгел, яуга киткәннәр,
Кирмән, имеш, янып, көлгә калган,
Ә чишмәләр, никтер, кипкәннәр.
Казанда су беткән.
Балыклары
Көеп ята казан төбендә.
Тугайларда тургай моңы тынган,
Һәр тарафта күмер-көл генә...
Һәр тарафта әче төтен исе,
Таңсылулар тиңсез калганнар,
Таңбатырлар бил алышкан җирне
Басып киткән маңкорт кылганнар.

...Манма тиргә чумып, уйга батып
Карап ятам тирмә читенә.
Чорлар аша гүя бабамнарның
Кисәтүле тавышы ишетелә.
Дәшә кебек алар:
«Үз Кирмәнең
Корырга син, улым, онытма!
Үз дәүләтең булсын – үз телеңдә
Сөйләшсеннәр өчен оныклар,
Без җан бирдек яу кырына ятып,
Саклау өчен нәсел-дәвамны,
Үз Кирмәнең кору тиеш, улым,
Җан авазын ишет бабаңның!»

**4**

Мин аңладым бабам ишарәсен –
Колак салдым тургай җырына.
Кара яллы төнне җаннан куып,
Кулларыңны алдым кулыма!
Ханнар чишмәсенең суын сибеп,
Утырттык без икәү куш имән.
Имәндәй нык гаилә булсак иде,
Һәм гомерлек ярлар, җан сөйгән!
Сүрелмәсен уртак учагыбыз!
Шаулап үссен имән, каеннар!
Яңа корган Кирмән нигезенә
Ут салмасын дошман, хаиннар!
Эт токымлы җаннар чокыр казып
Шартлатса да Бутлер дарысын,
Какшамаслык булсын нигезебез!
Кыенлыкның җиңеп барысын,
Яңа тарих ясыйк, елъязарлар
Үрнәк итеп дастан язарлык:
«Татар исән, яши, дәүләт кора,
Менә кайда, диеп, татарлык».
Казансудан бездәй балык тотсын
Һәм эзләсен асыл алтынын
Идел-йортның суын эчеп үскән
Һәр Сылуы, һәрбер Батыры!
Кирмән нигезендә урман булып,
Гаскәр булып үссен имәннәр!
Бездән соң да хөр дәүләтләр корсын
Берсен-берсе өзелеп сөйгәннәр.
Чикмәнле төн.
Тургайлы таң.
Учак...
Иске Казан – Кирмән нигезе.
Яңа Таңбатырлар, Таңсылулар,
Рәхмәт әйтеп, Сиңа кул изи.

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең гомер бәйрәмен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*

## *Фотомизгелләр...*

*25 апрель көнне ТР Фәннәр академиясендә татар әдәбияты классигы, сәясәтче, җәмәгать эшлеклесе, педагог һәм «Казан утлары» журналына нигез салучыларның берсе Галимҗан Ибраһимовның тууына – 130, «Казан утлары» журналы дөнья күрә башлауга 95 ел тулуга багышланган, «Мәдәниятләр төрлелеге контекстында Галимҗан Ибраһимов мирасы» дип аталган халыкара конференция узды.*



*Конференцияне ачу алдыннан. Сулдан уңга: Римма Ратникова, Ким Миңнуллин, Индус Таһиров, Ирек Сәетов, Марат Сәетов, Мәкъзүм Сәләхов.*




*Галимҗан Ибраһимовның бертуганы Габделхәким кызлары Сания (сулда) һәм Миңсылу (уңда).*



*Конференциядә катнашучы бер төркем галимнәр. Беренче рәттә – Лена Гайнанова; Икенче рәттә (сулдан уңга): Таһир Гыйләҗев, Әлфәт Закирҗанов, Фоат Галимуллин, Тәлгат Галиуллин; өченче рәттә (сулдан уңга): Тәэминә Биктимерова, Лирон Хәмидуллин.*

**Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ** *фотолары*



**Хәсән ТУФАН (1900-1981) – шагыйрь, язучы, җәмәгать эшлеклесе, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты:**

«Безнең юл» дигән журналның, хәзерге «Казан утлары»ның нигез ташларын Галимҗан абый Ибраһимов салган иде. Кайбер вакытта журналның үтелгән юлларына борылып карыйм да башта бераз сискәнеп куям. Аннары башны күтәрә төшеп, әдәби туфракка аякны киңрәк һәм ныграк итеп басам. Утызынчы еллар уртасында журналның редколлегиясендә Галимҗан Нигъмәтиләр, Гомәр Галиләр белән, Кәрим Тинчуриннар һәм Шәриф Камал абыйлар белән, Гомәр Толымбайскийлар белән бергә эшләгән идем, бергә яшәгән идем. Алар барсы да мәрхүм инде. Ләкин, юкка гына, йөрәк, янасың. Алар чордан чорга, дәвердән дәвергә күчә-күчә, әдәбиятыбызның алгы сызыгында халык белән, ил белән бергә киләчәккә баруны дәвам итәләр. Халык күңелендә һаман яшиләр бит. Әгәр дә безнең Тукайларыбыз, Сәйдәшләребез, Галимҗан абый Ибраһимовлар, Такташларыбыз, Җәлилләребез һәм башкалар булмаган булса, без халык буларак нинди ярлы, нинди фәкыйрь булыр идек. Халык күңелендәге рухи хәзинәдә, алтын фондта никадәр зур байлыгыбыз бар безнең. Халык күңеле түрендә сигез йөз яшьлек классик шагыйрь Кол Гали бабай утыра, анда, халык күңеле түрендә, безгә кыйммәтле хикмәт-киңәшләр бирә-бирә, дүртәр йөз яшьлек, өчәр йөз яшьлек, икешәр йөз яшьлек классик бабайлар – Мәүлә Колыйлар, Утыз Имәниләр, Кандалыйлар һәм башка классик шагыйрьләребез утыра. Алар янында лаеклы энеләре – Галимҗаннар, Такташлар, Җәлилләр нурлы маяк булып яктыртып тора.

*Яктыртыша алар һаман да*
*Заманалар аша киң илне.*
*Үзе инде күптән сүнсә дә,*
*Нуры калган йолдыз шикелле*
*Яктыртыша алар әле дә.*

Шигъри әдәби юл дәвам итә, күкрәп дәвам итә. Бу юлда буш урыннар, вакуумнар юк безнең.


*Өзелмәде безнең изге юл.*
*Төркем-төркем дәвамнар килә.*
*Үзе өчен түгел, ил өчен*
*Яши белгән яңалар килә.*
*Өзелмәде безнең нурлы юл.*
*Анда шигъри шонкарлар калка.*
*Зур һәм көчле, дәртле халыкның,*
*Әдип халык, шагыйрь халыкның*
*Чын баласы, үз баласы булганнар калка.*
*Дәвам итә безнең нурлы юл. Дәвам итә.*



**Гази КАШШАФ (1907-1975) – әдәбият галиме, тәнкыйтьче, җәмәгать эшлеклесе, Хезмәт Кызыл Байрагы, Почёт билгесе ордены иясе:**


Бөек Ватан сугышы еллары хәтердә нык уелып калган. Партиянең Татарстан өлкә комитеты «Совет әдәбияты» журналын саклап калырга булды. Ул вакытта журналны Гомәр Бәширов редакцияли иде. 1942 елны аны мин алыштырдым. Ул Татрадиокомитетның баш редакторы булып китте. Журналда хәл авырлыгына матбугат йортының котып салкыннары килеп кушылды. 1941 елның кышыннан бирле матбугат йорты ягылмый иде. Менә без

Абдулла Гомәр белән икәү «Совет әдәбияты»ның чираттагы санын әзерлибез. Бүлмәдә бер сәгатьтән артык утырып булмый. Салкын. Салкын үзәккә үтә һәм без урамнан әйләнеп керәбез. Абдулла Гомәр журналга барлык энергиясен салып эшләде. 1943 елның октябрендә миңа тагын бер эш йөкләделәр. Редакторлыктан бушатмыйча гына Язучылар Союзының җитәкчесе итеп сайладылар. Беркөнне кич белән мине җитәкче итеп сайладылар, икенче көнне Мәскәүгә юл алдык. СССР Язучылар союзының президиумында Татарстан Язучылары союзының эше турында хисап бирергә тиеш идек. Уңышлар турында сөйләмим, кимчелекләр турында әйтәсе килә, дип башлаган идем сүзне. Кызып киткәч, бердәнбер әдәби журналыбызның бик мөшкел хәлдә яшәве турында да сөйләргә туры килде. Кинәт мине сөйләүдән бүлдерделәр: «Ничек, сездә журнал чыгамыни?» Фадеев мин утырган урындык артында басып тора иде. Сорауны аңа да бирделәр: «Ә сез, Александр Александрович, бу хәлне беләсезме?» «А как же, без җитәклибез», диде Фадеев. Союздагы һәм Үзәк Комитеттагы иптәшләр безнең хәлне яхшы аңладылар. Авырлык белән булса да, журналны туктатмыйча, чыгарып килүне мактадылар, «бу сезнең подвиг», диделәр. Мактауны без журналда актив катнашучы барлык язучыларның казанышы дип кабул иттек.



**Фатих ХӨСНИ (1908-1996) – язучы, публицист, драматург, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты:**

Үземнең чын әдәби язмышымны 1927 елда «Безнең юл» журналында басылган «Дөнья матур миңа» дигән шат рухлы шигырем белән башладым дип горурлык белән әйтә алам. Хәер, саный китсәң, күп алар. Ләкин укучыларга билгеле булган, минем шулай уйларга тәвәккәллегем җитә, төп әсәрләрем – «Йөзек кашы», «Гыйльмениса һәм аның күршеләре», «Минем тәрәзәләрем», «Язмыш шуклыгы» кебек үзем бик яратып язган повестьларым, «Җәяүле кеше сукмагы», «Утызынчы ел» кебек романнарым һәм күп кенә хикәяләрем беренче шушы журнал битләрендә үзләренең укучыларын таптылар. Җәннәткә барып кергәнче, иң элек сират күпере аркылы үтәсе бар. Әлбәттә, без дә җәннәткә йөгереп кенә барып кермәгәнбездер. Редакция дигән сират күпере бар. Анда, үч иткән кебек, үтә дә төпченүчән, үтә дә ортодоксаль, гади телгә күчереп әйтсәк – үтә дә каеш кешеләрне утыртып куялар. Ә бит начарлык теләп түгел, яхшылык теләп. Укучыга, язучының үзенә, ниһаять, гомуми әдәби хәзинәбезгә яхшылык теләп шулай эшлиләр, рәхмәт төшкереләре. Шуны истә тотып, журналның бу тантаналы көннәрендә аларга, редакциядә эшләп киткән кешеләрнең элеккегеләренә дә, хәзергеләренә дә чын ихластан язучы рәхмәте җиткезәсе килә.



**Миркасыйм ГОСМАНОВ (1934-2010) – тарихчы, галим, археограф, фольклорчы, язучы, публицист, ТАССРның атказанган фән эшлеклесе, РФ Югары мәктәбенең атказанган хезмәткәре:**

«Казан утлары»ның бәйрәме – бөтен татар халкының бөек бәйрәмнәренең берсе. Чөнки, нинди авыр елларда да тегермәнгә тартылмаган татар теле кебек татар әдәбиятын, татар сәнгатен иң авыр шартларда да саклап, яшәп килгән «Казан утлары». Минем бер-ике генә мисал китерәсем килә. Университетта эшләп, кульязмалар җыю буенча миңа элеккеге Советлар Берлегенең һәрбер почмагында диярлек булырга туры килде. Әйтик, Рязань ягыннан алып Иркутскига кадәр, Байкал күленә кадәр. Киров, Пермь якларыннан алып Әстерхан, Бакуларга кадәр. Шунда һәрбер йортта булырга туры килә. Һәм, гаилә ничек? Бу гаиләдә культура-мәдәният ничек? Татарлык ничек? Шуны аңлата торган бер-ике галәмәт була. Аларның берсе – «Казан утлары», икенчесе – элекке «Азат хатын», яки бүгенге «Сөембикә» журналы. Әгәр шундый йортларга туры килгән икән, бу авылда, бу төбәктә безнең экспедициянең юллары уңды дип әйтергә була. Менә шуның өчен, мин «Казан утлары»на безнең халыкны, төрле төбәккә сибелгән милләттәшләребезне оештырып торучы органнарның берсе буларак яшәгәнлеге өчен, укучылар исеменнән рәхмәт әйтергә телим.

# ӘДӘБИЯТЫБЫЗДА «КАЗАН УТЛАРЫ» ЯКТЫСЫ

***– «Казан утлары» журналы милли әдәби-сәнгати барышта нинди урын тота? Сез аның ролен ничек бәяләр идегез? Гомумән, татарча әдәби-публицистик журналларның киләчәге бармы?***



**Рифә РАХМАН,**
*язучы, шагыйрә, филология фәннәре кандидаты:*

– Фаразлау кешене, шул эш-хәлнең вакыты җиткәч, күпчелек очракта авыр хәлгә куя, шуңа да карамастан, без, милләтнең яшәвен кайгыртсак, аңа мөнәсәбәтле һәм шуны тәэмин итешкән бер генә нәрсәне дә күз уңыннан ычкындырырга тиеш түгел. Татар вакытлы матбугаты да – милләт яшәешендә хәлиткеч роль уйный торган факторлардан. Бүгенге көндә, минемчә, аның эчтәлек һәм тел ноктасыннан тиешле таләпләргә җавап бирмәве, сәяси-иҗтимагый яссылыкта узган гасыр башында ук алган биеклекләреннән инде күптән төшүе ана телебез торышында, кулланыштагы сафлыгында-байлыгында, актив-пассив сүз катламнарының зарарлы якка үзгәрешендә чагылыш тапты. Газеталарның оперативлыгы юк, материаллар еш кына реаль тормышны чагылдырмый, милләтне алга җибәрүдә һәм гади халыкның көндәлек яшәешен җиңеләйтүгә бар тулылыгында хезмәт итми. Рәсмиләре хакимияткә ярауны алга куйса, шәхсиләренең күпчелегендә аралашу, язу, фикерләү әдәбе түбән, тематикасы – вак-төяк, укучысы – нигездә, мәдәни баскычта түбәндә торган катлам. Соңгыларының язмаларыннан матбугат органының идея планындагы максат-бурычларын чамалау кыен; гамәлгә куючыларына, абунәчеләрнең санын арттырып, акча эшләүдән артыгы кирәкми кебек тоела.

Зур тарихы булган газеталарны журналга әверелдерү дә вакытлы матбугат мәйданында кирәкмәгән эш эшләде: алар бер-берсенә охшап калды, материаллар кабатлана башлады, форматларына карасаң, күбесе ялтыравык реклама рисаләләренә, буклетларга, теге яки бу уңайдан чыгарган җыентыкларга тартым. Мондый шартларда әдәби-иҗтимагый һәм фәнни журналлар күпмедер ота. Алар бизәлеш һәм материал ноктасыннан башкалардан аерылып тора. Әлбәттә, шулай дип кенә, теләсә ни укып, интернетта утырып, буш яисә кызык сүз белән миңгерәүләндерелгән укучы аларны яздырырга атлыгып тормас. Моңа карамастан, алган мәсләккә хыянәт итәргә ярамый.

«Казан утлары» журналы татарның вакытлы матбугат мәйданында үзенә бер урын тота. Аның кабатланмас йөзе, үз авторлары һәм укучылары бар. Болар – әдәбият һәм сәнгатьтән хәбәрдар мәдәни катламнар. Журналга язылу, аны уку кешенең кем булуы турында сөйли дип саныйм. Бигрәк тә укытучылар татар әдәбиятын иләк аша уздырган әдәби-публицистик журналларыбызның төп укучысы булып калырга тиеш дигән караштa торам. Дөрес, әлеге иләкнең кайвакыт тишекләре эреләнеп яисә күзәнәк ясаган җепләре ертылып та китә, шул вакытта аннан кирәкмәгән әсәрләр дә үтәдер. Ахыр чиктә, укучы сүзе әлеге сыйфатсыз әдәби берәмлекләргә киртә була ала һәм булырга тиеш тә!

«Казан утлары» журналы, икенче яктан – әдәби барышның хәлен күрсәтүче барометр яисә дәрәҗә үлчәгече дә. Андагы әсәрләрнең идея-тематик төрлелеге,

сәнгати сыйфатлылыгы, аңа килгән хатлар саны бу барышның тизлеген, күләмен, көчен ачык күрсәтеп тора. Журналда басылган әсәрләр әдәбиятта мәйдан тотканнарны, шул мәйданга атлап кереп барганнарны ачыкларга ярдәм итә. Ул укучы хәтерен яңа исемнәргә һәм заман әсәрләренә баета. «Казан утлары», шигырь-хикәяләрне, роман-поэмаларны һәм башкаларны сайлау иләге аша уздырып, әдәбиятыбызның уртадагы агым көчен калыплаштырса, шул агымны йомшарта торган әсәрләрне дә үзенә бөтенләй үк кертми калалмый. Камил каләмгә ия булмаганнарның Язучылар берлегенә күпләп узуы аның эшен шактый кыенлаштырды дип саныйм, чөнки түш кесәсенә язучылык кенәгәсе салганнар үзләренә аннан мәйдан таләп итә башлады, журналның хәтта юбилейларын билгеләп узуын көтә шикелле. Шунлыктан мин «Казан утлары» хезмәткәрләренә үз эшләрендә сабырлык, кыюлык, авторларга дөресен әйтеп бирә алырлык холык сыйфатлары телим.

«Казан утлары» журналы бүгенге көндә бик күркәм башлангычларны тамырландырды: анда матур хикәя-повестьларга конкурслар даимигә әйләнде, ул үз битләрендә чыккан әсәрләргә тәнкыйть күзе белән карарлык батырлыкка ия булды. Моның шулай икәнлеген елдан-ел журнал битләрендә басылган әсәрләрне танылган тәнкыйтьчеләр аша бәяләттерү традициясе күрсәтеп тора. Бу баш мөхәррир Илфак Мирза улы Ибраһимовның үзтәнкыйтькә хәзер икәнлеген дә сөйли. Авторларга жанрны, мактау яисә тәнкыйтьләү объектын сайлау иреге куелган. Яхшы әсәрне яманлыймы ул, начарны мактыймы – бары тик тәнкыйтьченең намус эше генә булып тора. Редакция коллективы оештырган «түгәрәк өстәл»ләр дә әдәбиятны алга җибәрүгә, милләт һәм аның тел язмышын кайгыртуга, милли мөстәкыйльлеккә бәйле хыялларыбызның тәмам сүнмәвенә хезмәт итә.

«Казан утлары» журналын күпсоставлы йөк тартып баручы локомотивка да тиңләргә булыр иде. Ул берничә йөз язучы иҗат иткән әдәбиятның артка китмәвен, ничек тә алга баруын тәэмин итешә. Аның башындагылар алга таба бер адым атлый икән, аларга ияргәннәр дә күпмедер алга атлый дигән сүз. Журнал хезмәткәрләре әнә шул адымнарны ясауга көч биреп тора.

***– Әдәбиятыбызның таҗы – шигърият, дибез... Борын-борыннан шагыйрьләр ил һәм җәмгыять сулышын шигъри сүз белән җиткергән. Поэзиядәге вазгыять бүген нинди? Әдәби басмаларыбыз битләрендә шагыйрьләр ни хәлдә «яшәп ята»?***



**Нурфия ЮСУПОВА,**
*филология фәннәре кандидаты:*

– «Казан утлары» журналы – татар шигъриятенең көзгесе, аның үсеш процессын турыдан-туры чагылдырып торучы барометры ул. Аны чын мәгънәсендә шигъри мәйдан, шигърият гамен кайгырта торган рухи кыйблабыз дип атап булыр иде! 1922 елның май аеннан чыга башлап, чор идеологиясе үзгәрүгә бәйле нинди генә исемнәрдә («Безнең юл», «Яңалиф», «Атака», «Совет әдәбияты», «Казан утлары») дөнья күрсә дә, әлеге саллы басма озын һәм катлаулы үсеш юлында дистә еллар буена үз кыйбласына тугрылыклы кала: татарның төп журналы буларак, «табадан төшкән» һәр яңа шигъри әсәрне диярлек татар укучысына ирештереп тора, әдәби барышның үзенчәлеген, ритмын тоярга мөмкинлек бирә.

Татар поэзиясендәге эчтәлек һәм форма «борылышлары»н, «поэтик шартлаулар»ны да әлеге басма шәрехләп бара. Әгәр татар поэзиясенең үсеш үзенчәлеген, сукмакларын күрим, сулышын тойыйм, әдәби тормышыбызның төп сәхифәләрен күздән кичерим дисәң, иң беренче чиратта, «Казан утлары» журналы төпләнмәләренә мөрәҗәгать итү мөһим. Бу яктан ул XX йөз башында дөнья күргән «Аң» һәм «Шура» журналлары традицияләренең дәвамчысы буларак кабул ителә. Һ.Такташның чор әдәбиятына яңа аваз салган шигырьләре, Х.Туфан, К.Нәҗми кебек шагыйрьләрнең футуристик,

имажинистик иҗат үрнәкләре, М.Җәлилнең тоткынлык чоры лирикасыннан аерым үрнәкләр беренчеләрдән булып бирелә дөнья күрә. 1960 елларда Р.Фәйзуллинның әдәби тәнкыйтьтә кайнар бәхәсләр үзәгенә әверелгән «Нюанслар иле» шигырьләр циклы, Х.Туфанның тоткынлык чорында язылган аерым шигырьләре, Г.Афзалның сарказм һәм ирония белән сугарылган поэтик үрнәкләре тәүге тапкыр нәкъ менә «Совет әдәбияты» журналында басылып чыга. Мисал өчен, 1956 елгы санда Г.Афзалның «Тәнкыйть сүзе» шигыре тәкъдим ителә! XX гасыр татар поэзиясенең үсеш юлында мондый мисалларны күпләп китерергә мөмкин булыр иде. Болар бөтенесе дә үз чорында басмадан батырлык, кыюлык таләп итә.

Шул ук вакытта, журнал үз заманы белән үзгәреп барырга мәҗбүр була: ул шигърият үсешендәге идеологик борылышларны шәрехли, татар шагыйрьләренең яңалыкка омтылган, искене сүккән, халык дошманнары эзләгән, зур сугышка рухландырган, яңа тормыш төзүне, фәнни-техник алгарышны данлаган, милли үзаңны уяту омтылышы белән янган шигырь-поэмалары биредә дөнья күрә, «Сулф», ТАПП, «Җидегәнчеләр» кебек төрле әдәби күмәклекләр булуы хакында да «хәбәр ителә».

«Казан утлары» бик күп яшьләргә татар поэзиясенә юл яра, аларга киң җәмәгатьчелекне тәүге иҗат җимешләре белән таныштыру өчен мәйдан булып тора. Шуның белән бергә төрле буын, төрле милләт шагыйрьләре тарафыннан язылган иҗат җимешләренең, татар шигъриятенең алтын фондын тәшкил иткән әсәрләрнең даими яңартылып торуын да ассызыклап үтү мөһим. Бу яктан басма үзенә күрә бер шигъри мәктәп хезмәтен үти.

«Казан утлары» журналы үз сәхифәләрендә татар шигъриятенең үсеш юлын билгеләгән тәнкыйди материалларны да тәкъдим итеп бара. Әлеге язмаларда татар шигъриятенең үсеш кыйбласы билгеләнә, үзгәреш-яңарыш юллары шәрехләп барыла. Мәсәлән, журнал төпләнмәләрендә Г.Нигъмәти, Г.Гали, Г.Рәхим, Г.Сәгъди, Г.Кашшаф кебек олпат тәнкыйтьчеләрнең мәкаләләре белән дә очрашасың, вакыт-вакыт «пычакка пычак килеп», поэзия хакында бәхәсләшүләргә дә тап буласың. Бу традиция бүген дә эзлекле дәвам итә.

«Казан утлары»ның оештырып җибәрелүе Г.Ибраһимов исеме белән бәйле. Журналның тарихына күз салсаң, тагын бер кызыклы фактка юлыгасың: аннан соңгы редакторларның күбесе шагыйрьләр яки шигъри җанлы тәнкыйтьчеләр булган икән, образлы итеп әйткәндә, «шагыйрьләр ат уйнаткан». К.Нәҗми, С.Хәким, Г.Кашшаф, З.Нури, Р.Мостафин, Р.Харис, Р.Фәйзуллин, И.Ибраһимов исемнәре шул хакта сөйли.

«Казан утлары» журналы киләчәктә дә үзенең классик юнәлешен саклап, шигърият мәйданында барган һәр үзгәрешнең үзәгендә «кайнасын», әдәби бизмән булып торсын иде.

***– Әдәби сүзнең, сәнгатебезнең һәм, гомумән, милләт культурасының чишмә башы халык авыз иҗатына барып тоташа. Гомер-гомергә әдәби әсәрнең нигезенә халык сүзе салынган, ягъни фольклористик үрнәкләр иҗатчының таяну ноктасы булган. Бүген җәмгыять һәм әдәбиятыбыз бу кануни шартка нинди мөнәсәбәттә?***



**Луиза ҖАМАЛИЕВА,**
*филология фәннәре кандидаты:*

– Соңгы елларда киң җәмәгатьчелектә халыкның милли йолаларына, гореф-гадәтләренә, бәйрәмнәренә игътибар арту күзәтелә. Татарстанда бик күп милләт вәкилләре яши. Сан ягыннан күпчелекне алып торган татарларның Сабан туе, керәшеннәрнең Питравы, русларның Каравоны, удмуртларның Гырон-быдтоны республика дәрәҗәсендә зурлап уздырыла. Билгеле, бу – матур күренеш. Чөнки күренекле этнограф Рәүфә Уразман сүзләре белән әйткәндә, «...халык бәйрәмнәре – шул халыкны милләт итеп берләштерә торган чараларның берсе. Һәр милләтнең үзенә генә хас бәйрәмнәре була. Алар халыкның милли горурлык, милли

хисләр культурасын тәрбияләргә, формалаштырырга ярдәм итеп кенә калмыйлар, ә шул хисләрне кичергән кешеләрдә рухи канәгатьләнү дә тудыралар. Бәйрәмнәр халык тормышының, культурасының аерылгысыз бер элементы да булып торалар. Алар зәгыйфьләнә икән – халыкның культурасы, яшәеше зәгыйфьләнә».

Халыкның гасырлар дәвамында формалашкан йолалары фән-техника үсеше нәтиҗәсендә юкка чыга бара. Аеруча календарь йолалар зур югалту кичерә. Чөнки кайчандыр кешенең кул көче белән эшкәртелгән басу-кырлар бүген көчле техника астында «изелә». Йолаларга гамәли ихтыяҗ кимү аның онытылуына, юкка чыгуына китерә.

Бүгенге көндә календарь йола бәйрәмнәреннән табигый рәвештә сакланып калганнары бармак белән генә санарлык. Бу – Сабантуй, Каз өмәсе, бик сирәк төбәкләрдә генә – Карга боткасы. Кайчандыр яңа елны каршылау белән бәйле булган Нардуган йоласы хакында бүген без фәнни чыганаклардан һәм тарих китапларыннан гына укыйбыз. Язгы көн һәм төн тигезләшкән көн – төрки халыкларның Яңа елны каршылау бәйрәме – Нәүрүзне 90нчы елларда мәдәният йорты хезмәткәрләре һәм укытучылар торгызырга тырышып карадылар, әмма ул табигый рәвештә кулланылышка кереп китә алмады.

Кайчандыр авыл кешесе үз тормышын өмәләрдән башка күз алдына да китерә алмаган. Авыр эшләрне бергәләп, күмәкләшеп тиз арада башкару өчен өмә җыйганнар. Ә бүгенге көн баласы, хәтта авылда үссә дә, чалгы, урак, сүс, туку, орчык, тула өмәләре һәм аларда кулланылган эш кораллары хакында да китаптан укып кына белә. Безне, барыннан да бигрәк йолалар башкарган вакытта кулланылган фольклор текстлары, лексик берәмлекләр кызыксындыра. Ә йолаларның юкка чыгуы кайчандыр халык телендә актив кулланылышта булган сүзләрнең дә гамәлдән чыгуына китерә. Тора-бара бу сүзләр онытылып, сүзлекләрдә, тарих китапларында һәм шул чорны тасвирлап язган әдәби әсәрләрдә генә сакланып калырга мөмкин.

Календарь йолалардан иң популяры һәм бүген дә татарлар яшәгән һәр төбәктә дип әйтерлек зурлап үткәрелә торган бәйрәм – Сабантуй. Тарихы белән бик еракларга барып тоташучы әлеге аграр йола, хәзерге вакытта үткәрелсә дә, аның беренчел функциональ табигате шактый үзгәргән. Гасырлар дәвамында аны үткәрү вакыты сабан аеннан, ягъни чәчү аеннан җәй башына күчкән. Бәйрәмнең исеме – Сабан – җир эшкәртү коралы белән бәйле. Ягъни, сабанның туе. Исеменә бәйле рәвештә, бу җир эшкәртүчеләр, игенчеләр бәйрәме булырга тиеш. Хәзерге вакытта, Сабан туе, массакүләм күңел ачу чарасы буларак, бөтен халык җыелып бәйрәм итүгә әверелде. Шәһәр субкультурасына ия яшьләрнең күбесе Сабантуйны халык җыелып шау-гөр килү буларак кабул итә. Сабан туе өч этаптан тора: 1) бәйрәмгә әзерлек; 2) бәйрәммәйдан көне; 3) бәйрәмнән соңгы кичке уеннар.

Бәйрәмгә әзерлек этабы авыл тирәсен, шәхси хуҗалыкларны җыештыру, тәртипкә китерүдән башлана. Ким дигәндә, бер ай алдан атларны чабышка әзерли башларга кирәк. Элек-электән бу – ат аягы кыздыру дип атала. Әмма хәзер Сабан туендагы ат чабышы бары тик район үзәкләре, шәһәрләрдә генә уздырыла. Кечкенә авылларда ат чабышы булмый диярлек. Гасырлар дәвамында үз тормышларын аттан башка күз алдына да китерә алмаган төрки халыкларның бүгенге буыны атны һәм аңа бәйле йолаларны бөтенләй онытып бара. Озакламый «Ир канаты – ат булыр» дигән мәкальне бик тар мәгънәдә аңлата башларга туры киләчәк. Бәйрәмгә бүләк бирүчеләр, беренче чиратта, бер Сабантуй белән икенчесе арасында өйләнешкән яшь парларның кәләшләре иде. Алардан һәрвакыт чигүле сөлге таләп ителде. Кызганыч, йоланың бу өлеше дә юкка чыга бара. Шул сәбәпле, кул эшләренә дә ихтыяҗ кими.

Әлегә Сабан туе көнендә оештырыла торган күп уеннар сакланган: капчык сугышы, капчык киеп йөгерү, баганага менү, кашыкка йомырка салып йөгерү, чүлмәк вату һ.б. Бәйрәмнең бизәге – милли көрәш ярышы. Дөрес, бүгенге батырлар көрәш символы булган тәкә һәм килен сөлгесе өчен генә көрәшеп тормыйлар. Аларга әзерләнгән көнкүреш техникасына яки автомобильгә кушымта буларак кына бирелә ул бүләкләр.

Сабантуй халыкның физик көчен сынау урыны гына түгел, ул халыкның җырлап-


биеп күңел ачуы да булган. Кызганыч, соңгы елларда мәйдан тирәсенә җыелып, түгәрәк әйләнеп бию, җырлау да сирәгәя. Чөнки бу рухи ихтыяҗны махсус чакырып китерелгән артистлар канәгатьләндерә. Шул рәвешле, халык бәйрәмдә катнашучы түгел, читтән күзәтүчегә генә әверелә бара.

Ә Сабантуйның соңгы этабы булган кичке уеннар хәзер гадәти дискотекага әйләнеп калды. Шул рәвешле, йолаларның гамәли вазифасы бетү аларның онытылуына, юкка чыгуына китерә. Бу исә, үз чиратында, әлеге йола белән бәйле сүзлек запасына да ихтыяҗны бетерә.

Татар әдәбияты классикларыннан Г.Тукайның «Исемдә калганнар», Г.Ибраһимовның «Алмачуар», Ф.Хөснинең «Йөзек кашы», «Авыл өстендә йолдызлар», Г.Бәшировның «Туган ягым – яшел бишек» һ.б. әсәрләренә мөрәҗәгать итсәк, алар язылган яисә аларда сурәтләнгән вакыйгалар барган чорда уздырылган Сабантуйларның бик күп хасиятләре хакында гаҗәеп бай мәгълүмат алырга була. Ә менә йола бәйрәмнәренең хәзерге вакыттагы торышын тасвирлаган, аларның гомерләрен әдәби текстта булса да саклап калучы әсәрләр иҗат ителәме?

Кайсы гына чорда яшәсәк тә, йола бәйрәмнәре халыкның этнографиясен, аның рухи халәтен, шагыйранә телен чагылдыручы чыганак булган һәм булачак. Шуңа да аларны саклау һәм киләчәк буынга тапшыру безнең, аеруча да язучыларның бик зур бурычы. «Казан утлары» журналы авторларын шул хакта уйланырга, фольклор катламнарыннан яңа хәзинәләр табып, шаһәсәрләр, үлмәс классика тудырырга чакырам!

***– Татар драматургиясе һәм сәхнә сәнгатенең торышы безне бүген канәгатьләндерәме? Әдәбиятның һәм сәнгатьнең әлеге четерекле төрләренә тиешле юнәлеш бирүдә вакытлы матбугат нинди вазифа үти?***



**Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ,**
*филология фәннәре докторы:*

– Татар халкының бүгенге яшәешен матур әдәбияттан һәм театр сәнгатеннән башка күз алдына китерү мөмкин түгел. Татар тормышы борынгы чорлардан ук халык авыз иҗатында, соңрак язма әдәбиятта чагылыш тапкан һәм халык алардан рухи таяныч алган, күңеленә юаныч эзләгән. Шуңа да бездә китап сүзен изгеләштерү бар. Күпгасырлык тарихыбызның гыйбрәтле сәхифәләре, халыкның үзенә хас яшәү рәвеше, традицияләре, гореф-гадәтләре әдәби әсәрләрдә якланып һәм сакланып килә. Бәхеткә, әлеге изге бурычны бүген әдәби журналларыбыз, аерым алганда, «Казан утлары» журналы уңышлы үтәп килә. Ә инде Галиҗәнап театр XX гасыр дәвамында татарның мәдәни учагы булып, аның ут-ялкыны меңнәрчә милләттәшебезнең күңелен җылытып, рухи көч өстәп, матурлыкка чакыра һәм саф, чиста, аһәңле телебез сагында. Әдәбият һәм сәнгать белән кызыксынып яшәгән һәр кеше өчен «Казан утлары» журналы һәм татар театры үзара аерылгысыз төшенчәләр булып тора.

Татар театрларының хәл-торышын, җәмгыятьтәге урынын билгеләү җиңелдән түгел. Бүгенге көндә 13 татар театры уңышлы эшләп килә икән, бу безнең шатлыгыбыз һәм горурлыгыбыз. Туган телебезне, мәгарифне, традицияләрне югалту куркынычы зур булган чорда, милли яшәеш кыйммәтләре сагындагы театр коллективларына без рәхмәт әйтергә бурычлы. Дөрес, татар театрлары репертуар туплауда шактый кыенлык күрә. Моның сәбәпләре турында уйланганда, шуны да искәртик: совет чорында идеологик максатларда язылган әсәрләрне бүген сәхнәгә куеп булмый. Шул ук вакытта, театрларда заман сулышын, чор проблемаларын чагылдырган пьесаларның чагыштырмача аз булуын күрәбез. Бу исә татар драматургиясенең кыенлык кичерүе, торгынлыктан чыгып, җанланып китә алмавы нәтиҗәсе. Шундый шартларда театрларыбыз еш кына проза инсценировкаларына һәм безнең рухыбызга

якын булган чит ил авторлары әсәрләренә мөрәҗәгать итә. Бүген театр коллективлары, бигрәк тә баш режиссёрлар алдында җитди бурыч тора: бер яктан, Идел буе, Россия, шулай ук Гареб һәм Шәрык халыклары театрларындагы үзгәрешләр белән бергә атлау, икенче яктан, көчле глобализация шартларында милли үзенчәлегебезне саклап калу. Әлеге авыр мәсьәләләрне җиңеп чыгуда газета-журналларның да җитди өлеше бар. «Казан утлары» журналы театрларның фикердәше, таянычы буларак зур вазифа үти. Журнал битләрендә соңгы елларда Т.Миңнуллин, З.Хәким, Р.Сәгъди, Д.Салихов, А.Әхмәтгалиева, И.Зәйниев пьесалары басылып чыкты. А.Әхмәдуллин, Ә.Закирҗанов, М.Хәбетдинова һ.б.ның классик драматургларыбызның юбилее уңаеннан яисә хәзерге сәхнә әдәбияты торышы турындагы язмалары кызыклы фикер алышуларга җирлек булды. Ә инде әйдәп баручы театрлардагы премьералар яисә театр режиссёрлары, артистлары, музыкант-рәссамнары турындагы мәкаләләр, әңгәмәләр киң катлау укучыларда аеруча зур кызыксыну уятып килә. Әлеге бәйләнешнең киләчәктә тагы да ныгуына, тирәнәюенә өмет итәм. Журнал битләрендә барлык театрлар эшчәнлеге турында язмалар даими рәвештә урын алсын иде. Иң мөһиме, әлеге мәкаләләр, мәгълүмат бирү белән генә чикләнмичә, теге яисә бу эшчәнлек төренә бәя бирү, нәтиҗә ясау һәм үсү-үзгәрү мөмкинлекләрен билгеләү рәвешендәге аналитик фикерләүгә йөз тотсын иде дигән теләктә калам.

***– «Әдәбият» сүзенең нигезендә – «әдәп»! Ул гасырлар дәвамында тәрбияви вазифа үтәгән, аеруча да яшь буынга аң-белем биргән. Телдән телгә күчеп йөргән әсәрләр әдәби басмалар кочагына сыенгач, хәлфә-мөгаллимнәребезнең эше шактый җиңеләя. Бүген газета-журналлар укытучыларыбыз өчен нинди кимәлдә хезмәт итә? Милләт, тел сагында торучылар – алар бит...***



**Әлфия МОТЫЙГУЛЛИНА,**
*филология фәннәре кандидаты:*

– Гасырга якын тарихы булган «Казан утлары» журналы берничә буынга белем һәм тәрбия бирүдә катнашкан. Бүгенге көндә ул – «өстәл китабы» булып йөри торган журнал.

«Казан утлары», ялкын чәчеп, янып, балкып, татар халкының әдәбият, мәдәният дөньясын даими яктыртып торучы журнал буларак, киң катлау укучыларны күз уңыннан ычкындырмый, җәмәгатьчелекнең төрле вәкилен истә тотып иҗат итә.

Журналда татар әдәбияты дәресләренең нигезен тәшкил иткән әдәби әсәр беренче кат дөнья күрә. Шуннан соң күп юллар үтеп, кайбер дәреслекләргә шактый кыскартылып урнаштырыла. Әмма укучының укытучы җитәкчелегендә бу әсәрне алданрак та уку, танышу, аның турында сүз әйтү мөмкинлеге бар. Шуңа күрә әдәбият дөньясындагы сөйләм үстерү дәресләрен, дәрестән тыш уку өчен бирелгән сәгатьләрне журнал сәхифәләре белән танышуга багышларга мөмкин. Бу алымны мәктәпләребезнең алдынгы укытучылары үзләренең эш тәртибенә бүген уңышлы гына кертеп тә җибәрде инде.

Әмма журналның роле аның белән генә чикләнми. Татар әдәбиятын өйрәнү, тәнкыйди фикерне үстерүдә шактый аксый торган як бар. Ул да булса татар әдәбияты укытучысының укучыны кызыксындыру коралы – язучының иҗат лабораториясе. Әдипнең шәхси тормышын, язу үзенчәлекләрен өйрәнү аша кайбер гомумиләштерүләр ясау, шуның аша чор контекстын өйрәнү мөмкинлекләре ачыла. «Язучы остаханәсе» рубрикасы нәкъ шул максатны тормышка ашыру юлы булыр иде. Моны мин, күп еллар әдәбиятчыларны методик яктан әзерләүче һәм дәреслекләр авторы буларак, «Казан утлары»ның бурычы дип саныйм.

Журнал битләрендә укытучылар катнаша торган төрле конкурслар, аерым рубрикалар арткан сурәттә, әдәбият мөгаллименең үз мөнбәре дә биегәя. Аларны төрлечә оештыру мөмкинлекләре бар: беренчедән, мәктәп тормышы белән бәйле әдәби

әсәрләр бәйгесе, соңгы елларда «Казан утлары»нда басылган әдәби әсәр турында бәхәс, әдәби әсәргә укучылар белән берлектә анализ юлларын эзләү һ.б.

«Казан утлары»н укытучылар күргәзмә материал рәвешендә куллана бит. Рәссамнарның журнал тышлыкларында төсле репродукцияләрен, картиналарын урнаштырып (бу бүген өлешчә эшләнә дә инде), алар турында сәнгать белгечләренең фикерләрен күрү, уку шулай ук әдәбият дәресләрен культурологик яктан баета төшәр иде.

Татар теле һәм әдәбияты укытучылары журнал материалларын сыйныфтан тыш та файдалана, дидек. Соңгы елларда бер-бер артлы «гөмбәләр кебек үсеп чыккан» төрле исемдәге конференцияләргә эш җибәрү өчен, укытучы тема таба алмый газап чигә. Бер конференциядә кызыклы булган эш башкаларына да «күчеп йөри». Ә тикшеренү эше темасы буларак мәктәп программасында даими өйрәнелеп килүче Г.Тукай, Г.Ибраһимов, Ф.Әмирхан, М.Җәлил, Ф.Кәрим һ.б. иҗатларына бәя алына. Ул, китаптан китапка, дәреслектән дәреслеккә күчә-күчә, күптән ятланып беткән сүзләрне балалар Г.Тукайның «Туган тел»е урынына, тотлыгы-тотлыга, кәгазьдән укыйлар. Конференциягә нәтиҗә ясаган вакытта әйтелгән фикерләр, яңарак әдәбиятка мөрәҗәгать итегез, дигән киңәшләр «диварга аткан борчактай» кире үзеңә әйләнеп кайта. «Ә нигә, Г.Ибраһимовны өйрәнергә ярамыймыни?» – дип сорау куйган укытучыдан тагын нәрсә көтәсең?! Хәзерге әдәбиятның йөрәк тибеше – әдәби басмаларда! Шулай булгач, заманча әдәбият укытучысы аларны куен кесәсендә йөртергә тиеш! Билгеле, бу – икеяклы таяк. Мөгаллимнәребезгә редакция хезмәткәрләренең, язучы-әдипләребезнең йөз белән торуы лазем. Журнал битләрендә укытучыларга киңәшләр, аерым темаларны ачу юлларын күрсәткән язмалар урнаштырыла башласа, алар да укытуның, төрле конференция-конкурсларда катнашуның, балл җыю чарасы гына булмыйча, балаларны әдәбият, мәдәният, тел гыйлеме белән кызыксындыруга хезмәт иткәнен тирәнрәк аңлар иде.

Моннан тыш, журнал битләрендә укытучыларның җитди дәресләрендә укучыларны ял иттерү өчен тематик эчтәлекле мәзәкләр, аерым очраклар, кызыклы хәлләр турындагы язмаларның күбрәк урнаштырылуын күрәсе килә. Менә Илдар ага Юзеев белән очрашу истәлеге. Ул сөйли:

«Шулай 15нче шәһәр больницасында ятам. Карантин булу сәбәпле, бер кешене дә кертмиләр. Минем яныма Шәүкәт Галиев килеп керде.

– Бер сине генә ничек керттеләр? – дип сорыйм.

– Мин ЮЗИгә керәм, дидем, шуңа керттеләр, – дигән».

«УЗИ» белән «ЮЗИ» сүзләре алмашында килеп чыккан каламбур укучының игътибарын җәлеп итә, ул ике зур шагыйрьнең үзара дуслыгын, җор теллелеген, димәк, әсәрләрендә дә юмор яшәвен аңлап кала. Сыйныфны темага кертеп җибәрү җиңелләшә.

Гомумән алганда, «Казан утлары» әдәбият-сәнгать нигезләрен укучыларга җиткерүче, әдәбият укытучысының даими киңәшчесе, ярдәмчесе булып торырга тиеш.

***– Укытучы булуыма «Казан утлары» сәбәпче, дигән фикерләрне очрашулар вакытында еш ишетергә туры килә. Әлеге басма мөгаллимлек мәйданының капка төбендә басып торган яшь егет-кызларны инде бүген олпат остазларга әйләндергән бит...***



**Гөлсирә МУЛЛАСАЛИХОВА,**
*Саба районы Шәмәрдән лицееның югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы:*

– Нәкъ шулай! Һәркемнең көтеп алган кунагы, яраткан сые... һәм яратып укыган китабы яки журналы була. Минем өчен өчесен дә берләштергәне – «Казан утлары» журналы. Ничекме? Иң кадерле кунак кебек көтеп алам, чөнки ул айга бер тапкыр гына килә. Аны бер кат актарып чыкканнан соң, үземә тансык

булган язманы тәмле сый ашаган сыман рәхәтләнеп укыйм. Бер генә язманы укый икән дип хаталанмагыз, журналны укып бетермичә куя алмыйм.

«Казан утлары» журналы белән мәктәп елларыннан таныш. Бүгенге көндәге кебек яхшы сыйфатлы кәгазьдә басылмаса да, эчендәге язмалары энҗе-мәрҗәннәргә тиң иде. Әдәбиятны яратуымда да шушы журнал зур роль уйнады. Анда эшләүчеләр миңа кул җитмәслек биеклектәге кешеләр булып тоелалар иде.

Мәктәпне тәмамлагач, Казан дәүләт университетына укырга кердем. Хыялым «Казан утлары» журналында эшләү иде, тик яшьлек хыяллары гына тормышка ашмады... Казаннан китәргә туры килде. Бүгенге көндә мәктәптә эшлим. Әдәбиятны ярату турында сүз чыккач, укучыларыма да «Казан утлары» журналын яратып укуым аркасында мәгълүматлы булуым, укытучы булуыма да аның сәбәпче икәнен әйткәнем бар.

Яраткан журналым – минем өстәл китабым. «Казан утлары» – әдәби-мәдәни тормышыбызның тарихи елъязмасы. Әдәбият укытучысына гына түгел, үзен татар дип санаган һәркемгә маяк ул. Халкыбызның үткәне турында белергә, киләчәген күзалларга ярдәм итә. «Татар галәме», «Миллият», «Тарих» сәхифәләре татар милләтен саклауга юнәлтелгән.

Әдәбият белән сәнгать гомер-гомергә янәшә «атлыйлар». Сәнгатьнең кайсы тармагын гына алма, театрмы ул, җыр-музыкамы, сынлы сәнгатьме, һәркайсында дөньякүләм масштабта күрсәтерлек, чын-чынлап горурланырлык шәхесләребез бар. Алар турында, иң беренче булып, «Казан утлары» журналы битләрендә басыла.

Яңа әсәрләр белән танышу – күңелгә әйтеп бетермәслек рәхәтлек бирә. Журналда өзекләрен укыганнан соң, хыялланып, китап булып басылганын көтәсең. Кайбер китаплар кулга эләкми дә кала. Ярый әле өзекләрен укыдым, дип сөенәсең.

Каләм тибрәтүчеләргә дә махсус сәхифә бар. Аларның фатихасы белән күпме яшьләребез талантлы язучылар булып китә. «Казан утлары» халкыбызның рухи дөньясын һәм мәдәниятен саклауга хезмәт итә.

Халкыбыз бүгенге көндә туган телебезне, моңыбызны, матур гореф-гадәтләрне саклап, олы бер милләт булып яши икән, әлбәттә, әлеге журналда эшләүче оста каләм ияләренең хезмәте дә монда әйтеп бетергесез зур. Журнал зәвыклы укучыга исәпләнгән.


Укытучылар өчен «Казан утлары» журналы – бәяләп бетермәслек хәзинә. Мин журналга реклама ясарга җыенмыйм, әдәбият укытучыларына аннан башка мөмкин түгеллеген генә әйтәсем килә. Дәреслектә бөтенесе язылган, нигә кирәк ул, Интернет заманы, дияр кайберәүләр. Дәреслекләр биш елга бер чыга, күп кенә мәгълүматлар искерә. Без яңалыкны белеп торырга, аны укучыга җиткерергә тиеш. Яшерен-батырын түгел, укучыларның күбесе китап укымый, ә укытучы әйткән яңалык, барыбер, баланың колагына керә.

«Казан утлары» халкыбызның рухи дөньясын һәм мәдәниятен саклауга хезмәт итә.


Яше гасырга якынлашкан журналымның һәрвакытта шулай зәвыклы булуын теләп калам. Шушы журналда эшләүчеләргә баш иям.


**Рамил ХАННАНОВ** *әзерләде*.

## **Баш мөхәррирләр**


*Галимҗан Ибраһимов*


*Гасыйм Мансуров*


*Галимҗан Нигъмәти*


*Гомәр Гали*



*Гомәр Бәширов*



*Кави Нәҗми*


*Гази Кашшаф*


*Газиз Иделле*



*Абдулла Гомәр*



*Газиз Мөхәммәтшин*


*Рафаэль Мостафин*


*Зәки Нури*


*Гариф Ахунов*



*Ренат Харис*


*Равил Фәйзуллин*


*Илфак Ибраһимов*



*Язучылар, журналистлар, сәнгать эшлеклеләре милли республикалар буйлап зур сәяхәткә чыгар алдыннан. Беренче рәттә (сулдан уңга): Газиз Иделле, Мирсәй Әмир, Гадел Кутуй, Һади Такташ, Демьян Фәтхи; икенче рәттә: Закир Гали, Гомәр Гали, Галимҗан Нигъмәти, Кави Нәҗми; өченче рәттә: Зариф Бәшири, Исмәгыйль Рәми, Гавриил Беляев, Шәриф Камал, Кәрим Тинчурин, Лев Рубинштейн, Галиәсгар Камал, Салих Сәйдәшев, Шакир Шамильский. Казан, 1929 ел.*




*«Казан утлары»ның элгәреләре булган журнал тышлыклары («Безнең юл», «Атака», «Совет әдәбияты» )*



*«Казан утлары» журналының редколлегия утырышыннан соң. Утырганнар (сулдан уңга): Флүс Латыйфи, Рәдиф Гаташ, Рашат Низами, Аяз Гыйләҗев, Хатыйп Миңнегулов, Әхсән Баян, Әмирхан Еники, Гариф Ахунов, Равил Фәйзуллин, Әхмәт Рәшитов; басып торалар: Харрас Әюп, Ркаил Зәйдулла, Шәүкәт Галиев, Миркасыйм Госманов, Зиннур Хөснияр, Тәлгат Галиуллин, Ринат Мөхәммәдиев. 1998 ел.*



Мәгъсум Харисов

# УКЫТУЧЫ ИРТӘ ЧАЛАРА[1]

## АВТОБИОГРАФИК СӘХИФӘЛӘР

### Балачак

*Кеше өчен беренче мәктәп – ана мәктәбе, ул яхшы гадәтләр, хезмәткә мәхәббәт тәрбияләүгә нигезләнергә тиеш.*
Ян Амос Коменский

Елларны саный-саный, гомер үткәнен, картаюны сизми дә каласың икән. Балалар, оныклар соравына җавап биргәндә, яки дус-ишләр белән әңгәмә корганда, яки ялгыз калып уйланып утырганда, үткән гомернең кайбер сәхифәләрен өзек-өзек кенә искә төшерәсең. Тормыш дулкыннары безнең буын кешеләрен бөтереп алып, язмышларны төрлечә хәл иткән чорда, мин дә шул дулкын эчендә булдым. Мин – укытучы. Профессиям уку-язуга нигезләнгән булса да, үзем турында язарга вакыт тимәде. Пенсиягә чыгып, буш вакыт була башлагач, мин дә үз тормышымны, баштан үткән хәлләрне, шатлыклы һәм кайгылы минутларны акка кара белән төшерү өчен кулыма каләм алдым. Үткәнне белү балаларга да, оныкларга да зыян итми, киресенчә, киләчәк буын үз ата-бабасының, әни-әбисенең көнкүрешен, әхлак-тәрбия сыйфатын, сәяси карашларын, омтылышларын яхшы белеп, уңай якларын үзләренә өлге итеп алып горурлансын, җитешсезлекләренә тәнкыйть күзе белән карап гыйбрәт алсын.

Без туганбыз, яшьләй үк заман дулкынына кушылганбыз, айкалганбыз-чайкалганбыз. Димәк, язарлык эшебез бар.

***

Мин туу таныклыгы буенча – 1917 елның 5 апрелендә, ул вакыттагы административ бүленеш буенча – Сембер губернасы Буа өязе Килдураз волостеның Казма авылында урта хәлле крестьян Әхмәтҗанов Харис гаиләсендә дүртенче бала булып дөньяга килгәнмен. Әнием Бибисәхия дә Казма авылының урта хәлле игенче, итек-читек тегүче Гыйниятулла кызы. Аның әнисе Хәдичә яшьләй үлеп, ул үги әнисе Зәкия әби кулында тәрбияләнеп үскән.

1917 ел Россия тарихында искелекне җимереп, яңа дәвергә юл ярып, мәңге җуелмас эзен калдыргангамы, Октябрь революциясенең мәгънәсен аңлый башлаганнан бирле, мин үземне Яңа дәвер кешесе – Октябрь баласы итеп хис итәм. 1917 ел. Россия тарихына күз салсак, бу чорның нинди дәһшәтле еллар булуын, халыкның тормыш авырлыгы кичерүен, искелек белән яңалыкка мөнәсәбәтен аңлавы бүгенге көн кешесе өчен әллә ни авыр булмаса да, ул вакыт кешеләре өчен гаҗәеп дәрәҗәдә читен булган,

[1]Редакциядән: Әсәрнең авторы Мәгъсум Харис улы Харисов (1917-2004) – фронтовик, Россиянең атказанган укытучысы, РСФСР Халык мәгарифе отличнигы, Татарстан мәктәпләрендә 44 ел эшләгән. Әсәрне журналга авторның улы Ренат Харис тәкъдим итте.

яңа үзгәрешләр кеше психологиясенә зур йогынты ясаган. Бу елларның авырлыгы безнең ишле Әхмәтҗановларны да читләтеп үтмәгән. Ишле семья дигәннән, белмим ни сәбәптәндер, шактый олыгаеп, берничәшәр балалары булуга карамастан, әтием Харис үзенең бертуган абыйсы Хәнәфия белән бер йортта яшәгән. Аларның әниләре, миңа дәү әни тиешле Бибинавал әби дә исән булып, әтиемнең сеңлесе Нурлыһада апа да шунда. Шуның өстенә, әтиемнең апасы Өммеһани Сориле авылында Сабирҗан муллада тормышта булып, ике баласын калдырып авырып үлә. Аның ике баласы – Мирзакрам белән Исмәгыйль – әтиемнәрдә калып, барысы 13 җан бер гаиләдә тәрбияләнгән. Билгеле, атлы, сыер-сарыклы, имана җирле йортта тамак ягыннан кысанлык кичермәсә дә, чәй-шикәре, кием-салымы ягыннан бу авыр елларда зур гаиләгә бик үк рәхәт булмагандыр.

Гражданнар сугышы вакытында әтием Харисны мобилизация белән Ижау мылтык заводына хезмәткә җибәргәннәр. Ул, анда күпмедер эшләгәннән соң, авылга кайтып игенчелек белән шөгыльләнгән. Әтиемнең шуннан башка эш эзләп читкә чыгып китүен белмим.

Урта Идел буйларындагы 1921 елгы корылык, чөй өстенә тукмак дигәндәй, халыкның болай да авыр тормышын тагын да кыенлаштыра, ачлыктан җанны саклап калу өчен каты көрәш башлана. Авылның кайбер кешеләре семьялары белән Донбасс, Себер якларына сәфәр тота. Безнең гаилә читкә китәргә җыенмый, бар булганын чамалап кына тотып, алдагы уңышка ялгарга тырыша.

Ачлык белән көрәшү дәүләткүләм әһәмияткә әверелә. Яшь Совет дәүләте халыкны ачлыктан коткару өчен төрле чаралар күрә. Шундый чараларның берсе – Америка паёгы. Балалар өчен бирелә торган «американ аш паёгы» Сәйфетдин мәзиннәр йортында пешерелеп, аш алу өчен Исмәгыйль абыйга ияреп барганымны хәтерлим кебек. Авыл халкы ачтан үлмәс өчен кош-корт, сарык-кәҗә, сыер, хәтта атларына кадәр суеп ашаган яки азык-төлеккә алмаштырган. Мөбарәкшин Гаделша абыйның сөйләвенә караганда, ялгыз яшәүче Газзә әби үзенең өен пот ярым арыш онына Сираҗ байга саткан, шулай да гомерен саклап кала алмаган, ачлыктан җәфа чигеп үлгән. Ачлык кешене төрле авыр, фаҗигале хәлләргә төшерә. Балалары белән генә калган Заһирә (исеме шулай иде бугай) иртә белән көтү куганда Фәсхетдинов Гыймадетдиннең ачык тәрәзәсе аша мичтән чыгарган икмәкләрен күрә. Ач кешенең, икмәкне күргәч, күзе яна, аңы болгана. Өендәге ач балалары тавышын ишеткән кебек була. Үзе дә сизмәстән, тәрәзә аша үрелеп, бер ипине алъяпкыч астына тыга. Кайсыдыр моны күреп, Гыймадетдин абыйга әйтә. Менә шул бер икмәк өчен Заһирә абыстайның кулларын бәйләп, урам буенча йөртәләр, артыннан мыскыллы сүзләр кычкыралар.

Халык, ачтан үлмәс өчен, алабута җыеп, алабута икмәге пешереп ашаган. Авыл халкы шундый шартларда яшәгәндә, безнең ишле гаиләдә дә ашау-эчү чамалы булгандыр. Кеше алдында ригаялек өчен генә булса да, безнекеләр дә алабута җыйнаганнар һәм кәтерги[2] пешергәннәр. Хәбибрахман абыйлар белән алабута кәтергие кимерүебез исемдә калган. Менә шундый шартларда чәй, шикәр, конфет, прәннек турында уйларга да мөмкин булмаган, андый татлы әйберләрнең тәмен авыз татымаган. Ул елларны кием-салым да әниләрнең җитен сүсеннән эрләп суккан киндер күлмәк һәм ыштан була торган иде. «Мин киндер күлмәк кимим, тәнне каклата», – дип, озак кына елап, әнкәй белән тарткалашканымны әле дә хәтерлим. Киндер күлмәк дигәннән, шулары нык истә калган: ул елларны һәр хуҗалык үзенә бүленеп биргән имана җиренә һәм бәрәңге бакчаларына киндераш (конопля) чәчә иде. Кырга җитен чәчүчеләр дә була торган иде. Киндераш үсеп орлыклангач, ата үсемлекләрне («баса» дип йөртелә), арадан кереп, чүпләп йолкып аласың. Аны чүпләү-җыйнау бала-чага һәм хатын-кыз эше булып санала. Ләкә[3] буйлап киндераш арасына кереп киткән бала-чагаларның чыр-чуы белән бергә, буй җиткән кызларның, киленнәрнең үзара көлешеп сөйләшкәннәре, ара-тирә җыр сузуларын тыңлау шундый күңелле була торган иде.

Орлыгы көзен сугып алынган киндераш-баса һәм җитен көлтә-бәйләмнәрен йомшарту өчен сал ясап, язын Саз күленә батыралар. Йомшап сүсләнгәч, судан чыгарып юып киптерәләр, аннан авылга ындырга алып кайталар. Болар – ирләр эше.

[2] Кәтерги – алабута оныннан пешергән кабартма.
[3] Ләкә – кишәрлекне түтәлләргә бүлү өчен калдырылган буш буразна-юл.

Кипкән киндер, җитенне махсус станда талку башлана, ягъни сүсне талкышыннан аералар. Менә мондый эшләрдә әниләргә бала-чагалар да булыша. Көз көне, урып-җыюлар беткәч, әлеге сүсләрне йомшарту өчен киндер төю өмәсе оештырыла. Кичлегеннән үк өмәгә килергә тиешле кызлар чакырыла. Камыр ашы пешерелә. Тирә-күршеләрдән киле һәм кисаплар җыйнала. Иртә таңнан кызлар җыела. Кайнар коймак, кабартма белән сыйланып алгач, өчәрләп-дүртәрләп сүс төю башлана. Биш-алты киледә 18-20 яшьләрдәге буй җиткән кызларның-апаларның, көлешә-көлешә, бер-берсенә мәзәк сүзләр әйтешен, үзенә күрә бер ритм белән музыкаль «дөп-дөп» иткән тавышны, яңгырашны тыңлавы, алар арасында «әшем» кешесе булып, олылар кушканны башкарып йөрү күңелгә рәхәтлек бирә иде. Билгеле, өмә булгач, кызлар янына егетләр дә килә. Егетләр кызларга сүз кушып, үзләре дә сүс төюдә булышалар иде. Кичен өмә кызлары уен оештыралар, җырлыйлар, бииләр. Иң хәтердә калганы шул: Миргалим абзыйның кызы Галия апаның, тальян гармунда уйнап, кызларны биетүе һәм җырлатуы. Галия апа ул вакытта гармунны авылның иң оста гармунчылары Фәтхелислам, Тәүфикъ, безнең Исмәгыйль абыйлардан калышмый уйный дисәң дә ярый торгандыр. Белер-белмәс биегән кызларның көенә китереп уйный ул тальян гармунны. Өмәнең иң күңелле вакыты – кичәнең кызган чагы – авыл егетләренең өмә йортына, төркем булып, гармун белән җырлашып килүләре, чиртлек уены. Исеменнән үк күренеп тора – чиертеп уйнала торган уен. 1,5-2 см юанлыктагы кабыклы чикләвек чыбыгын 1,5-2 см озынлыкта итеп вак тешле пычкы белән кисәсең. Аннары аларны үзәктән урталай буйга ярасың. Аларны пычак, пыяла кисәге белән шомартасың. 15-20 пар шундый чиертлекләрне учың белән җиңелчә генә өстәлгә яки идәнгә, яки сәкегә сибеп җибәрәсең. Уенга кимендә икедән бишкә кадәр кеше катнаша ала. Әгәр дә чиертлек кискән ягы (башы) белән басса, «баба» дип атала һәм уенчы аларны үзенә җыйнап ала. Аннан соң төсләренә карап (кабыклы ягы кара, ярган ягы ак) караларны бер-беренә (әгәр башкаларга тимәсә), акларны бер-беренә чиертеп үзенә җыя. Чиерткән ак чиертлек карага тисә, ул уенчы уенны туктата, уенны күршесе дәвам итә. Кем күбрәк җыйса, шул отучы була. Бу уен хәзерге бильярд уенын хәтерләтә. Балаларда ихтыяр һәм дикъкать, коллективизм рухы тәрбияләргә ярдәм итә, шул ук вакытта төз ату, гадел булу, җитезлек кебек күнекмәләр дә бирә. Өйгә кергәч, төрле мәзәк сүзләр әйтеп, кызлар белән сүз алышулар, җырлау һәм биюләр була. Шунысын да әйтергә кирәк: бу егетләр өмә өенә хуҗадан рөхсәт сорап керәләр, шулай ук хуҗа кушуы буенча өйдән чыгып та китәләр. Егетләр арасында сүгенү, мыскыллы сүзләр әйтү, тәмәке тарту, өмә өенә исереп килүләрне күрмәдем, башкалар сөйләгәнне дә хәтерләмим. Сүс өмәсе безнең әниләребезгә, апаларыбызга көзге, кышкы озын төннәрдә җеп эрләп, тукыма сугу өчен сүс әзерләп калдыра.

Кышкы озын төннәрдә без кичне-көнне ничек үткәрә идек икән?! Көзен каз сую, киндер төю өмәләре үткәрү җәйге-көзге авыр эштән соң бәйрәм төсен алып, авыл халкын яшеннән картына кадәр берләштергән кызык бер сәхифә булып истә калган. Бу өмәләрнең яшьләр өчен иң әһәмиятлесе – бер-берен күреп сөйләшергә, мәхәббәт чаткыларын дөрләтергә, бер-бере белән аңлашырга мөмкинлек биргән. Шул вакыттагы нинди вакыйгалар истә икән?

Башта без – ир малайлар (мин, Хәбибрахман, Хәлилрахман һәм Исмәгыйль абый) йорт эшләрен, ягъни терлек-туарны төнгелеккә ябу өчен асларын чистарту, утлыкларга салам салып, атларга арыш башагы чылатып, он сибеп бирү, бәрәннәрнең алдына печән салып, җылы абзарга ябып калдыру кебек эшләрне башкара идек. Иртә белән өйгә ягу өчен әниләр бәйләгән салам көлтәләрен чоланга ташу да безнең өстә иде. Иртә һәм кичен ат җигеп, Зөя елгасыннан мичкә белән су алып кайтуны Исмәгыйль абый, ә бик салкын кыш көннәрендә әткәй башкара иде.

НЭП чорында безнең хуҗалыкта 2 ат, 2 сыер, башмак тана, бозау, 20ләп сарык (бәрәннәре белән җәй көне 50 баш була иде) һәм 2 эте булган йортта балаларга да, олыларга да эш җитәрлек. Кичке аштан соң өйдә үзенә күрә бер җанлану башлана. Без, балалар, әлеге дә баягы «чиртлек» уйный идек. Безнең авыл зур түгел – 155[4] йорттан төтен чыга. Төп дүрт урамы булып, шул урам егетләре, җыелышып, гармунга җырлап,

[4]Бүгенге көндә – 50-60 йорт.

Зөя елгасы буена җыелыша. Менә шунда инде гармунчылар ансамбле башлана. Безнең авыл егетләре «вараксин» гармунын хуп күрәләр иде. Яңа көйләрне беренче булып Фәтхелислам һәм Тәүфикъ абыйлар башкара, хәзерге тел белән әйткәндә, ансамбльгә дирижёрлык итә. Әниемнең үги энесе Тәүфикъ абый көйне оста башкаруы өстенә, аның уйнау рәвешен карап торуы да бик күңелле иде. Ул, гармунын тартып сузганда, үзе дә 90 градуска борылып, япканда элекке хәленә кайта. Шулай дәртләнеп, киерелеп уйный иде ул гармунны.

Җырлашып-биешеп алгач, ягъни репетиция ясагач, өмә өенә юл тоталар. Алар җыры якынлашкач, хуҗа капкасын бикләп куяр да, үзе терлек-туарын караган булып йөрер. Кызлар исә үз җайларын, дәрәҗәләрен белеп, иннек-кершәннәрен кабат төзәтеп, сәкегә һәм эскәмияләргә урнашыр һәм гармунга кушылып җыр сузар. Капка төбендә җыр дәвам иткәндә, егетләрнең кыюрагы, хуҗа капкасын кагып, өйгә керергә рөхсәт сорар. Хуҗа рөхсәте белән егетләр өйгә узып, үз дәрәҗәләрен белеп кенә кайсы-кая урнашыр. Билгеле, өлкәнрәкләре түргә узып, яшьрәкләре ишек катында калыр. Ә гармунчы?! Ул түр башында, сәке йөзлегендә, кызлар арасында. Китә мәзәк сүзләр, көлешү, үртәшүләр. Аннан китә биеш, җырлаш, күмәк уен. Иң таралган уеннарның берсе – кызлар белән егетләрнең әйләнәдә җырлап, әйләнә уртасында егет белән кызга чәнечтереп җыр җырлау һәм аларга җәза бирү: җырлату, биетү, табышмакка җавап эзләтү һ.б.

Егетләр, кызлар үзләрен иркен тотсын өчен, хуҗа абзый, йомыш табып, күрше-күләнгә чыгып китә, билгеле, егетләрне ышанычлы дип тапса. Сәгать кичке 11ләрдә егетләр аулак өйдән чыгып китәләр. Аларның гармунга кушылып җырлап таралышуы әле озак ишетелеп тора. Егетләр чыгып киткәч, берара кызлар да тынып калалар. Суынып кергәннән соң, уен элеккечә үк җанланмый. Кызлар егетләргә бәя бирәләр. Кайберләрен мактыйлар, ә кайберләренә «кәҗә тәкәсе кебек сасы» (тәмәке тартучы), «корчаңгы тай» (ышкынгалап утыручы), «мүкләк бозау» (сөйләшмәүче, уенга катнашмаучы), «озын куллы» (тоткалаучы) һ.б. дип, үзләренең бәяләрен дә бирәләр. Безнең авылда аулак өйдә егетләрнең кызлар белән куну гадәте булмаган. Кызлар белән егетләр мәхәббәте күреп сөйләшү, сәлам хатлары аша алып барылган. Өйләнгәндә кызны яучылап алганнар.

Олылар нишләделәр икән?

Әнкәй белән аның килендәше Зоха аптый[5] кабаларын сәке йөзлегенә куеп, йон яки җитен-киндер сүсе эрләргә, яки бияләй һәм оек бәйләргә утыралар. Әткәй белән Хәнәфия абый кичке тегү эшендә – аяк киеме тегәләр. Ә дәү әнкәйнең төп эше – китап уку. Бу – көндәлек гадәти күренеш.

Дәү әнкәйне без – балалар – бик ярата идек, олылар да бик ихтирам итә иде. Аның сүзе – йорттагы һәрбер кеше өчен закон. Ул уртача гына буйлы, аксыл, түгәрәк, мөлаем йөзле, кечерәк кенә борынлы, чал чәчле карчык иде. Кунакка барганда битенә кершән сылар, күзенә сөрмә тартыр, бармакларына йөзекләр, беләгенә киң, ахак кашлы беләзекләр кияр, чәченә көмеш чулпылар тагып, йон күлмәк өстеннән күкрәкчә (хәситә), аның өстеннән укалы бәрхет камзул, аягына чигешле читек киеп алгач, бигрәк тә матур күренә иде. Кыш көннәрендә башына ак каймалы Оренбур мамык шәлен ябынып, камалы тун, аягына кама мехы тоткан калуш (кыска балтырлы киез итек) кияр иде. Кунактан алып кайткан күчтәнәчне башлап апага бирә торган иде. Янәсе, ул – кыз бала, аны ихтирам итәргә кирәк.

Дәү әнкәйдә нинди кием булса, безнең әнкәй һәм Зоха аптыйның да (әткәй агасы Хәнәфия хатыны) шундый ук киемнәре бар иде. Алар да кунакка шулай киенеп йөриләр. Бу киемнәр аларга бирнә бүләге итеп бирелгән булгандыр. Зоха аптый – Югары Наратбашының таза хәлле крестьян Гали кызы, әнкәй (Сәхия) – шулай ук үзебезнең нәсел тиешле таза хәлле крестьян Гыйниятулла кызы. Тегү-сату белән шөгыльләнгән һәм Казан байлары-сәүдәгәрләре белән эш йөрткән Әхмәтҗан бабай кием-салымны һәм китапларны Казаннан алып кайта торган булган. Безнең өйдә китап булу Әхмәтҗан бабайдан килә. «Кояш» газетасын, «Карчыга» журналын да Әхмәтҗан бабай алдырган. Журналның барлык номерлары әле дә булса миндә саклана. Ул вакытларда «Кояш» газетасын авылның аек фикерле Әхмәтҗан, Гыйниятулла бабамнар

[5]Аптый – абыстайны безнең якларда шулай әйтәләр.

һәм Гафиятуллалар гына алдырган. Кичләрен капка төпләренә халык җыелып газета укуларын әткәй бик тәфсилләп сөйли иде.

Кайбер очракларда «чиртлек» уены нәтиҗәсе маңгай шешү белән, ягъни алдан килешү буенча оттырганы чиртлек санынча маңгайга чиертү белән тәмамлана иде. Ләкин бу уен артык озакка бармый, олыраклар – Хәлилрахман абый, Мәсрура апа, Исмәгыйль[6] абыйлар дәү әнкәйдән сабак алалар, үткән сабакларын яттан тыңлаталар. Белмим, мин үзем кайчан сабак укый, ятлый башлаганмындыр, бер дә хәтердә калмаган. Олыларга ияреп хәреф таныргa өйрәнгәнмен, укый башлаганмын. Шулай итеп, минем беренче хәреф өйрәтүчем-укытучым дәү әнием Бибинавал булып чыга! Дини сабак укылып, ятланып, дәү әнкәйгә тыңлатылганнан соң, без иректә кала идек. Буш вакытларда кемнең нинди китап укыйсы килә – шуны укый. Төрле төстәге юка тышлы китаплардан башлап, әткәй, Хәнәфия абый укый торган шактый калын китапларны да укый идек. Әткәй белән туган абыйның итек-читек теккәндә укыган китаплары, газета мәкаләләре турында фикер алышуларын, кызып-кызып бәхәсләшүләрен безгә тыңлап торуы кызык иде. Өйдәге китапларга дәү әнкәй хуҗа булып, аның рөхсәте белән генә ала идек. Дәү әнкәй үзе дә сөйләргә иренми иде. Ул йокларга ятып, ут сүнгәч, дингә бәйләп әкият сөйли. Соңы «аятелкөрси» догасын уку белән бетә иде.

Буа районында бердәнбер Казма авылы халкы күн-аяк киемнәре тегү белән шөгыльләнгән. Мәҗит бабай улы Вәлиулла 1920 елны 110 яшенә җитеп дөнья куя. Ул яшьләй үк читтә хезмәттә йөри. Иделдә бурлак та булган. Ул читтә йөргәндә «сапожниклык» һөнәренә дә өйрәнеп, авыл кешеләрен дә аяк киеме тегәргә өйрәткән. (Вәлиев Сафиулла сүзе.)

Габит бабай Казанга барып, аяк киемнәре тегү өчен күн-ярылар алып кайта башлый. Казан сәүдәгәреннән сорап, авылга бер оста-һөнәрче дә алып кайта. Безнең нәсел кешеләре шул остадан итек-читек тегү һөнәренә өйрәнәләр. Шул вакытларда Баһаветдинов Кәлимулла (безнең нәсел – шәҗәрәдән карап дөресләнде) һәм Сибгатуллин Сөнгатьләр оста тегүче булып җитешәләр. Бу һөнәргә Габит абзый һәм уллары Гарифулла һәм Гафиятулла да, Сәйфетдин улы Әхмәтҗан да өйрәнә. Бабай үз чиратында уллары Хәнәфия белән Харисны өйрәтә. Хәнәфия уллары Хәлилрахман һәм Хәбибрахман абый да, Исмәгыйль абый да олылар эшенә кушылып киттеләр. Алар белән мин дә шул һөнәрне үзләштердем.

Авыл халкының аяк киемен нинди дәрәҗәдә тегүен түбәндәге мисаллар белән раслап була. 1913 елны патша Романовларның 300 еллык юбилеена Сибгатуллин Сөнгатулла абзый патшага бүләк өчен күн итек тегә. Ул итекне Гариф абзый, Казандагы сәүдәгәре кушуы буенча эшләнгәнлектән, шул кешегә илтеп тапшыра. Казанлылар үз бүләкләрен Петербургка җибәргәннәр.

1914 елгы Беренче Бөтендөнья сугышы башлана. Солдат һәм офицерларны аяк киеме белән тәэмин итү өчен Казан байлары заказ ала. Алар үз чиратларында Казма авылы тегүчеләрен Казанга алдыра һәм итек тегәргә заказ бирәләр. Казмадан 8 кеше патша армиясенә итек тегә (хәзерге Тукай урамы «Пельменная» аскы каты, 1983 ел), һәм алар бронь белән калалар. Алар арасында: Гыйниятуллин Фарук, Гарифуллин Гатаулла, Миңгалиев Әскар, Әхмәтҗанов Хәнәфия, Садыйков Галимулла. Солдатка алынмыйча Казанда итек тегүләренә көнләшеп, «Гариф аларны солдатка барудан яшереп ята», – дип, волостька донос ясаучылар да табыла. Ләкин волостьтан: «Алар солдат хезмәтен үтиләр», – дигән җавап килә.

Революция булып, алпавыт җирләре крестьяннарга бүленеп бирелгән. Волостька землемер килгән. Волостьта Казма кешесе Хөсәенов Сираҗ эшләгәнлектән, землемерны ул башта Казмага алып килгән. Әгәр дә Казмага алпавыттан калган яхшы җирләр беркетелсә, күн итек бүләк итәргә вәгъдә биргән. Шулай итеп, 40 гектар казна җире һәм Зөя аръягы Понтелей алпавытның сулы, болынлы, уңдырышлы җирләреннән дә Казмага шактый өлеш тигән. Бер пар итеккә!.. Димәк, Казма итеге землемерга ошаган.

Туган абый белән әткәй буш вакытларында аяк киеме тегәләр. Алар кул арасына Исмәгыйль абый кушылып китә. Зур өйнең көньякка караган тәрәзә төбенә тегү өстәле

[6]Исмәгыйль Сабирҗанов – сугыш вакытында майор, Сугышчан Кызыл байрак, II дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз, ике Александр Невский орденнары һәм медальләр белән бүләкләнә. Аның кызы Рауза – Буа шикәр заводы директоры Миңнулла Кепечев хатыны.

(верстак) куелып, аның аскы ящигында төрле үлчәмдәге калыплар, төрле эш кораллары саклана. Өстәл өстендә дә – кирәкле эш кораллары. Уңдарак этажерка булып, аның шүрлекләрендә төргәк-төргәк төрле төстәге күннәр (заготовкалар) һ.б. саклана. Стенада итек, читек, сандал, калуш, кәвеш һ.б. картон өлгеләре эленеп тора. Сулъяк стенадагы шүрлектә төрле вак-төяк әйберләр: җеп, сумала, балавыз, лак, буяулар. Аннан да өстәге шүрлектә газета, китап, географик атлас һәм тальян гармун тора. Гадәттә, газетаны туган абый ашау алдыннан, аштан соң ял иткәндә укый иде. Яңалыкларны безгә дә сөйләп, атластан вакыйга булган илләрне, урыннарны безгә дә күрсәтә. Тегү эше – ялыктыргыч эш. Әткәй арган сөякләрен язу өчен һәм вакытын белеп, терлек-туар карарга яки безнең эшне тикшерергә чыга. Ә туган абый шүрлектән гармунны сузылып алыр иде дә салмак кына шул заман көйләрен уйнар иде. Кайбер вакытларда, дәү әнкәй өйдә юкта, үзе уйнап:

*Итек тегәм, итек тегәм, әй,*
*Итек тегәм, читек түгелләй,*
*Гармун уйнап, үзем җырлыйм, әй,*
*Күңелем китек түгелләй.*

*Уйныймын да, җырлыймын да, ай,*
*Кулда гармун булганда, ай,*
*Нигә миңа җырламаска, ай,*
*Җанкай тыңлап торганда, ай, –*

дип җырлар иде дә безгә карапketкелдәп көләр иде. – Әгәр уйнарга өйрәнсәгез, сезгә дә гармун алып бирәм, – дип, безне гармун уйнарга өйрәнергә өнди иде.

Исмәгыйль абый аз-маз гармун кычкырта башлагач, аның үзен дә Казанга алып барып, аңа 10 бармаклы, 4 бакалы, 5 планкалы «вараксин» гармуны сатып алдылар (22 сум иде бугай, 12 теллесе – 28 сум). Тәүфикъ абыйның гармуны 28 сумлык иде. Туган абый Исмәгыйль абыйны кибеткә ияртеп кергән дә: «Исмәгыйль, сайла үзеңә гармун, шуны сатып алабыз», – дигән. Исмәгыйль абый гармунны үзенчә сайлаган. Ләкин аның сайлавы туган абыйга ошамаган. Берничә гармунны алып баскалаштырган да берсен, кибеттән чыгып, урамда уйнап караган.

– Гармунны күпчелек урамда уйныйлар, урамда яңгырасын аның тавышы, – дип әйтә икән.

Туган абый гармунны сайлауда ялгышмаган. Авылдагы барлык гармуннардан да өстен чыкты аның гармуны.

– Эх, Исмәгыйль гармунының тавышы! Эх, Исмәгыйль гармунының моңы! – дип башкалар соклана иде. Тагын шунысы истә: остарак гармунчы дигән егетләр үз гармуннарын башкалар кулына тоттырмый иде.

Өйгә яңа гармун керде. Барыбызда да гармун уйнарга өйрәнү теләге туды. Исмәгыйль абый оста гармунчылар янында еш була. Кыш көне мунчаларда егетләрне җырлата, биетә, осталыгын арттыра. Аның безне өйрәтәсе килми. Буш вакыты да аз – хуҗалыкта терлек-туар карый, әткәйләргә тегү эшендә дә булыша. Укуны да ташларга ярамый. Өйдә гармун кычкырткан өчен безне әрләүче юк, шөкер. Ә кемнән, ничек өйрәнергә? Өйдә әти-әни, дәү әниләр алдында авыз күтәреп җырлап булмый бит. Гармун кулга чират буенча гына эләгә. Без, ир малайлар, яз көне кояш карау белән, әверселек[7] башына менеп, кояшка каршы җылынган салам өстендә иркенләп эшкә керешәбез. Беребез уйнаганда икенчебез җырлый. Гамунчы җырчылар артыннан барырга тиеш. Җәй көне урын күп, ләкин вакыт аз кала. Эш күбәя: бәрәңге чүбе утау, кырда иген утау, балык тоту, су коену, тизәк кирпеч әзерләү, терлеккә үлән җыю һ.б. Ә кыш көне – ягылган җылы мунча. Хәер, ягылмаган мунча да – гармунга өйрәнү урыны. Күршедән Фәрхинур апа, Мәсрура апа, Хәлилрахман, Хәбибрахман, мин җыелабыз да гармун кычкыртабыз. Соңыннан Хәлилрахман абый, Фәрхинур апалар оста гармунчы булып җитештеләр.

Яңа гармун булгач, иске гармунның кадере бетте. Ул шүрлектән төште. Без аны

[7]Әверселек – әвеслекне – түбәсе ябык, бер стенасы ачык каралтыны – безнең якта шулай диләр.

теләгән жиргә өстерәп йөрдек. Ә соңыннан бөтенләй сүтеп, аерым телләрен өреп кычкыртып йөри башладык. Яңа гармунның дәрәҗәсе зур булса да, аңа карап, аны югары шүрлеккә куймадылар. Аның урыны кыш көннәрендә урта өйнең сәке асты, ә җәй көннәрендә нәүрәп[8] өстендә салкынча, караңгы урында булды. Элек аңламасам да, үсә төшкәч аңладым: гармунны эсседә тотарга ярамый икән ләбаса.

## Сындырды кәҗә тәртәне

Аяк киемнәре тегү һөнәренә башта, әткәйләр кул арасына кереп, Исмәгыйль абый кушылып киткән. Аннары Хәлилрахман белән Хәбибрахман, соңыннан мин дә кушылганмын. Тегү эшен кечкенәдән күреп үссәң дә, аңа кушылып китү өчен берничә баскыч үтәргә кирәк. Башта әзер аяк киемен тиешле буяуга буяу, лаклау, ваксалау, ялтырату кебек эшләрне башкарасың. Тегү җебе әзерләү – җепкә сумала сеңдереп, аңа щетина, ягъни дуңгыз кылы утырту. Сумала җепнең тышына гына түгел, эченә үк сеңәргә тиеш. Тегү җебенә щетина утырту – нечкә эш. Щетинаны дөрес утырту – осталыкның бер баскычы-дәрәҗәсе санала. Мин тегү җебе ясарга этиемнән өйрәндем. Ул һәр эш этабын аерым-аерым өйрәтте. Әткәйнең мине өйрәтүен күреп, Хәнәфия абый:

– Син, Харис, аңа куш кына. Үзе өйрәнә ул. Өйрәнгәндә «нужа» да күрсен безрик[9], – дип әйтә торган иде.

– Юк, башта төшендерергә, күрсәтергә, аннан соң «нужаны» үзенә калдырсаң да ярый, – дип көлемсерәп җавап бирә иде әткәй.

Мин әзерләгән җеп белән әткәй үзе эш итәчәк бит. Аның эшен үземнең осталыгым белән җиңеләйтмәкче булам. Вак-төяк ремонт эшләре башкарыла башлагач, мин әниемнең читеген төзәттем. Шул эш өчен мине әнкәй бик мактады, рәхмәтләр әйтте.

Аннан тегеләчәк читек, итек өчен үкчә җыйнау башлана, төрле каю эшләре тапшырыла. Куллар ныгыгач, зуррак, катлаулырак эшләрне дә кушалар. Иң беренче эшем – үземә сандал тегү булды. Шулай итеп, акрынлап, мин дә эти-бабайлар һөнәрен үзләштердем. Бу һөнәрем олыгайгач та миңа ярдәм итте. Һөнәр белү бер булмаса бер ярдәм итә. Кепкадан башлап фуражка, сандал, чүәк, читек, итек тә тектем гомеремдә.

Дәү әнкәйнең тормышы башлыча яңа ызбада. Олы якка ул ашарга-эчәргә, башкаларга йомышы төшсә генә чыга. Ул яңа ызбаның тәрәзәләргә корылган ике катлы, өскесе аермалы пәрдәләрне тәртиптә тоту, тәрәзә төбендәге гөлләрне карау, аларга су сибү, күчереп утырту, кертеп биргән салам яки утын белән мич ягу, пыялалы шкаф эчендәге рәеш савыт-сабаларны, сервизларны тәртиптә тоту, шкаф башындагы китапларны рәткә салу, идәнгә җәелгән паласны каз канаты белән себерү, стена буйлата идәнгә җәелгән җәйгечләрне тәртиптә тоту эшләрен апа белән икәү башкара иде. Гомумән, ул һәрнәрсәне эшкиндереп[10] башкара иде. Мин кечкенәдән барлык әйберне дә сул кулга тотарга өйрәнгәнмен. Кыскасы, сулагай булганмын. Дәү әнкәй:

– Мәгъсум, тәти кул.

– Мәгъсум, борын...

– Мәгъсум, кәләпүш...

– Мәгъсум, дөрес утыр, – дип кисәткәндә, мин бик тиз генә әйберне уң кулга авыштырып, борын астын корытып, кәләпүшне дөресләп-турылап киеп, аякларны дөрес бөкләп утыра идем. Аның ачуланып кычкырганын яки кул органын белмим. Нәтиҗәдә, мин уң кулга кашык тотып ашарга, уң кул белән язарга өйрәндем. Тагын шунысы истә калган: ул һәрвакыт килennәрне яклый, әткәйдән дә, туган абыйдан да авыр сүз әйттерми иде. Әгәр дә киленнәргә катырак бәрелсәләр:

– Барыгыз, үз эшегездә булыгыз, мин алар белән үзем сөйләшермен, – дия торган иде. Әнкәй дә, Зоха аптый да каенаналарын бервакытта да яманлап телгә алмадылар. Алар:

– Урыны җәннәттә булсын, әйбәт кеше иде, – дип кенә искә алдылар.

Җәйге көннәрнең берсендә, төш авышкач, кичкә кырын, без, малайлар (мин,

[8]Нәүрәп – баз, кар базы.
[9]Безрик – бераз.
[10] Эшкиндерү – җиренә җиткереп эшләү.

Хәбибрахман, Хәлилрахман) зур өйдән чолан аша яңа ызбага йөгереп кереп, кача-кача уйный идекме, башкача булганмы, шулай кереп-чыгып йөргәндә, дәү әнкәй урам як тәрәзә буендагы кәнәфидә ниндидер китап укып утыра иде. Бер әйләнеп кергәндә күрәбез: дәү әнкәй кәнәфидән егылып төшкән, күзлеге, китабы идәндә ята, үзе күзен йомган, сүзсез. Без, бу хәлне күреп, зур өйдә тегеп утыручы әткәй белән туган абыйга һәм әнкәйләргә әйттек. Алар:

– Әни, әни, ни булды?! – дип эндәшсәләр дә, җавап бирмәде. Аны җайлап кына кәнәфигә салдылар. Шул минуттан башлап, аның яныннан китмичә саклап кундылар. Дәү әни бер тәүлек дигәндә үлде. Безнең өйгә зур кайгы-хәсрәт килде. Нинди авырудан үлгәнен һич белмәдек. Тик карчыкларның:

– Яхшы кешенең үлеме дә җиңел, – дигәннәрен генә хәтерлим. Бу хәл 1926 елның җәендә булды. Аның туган елы – 1859 (кабер ташы).

Дәү әнкәйне ничек күмүләре һич тә хәтердә калмаган. Авыл зиратында Әхмәтҗан бабай (1911 елда үлә), Бибинавал әби, Нурлыһада апа (1893-1923) (әнкәйнең сеңлесе) каберләренә чардуган-рәшәткә корылган. Әткәй белән әнкәй үлгәч, мин цементтан ясап, уеп язып, җиде кабер өстенә җиде истәлек ташы куйдым. Һәр елны әби-бабай һәм әти-әниләрнең каберләренә оныкларымны да алып барып, аларны искә алу гадәткә әйләнде. 1982 елны әткәй белән әнкәй кабере өстендәге тузган агач чардуганнарны үзем ясаган тимер чардуганнар белән алмаштырдым. Үзем эшләгән-ясаган һәрнәрсә минем өчен куаныч һәм эшемә дәрт бирә. Зираттагы кайбер каберләр өстендә бик матур чардуганнар булса да, минем күңелгә үзем ясаган чардуганнар, үзем язган ташлар кадерлерәк шикелле. Исән вакытларында әтием һәм әнием дә минем эшемне мактыйлар, яраталар иде.

Балачак хатирәләреннән тагын шунысы истә калган: без үскән заманнарда чаңгының нәрсә икәнен дә белми идек, тал агачыннан бөгеп ясалган кечкенә чаналарда бер-беребезне тартышып йөри идек. Кар көртләре, өемнәре булгач, су сибеп боз катырып, шул таулардан чанада шуа идек. Зөя ярыннан шуарга да бара идек. Чана шуу дигәннән, шул хәтердә калган: чанага кәҗә җигү. Ул болай булды. Безнең ындырдагы такта әрбәлеккә (сугылган иген-икмәкнең башагын, кибәген җыю, ындыр кирәк-ярак эш коралларын саклау урыны) күрше-күләннең кәҗәләреияләште. Кәҗәләрне әрбәлектән куып җибәрү – безнең бурыч. Без бу эштән тәмам гарык булдык. Көннәрдән бер көнне Хәлилрахман абый:

– Малайлар, бүген әрбәлектәге кәҗәләрне кумыйбыз, алар эчкә үткәч, әрбәлек ишеген тышкы яктан ябып, иң зур кәҗәне тотабыз да чанага җигәбез, менә аларга сабак шул булыр, – ди.

– Бик әйбәт, бик әйбәт, шулай эшлибез.

Алдан корылган план буенча эш итеп, кергән кәҗәләрне ябып куйдык. Зур, карт кәҗәне тотып калып, калганнарын куалап чыгардык.

– Ну, малайлар, эшкә! Кәҗәне кем чанасына җигәбез?!

– Мәгъсум чанасына, – ди Хәбибрахман.

– Минекенә, – дим мин дә, шатланып. Кәҗәнең мөгезеннән Хәбибрахман нык кына тотып тора, Хәлилрахман абый үзенчә чанага кәҗәне җигә. Кәҗә җигелеп бетте. Кәҗәгә дилбегә кирәк.

– Минем чана бавын ал, – ди Хәбибрахман.

Кәҗәгә дилбегә дә тагылды. Әрбәлектә җигелгән кәҗә ындыр сукмагына бастырыла. Мин чанага ипләп кенә утырам һәм кулга дилбегәне алам.

– Кәҗәне җибәрәм, яхшы тотын.

– Җибәрәм айгырны, мин аны...

Китте «айгырым», барам дилбегәгә тотынып. Берзаман кәҗә башын артка чөеп җибәрмәсенме, шулвакыт мөгезгә бәйләп куйган дилбегә шуып та төште, мин дә чанадан мәтәлеп, карга чумдым. Елый-елый, аякка торып басканда, кәҗә үзенә бәйләнгән чананы сикертеп, арт ягына бәрелгән саен, кар бураны туздырып, үзләренә (Җиһаншин Гаделша абыйлар кәҗәсе булган икән) таба чаба, ә Хәбибрахман белән Хәлилрахман абыйларның авызлары колакларына җиткән, бот чабып, бу тамашадан көләләр иде.

Мин чанасыз калдым. Нишләргә?! Хәлилрахман абый мондый киңәш бирә:

– Мәгъсум, хәзер үк кәҗә артыннан чап. Кәҗә арт як капкадан кергәндә, чана сыймыйча терәлеп калачак, курыкма, – ди бу миңа.

Барсам, нәрсә күрәм: кәҗә чана өстерәп кайтканда, Гаделша абыйның Мәскәүдән ялга кайткан энесе Мөхәммәтша абый, өйдәгеләрдән качып, тәмәке тартып утыра икән. Кәҗәнең муеныннан чананы чишеп алды да, бавыннан тотып, һавада әйләндереп амбар бүрәнәсенә сукты. Бу хәлне ике-өч мәртәбә кабатлагач, ватык чананы амбар астына типкәләп кертте. Аннары авызындагы тәмәке калдыгын карга төкереп, аңа аягы белән баскач, бик зур эш башкарган кеше кыяфәтендә, арт капканы ачып, кәҗәне кертте һәм үзе дә кәҗәгә иярде. Белсәгез иде бу вакыттагы йөрәк тибүен?! Кышкы кием аша йөрәк тибеше үземә ишетелеп тора иде. Бик тә курыксам да, тәвәккәлләп бардым да чанамны амбар астыннан өстерәп чыгардым. Билгеле, чанам тәмам җимерелгән, тау шуарга яраксыз хәлгә килгән иде.

Бу көлкеле, шул ук вакытта фаҗигале вакыйганы гаиләдәгеләрдән башка беркем дә белмәде, телне теш арасына нык кыстык, чөнки ул вакытта авыл халкы берне биш итеп сөйләргә, кушамат кушарга да күп алмый иде. Безнең авыл кечкенә булганга, бер-берен яхшы белгәнгә, кушаматлы кешеләр әз иде.

## Безрик сабак

Галәтдин абзыйга кызу канлы булуы өчен «чүпрә» кушаматы кушып, аны Җәләлетдинов Галәтдиннән аеру өчен «чүпрә» Галәтдине дип кенә йөртәләр иде. Бәйрәм алдыннан кайбер шаянраклары ваемсызрак хатыннарны, башка авылдан төшкән яшь киленнәрне Галәтдин абзыйларга чүпрә сорарга җибәрү фактлары да булгалый дип сөйлиләр иде. Безнең авылда кушаматны өнәп бетермиләр, кушамат кеше шәхесен мыскыллау, аңардан көлү, кимсетү булып яңгырый. Балалар арасында әйтелгән кайбер кушаматлар, җирлек табалмыйча, тиз үк арада онытылалар да.

Һәр яз саен диярлек безгә әткәйләр күннән итек яки күн галуш тегеп бирәләр иде. Язгы ташу китәсе көннәрдә әткәй миңа күн галуш тегеп өлгертте. Бала вакытта яңа кием киюнең шатлыгын һәркем белә инде. Зөя сулары тулып акканда, авыл халкының кечесеннән алып таякка таянып йөри торган карт-корысына кадәр Зөя буена чыгып тамаша кылганда, яңа киемнең кыйммәте икеләтә, өчләтә үсә. Мин яңа галушны киеп, Зөя буенда бик тә хозурланып йөргәндә, без – малайлар, гөрләп Зөягә ага торган ермак аша сикереп чыгып уйнарга тотындык. Башкалар артыннан мин дә сикердем. Сикерүен сикердем, әмма ләкин уң аяктагы күн галуш кына аяктан төшеп, ермак буйлап Зөягә агып китте. Бу хәлне Хәнәфия абый күреп торган икән. Ул минем яныма килде дә, «Безрик[11] сабак укытып алыйм әле!» дип, колагымны борган итте. Авырттырмады, билгеле. Шул вакыттагы шатлыкның бер мизгелдә кайгыга әйләнүенә йөрәк ничек түзгәндер?! Арткы урамнан үзебезгә кадәр йон оекбаштан быкырдык ерып кайтулары әйбәт булмагандыр. Галушны Зөягә агызу белән, билгеле, аягыма чабата кимәдем, мәрхәмәтле әткәй дә кызып китеп әрләмәде, иртәгесен үк сыңар галушны тегеп тә бирде. Шул вакыйгадан соң миңа дусларым «Безрик» дигән кушамат тактылар. Ләкин ул озакка чыдамады, язгы сулар булып агып китте.

Җәйне сагынып көтеп аласың. Җәйге чирәмдә яланаяк йөрүгә ни җитә?! Кайбер малайлар, әле кар да эреп бетмәс борын, яланаяк йөгерә башлыйлар. Минем яшьтәшләрдән Хөсәен, Гайфулла, Зәйнулла, Сибгатуллалар яланаяк йөреп, аякларына «чеби» чыга башлагач кына, безгә яланаяк йөрергә рөхсәт итәләр иде. Без, ялан аяклылардан көнләшсәк тә, түзә идек.

Урамнарны тоташ яшел хәтфә чирәм каплагач, әлбәттә, язгы чәчү беткәч, сабан туйлары башлана. Күрше авыл Каенлыкта аны язгы чәчүгә чыкканчы ук үткәрәләр иде. Сабан туена авыл халкы кыштан ук әзерләнә. Онын, маен, балын әзерли, тәкә симертә, чакырасы кунакларын тәгаенли. Иң зәвыклысы – көрәшкә әзерләнү, чабышкы ашату, аның аягын күндерү. Без, малайларга, иң кызыгы ат аягы күндерү – сабан туена күрше-күлән авылдашларны чакыру. Ул болай була: сабан туена 2-3 көн калгач, авылның 10-15

[11] Безрик – бераз гына.

яшьлек малайлары үзләренең атларын кыргычлап юып, чистарталар. Койрыкларын тиешенчә калдырып кисәләр, ял, койрыкларын матур итеп үрәләр. Атның койрык һәм ялларына төсле чүпрәкләр, йөгәннәргә чигелгән кульяулыклар бәйләнә. Атларның муеннарына кыңгырау һәм шөлдерләр тагыла, үзләре дә яңа күлмәк-ыштан, камзул, кәләпүшләр кияләр. Атларга атланып, күрше авылларга ат аягы күндерергә – Сабан туена чакырырга китәләр. Күрше авылга барып кергәч, алар:

– Киби-киби кипкән, Сабан туе җиткән, иртәгә безгә Сабан туена барыгыз, – дип, беравыздан кычкырып, урам әйләнәләр. Һай, бу вакыттагы күңел көрлеге, сүз белән аңлатып булмый аны.

Авыл бик иртә уяна. Морҗалардан төтен күтәрелә, авыл урамнарына тәмле ризык исе тарала. Авылга төрле яктан кунаклар килә башлый. Хуҗалары гына түгел, атлары да бизәлгән. Дугалардагы кыңгырау, ат муенындагы шөлдер чыңнары авылга ямь бирә. Зөя урамы башында Сабан туе буласы урын чиста итеп себерелеп, шунда тирә-як авылларының кибетчеләре арба тәртәләрен аркалык белән күтәртеп бәйлиләр дә өстенә палас, киндер ашъяулык, чыпта ябып, кояш, җилдән ышык ясыйлар. Яшел чирәм өстенә чыпта җәеп, үзләренең товарларын таратып салалар. Капчыгы белән көнбагыш, әрҗәсе белән кызыл билле прәннек, эрбет, әстерхан, урман чикләвеге, мампаси, карандаш конфет һ.б. малайларның иң яраткан Сабан туе сые була торган иде. Авыл Сабан туе кибетләрендә тәмәке, папирос сатылса да, исерткеч эчемлекләр сатылганны хәтерләмим. Сабан туеның тәртибе һәр авылда бер үк төслерәк була торган иде. Иң кызыгы – ат чабышы, көрәшү. Чабышкы ат безнең авылда бер генә булган. Гыйниятуллин Тәүфикъ абыйның «Актив» кушаматлы юргасы колхозлашу елларыннан соң да район сабан туйларында чапты. Ул кызгылт-җирән, кечерәк кенә йомры атның йөреше дә башка иде. Ул гади атлап йөрми, ә биеп йөри. Аның йөрешенә сокланмаган кеше юк иде. Минем андый йөрешле атны башка күргәнем булмады. Безнең авыл кешеләреннән атаклы көрәшчеләр булмаса да, Сабан туе күрке һәм авыл даны өчен көрәшкә чыгучылар булгалады. Хөснетдинов Сәхабетдин, Сәгъдиев Шиһап, соңрак Гыйниятуллин Тәүфикъ, Әхмәдуллин Нурмөхәммәт, Сәләхиев Хисаметдин, Вәлиев Салават, Исмәгыйлов Шакир тирә-якта яхшы көрәшчеләрдән саналалар иде.

Кичен авыл урамында кунак егетләре белән яшьләр гармун уйнап, җырлап йөрсә, өлкәнрәкләр өйдә кунаклар белән үзләре дә кунак була. Бәйрәм шаукымы ике-өч көнгә сузыла. Сабан туйлары үткәч тә малайлар өчен «сабан туе» уены урак өстенә кадәр дәвам итә. Һәр йортка кереп, чүпрәк кисәге җыеп таяк башына бәйлисең, бирүче булса, акча, тавык күкәеннән дә баш тартмыйсың. Шуннан соң икенче урам малайларын Сабан туена чакырасың. Менә Сабан туе башлана. Башта йөгерү ярышы, аннан бил алып көрәш. Балалар уенын зурлар да кызыксынып карый, арада чын йөрәктән уңай киңәш биреп торучылар белән бергә, котыртып йә шаяртып торучылары да табыла. Зөя урамында Сабан туе булганда, мондый хәл булды. Авылның йөгерешче малайлары Мөхитов Шәрәфлислам, Галәтдинов Гыйлфан, Әхмәтҗанов Хәбибрахман, Әфләтунов Гыйбадрахман белән бергә мин дә чабу стартына бастым. Команда булу белән, юлга чыктык. Чабабыз, күзгә ак-кара күренми. Миннән алда бер генә шәүлә. Кинәт мин сөртенеп китәм һәм читкә авам, дөпе-дөпе иткән аяк тавышлары гына ишетелеп кала. Торып бассам, ни күрәм: миннән ерак та түгел каз оясы – мөрге[12] аунап ята. Ә капка төбендә Исхак абзый Саматы бот чабып көлә. Әлеге мөргене – каз оясын – безнең аяк астына тәгәрәтеп җибәргән икән. Кызганычка каршы, ул мөрге, мин бәхетсез аяк астына эләгеп, мине икенче урынга чыгу мөмкинлегеннән мәхрүм итте. Соңыннан малайлар:

– Мәгъсум, нәрсә таптың, алтын булса, безне дә өлешсез калдырма! – дип көлештеләр. Миңа бик ямансу булды ул чакта. Бу егылу минем йөгерүгә булган дәртемне сүндермәде, мин андый сабан туйларында байтак чаптым, беренче булмасам да, 2-3 нче урыннарны бүлештем. Мактанып әйтүем түгел, безнең бабабыз Әхмәтҗан да сабан туйларында йөгерештә катнашкан. Хәнәфия абый улы Хәбибрахман да яхшы йөгерә иде. Минем кече улым Наил йөгерү буенча Казан педагогия институтының чемпионы исеменә дә лаек булды. Алга китеп булса да, шуны әйтим: оныгым Надир да бик яхшы йөгерүче булыр, ахры.

[12] Мөрге – яшь тал чыбыгыннан үрелгән кәрзин (кибәк, башак, печән, салам тутыру өчен).

Оныкларга гына түгел, бала-чага өчен дә җәй күз ачып йомганчы үтеп китә. Безнең авыл Зөя елгасына ук орынып утыргангадыр, бала-чагасыннан алып олы ук яшьтәгеләренә кадәр Зөядән балык тота.

Язгы ташу вакытында егетләр болганчык суда адашкан балыкларны җәтмә белән сөзәләр. Зөя суы язын ярдан китеп, үз урынына кайткач, уйсу күлләвекләрдә бүленеп калган балыкларны сөзү башлана. Зөя суы тәмам тынгач, кармак белән балык чиерттерергә йөрисең. Без – малайларга ташбаш-ёрш, күтәмә-пескарь, алабуга-окунь, чабак кебекләр эләксә, бик шат була идек. Олыраклар яшь тал чыбыгыннан нәрәтә үреп, шуны төнгә суга салалар иде. Кайбер иртәләрдә Исмәгыйль абый нәрәтәдән яртышар чиләк балык алып кайта иде. Арыш серкә очырганда, кармакка падус балыгы эләгә иде. Торна сазы күленнән кәрәкәне җәтмә белән сөзеп тота идек. Ул күлне 1911 елны казып ясаган булганнар.

Җәйге көн су коенып, комда кызынып, балык чиерттереп үткәнлектән, безгә җәй бигрәк тә кыска булып тоела иде. Көз көнендә безнең иң яратып уйнаган уеныбыз – кәшәкә уйнау булды. Кәшәкә – башы бөгелеп үскән сәрби агачы, тал, алмагач ботагы, чикләвек таягы һәм агач тамырыннан түгәрәкләп ясалган, диаметры 5-6 сантиметрлы шар. Бу уенны иң оста оештыручылар булып Мөкри (мокрый) урам малайлары санала иде. Төштән соң – кичкырын авыл малайлары, кәшәкәләрен тотып, бер урынга җыела. 100-200 метр ераклыкта капка – чик билгелиләр. Барлык кәшәкәләрне җыеп бер өемгә өяләр дә, бер уенчының күзен бәйләп, шуңардан кәшә таякларын ике якка ыргыттырып бүлдерәләр. Менә шулай ике команда хасил була. Командадагы уенчылар саны чикләнми. Менә шуннан соң китә инде шар куыш. Бу уенга малайлар гына түгел, буй җиткән егетләр дә, хәтта өйләнгәннәр дә кушылып китә иде. Уенны кырдан кайткан көтү генә бүлдерә. Көтү тавышы ишетелә башлау белән, терлекләргә каршы китә идек. Уен шуның белән туктала.

Балалар булган җирдә һәрвакыт нинди дә булса уен уйнала. Балачак уенсыз үтми. Урманда чикләвек өлгергәч, олыларга ияреп урманга йөрү дә, яшь тал чыбыгыннан бәрәңге җыйнау өчен кәрзиннәр, кибәк-башак өчен мөрге үрүләр дә бик нык истә калган. Безнең өй якшәмбе көнне үзенә бер төс ала. Иртә таңнан әткәй белән туган абый Буа базарына сәүдәгә китәләр. Бу көнне безгә хатын-кыз кунаклар килә. Кунак килгәч, самовар куела, коймак, ботка пешә. Безгә кызыгы ашап-эчүдә түгел, ә яңа хәбәрләр ишетүдә иде. Хатын-кызларның хәбәрләре бөтенләй башкачарак. Ир-атлар тормыш-көнкүреш, ат, җир, дөнья хәлләре турында, җен, пәри, юлда адашу һ.б. сөйләшсәләр, хатын-кызлар алай зурдан кубып, хуҗалык турында, дөнья хәлләре турында тирәнгә кереп сүз куертмыйлар. Дини мәсьәләләр дә читтәрәк кала. Аларның төп темасы – гаилә, туган-тумача. Сүз кемнең баласы ничек авырганнан башлап, кыз-кыркын, егетләр, киленнәр, каената, каенаналар, аларның мөнәсәбәтләре турында бара. Бу араларда авылда, күрше авылда шушы темага нинди яңалыклар булганын ишетәсең. Шунысы гыйбрәтле: алар булган хәлне сөйләп кенә калмыйлар, шул кешегә, вакыйгага карата хөкемнәрен дә чыгаралар яки характеристика бирәләр: «Фәлән егет белән фәлән кыз сөешәләр, бигрәк пар килгәннәр», «Тапкан кыз, шул чибәрлеге, шул булдыклылыгы белән – учак астына салам бөтереп тыга белмәгән булдыксызны», «Төс, имеш! Төс туйда кирәк, ә акыл белән кул көн дә кирәк», «Фәләннең кызын фәлән яучылый икән дә, әтиләре, зимагур дип, кызларын бирмиләр икән». «Урлыйм дип әйтә икән, булыр микән?!» «Булыр, фәлән авыл кызын фәлән алып кайтты, бик әйбәт торалар бит» һ.б...

– Сез ишеттегезме әле, Закир абзый белән Нәсимә абыстай сугышкан. Закир абзый тәрәзәдән чыгып төшкән бит?!

– Нибуч, төшәрсең дә, өстеңә кайнап торган сөтле чүлмәк тондыргач.

– Әй, аларның шул инде, иртән сугышалар, кичен мунча ягалар, белмәссең аларныкын.

– Хәкимә абыстайны әйтәм әле, үзе диндар, укымышлы нәселдән, Бакыйны укуыннан кайткач та килене белән бергә яткырмый икән ләбаса.

– Әле генә ишеттегезме аларның шулай яшәүләрен? Хәкимә абыстайга – килен, малаена – хатын кирәкми, аларга рабучи кирәк, беләсегез килсә.

– Диндарлар алар, тышкы яктан гына кеше, эчләре зәһәр аларның.

– Әйе шул, Әхмәдулла Ярулласын, мескен ятим баланы, нишләттеләр.

– Маһриҗамал абыстай, Мөхәммәтгарифыгызны быел өйләндерәсез, имеш, дип ишеттек, шул сүз дөресме?

– Кеше авызына кергәч, дөрестер. Галиулла Гайшәсенә өйләнәсе килми, үзенең сүәркәсе бар, шуны алам дип бәйләнә.

– Сүгәнен алсын, сүешеп барсаңые аны!

– Безнең атасын беләсез. Ике бозауга кибән аерып бирә белмәгән башыннан малае яклы. Килен каенанага кирәк. Әйттем мин аларга, булыр минемчә.

– Галия нишли инде, Карибуллага чыгармы?

– Шулай булыр дип торабыз.

Дөрестән дә, Миңгариф абый – Галиулла кызы Гайшәгә, Миргалим кызы Галия Галиулла улы Кәрибуллага тормышка чыкты. Сугышка кадәр матур гына көн күрделәр. Кәрибулла абый сугыш кырында ятып калды. Гайшә апа сугыш вакытында 1941 ел суыгында Каенлык белән Казма арасында, каты кышкы суык буранда адашып, туңып үлде.

Үз сүзләрендә күрше авылларны да искә алалар. Без – балалар олылар сүзен күпме генә колактан ычкындырмаска тырышсак та, яшерен пышылдашып алулар да булгалый. Игътибар беләнрәк тыңлый башласаң: «Нәрсә колагыңны торгыздың?! Коймак кирәкме? Мә, ал да ычкын моннан», – дип куулар да күп була торган иде. Чәйдән соң, һәрберсе үзенең өйдә бик хаҗәт эшләре барлыгын исләренә төшереп, берәм-берәм тарала башлыйлар.

Зур гаиләле йорттан булганга, әнкәй һәм Зоха аптыйга кешегә кереп әңгәмә сатарга вакыт калмый. Үзләренә туган-тумача, күрше-күләннең хәл белергә керүенә бик шатланалар. Кеше белән аралашып, күп кенә яңалыклар ишетәләр. Безнең өйгә хатын-кызның шулай җыелып утыруы дәү әнкәй вакытыннан калган гадәткә әйләнгән. Бездә кыш көннәрендә «Казан аулагы» еш була. Аяк киеме тегү өчен күп товар – игүле читек кунычы, штиблет заготовкасы, галушлык, тоташ башлы күн итек заготовкалары, олтанлыклар – һәммәсе дә Казаннан кайтартыла. Авылдан Казан каласы 120 чакрым дип йөргәннәр. Казанга ат белән барып кайту өчен 4-5 көн сарыф ителгән. «Казан аулагын» ишетү белән, безгә килгән туган-тумача, дус-ишләр бер мәртәбә коймаклы чәй эчеп кенә китмиләр. Кайберләре бер-ике көн тора. Казан аулагында ләңгәче[13] белән карабодай коймагы, сызык сумсасы, йөземле бәлешләр дә, тутырмачлар да пешә. Безгә кызыгы шул: олы хатыннарның, карчыкларның күңел ачулары. Аларның нинди көйгә, ничек җырлаулары истә калмаган. Алар мөнәҗәт кебегрәк сузып, авызны ачмый гына җырлыйлар. Мондый уеннарны әнкәй ярата. Ул үзе генә белгән җирдән кубызын алыр да, иреннәренә кыстырып, бармагы белән кубыз телен чиертер. Нинди дәрәҗәдә яхшы уйнагандыр, әмма ул апаларны биетә иде. Майҗамал апаның курай уйнавын тыңлап, башларын түбән иеп, моңланып утыралар да, тагын җанланып, биешеп, җырлашып алалар. Күрше Зариф абый кызы Фәрхенур апа керсә, ул уйнаган бию көенә («Әпипә») һәммәсе дә биеп чыгалар. Иң оста биючеләр булып әнкәй абыйсы Фарук азый[14] хатыны Мәрьям аптый белән безнең әнкәй санала. (Алга китеп, шуны да әйтим: әнкәй, исәнлегендә, соңгы гомеренәчә биеде-бөтерелде. Зәкия белән минем туйда да ул рәхәтләнеп, очына-очына, бөгелә-сыгыла биеде.) Бала итәкле күлмәгенең читләреннән чеметеп тотып, аяк очларында әйләнә-әйләнә, чигешле читегенең бераз гына күтәренке үкчәсе белән идәнгә дык иттергәндә, чәч толымындагы аерылган чулпыларының бергә кушылып чыңгылдавын ишетү, йөзенең алсуланып китүен күрү мине сокландыра иде. Мин әниемнең шундый җиңел гәүдәле һәм җитез булуы белән горурлана идем.

Әнием ачык фикерле, эш сөючән, итагатьле, кешелекле, бик тә ярдәмчел, юмарт иде. Аның кемгәдер авыр сүз әйткәнен ишетмәдем. Аның гомере кыска булды. 1952 елның 25 сентябрендә, күкрәгенә суык тиюдән айный алмыйча, 59 яшендә вафат булды. Урыны җәннәттә булсын.

## Беренче тетрәнүләр

Үземнең кайчан укырга-язарга өйрәнгәнемне тәгаен генә әйтә алмыйм.

Мин авыл мәдрәсәсенә Исмәгыйль абыйга ияреп баргалаганымны, андагы шәкертләрнең идәнгә утырып, алларындагы кечкенә сандык өстенә китапларын куеп укыганнарын, хәлфәләренә сабак тыңлатуларын күргәләгән булсам да, үземә

[13] Ләңгәч – куыш агачтан ясалган кисмәк.
[14] Азый – абзый.

андый мәдрәсәдә укырга туры килмәде. Мин сабак яшенә җиткәндә, Хәлилрахман, Хәбибрахман абыйлар – мәдрәсәгә, ә Мәсрура апам авыл остабикәсенә укырга йөриләр иде. Шуларга ияреп, шулардан күреп-ишетеп булса кирәк, җәдитчә укый һәм яза беләидем инде. Ничәнче ел икәнен төгәл белмим, 1926 ел булса кирәк, көзнең бик матур бер көнендә Хәбибрахман мине мәктәпкә ияртеп китте. Кулын артка куеп, ишекле-түрле йөрүче кара тут йөзле, озын чәчле, билен каеш белән буган, аягына ялтыравык хром итек кигән кешегә – укытучыбыз Кадәрмитов Галимҗан абыйга, мине күрсәтеп:

– Яңа укучы алып килдем, – диде.

Галимҗан абый, йөрүеннән туктап, аяктан алып башыма кадәр карап чыкканнан соң, әкрен генә өстәле артына утырды да мине өстәле кырына чакырды.

– Укыйсың киләме?

– Укыйсым килә.

– Кем малае?

– Харис малае.

– Һем… Син Харис абый малае буласың. Бик яхшы. Әтиең әйбәт кеше.

Өстәл өстендә яткан уку китабын ачып, миннән хәрефләр укыта башлады. Хәрефләрне бер дә төртелми әйтеп бирә торгач, сүзләргә күчте. «Сара суга бара», «Суда сал» һәм башкаларны да җиңел укып биргәч:

– Бик әйбәт, бик әйбәт, сине укырга кем өйрәтте, – дигән сорауга мин, башымны иеп, бер җавап та бирмәдем. Чөнки үземне кем укырга-язарга өйрәткәнне белмим.

Укытучыбыз Галимҗан абый, урыннан торып, сыйныфка бераз карап торды да, минем күлмәк җиңемнән тотып, алгы парталарның берсенә илтеп утыртты. Укытучы өстәле яныннан китеп, сыйныфка карасам, ни күрәм, Казма авылының бөтен малайлары-кызларының күзе миндә иде кебек. Шуны да әйтеп үтәргә кирәк: ул елларда авылда бер бүлмәле мәдрәсә булып, беренче-дүртенче сыйныф укучыларын бер укытучы шул бүлмәдә укыта иде әле. Беренче сыйныф укучылары – алгы, аннан соң икенче, өченче сыйныф укучылары, ә соңгы рәтләрдә дүртенче сыйныфлар утыра. Ләкин миңа беренче сыйныф укучылары белән озак утырырга туры килмәде, укуда өстен булганлыгым өчен, Галимҗан абый мине икенче сыйныфка күчерде. Анда да укулар минем өчен авыр булмады. Хәтта укытучы үзе өлгермәгәндә яки класстан чыкканда, миңа иптәшләрем өстеннән күзәтергә – укытучылык итәргә куша иде. Бу елларда уку-язу әсбапларына кытлык иде. Кәгазь, карандаш, бунау, каләм кебек нәрсәләр «бай» укучыларда гына. «Бай» укучылар алар белән сату да итәләр. Без ул елларда хисапны, рәсемне, диктантларны кара тактага грифель белән яза идек. Дәфтәрне табаклы кәгазьдән дә, тәмәке кәгазеннән дә үзебез ясап тегәбез. Язу ирекле. Карандаш белән дә, төрле төстәге карага манып, төрле маркадагы каләм белән дә язарга ярый. Кәгазь-каләмне Казаннан әтиемнәр алып кайта иде. Безнекеләр кәгазь-каләм кытлыгы күрмәде. Мәктәптәге бөтен тәртип дүртенче сыйныф кулында. Алар барлык укучыларны да үзләренә кул көче белән буйсындыралар, «сәүдә»не дә алар алып бара. Мәктәптәге кизүлекне дә алар билгели. Мәктәпне җыештыру, ягып җылыту эшләре укучыларның ата-аналарына төшә. Безгә чират җиткәч, бу эшне Исмәгыйль абый башкара, ә без аңа булышабыз, ягъни ул күтәреп барган салам бәйләмен мичкә ягабыз. Ул, коедан су алып кереп, идән юса, без парталарны, өстәлләрне, урыннарыннан алмаштырып торабыз, тузаннарын юеш чүпрәк белән сөртәбез. Тагын шунысы истә: мәктәп стенасының тәрәзә араларындагы буш стена, хәтта арткы буш стена укучылар рәсеме белән каплана иде. Укучылар үзләренең «иң яхшы» рәсемнәрен стенага беркетеп, конкурс үткәреп, билге алалар. Мин үземнең җил тегермәне, мәчет, өй рәсемнәре белән катнашып, югары билге алгаладым. Кечкенәдән өй, мәчет рәсемнәре ясый идем. Бу рәсемнәрне әткәй бик яратып карый, җитмәгән җирләрен җиткерә, килешмәгән җирләрен төзәтә, гомумән, ничек рәсем ясарга кирәклеген өйрәтә иде.

Яз җитсә, пешмәгән бәрәңгене юнып, сыерчык ясап, аны корымга буяп, конкурс үткәрә идек. 4 тәрәзәле, шыр ялангач стеналы, кием элү өчен такта бүлемле, ишек башында сәндерәле, акшары аз гына беленеп тора торган мичле мәктәбебез миңа нигәдер бик якын иде, мин мәктәпкә бик теләп йөри идем. Башкалар өчен Галимҗан абый укытучы булса да, минем өчен үз кеше. Дәү әнкәйнең энесе Җиһанша абзыйны

без Хаҗи абзый дип йөртә идек, чөнки ул – Мәккәгә хаҗ кылган кеше. Аның хатыны Миһриҗамал абыстай Кырлангы авылыныкы булып, аның абыйларының уллары Шакирҗан белән Галимҗан Казмага кунакка бик еш киләләр иде. Алар гыйлемне башта әтиләреннән (мөәзинме, мулламы), аннан Буа мәдрәсәсендә алганнар булса кирәк. Җәй көннәрендә бергә су коенып, балык каптырып, без – Хаҗи абзыйларда, алар бездә булып, аралашып яшәгәнлектән, мин укытучымнан һич тә тартынмадым да, курыкмадым да. Укытучыбызның «Кара Галимҗан» дигән кушаматы да булып, бу кушамат аңа бик белеп бирелгән. Уртача шадралык өстенә карасу көрән йөз аны африкалыларга охшата.

– Бу безнең як кешесе түгелдер...

– Моңа Урта Азия якларына гына китәргә... – дип сөйләүчеләр дә очрый.

Шуны әйтим: ул бер ел гына безне укытты да Урта Азия ягына китеп, шунда гомер буе мөгаллимлек итте. Пенсиягә чыккач, туган якларына кайткалап та китте. Яңа уку елы башланыр алдыннан, безнең авылга яңа укытучы килде. Аны авыл халкы бик теләп каршы алды. Авылда кызу кыр эшләре булуга карамастан, Апас районы Аюкөйдергән авылыннан гаиләсен ат белән барып алдылар. Авыл халкы арасында аның турында мактау сүзләре таралды.

– Яңа мөгаллим һәр җәһәттән белемле, имеш.

– Үзе рус мәктәбендә дә укып, балаларны да русча укыта, имеш.

Яңа укытучыбыз Ибраһимов Котдус абый 35-40 яшьләрендә булып, уртачадан калку буйлы, чандыр гына гәүдәле, кара куе чәчле, калын кара кашлы, туры кылыч борыны астында кечкенә генә кара мыек йөртүче кеше иде.

Ул, Кадәрмитовтан аермалы буларак, аягына күн итек түгел, ә штиблет-ботинка кияр иде. Чәче дә озын булмыйча, башына кепка киеп йөрер иде.

Авыл халкы аны да аш-су мәҗлесеннән калдырмады. Ул аш-суга киткәндә, олы сыйныф укучылары безнең өстән хәлфәлек итәләр иде. Котдус абыйның балаларны рәнҗетүен – орышу, кыйнау-сугуын һич тә хәтерләмим. Шулай ук русча укытуы да истә калмаган. Яңа укытучыбыз язу каллиграфиясенә бик нык игътибар итә иде. Имля, иншаны еш яздырып, аларны кызыл кара белән тикшереп, төзәтеп, асларына «афәрин» (шәп), «тәхсин» (яхшы) дип язып куяр иде. Мин гарәп шрифты белән бик матур язарга өйрәндем – язу үрнәген Хәлилрахман абый белән Исмәгыйль абыйдан алдым. Алар төрле кара белән, хәрефләрне төрлечә куеп, бик матур итеп язалар иде. Ул вакытта стандарт хәреф үрнәге булмаган, ахры.

Котдус абый халыкка газета укып, дөнья хәлләре турында да сөйләргә иренми. Авыл халкы яңалыкны ишетергә, дөнья хәлләре белән кызыксынырга ярата. Авыл халкының аң дәрәҗәсе күтәрелеп, искелекне яклаучылар – консерваторлар – көчсезләнә баралар. Мәдрәсәләрдә җәдитчә укыта башлау белән, революциягә кадәр үк, Казма авылына беренче булып Мирзаҗан дигән мөгаллим Өчмунчадан килгән. Ул килгәч, авылның иске фикерле кешеләре укытучыга һәм авыл мулласына үлем (Исмәгыйль, Сәйфулла, Зариф, Гозәер Сәйфулласы һ.б.) белән янаганнар. Сәнәкләр күтәреп мулла өенә барганнар.

– Син балаларны кяфер итәргә рөхсәт биргәнсең, – диләр икән. Ләкин авыл халкы аларга узынырга ирек куймаган. Яңача укытуны яклаганнар, мулла һәм укытучыны яклап, саклап калганнар.

1930-1931 уку елы башланыр алдыннан, безнең авылга тагын яңа укытучылар килде. Аларның ничек килеп төшүе, кем барып алуы хәтердә калмаган, фатир тапканчы диеп, алар бездә 2-3 көн кунак булдылар. Соңыннан шунысы билгеле булды: әткәй авырсынып торганлыктан, аларны безнең тимер ходлы арбада («кламашка» дип йөртә идек) күк алашабызны җигеп, Дәүләтшин Җиһанша абый алып кайткан.

Апас районы Чирмешән авылыннан Ибраһимов Котдусны да безнең ат белән барып алган булган. Буйга уртачадан калкурак, ач яңаклы, озын борынлы, аксыл сары кашлы, гөлдер тавышлы укытучы алга сөзелеп, йөгергән сымак ашыгып йөрүе белән истә калган. Бу юлларны язганда, 40 елдан артык гомер узса да, аның кыяфәте һаман да беренче күргәндәге кебек хәтердә саклана. Йомшак күңеллелеге, тиз ярсучанлыгы, тиз үпкәләүчәнлеге, гадилеге, беркатлылыгы, ачу сакламавы, үпкәсенең тиз язылуы

белән Кадәрмитов Галимҗан һәм Котдус абыйларның киресе – капма-каршы типтагы, капма-каршы характердагы кеше иде ул. Баштарак авыл кешеләре йөрү формасыннан шикләнебрәк:

– Әллә укытучыбыз «салырга» ярата инде, аек чагын күргәнебез юк, һаман сөрлегеп йөри, – дип тә сөйләштергәләделәр. Соңга табарак, имеш, көпә-көндез «исереп» йөргәне өчен Буада, милиция бүлегенә тотып кереп, сорау алганнар, дип тә сөйләделәр. Аның хатыны Фаизә апа төскә-биткә чибәр генә булып, кигән киемнәре дә авыл хатын-кызларыныкыннан килешлеге, пөхтәлеге белән аерылып тора иде.

Ногманов Галимҗан, Кәшә авылы мулла малае, белемне Кәшә авылы мәдрәсәсендә, ә хатыны Фаизә[15] апа мәзин кызы булып, авыл остабикәсендә укыган.

Мәктәп балаларын яңа уку елында ике төркемгә бүлеп, беренче, икенче сыйныфларны – Ногманова Фаизә апа, ә өченче, дүртенче сыйныфларны Ногманов Галимҗан абый укыта башлады. Мәктәптә китапханә оештырылды. Анда булган берничә дистә китапны мин шул уку елында ук укып чыктым, ләкин кем әсәрләре икәне һич тә истә калмаган. Бу уку елы бик тиз үтеп китте, хәер, ул еллардагы уку елының дәвамы кыска иде шул. Көзен укулар, гадәттә, кыр эшләре тәмамлангач кына башланып, язын карлар эреп, Зөя елгасы тулышып, язгы бозлар кузгалгач та тәмам була. Авыл халкының:

– Ташу китә, боз күчә! – дип кычкырып, Зөя буена чабулары мәктәптә уку елының бетүен дә белдерә иде. Кайбер көндәм малайлар укырга йөрсәләр дә, күпчелек укучы өчен соңгы звонок шул була иде.

Шунысы истә калган: җәйге матур бер көнне укытучыбыз Галимҗан абый мәктәп балаларын җыеп, Каенлык урманына экскурсиягә алып китте. Җәйнең бик матур, җилсез, кояшлы эссе бер көне. Без күләгәле урманда байтак кына йөрдек. Укытучыбыз агач төрләрен, имән, юкә, өрәңге, усак һ.б. агачларны бер-берсеннән ничек аерырга, яфрак рәвешләрен аңлатты. Малайлар өчен иң әһәмиятлесе чикләвек куаклыгыннан кармак саплары кисү иде. Өйдән юлга алган азыкларыбызны мактана-мактана ашап-эчеп бетергәч, җиңеләеп калгач, төш авышкач, кайтыр юлга чыктык. Көн эссе. Йөгерә-йөгерә уйнап кайткангадыр, бик тә әлсерәдек, тирләп-пештек. Туры кыр юлыннан кайтып, Өчмунча комлыгы турысына Зөягә килеп чыктык. Зөягә килеп тә җиттек, күпчелек укучылар, күлмәк-ыштаннарын салып, суга да кереп киттеләр. Су чәчрәтеп уйнап, чумып, уздырыштан йөзү китте. Кызлар ир балалардан шактый югары агымгарак китеп, чишенмичә генә кул-битләрен юалар. Ир балалар коенган төштә су әллә ни тирән түгел, озынрак буйлы малайлар буйлап та аргы як комлыкка чыга алалар.

Кинәт:

– Батам, коткарыгыз, – дигән әче тавыш һәм «бата, бата», дигән тавышлар яңгырады.

Карасак, агымның түбәнге ягында, ярдан 8-10 метр ераклыкта бер калкып, бер чумып кемдер ага. Аңа таба өлкәнрәк 2-3 укучы йөзеп китте. Шул арада укучылар төркеменнән шактый артта калган укытучыбыз да килеп җитте, судагы хәлне күреп, киемнәре белән ярдан суга да сикерде. Сикерүен сикерде, ләкин йөзеп китә алмады, үзе суда бата башлады, бу хәлне күреп, аңа кемдер озын кармак сабы сузды, укытучыбыз кармак сабын тота алды, без аны ярга өстерәп чыгардык, шулай итеп, аны үлемнән коткарып калдык. Ул, мескен, Кәшә авылында Зөя суы буенда туып-үссә дә, йөзә белми икән.

Бер-беребезне барлагач, Садыйков Гайфулла абый малае Фәрхулла арабызда юклыгы беленде. Суга агып китүче Фәрхулла икән. Ул арада кемдер авылга йөгергән, хәлне сөйләп биргән. Озак та үтмәде, атларга атланып, җәяүләп авыл халкының безгә таба килүе күренде. Билгеле, иң ярсулы Садыйкныкылар иде. Алар иң беренче суга батучыны судан эзләү түгел, ә суга батыручы укытучының үзен суга ыргытырга омтылдылар, ярый әле, авыл кешеләренең кайберләре, яр башында һушыннан язу дәрәҗәсенә җиткән, курыккан, хәлсез Галимҗан абыйны уратып алып, Садыйкныкыларга бирмәделәр, җигүле атка салып, авылга озаттылар. Батучыны эзләү башланды. Без су коенган урын сай булса да, Фәрхулла аккан урын бик тирән булып чыкты. Авылның оста йөзүчеләре, чумучылары да таба алмадылар. Черкен авылыннан

[15] Аларның улы Рәмзи Галимҗанович Ногманов соңыннан культурология профессоры булды.

җылым алып килеп, шуның белән генә эзләп таптылар. Садыйкныкылар (Әхмәтша, Хәйрулла, Галиулла, Шәйхулла, Зәйнулла, Гайфулла – бертуганнар) Галимҗан абыйны үтерү белән байтак вакытлар янадылар дип сөйләделәр ул вакытта. Бу экскурсиябез гомер онытылмас фаҗига белән тәмамланды.

Тагын бер экскурсия истә калган. Көзнең матур көнендә без Буа шәһәренә бардык. Экскурсиядә күргәннәрнең иң гаҗәбе шул: ниндидер бер учреждениегә кердек (соңыннан белүемчә – РОНО) һәм анда бер абыйның (соңыннан белүемчә – Салихов Галимҗан – зав.РОНО) кем беләндер телефоннан сөйләшүен ишеттек. Һәм безнең үзебезне дә кем беләндер сөйләштереп карадылар. Телефоннан сөйләшү, хәзерге балалар өчен гадәти күренеш булса да, ул вакытта безнең өчен гаҗәеп хәл иде.

Икенчесе – беренче мәртәбә фотообъектив каршына утырып, беренче мәртәбә фотога төшү дә зур вакыйга булды. Шул беренче күмәк төшкән фоторәсемнәр альбомда сакланып калганнар. Сәмигуллин Хәлилулла (авылда), Каюмова Миңсылу (Ленинградта), Ибраһимова Мәхүпҗиһан (Мәскәүдә), Гыйльфанов Хөсәен (Горькийда), Садыйков Зиннәтулла (Салаватта). Еллар үткәч тә, «акыл» белә башлагач, матур белән ямьсезне «төсмерли» башлагач, янәсе минем фоторәсемем үз чибәрлегемә туры килми, ямьсез дип, башкалар арасыннан кисеп алып ертып ыргытканмын. Ә кайберләрен, кисеп алып, хуҗаларына биргәнмен. Кара инде бу ахмаклыкны?! Миннән башка бу ахмаклыкны, акыллы түгел, җүләр кеше дә эшләмәс.

Мин укытучыларга тиз ияләштем. Укытучылар да мине күреп алдылар. Уку миңа ул елларны бик тиз, җиңел бирелде. Хәтта кайбер вакытларда укытучылар мине үземнән олыракларга да остаз итеп куялар иде. Дәресеңне белгәч, укытучыларың сине яраткач, мактагач, мәктәпкә барасы гына килеп тора. «Мәгъсум йә мөгаллим, йә мулла булыр», – диләр иде. Ул вакытта укучыларның белем дәрәҗәсен бәяләү көндәлекләре булмаган. Йөгерек укысаң, матур язсаң, тотлыкмый санасаң, хисаптан 4 гамәлне белсәң, тапкырлау җәдвәлен ятласаң – болар гыйлемлекнең нигезе – укытучы мактый. Укытучының сине ата-анаңа мактавы – әйтеп бетергесез зур дәрәҗә.

Өлкәнрәк кешеләрнең:

– Син кайда укыдың?

– Кем дәрес бирде, кем тыңлатты?

– Габдулла хәлфәгә эләктеңмени?! – кебек сорашуларны ишетәсең дә уйга каласың. Дәрәҗәле укытучылар, абруйлы мәдрәсәләр булган. Элек-электән үк мәдрәсәләр һәм аларның белем бирү системалары аерылып торган. «Кемнән дәрес алдың, кемгә тыңлаттың?» соравының мәгънәсе дә тирән булган.

Безнең Казмада Чәчкап авылыннан Габдулла хәзрәт озак еллар хәлфәлек иткән. Габдулла хәзрәт шәкертләре озак еллар абруйлы дәрәҗәне үз кулларында тотканнар. Күрше авыл шәкертләре Габдулла хәзрәт шәкертләре белән бәхәскә керергә, ярышып коръән укырга теләмәгәннәр. Димәк, нинди авыл, шәһәр мәктәбендә, кемнән укуыңның әһәмияте бик зур. Бәс, шулай икән, һәр укытучы үз мәктәбе данын саклау яки күтәрү өчен һәм үзе укыта торган фәннән системалы, төпле белем бирү өчен көрәшергә тиеш. Мин үземнең укытучылык дәверемдә шушы хакыйкатьне раслый алдыммы икән?! Анысын шәкертләрем һәм аларның ата-аналары хөкеменә калдырам.

Әти-әниемнәрнең һәм башкаларның «Бу мулла булыр, мөгаллим булыр», диюләре ничек тормышка ашуы заманга, зур үзгәрешләргә бәйле булып чыкты. Мулла булу түгел, «мулла» сүзеннән дә курку заманалары килде.

*(Дәвамы алдагы санда)*

# СИЗГЕР КҮҢЕЛ – НӘЗБЕРЕК КАЛӘМ

Каләмдәшләребез арасында шагыйрәләрдән дисеңме, прозаиклардanмы, шөкер, гүзәл затларыбыз шактый. Алай гына да түгел: сүз сәнгатебезнең шушы төрләрендә, Тукай әйткәнчә, ат уйнатканнары да байтак. Сүзем үзенең матур гомер бәйрәмен каршы алучы Флёра ханым Тарханова турында. Ходай биргән зәвыклылыгына бәрабәр шәхси сыйфатлары: эчке культурасы, әйләнә-тирәдәгеләр белән мөнәсәбәтләрендәге зыялылыгы, сәнгатькә гашыйклыгы белән дә ул замандашларында үзенә карата җылы караш уята, аларда уңай хисләр тууына сәбәп була. Әйтерсең лә ул элекке заманнардагы морзалар яшәгән мохиттә генә, җил-яңгыр тими торган шартларда үтә нәзберек тиреләккә көйләнеп яшәгән дә хәзерге көнебезгә дә шул хәлендә килеп җиткән. Әмма дөньяда яшәүнең кырыс кагыйдәләре берәүгә дә сәгадәтлелекне әзер килеш кенә китереп бирми. Гомер иткәндә кеше юлында, әкиятләрдәге кебек, төрле сукмаклар пәйда була. Шуларның кайсы хәерле офыкка илтәсен чамалау еш кына мөмкин дә түгел.

Әйе, шул исәптән Флёра Габдрахман кызының да юлларына маяклар тезелеп куелмаган иде. Әмма туып-үскән һәм тәрбияләнгән ата-ана гаиләсендәге зыялылык, кешелекле тирәлек, Арча педагогия көллияте биргән төпле универсаль әзерлек (математик һәм тел белгече) аның өчен алга таба яшәешендә ныклы нигезне тәшкил итә. Туган ягындагы мәктәптә генә түгел, таулы Кыргызстанда да математика һәм рус теле укыта, балаларның мәхәббәтен яулап ала. Ихтимал, ул шушы юнәлешләрдә эшләп китеп, анда да үзенең ныклы урынын таба алган булыр иде. Тик әби-бабасыннан, әти-әнисеннән алган рухи тәрбия мохитен, күңеле өчен табигый булган милли яшәү рәвешен, туган телне, йөрәккә якын моңнарны сагыну аны Казанга тартып кайтара, дарелфөнүн талибәсе итә. Югары белем алгач, аспирантурада калдырылуы да очраклы түгел. Ник дигәндә, кыз ниндидер билге алу өчен генә түгел, белү өчен укый, үзенә кадәрге йөзләрчә буын элгәрләребез тудырган хәзинәне үзләштереп, алар башыннан үткән хәл-әхвәлләрне күңеленнән кичереп, хәтер төпкелләрендә гомер буе сакланырлык итеп беркетергә тырыша. «Иң яхшы драма әсәре» конкурсында икенче урынны яулаган «Сөю газабы, яки Ташлама мине» исемле сәхнә әсәрендә гәүдәләндерелгән Фирая образында без авторның үзен шәйлибез икән, хаклы булырбыз. Тормыш агымына каршы тора алмыйча, уникe ел буена күңелен нык ымсындырган офыклардан читкә тайпылып яшәгәннән соң, Ф.Тархнованың тормыш сукмагы яңадан табигый эзенә төшә: аны тәрҗемәчелек, журналистлык эше мавыктыра. Мондый максатчанлык хәтта эзләнү юлына да алып килә – фәннәр кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә алуга ирешә.

Шулай да Флёра ханымның туганнан алып шушы көнгә кадәр килә торган тагын бер аерылмас юлдашы бар, ул да булса – күңелендә туган ярату-нәфрәтләнү, шатлану-борчылу, матурлыкка соклану, ямьсез күренешләргә әрнү, төрле хәлләргә битараф кала алмау, уйлары-хисләре аша үткәреп, аларның асылын ачу... Баштарак аның күңелендә алар гадәти фикерләр рәвешендә барлыкка килсә, тора-бара шигъри юллар булып бөреләнә, кәгазьгә төшерүне сорый башлый. Әнә шулай, табигый рәвештә, ул шагыйрьлек сукмагыннан олы юлга чыга. Узган гасырның туксанынчы елларында ул инде иҗат җимешләре белән укучылар хозурына килеп керә. Шагыйрә, үзенең бу халәтен аңлатып, болай ди:

*Кайгы-хәсрәт дәрьяларын*
*Колачлап кичкән идем,*
*Күңелгә шатлык иңсен, дип,*
*Соңарган бәхет килсен, дип,*
*Җырларга күчкән идем.*

Әйе, иҗат шатлыгыннан килүче бәхет аны, шактый соңарып булса да, барыбер эзләп тапты. Аның каравы, бер юлыккач, Флёра ханым бу тавис кошыдай гүзәллекне кулында нык тотты. Шигъриятебезнең Шәрык традицияләреннән килә торган нәфислеген үзенең хисси фикерләү рәвешенә әйләндерде. Робагый, газәл, мөрәббагъ, мөсәммән, тәрҗибәнд кебек жанрларда да зәвыклылык сыйфатларына тугры калды. Менә бу робагыйдагы тыгыз фикер сөреше аның күңел дөньясын аеруча төгәл ача булса кирәк:

*Юлларыңда туктап калма – юлаучы барып җитәр,*
*Җиңел тормыш эзләгәннәр табалмый йончып бетәр.*
*Сынау өчен җибәрелгән ачы кайгы-хәсрәттән*
*Гыйбрәт алсаң сабыр булып, авырлык үзе китәр.*

Мөрәббагъларындагы уй-хисләрне тиешенчә әйтеп бирү өчен дә күңеле сөю тулы яшь егет яки кыз булу гына җитми, алар артында зур тормыш тәҗрибәсе булган, зирәк акылга ия зат торуы да бәхәссез:

*Сөя, дип әйтеп буламы – газабында көймәсә,*
*Бар дөньясын онытырып сөелмәсә, сөймәсә,*
*Үзе янып, сөйгән ярын ялкынына төрмәсә? –*
*Ярата, дип әйтеп булмас, бу хисләрне белмәсә.*

Флёра Тархановaның шигъри күңел байлыгы тупланган җыентыклары әнә шуның өчен укучылар тарафыннан да җылы кабул ителде. Алар – «Синең кайнар сулышың», «Йөрәгемә яшерелгән серләр», «Яшьлек эзем калган сукмаклар» һәм башкалар. Аның шигырьләренә язылган музыкаль әсәрләр эстрададан, радио һәм телевидениедән еш яңгырап тора. Балаларны да онытмый ул. Язучының «Уңган кыз», «Серле дөнья», «Өч каурый», «Алтын уклар», «Карлыган белән Чия» китапларындагы шигырь һәм әкиятләр балалар күңеленә юл тапты. Шигъри юлларга салынган «Өч каурый» әкияте буенча Казан «Әкият» курчак театры спектакль куйды.

Г.Бәширов, И.Юзеев, Р.Гаташ, Ә.Рәшитов, Зөлфәт кебек әдипләр һәм шагыйрьләр, төрле басмаларда бастырып чыгарып, аның шигъри иҗатына үзләренең уңай фикерләрен инде күптән белдерде. Бүгенге көндә дә аның иҗатына багышлап язылган мәкаләләр вакытлы матбугатта басылып тора.

Ф.Тарханова проза жанрларында да иҗат итә. «Язмышлар язылганда» дигән җыентыгында (2007) урнаштырылган хикәяләре аеруча хәтердә уелып калган. «Хисләр дәрьясында» дип аталган чираттагы китабы аның бу юнәлештәге иҗатының тагын да камилләшә төшүен күрсәтте.

Җыентыкта төп урынны «Даулы көннәр, яки Үлем баржасы» дигән тарихи повесть били. Ни өчен тарих? Чөнки биредә сурәтләнгән вакыйгалар инде тарих битләрендә генә сакланып калган чынбарлыктан алынган. Аларны Флёра ханымның әтисенең бертуган абыйсы Нурулла үз вакытында кәгазьгә теркәп калдырган булган.

1918 ел. Казан, Чистай төбәкләрендә, Идел-Чулман буйларында Гражданнар сугышының иң кызган чагы. Акларның һәм чехларның берләштерелгән көчләре ничек кенә булса да өстен катлау хакимлеген кире кайтарырга омтыла. Аларга таянып, инкыйлабка каршы булган җирле көчләр дә баш күтәрә. Флёра ханым шушы канлы вакыйгалар кисешкән урын итеп туган авылы Яуширмәне ала. Бер якта – биредәге инкыйлаб җитәкчесе, акыллы, алдан күрүчән, тирә-якта абруйлы Гаяз Садыйков, каршы якта – авылда гына түгел, Чистайның үзендә дә ташпулатлары булган Шәйхи кебек атаклы байлар. Бу көрәш рәхимсез, көчләрнең максаты бер-берсен бугазлаудан гыйбарәт. Биредә әлеге капма-каршылык арасында нинди дә булса чигенешләр булуы мөмкин түгел. Шәйхиләр, поручик Бутлеровлар үзләренең дошманнарын Идел уртасына кертеп батырса, Гаязлар, җае чыгу белән, Шәйхиләрнең тамырларын корыта.

Дөрес, биредә өченче көч тә шәйләнеп кала. Автор әлеге авылда туып-үскән тагын бер күренекле шәхесне – Мөхәммәтгаяз Гыйләҗетдин улы Исхаковны да (Гаяз

Исхакыйны) шушы мохиттә тасвирлап алу җаен тапкан. Ул әлеге кан коелышлардан читтәрәк тора, чөнки вазгыятьне сәяси юллар белән хәл итү карашын яклый. Учредительное собрание тарафдары буларак, чираттагы чарада катнашу ниятендә, Самарага китеп бара. Авылда гаять катлаулы шартларда сыйнфый көрәшкә тартылган элекке фикердәшләре аны аңламый. Һади Вәлиуллин дигәне аңа: «Күрәм, безнең юллар аерылган, юкка җил куып йөрисең икән», – дип, каршылыклы фикерен белдерә.

Без биредә гаять буталчык вакытта да хәл-әхвәлне дөрес бәяләүче, киләчәккә карап фикер йөртүче Г.Исхакыйны күреп калабыз. «Ленинга атканнар икән, ул кадәр зур кайгы түгел әле. Үлмәгән бит, дәваларлар да аякка басар. Акларның килүе дә ул кадәр куркыныч булмас. Дөрес, аларның нинди тәртип урнаштырачаклары, нишләп бетәчәкләре билгесез әлегә. Ә менә акны карадан аера белмәгән большевиклар ни кырыр, илне, халыкны нәрсәгә алып барып җиткерер, шулай ук билгесез. Әмма бу билгесезлек – иң куркынычы», – дип фикер йөртә ул. Г.Исхакый уйлана, теге яки бу тарафдарларның нинди сәясәт алып барачакларын аңларга тырыша. Аны борчыган төп проблемаларның берсе – татарның милли мәнфәгате. Әлеге көчләрнең кайсысы хакимияттә булганда ул хәл ителер?! «Эшләрнең кызу чагы. Тик утырып булмый», – ди ул. Сәяси җирлектә эш алып бару – аның өчен хәрәкәттә булуның иң файдалы ысулы, уңышка ирешүнең дөрес юлы.

Автор дөрес сурәтләгәнчә, әлегә кемнең кем булуы өчен көрәш сыйнфый характерда бара. Сыйнфый баскычның бер ягында торган авылдашлар бер-берсенең байлыкларын, җир-суларын тартып ала, икенчеләре шуның өчен аларны үлем баржасына илтеп тыга, суга батырып юк итәргә тырыша. Шул мәхшәрдән исән котыла алганы тагын канлы үч алу юлыннан китә. Аның каравы, әлеге документаль повестьта татар Гаяз белән рус Иванның бер-берсенә булган игелекле мөнәсәбәте, аларның кешелекле сыйфатлары укучыларны сокландырырлык итеп тасвирланган. Бу хәлләрнең, уйлап кына чыгарылмыйча, сурәтләнелгән чын кешеләр язмышына нигезләнеп язылуы күңелне аеруча тетрәтә. Ф.Тарханова бу көчләрнең берсен дә якламый, шуңа күрә сурәтләү гадел бара, әсәрдә гомумкешелек идеаллары алгы планга чыга. Бу дөрес тә. Чөнки патшаны хакимияттән читләштерү иҗтимагый тормыш барышы белән тулысынча акланса да, илдә Гражданнар сугышын җәелдерү ихтыяҗы юк иде. Бу канлы бәрелешләр миллионнарча кешеләргә һәлакәт, җәбер, күз яше генә алып килде. Аның нәтиҗәләре табигый барышка, яшәешкә, дистә елларга сузылачак тайпылышларга китерде. Повесть бу хакта уйлану, гыйбрәт алу өчен тагын бер нигез бирә.

Шулай да шагыйрәнең проза каләме, әлеге повестьны язганда, үзен бераз киеренкерәк тота. Ник дигәндә, үз күзләре белән күргән, үзе кичергән вакыйгалар түгел. Гражданнар сугышы турында күп язылган, бу әсәрем белән шуларга нәрсә өстәргә була, дип тә уйлангандыр. Ни дисәң дә, туган авыл тарихы күңелне яраламый һәм җилкендерми калмый. Ә менә җыентыктагы бәянда, хикәяләрдә автор бөтенләй башкача. Ул инде, әйтергә яраса, үз стихиясендә. Бүгенге тормышның үзенә нигезләнгән бу әсәрләрне берсе артыннан икенчесен кызыксынып укып барганда, синең алда хатын-кыз күңеленең серле пәрдәсе ачылганнан-ачыла бара. Еш кына ир-ат язучыларның хатын-кыз күңелен бөтен нечкәлекләре белән белеп язулары турында шаккатып сөйләүләренә юлыгырга туры килә. Бар, әлбәттә, шактый тирән үтеп сурәтләүчеләр дә, әмма барыбер тамырына төшеп, тәмам белеп түгел. Моны хатын-кыз үзе генә белә. Шуңа инанасы килгән кешегә Ф.Тарханова хикәяләрен укырга киңәш итәр идем. Бу хасият «Мәхәббәтнамә» дип искәрмә куелган «Күзләр» хикәясендә үзен аеруча сиздерә. Кешеләрнең карашын бөтен күзәнәкләре ярдәмендә тоя алу мөмкинлеген раславы белән әсәр үзенә җәлеп итә. Биредә Ф.Тарханова хикәяләренең шигырьдәгечә нечкә лирикалылыгы аша да көчле тәэсир итүен әйтмичә булмый.

Бәян һәм хикәяләрнең күбесе мәхәббәт хисләрен үзенчәлекле һәм җанга үтеп керерлек итеп тасвирлаудан гыйбарәт. Бу хисләр шулкадәр катлаулы һәм бер үк вакытта үтә шәхси, бер генә язучыга да, шул ук вакытта Флёра ханымның үзенә дә аларның тулы гармониясен биреп бетерү мөмкин түгелдер. Әмма шунысы бар: Ф.Тарханова бәян иткән хисләр – затлы, ихлас, саф.

«Хисләр дәрьясында» дигән бәяндагы хәлләр, вакыйгалар илебездә соңгы дистә

еллар эчендә, бигрәк тә киң таралган эшмәкәрлек өлкәсендә әллә ни тирәнгә кереп китмичә генә ачыкланган кайбер мәсьәләләрне (мәсәлән, Мәскәүдә яшәп тә, Чаллыда үз бизнесын булдырып һәм шуннан торып идарә итү; варислык һәм байлыкны бүлешкәндәге кыенлыклар, дошманлык, үчлек...); әлбәттә инде, кайнар мәхәббәтне, баштагы мәлләрдә әсәрнең төп геройлары Руслан белән Диана арасындагы бары тик каршылыклы һәм нәфрәтле хисләрнең тора-бара бер-береннән башка яши алмаслык дәрәҗәгә җитеп өзелеп сөю хисләренә әйләнүен; ниһаять, гаилә корганда, кайбер табигый һәм махсус оештырылган киртәләрне җиңеп, бәхетле тормышка аяк басуларын һәм, беркем сүзенә дә, басымына да буйсынмыйча, үз хисләренә һәм көчләренә ышанып, үзләренчә яшәп китү хәлләрен иңли.

«Бәгырь» хикәясенең геройлары Гөлгенә белән Дәүфит, минутлык ләззәт алдына мәхәббәт дип аталучы олы киртәне куеп, укучы күз алдында абруйларын саклап калалар. Юк, алар кешене зурлый торган яратып яну кебек сыйфаттан мәхрүм түгел. Киресенчә, шушы хиснең кадерен саклап калучылар буларак күзаллана.

«Ярчык» хикәясендәге исеме билгесез кыз да шундыйлар рәтеннән карала ала. «...Мин сине башымны югалтып өзелеп сөйдем», – ди ул. Шушы читтән торып кына, җавапсыз һәм газаплы сөю дә аны дөньядагы иң бәхетле кеше итә. «Гариф белән Гөлфия» исемле әсәр шулай ук мәхәббәт хикәяләренең үзәгендә тора, дисәк, һич ялгышмабыз. Кешене бәхетсез итеп, үзеңнең тормышыңны ныклы нигезгә корып булмаячагын сәнгатьчә күрсәтеп бирүе белән әлеге хикәя укучыга гыйбрәтле сабак. Хикәянең ритмлы проза белән язылуы да аның сәнгатьчә кызыклы бер үзенчәлеген тәшкил итә.

Тормышта еш очрый торган гаделлек һәм гаделсезлек, игелеклелек һәм явызлык, тугрылык һәм хыянәт кебек күренешләрне капма-каршы куеп сурәтләгән отышлы хикәяләр шактый бу җыентыкта.

Аерым алганда, «Язмышмы бу, әллә каргышмы?», «Үлмәдеңме әле?», «Үч», «Кара күңел – кара күмер» һәм «Укол» хикәяләре, мәхәббәтнең илаһилыгын күрсәткән хикәяләреннән аермалы буларак, бүгенге тормышта шактый еш очрый торган шәфкатьсезлекне, кешеләрнең бер-беренә рәхимсез мөнәсәбәтен, хәтта вәхшилекне ачып сала. Әлеге хикәяләр һәрберебез күңелендә тиешле урынын табар һәм хәзерге укучыларыбызга гына түгел, киләчәк буыннарга да гыйбрәт булыр дип ышанасы килә.

Үзенчәлекле юмор белән язылган «Хәтәр урын» хикәясе үзенә бертөрле кызыклылыгы һәм тәрбияви ягы белән аерылып тора. Ихтимал, бу хикәяне укыганнан соң, кемнәрдер сурәтләнгән хәлләрдән олы сабак алыр, күңелләрендә дөрес юлга басу теләге туар.

Ф.Тархankованың иҗаты әле моның белән генә чикләнми. Ул – профессиональ тәрҗемәче һәм публицист та, байтак китаплар мөхәррире дә. Төрле телләрдән (рус, украин, казакъ, авар, балкар, азәрбайҗан, үзбәк, фарсы телләреннән) тәрҗемә иткән шигырьләре, повесть, хикәяләре, романнары укучыларда шулай ук зур кызыксыну уятты.

Әйе, аларны укып, уйланып йөргәннән соң, күңел яңа хисләр, яңа уйлар белән баец икән, димәк, автор үзенең төп максатына – кеше күңеленә нечкәләп тәэсир итү куәсенә ия дигән сүз. Иҗат кешесе өчен монысы – иң мөһиме. Һәм шигърияттә, һәм прозада, һәм тәрҗемәдә Флёра Тархановaның каләм көче арта бара, аңа алга таба да бу юлда яңа табышлар телик.

**Фоат ГАЛИМУЛЛИН,**
*филология фәннәре докторы, профессор*

*«Казан утлары» журналының татар халкына тугры хезмәт итә башлавына 95 ел тулу һәм Рабит Батулланың ТРның Беренче Президенты Минтимер Шәймиев турындагы документаль романы – «Илбашы» басылып чыгу уңаеннан, Актаныш, Мөслим, Сарман, Зәй районнарында «Казан утлары» журналы көннәре узды. Әлеге кичәләрдә әсәрнең авторы Рабит Батулла, «Казан утлары» журналының редакция коллективы җирле җитәкчеләр һәм халык белән очрашты.*



*Актаныш муниципаль районы башлыгы Фаил Камаев хозурында. Сулдан уңга: бүлек мөхәррирләре, язучылар Камил Кәримов, Айгөл Әхмәтгалиева, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире, шагыйрь Илфак Ибраһимов.*



*Татарстанның халык язучысы Рабит Батулла чыгыш ясый. ТР Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов (сулда), шагыйрь Илфак Ибраһимов (уңда).*



*Рабит Батулла Пучы (Актаныш районы) халкын бавырсак белән сыйлый.*



*Мөслим муниципаль районы башлыгы Рамил Муллин белән очрашу.*
*Уңда – Илфак Ибраһимов; сулда – Рабит Батулла, Рамил Ханнанов.*




*Зәй районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарлары Павел Байрашев (сулдан дүртенче) һәм Александр Чапков (уңнан беренче) белән.*




*Сарман районы Ләке авылында укучылар белән очрашудан соң.*

**Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ** *фотолары*

# АРЧА МУЗЕЙЛАРЫ

## Бөек Тукайның туган җирендә

Шагыйрьләр озак яшәми, диләр. Моның сәбәпләрен аларның һәрнәрсәне күңелләренә бик якын кабул итүләре, йөрәкләренең тиз яралануы, үзләрен ялгыз хис итүләре белән аңлаталар. Габдулла Тукайга Ходай тарафыннан бары 27 ел гомер бирелгән булган. Шулай да Гариф Ахунов әйткәнчә:

*Мәңге тере, мәңге үлмәс*
*Классиклар, даһилар*
*Гасырлар узганнан соң да*
*Безнең белән яшиләр.*

Вафатыннан соң Габдулла Тукайның шигырьләре 29 телгә тәрҗемә ителә. Китаплары 7 миллион данә тираж белән басылып чыга. Тукай исемен йөрткән урамнар республиканың һәр шәһәрендә, бистәсендә бар. Бохарада, Ферганәдә, Алматы, Анкарада да бар андый урамнар.

Һәр елны шагыйрьнең туган көне 26 апрельдә Россиянең татарлар яшәгән һәр төбәгендә генә түгел, Америка Кушма Штатларында, Төркиядә, Финляндиядә һәм башка илләрдә дә билгеләп үтелә. Аңа бюстлар, һәйкәлләр куелган, Тукай сүзләренә йөздән артык җыр язылган, әсәрләре өч балет өчен нигез булып торды. Кайбер әдәбият белгечләре Тукайны татарның Пушкины, диләр. Әмма нигә соң Пушкин булсын ди әле ул? Ул – Тукай, артык та, ким дә түгел. Тукай – милли кысалар белән генә чикләнмәгән, гаҗәеп зур масштабтагы шагыйрь. Аның иҗатына тулы күләмдә бәя бирү бик авыр, бәлки, бөтенләй үк мөмкин дә түгелдер. Тукай кебек аз яшәгән даһилар – Пушкин, Байрон, Гейне, Рембо, Лермонтов та үлгәннән соң гына данландылар.

Җисми яктан тормыштан китсә дә, Тукай, шагыйрь буларак, бу дөньядан китмәде. Аның авазы һаман да яңгырый һәм халык күңелендә теләктәшлек таба. Ул авазны яхшырак ишетергә омтылу шагыйрь яшәгән урыннарга аеруча бер мөнәсәбәт тудыра.

Арча ягына килгән кеше Г.Тукайның туган авылы Кушлавычка барып кайтуны үзенең намус эше дип саный. Шагыйрь тормышы белән бәйле һәр урын, истәлеген саклаучы һәр музей аны безгә тагын да якынайта.

Тукаевларның Кушлавычтагы музей-йорты Мөхәммәтгариф мулланың йорты урынында, элеккечә итеп, яңадан торгызылган. Музей экспозициясендә шагыйрьнең ата-анасы йорты, ишегалды, каралты-курасы, ул замандагы йортның эчке күренеше элекке хәленә кайтарылган. Тукаевлар утары комплексына хәзерге вакытта музейның төп экспозициясе урнашкан өч залдан гыйбарәт алты почмаклы йорт (1996 елда төзелә), Казан арты крестьяннарының көнкүрешен яктырткан дүрт почмаклы йорт (1979 елда реконструкцияләнә), мунча (2011 елда салына), келәт (2011 елда төзелә) керә. 1956 елда Тукаевлар нигезе урынында шагыйрьгә бюст ачыла (сынчы И.А.Новосёлов). 1959 елда һәйкәл артында агач китапханә бинасы төзелә.

Алты почмаклы йортта урнашкан экспозиция шагыйрь әти-әнисенең шул чордагы йорты белән таныштыра. Музей экспозициясенең төп темасы – Габдулланың балачак дөньясы. Шагыйрьнең балачагы һәм аның балалар өчен язылган әсәрләре экспозициядә мөһим урын алып тора. Китап образы музейның барлык заллары аша уза.

Экспозицияләрдә Арча районы авылларыннан тупланган XIX-XX гасырларга нисбәтле көнкүреш әйберләре, авыл тарихын бәян итүче Кушлавычта яшәгән

*Ахыры. Башы узган санда.*

мөселман дин әһелләре, Тукайның әти-әнисе һәм башка туганнары турындагы архив документлары, фотосурәтләр урын алган. Музей экспозициясендә шагыйрьнең ата-анасы йортын, аның ул замандагы эчке күренешен күрсәтергә тырышылган. Мәдрәсә күренеше дә тасвирлана. Ул – ирләр ягында. Тукай әтисе ягыннан да, әнисе ягыннан да муллалар нәселеннән булган бит. Әтисе ягыннан шәҗәрәсенең җиде буынының мулла булуы мәгълүм. Күрәсең шунлыктандыр, экспозициядә мөселман руханиларының халыкны агартудагы эшчәнлегенә басым ясала.

Йортның хатын-кызлар ягы традицион татар авылы өен гәүдәләндерә. Монда – ана дөньясы: бик күп әйберләр уңган һәм тырыш хатын-кыз кулы белән эшләнгән. Бүлмәнең бер почмагында зур мич урнашкан, ул музейга чын мәгънәсендә гаилә учагы җылысы биреп тора. Аның янәшәсендәге витринада шагыйрь әтисенең шәхси әйберләре куелган. Уникаль мемориаль әйберләр арасында, риваятьләр буенча, кайчандыр шагыйрьнең әнисенеке булган дип саналган өч тәлинкә бар.

Элек Казан губернасы Мәңгәр волостена кергән Кушлавыч авылы Казан арты татар авылларыннан әллә ни аерылмый: Казаннан 60 чакрым ераклыкта урнашкан, 1885 елгы мәгълүматларга караганда, анда 120 хуҗалык, 794 кеше исәпләнгән. Халык фәкыйрь яшәгән, аларның төп шөгыле – умартачылык. Авылда бер кибет, бер тимерчелек алачыгы булган. Иң күренекле урын – мәчет. Шулай да бу авылда үткән көннәр һәм аның гүзәл табигате бөек шагыйрь иҗатында чагылыш таба.

Хәзерге көндә Кушлавычта Тукай чорыннан калган бер генә бина да сакланмаган. Ләкин монда шагыйрьнең балачагын искә төшерүче мохит, тирәлек бар. Булачак шагыйрьнең илһам чишмәсе, туган телгә мәхәббәт хисе, әйләнә-тирәне аңларга омтылышы нәкъ менә Казан артында формалаша.

## Шагыйрь эзләре калган сукмаклар

Кушлавычтан соң нәни Габдулланың ятимлек сукмагы Сасна, Өчиле авыллары аша уза, ике ел ул Казанда үзен тәрбиягә алган үги әти-әнисендә яши. Аннары Кырлай авылы кешесе Сәгъди абзый аны тәрбиягә ала һәм үзләренә алып кайта.

Өчиледә Тукайның әнисе ягыннан бабасы Зиннәтулла хәзрәт яшәгән. Бу авылны бүген дә халык телендә еш кына Тукай Өчилесе дип йөртәләр. Ник дигәндә, бу төбәктә вакытында Өчиле авыллары икәү булган. Икенчесе – Гариф Ахуновның туган авылы – Кече Өчиле. Кызганыч, ул сакланмаган, таралып юкка чыккан.

Сөекле шагыйребезне үз кочагына алган Өчиленең мәһабәт мәктәп бинасында бу борынгы авыл тарихына, Тукайга багышланган музей эшли. Аны оештыруга Татарстанның атказанган укытучысы, Россиянең мәгариф отличнигы Фәрхәт Зыятов күп көч куйган.

Габдулла Тукайны бәләкәй вакытында үзенә сыендырган Яңа Кырлай авылы үзе үк хаклы рәвештә мемориаль һәйкәл булып тора. Кырлайда ул Сәгъди абзыйлар гаиләсендә биш елга якын яши. Габдулланың гади крестьян тормышының көндәлек ихтыяҗларын сиземләве нәкъ менә Кырлайдан башлана. Монда ул мәдрәсәгә йөреп белем ала, тормышны өйрәнә, халык җәүһәрләре белән таныша. «Кырлай авылы минем дөньяга иң элек күзем ачылган урыным», – дип язды соңыннан шагыйрь.

Авылда шагыйрь эзләре калган сукмаклар әле дә саклана. Аларның кайберләре «Кырлай» мемориаль комплексына да алып килә. Музей Тукай үзенең бик күп шигырьләрен багышлаган елга буена урнашкан, улерактан ук күренеп тора. Туры сукмак буенда бөдрә каеннар үсеп утыра. Шулай гадәткә кергән инде, музейга кунакка килүче һәркем биредә агач утыртып калдыра. Шул рәвешле, «Дуслык» аллеясы барлыкка килгән.

Музей янында Тукай һәйкәле каршы ала. Әйтерсең, шушы йортка керер алдыннан Тукай ял итәргә, хәл җыярга уйлаган. Киләчәккә зур планнар корып утыра ул. Еллар үтеп, инде чын шәһәр кешесе булып җиткәч, Тукай үзенең истәлекләрендә һәм иҗатында Казан артына, балачак чорына торган саен ешрак әйләнеп кайта.

Кырлай музее экспозициясе шагыйрьнең бөтен тормыш юлын гәүдәләндерә: экспонатлар арасында Тукайның үзе исән чакта басылган китапларын, аның туганнары һәм дусларының шәхси әйберләрен, Казанның «Болгар» кунакханәсендәге җиһазларны күрергә мөмкин. «Шүрәле» темасы музейга тирән бер үзенчәлек биреп тора. Ул шагыйрьнең үз

тормышы һәм иҗаты материалларында да, аның мирасының бүгенге язмышы аша да яктыртыла. Монда Шүрәле образының музыкада (Ф.Яруллинның шул исемдәге балеты), сынлы һәм декоратив-гамәли сәнгатьтә, китап графикасында гәүдәләнеше күрсәтелгән. Музейга шулай ук Тукай әсәрләренә нигезләнеп эшләгән республиканың күренекле рәссамнары Б.Урманче, Ф.Әминов, А.Абзгильдин, Р.Заһидуллин әсәрләре тупланган.

Г.Тукай әдәби-мемориаль музей-комплексының Яңа Кырлайдагы музеенда Россиянең Беренче Президенты бүләк иткән китап та саклана. Дөрес, ул Тукайга багышланмаган. Калын, затлы бу китапны Мәскәүнең «Огонёк» нәшрияты 1994 елда чыгарган. Ул «Борис Ельцин. Записки Президента» дип атала. Эчке битенә «В память о посещении музея Г.Тукая, 9.06.96 г.» дип язып, култамгасын да салган.

Билгеле булганча, ул елны Б.Ельцин Арча район Сабан туенда катнашты, чүлмәк ватты. Аннары бөек Тукаебызга баш иеп, аның Кырлайдагы һәйкәленә чәчәкләр куеп, истәлеккә китабын бүләк итеп калдырды. Бөек Тукай һәйкәленә баш иеп, чәчәкләр салуы, музейда шагыйрь турында лекция тыңлавы, музей китабына теләкләрен язып калдыруы татар халкын олылау, аңа хөрмәт күрсәтү буларак кабул ителде.

Яңа Кырлайда Г.Тукайга багышланган музей экспозициясе 1960 елларның икенче яртысында авыл китапханәсендә оештырыла. 1971 елның 30 мартында Г.Тукай музее Казандагы М.Горький музее филиалы статусын ала. 1976 елдан – ТАССР Дәүләт музее филиалы. Республика Министрлар Советының 1978 елның 7 декабрендәге «Яңа Кырлай авылын һәм Г.Тукай мемориаль үзәген төзекләндерү, архитектура-сынлы бизәү буенча чаралар турында» карары буенча, Б.Урманче проекты белән, яңа музей комплексы бинасы төзелә. Аны ачу тантанасы 1979 елның 25 апрелендә үткәрелә. Бүген Г.Тукай музей комплексы бу бинадан тыш Сәгъди абзый йортын да үз эченә ала. Б.Урманче проекты буенча салынган бинада «Г.Тукайның тормышы һәм иҗаты» экспозициясе Сәгъди абзый йортында көнкүреш мемориалы урнашкан.

Арча төбәгендә Сәгъди абыйны шагыйрьнең икенче әтисе дип йөртәләр. 1978 елда аның йорты Тукай яшәгән еллардагыча итеп төзекләндерелде. Капка-койма, келәт, аның эчендәге йорт кирәк-ярагы, кар базы, сиртмәле кое, лапас – һәммәсе нәни Апушның бу йортта өч елга якын яшәү рухын саклый кебек. Монда аяк баскан өлкәннәр, бигрәк тә читтән кайткан әби-бабайлар юкка гына үз балачаклары, яшьлекләре белән очрашкандай, күз яшьләренә буылып, истәлекләргә чумып йөрмиләрдер.

Шагыйрьнең 120 еллыгына әзерлек барганда, комплексны Татарстанның ул чактагы Президенты Минтимер Шәймиев карады. Ул музейны яңартырга, төзекләндерергә күрсәтмә бирде. Аның әмере белән, Г.Тукай һәйкәле бронзадан эшләнеп куелды.

Тукай – күпкырлы талант. Ул туган як табигатенә гашыйк, җир йөзендә яшәүче һәркемнең иректә, азат булуын теләде. Шул ук вакытта ул үткен телле сатирик та, ялганчыларның, идарә итүчеләрнең, надан руханиларның икейөзлелеген фаш итә. Тукай биографиясе – дөнья әдәбияты тарихында иң драматик биографияләрнең берсе. Болай караганда, шагыйрьнең узган юлы озын түгел. Аның төп урыннары Кушлавыч-Өчиле-Кырлай-Казан-Уральск. Яңадан Казан... Ләкин шул авыллар, шул шәһәрләр арасында күпме фаҗига!

## Белем «Әлифба»дан башлана

Арча педагогия көллиятендә 1999 елда «Әлифба» музее оеша, ә 2001 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Мәдәният министрлыгы карамагындагы музей буларак эшли башлый. Музей үзенең фәнни эчтәлеге, экспонатларга байлыгы, уникаль булуы белән аерылып тора. Биредә бөтендөнья халыкларының язу системасы барлыкка килү һәм аның борынгы вакыттан алып хәзерге көнгәчә үсешен күрсәткән бай фонды бар. Музейның бу фонды хәзер 1226 данә экспонаттан тора.

Дөньяда башка бер генә җирдә дә «Әлифба» музее юк, диләр. Арча педагогия көллиятендә укучылар күпме генә тырышып эзләсәләр дә, Интернет челтәреннән андый музейны таба алмаганнар.

Коръәннең безгә иңгән иң беренче сүзе – «икъра» («укы») һәм «Әлифба» музее экспонатларының 900 нче елларда ук Идел буе Болгарстанына килеп кергән һәм татар халкына мең елдан артык хезмәт иткән гарәп әлифбасыннан башлануы табигый хәл.

Безгә килеп җиткән әлифбалар «Иман шарты» дип аталган һәм озак еллар буе гарәп грамматикасы үзгәрешсез калган. Гарәп язуы бик кызыклы – аның 250дән артык үрнәге бар. Моны аңлап та була: җанлы предмет, тере затларны сурәтләү тыелганлыктан, рәссамнар, каллиграфлар барлык талантларын хәреф бизәүгә сарыф иткәннәр.

Әмма гарәп әлифбасы белән укыганнарның күбесе гарәп телен белмәгән, шуңа күрә «Иман шарты»ннан башланган гыйлем өстәү, нигездә, ятлауга корылган булган. Моны аңлаган галимнәр (күбесе – вакытында мәдрәсәдә белем алып чыккан шәкертләр) тора-бара үзләре «Әлифба» төзергә алынганнар. Шундыйларның берсе – Сәгыйть Хәлфин. Ул 1778 елда Петербургта урыс телендә «Азбука татарского языка» дигән китап чыгарган. Татар теленең эчке законнарын тоеп, аны үзгәртү мәсьәләсен беренче булып Каюм Насыйри күтәреп чыга. 1895 елда басылган «Әнмузәҗ» дигән татар грамматикасы китабында ул бездә ун сузык барлыгын күрсәтә һәм шуларны белдерү өчен өстәмә хәрефләр тәкъдим итә.

Татар имлясын камилләштерүгә зур өлеш керткән галимнәр арасында Әхмәтһади Максуди аерым урын алып тора. Аның 1892 елдан башлап басылып килгән «Мөгаллим әүвәл» исемле әлифбасы 30 тапкырдан артык басылып чыга, XX гасыр башында гарәп язуы нигезендә М.Корбангалиев, Х.Зәбири, Г.Нугайбәк, Г.Әхмәров, Г.Алпаров, Н.Думави, Х.Гали, Г.Ибраһимов әлифбалары да дөнья күрә.

Әлбәттә, башлангыч сыйныфлар өчен укытучылар әзерләүче Арча көллиятендә андый музейның барлыкка килүе, беренче карашка, гадәти күренеш кебек. Әмма ул биредә очраклы рәвештә генә тумады. Эш шунда ки: көллияттә озак еллар буе татар «Әлифба»сы авторлары Рәмзия Вәлитова һәм Сәләй Вагыйзов эшләде. Алар татар теле һәм әдәбияты, балалар әдәбияты, башлангыч сыйныфларда татар теле укыту методикасы буенча дәресләр бирделәр.

Р.Вәлитова һәм С.Вагыйзов тумышлары белән Арча кешеләре түгел. Бирегә эшкә алар Бөек Ватан сугышына кадәр үк, институт тәмамлап, юллама белән килгәннәр. Аннары Сәләй Гатат улы сугышка киткән. Харьков тирәсендә әсирлеккә төшкән. Әсирләрнең сугыштан соңгы язмышы билгеле инде. Сталин лагерьлары... Ире янына барып йөргәне өчен, Рәмзияне эшеннән чыгаралар. Халык дошманы хатыны бит. Сәләйгә ун ел гомерен лагерьларда үткәреп кайтырга туры килә. 1955 елда Арчага кайткач, элекке «халык дошманы» иң игелекле эшкә керешә. Хатыны Рәмзия белән бергәләп беренче сыйныфтагылар өчен «Әлифба» дәреслеге әзерлиләр. Кырыс тормышның җитди сынаулары сындыра алмый аларны.

Хәер, язмыш авырлыкларны Сәләйгә тугач ук мул бирә башлый. Самара өлкәсе Камышлы районының Байтуган авылында 1908 елда туып, әле ярты яше генә тулган баланың әтисен, башка кеше белән бутап, базарда кыйнап үтерәләр. Әнисе Гайниҗамал улын алып китәргә җыенгач, әтисенең әнисе Шәмсехәят апа: «Улымның бердәнбер улы шәригать буенча миңа калырга тиеш», – дип, малайны әнисенә бирми, үзенә алып кала.

Бичара хатынның ниләр кичергәнен, мөгаен, Аллаһы Тәгалә үзе генә белгәндер. Тик кечкенә Сөләйман гына урамда кара шәл бөркәнгән хатынның үзен күкрәгенә кочып елаганын ничек тә аңлый алмый. Шәмсехәят апа үзе авырый башлагач, оныгын балалары булмаган Гататдин һәм Гайшә Вагыйзовларга асрамага бирә. Алар Сөләйманны үз фамилияләренә күчерәләр, исемен дә Сәләйгә әйләндерәләр. Шул рәвешле, Сөләйман Хәлиуллин Сәләй Вагыйзовка әйләнә. Кечкенәдән нечкә күңелле, белемгә омтылучан Сәләй хикәяләр, шигырьләр язарга ярата. Аның язмалары хәзер Арча музеенда саклана.

«Әлифба» музееның төп нигезен С.Вагыйзов һәм Р.Вәлитоваларның педагогик һәм иҗат эшчәнлекләренең нәтиҗәсе тәшкил итә. 1965 елдан башлап алар – бөтен татар мәктәпләре өчен булган «Әлифба»ның авторлары. Моннан тыш алар 43 төрле дәреслек һәм методик китаплар да язганнар. Сәләй Гатат улы, үзләренең «Әлифба»ларындагы хәрефләрне кулланып, беренче сыйныфтагылар өчен язу дәфтәрләре формасын да әзерләп бирә. Аннан соң шулай ук беренче сыйныфлар өчен «Туган тел», «Татар телен укыту методикасы» китаплары дөнья күрә.

Шунысын да искәртергә кирәк: дөньяда төрле телләрне укыту методикалары шактый җентекләп эшләнгән. Әмма татар телен укыту методикасы юк иде. Аны

беренче булып нәкъ менә Вагыйзов һәм Вәлитова әзерләде. Кырык елдан артык элек әзерләнгән «Әлифба» бүген дә искермәде. Чөнки С.Вагыйзов һәм Р.Вәлитова аны даими рәвештә яңартып тордылар.

Биредә татар имлясын камилләштерүгә зур өлеш керткән Әхмәтһади Максудиның үз кулы белән язылган «Әлифба»сы – «Мөгаллим әүвәл» урнаштырылган. Бу кулъязма Ә.Максудиның үз кулы белән төзелеп, тел галиме Хәлиф Курбатов тарафыннан «Бөек зат Һади Максудиның бу кулъязмасы бүгеннән Рәмзия ханым белән Сәләй туган милкенә күчә. Хәлиф Курбатов. Казан. 1997 ел, 12 март» дип язылып, татар әлифбаларын төзүчеләр Р.Вәлитова һәм С.Вагыйзовка тапшырыла. Шулай итеп, әлеге кыйммәтле кулъязма музей экспонатына әверелә.

Ә менә латин графикасы нигезендә беренче татар «Әлифба»сын Г.Нугайбәк белән М.Корбангалиев төзи. Ул елларда балалар, өлкәннәр, эшчеләр, крестьяннар өчен аерым-аерым «Әлифба»лар эшләнә. 1939 елда татар язуын кириллицага күчергәч, беренче татар «Әлифба»сын Мөхетдин Корбангалиев һәм Габбас Сәйфуллин төзи. Бу «Әлифба» 1964 елга кадәр хезмәт итә.

Музей экспонатлары гаҗәеп кызыклы. Биредә атаклы Кышкар мәдрәсәсе белән танышасың. «Мотыйгия» мәдрәсәсе шәкертләре арасында Г.Тукай фотосы да бар. Муллалыкка указ үрнәкләре дә куелган. 1951 елда галимнәр тарафыннан төзелгән үзенчәлекле харита (карта) игътибарны җәлеп итә: анда дөньядагы зур шәһәрләрнең Мәккәгә карата кайсы юнәлештә икәнлеге күрсәтелгән.

«Афәрин» – шәкертләргә бирелә торган мактау кәгазе икән. Музейда зәңгәр, кызыл «афәрин»нәр куелган. Кызылы – иң дәрәҗәлесе. Бер почмакта Рәмзия Вәлитова, Сәләй Вагыйзовның эш бүлмәсен күзаллау мөмкинлеге бирелә. Үзләре исән булмасалар да, бүген музейның һәр урыныннан Рәмзия апа һәм Сәләй ага рухы бөркелә кебек. Аларның 1964 елда төзегән «Әлифба»лары Татарстан Мәгариф министрлыгы үткәргән бәйгедә икенче урынны ала, ә Россиядә әлеге китап бизәлеше буенча беренче урынга лаек була. Шуннан башлап «Әлифба» ел саен меңәрләгән тираж белән чыга, тулылана, камилләшә бара. Соңгы елларда авторлар алты яшьлекләр, өчьеллык, дүртьеллык башлангыч мәктәпләр өчен «Әлифба» һәм латин графикасына нигезләнгән «Әлифба»лар төзеделәр.

Музейда дөньядагы бик күп төрле алфавит һәм язу системалары турында бай материал тупланган. Аваз системасына корылган беренче алфавит-финикция алфавиты. Аңа нигезләнеп гарәп, грек, латин һәм башка төрле алфавитлар безнең эрага кадәр X гасырда ук барлыкка килгән. Дөньядагы бик күп халыклар аларны үзләренең милли алфавитларын төзүдә нигез итеп ала.

Хәзер музейда төрле илләрдән килгән 265 төрле «Әлифба» бар. Алар арасында Азәрбайҗан халыклары – курд, тамин, сахир милләтләре; угро-фин халыклары – коми, мари, мордва, удмурт, манси, хант, саами милләтләре, мисыр, таиланд, япон һәм башка халыкларның әлифбалары бар.

«Әлифба» музее Арча педагогия көллияте тормышында зур роль уйный. Шушындагы материалларга нигезләнеп, диплом һәм курс эшләре языла, фәнни эш алып барыла. Музей каршында экскурсоводлар төркеме эшли. Соңгы кыңгырау, көллият белән саубуллашу бәйрәмнәре дә биредә үткәрелә. Экскурсияләр татар, рус, инглиз, немец һәм төрек телләрендә оештырыла. Алар кунаклар өчен генә түгел, укучыларның үзләре өчен дә файдалы. Дөньяда өч меңгә якын тел бар ди. Аларның барысының да үз «Әлифба»лары бар икән. Методик яктан алар бер үк нигездә төзелгән. 30 тел белгән кеше планетадагы теләсә кайсы кеше белән аралаша ала дип саныйлар «Әлифба» авторлары.

Музейда беренче алфавитларның килеп чыгышы турында кызыклы мәгълүматлар тупланган, төрле халыкларның идеографик язу үрнәкләре бирелгән. Кайсы телдә ничә хәреф барлыгын белү дә кызыклы. Латин графикасында – 26, грекларда – 28, Индонезиядә яшәүче бер кабиләдә 12 хәреф тә җиткән. Кытайда исә 25 меңнән артык иероглиф бар, урта мәктәптә аларның 300ләбе генә өйрәнелә икән.

Татар халкы исә йөз еллар дәвамында гарәп мәдәнияте һәм әдәбияты тәэсирендә яшәгән. Гарәп телен татарлар IX гасыр ахырыннан куллана башлаган. Әмма татар мәгърифәтчеләре татарның үз графикасын, үз алфавитын булдыру мәсьәләсен даими рәвештә куя килгәннәр.

Дөнья халыклары әлифбалары һәм язу үрнәкләре арасында Иван Фёдоровның 1574 елда эшләп бастырган букваре – «Азбука» да бар. Бу, әлбәттә, аның күчермәсе, ә төп нөсхәсе Американың Гарвард университетында саклана. Шуннан бирле азбукага эзлекле рәвештә өстәмәләр керә. Руслар үз алфавитларын беркайчан да алыштырмыйча, бары тик сыйфатын гына яхшырталар, әледән-әле төзәтмәләр кертәләр һәм ул бүген дөньяда иң яхшылардан санала. Әйтик, немец алфавитында бер хәрефне икешәр-өчәр аваз белдерсә, азбукада мондый хәл юк. Русларның «Букварь»лары һәрвакыт тотрыклы, «продаже не подлежит, обеспечивается государством» диелгән. Бу җәһәттән алардан үрнәк алырга гына кала.

Музейда 1740 елгы мәдрәсә интерьеры тарихи яктан төгәл күрсәтелгән. Анда шәкертләрнең көнкүреш әйберләрен күрергә була, шунда ук – Коръән. Шәкертләрнең дәрестә ничек утыруларын, әйберләрне ничек саклауларын төсмерләргә була. Шәкертләр шул ук бүлмәдә чаршау артында йоклаганнар да. Борынгы мәдрәсәләрнең уку планы да сакланган. Ул хәзерге планнан әлләни аерылмый. Шул ук фәннәр, телләр өйрәтелгән, физика, арифметика, астрономия, химия. Залда шулай ук XX гасырның 60 нчы еллары интерьерлары – парталар, кара такта, кара савытлары...

Музейдагы һәр экспонат кызыклы. Шулай да биредә иң мөһиме – «Әлифба». Хәер, нәниләр өчен продукция зур зәвык, тырышлык белән эшләнә. Музейга тупланган бай материалны җыюда көллиятнең тарих укытучысы Хөсәен Хәйруллин, озак еллар директор вазифасын үтәгән Илдус Сәгъдиев Татарстан берләштерелгән дәүләт музее фәнни хезмәткәрләре күп көч куйганнар. Көллият ишегалдында «Әлифба»га һәйкәл дә торгызылды.

## Кеше китә – җыры кала

Татарстанның халык язучысы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Мөхәммәт Мәһдиевне чын мәгънәсендә туган ягы җырчысы дияргә мөмкин. Аның барлык әсәрләре дә туган ягы табигатенә, якташларына мәхәббәт белән сугарылган. «Исәнме, туган ягым! Исән-сау тордыңмы? Мин бит әллә ниткән күтәренке – романтик хыяллар, куәтле җырлар патшалыгыннан кайтып киләм. Синдә яшәп, синдә үләргә, шушы җирдә күмелергә дип кайтып киләм. Тормышның авыр минутларында юатырга онытма мине. Син бит җырларга бик бай, бик моңлы, бик хәсрәтле алар. Шулай да, миңа авыр булганда, мине юатырга онытма...» – дип язды М.Мәһдиев.

Мөхәммәт Мәһдиев әсәрләре аша без сугышка кадәрге, сугыш һәм аннан соңгы чордагы татар авылы тормышын, аның гореф-гадәтләрен, күңел серләрен укып белдек. Язучы тормышны үзенчә күрде, бәяләде һәм берәүгә дә ярарга тырышмады, тормышта очрый торган катлаулы вакыйгаларны да моңсу юмор аша укучыларына җиткерде. Табигатькә мәхәббәте чиксез иде әдипнең: һәр үсеп утырган агач, чишмә, очып барган кош турында әйтер сүзе күп иде аның.

Мөхәммәт Сөнгатулла улы – XX гасыр татар әдәбиятының соңгы чирегендә татар авылы тормышын чагылдырып, кабатланмас әсәрләр, образлар тудыручы, күпсанлы очерклар, мәкаләләр иҗат итеп, аңыбызны, тормыш тәҗрибәбезне баеткан шәхес.

М.Мәһдиев үзе туып-үскән җирдә яшәүче кешеләрнең гыйбрәтле язмышларын «Без – кырык беренче ел балалары», «Кеше китә – җыры кала», «Торналар төшкән җирдә», «Бәхилләшү» әсәрләрендә тасвирлады. Язучының «Ачы тәҗрибә авазы» дип исемләнгән соңгы китабы белән танышкач, укучы язучының катлаулы, каршылыклы язмышын күрде һәм автор галим буларак та ачылды.

Дөрестән дә, язучы, галим М.Мәһдиевнең рухи мирасы бай, тормышы үзенчәлекле, аны киләчәк буыннарга җиткерү зарур. Нәкъ шуны күздә тотып, әдипнең туган авылы Гөберчәктә 2000 елның 13 июлендә Мөхәммәт Мәһдиев музее ачылды. Язучының васыяте буенча, музей бинасы Мәһдиев туган йортның бакчасында зур, зиннәтле агач бинада урнашкан. Музей бинасының бер ягын китапханә били.

Музейдагы экспонатлар мөхтәрәм язучының балалык, үсмер, студент чагын һәм аны галим буларак чагылдыралар, һәм, ниһаять, безнең алга үзенең кабатланмас әсәрләре белән халык күңелен яулаган, хаклы рәвештә халык язучысы исеменә лаек булган әдип образы килеп баса. Биредә М.Мәһдиевнең дуслары, замандашлары, укучылары,

геройларының прототиплары белән очрашасың. Язучы туып-үскән йортның эчке күренеше, эти-әнисе белән бәйле истәлекләр һәм Казандагы фатирындагы эш бүлмәсе күренешләре аеруча хәтердә саклана.

«Мөхәммәт бик нечкә психолог һәм күзәтүчән кеше иде. Беркем күрмәгән нәрсәләрне күрә, кирәк вакытта берәүне дә рәнҗетмәстән көлә һәм көлдерә белә иде», – дип язды академик Индус Таһиров.

М.Мәһдиевне күп кеше язучы буларак белсә, аның шагыйрьлек сыйфатлары да сокландырырлык иде. 1959 елда язылган менә бу юлларны хәтергә төшерик:

*Тыңладыңмы яр буенда дулкын тавышын?*
*Сизмәдеңме шул вакытта йөрәк сагышын?*

Сагыш... Бу сүз күңелгә әллә нинди уйлар китерә. Әйе, һәркем сагына Мөхәммәт аганы. Вафатына егерме елдан артык вакыт үтсә дә, аның әсәрләре үлемсез, мәңгелек. Әсәрләре үлемсез булганда, аның авторы да яши, күңел түрендә саклана. Татарстанның халык язучысы Мөхәммәт Мәһдиев бу дөньядан бик иртә китте, ләкин ул татар халкының сөекле улы, бөек язучы булып әдәбиятыбыз тарихында үзенә тиң урынны күптән тапты инде.

М.Мәһдиев әсәрләрен кулга алуга, күңелгә ниндидер җылылык хисе иңә, рәхәт булып китә. Аның әсәрләре гадилеге, халыкчанлыгы белән аерылып тора. Алар моң белән сугарылган, һәр сүзе энҗе-мәрҗән кебек тезелгән. Күренекле әдип Аяз Гыйләҗев болай дип язган иде: «...Мәһдиев теле – милли байлыгыбыз. Аның сурәтләү чараларының палитрасы, тел бизәкләребезнең кабатланмас вә тутыкмас көзгебез түгелмени?...»

М.Мәһдиев – олуг язучы булу өстенә, олпат хәлфә, галим, остаз да иде. Аңарда гыйлем алган студентлар арасыннан да илгә-көнгә билгеле каләм әһелләре, галимнәр, мөгаллимнәр үсеп чыкты. Алар да үз чиратларында остазларының рухын һәрвакыт яд итеп, аның туган авылындагы музеен яңа экспонатлар белән баетуга үз өлешен кертер, иншаллаһ.

2009 елның июнь аенда М.Мәһдиевнең биш томлыгы дөнья күрде. Бишенче томда өр-яңа материаллар тупланган. Язучы үзен драматургия өлкәсендә дә сынап караган, аның ике пьесасы – «Әгәр җилләр очырса», «Хәсрәтле өч көн» бишенче томда үз урыннарын алган. Аның балаларга җиткерәсе уй-фикерләре дә шул ук китапта бәян ителгән. Киләчәктә бәлки тагын да күбрәк томлыклары чыгар, чөнки Мөхәммәт аганың иҗади мирасы зур. Язган мәкаләләрен генә җыйнасаң да, үзе әллә ничә китап булыр иде.

## Шүрәле урманнары

Үрнәк бистәсендә табигать, аерым алганда, урманнар белән бәйле ике музей бар. Беренчесе – Арча урман хуҗалыгының тарих музее, икенчесе – Сунар урманчылыгындагы җәнлекләр һәм үсемлекләр музее.

Район мәйданының 32 мең гектарын биләгән урманнар табигатьнең хозурлыгын, һаваның саф, чиста булуын тәэмин итәләр. Табигать үзенчәлекләре буенча район урман зонасына керә. Казансу елгасының югары агымындагы ак һәм кара чыршылы урманнары үзенең куелыгы, агачларның төзлеге белән типик тайга урманнарына охшый. Хәзер инде урманнар аз калган, алар территориянең 11 процентын гына тәшкил итә. Урманнарның күбесе киселеп, кыр-басуларга әверелдерелгән.

Киселми калган урманнарның күпчелеге киң яфраклы агачлардан тора. Алар күпкатлы. Биек агачлардан имән, юкә өстенлек итә, өрәңге һәм карама да бар. Куаклар катында чикләвек куагы һәм башкалар очрый. Урман үләннәре – сәрдә, тайтояк, keләчел, калканлы абага, йолдыак, урман миләүшәсе яхшы үсә. Зур булмаган урман җирләре болын һәм басу үләннәре (болын күкчәсе, тукранбаш, ала миләүшә, шайтан таягы, кузгалак һ.б.) белән «чүпләнгән». Сирәк урыннарда каен һәм усак агачларыннан торган вак яфраклы урман «утраулары» очрый. Яфраклы урманнарда кош сайраган,

бөҗәкләр безелдәгән тавышлар ишетергә, куян, төлке, поши, кабан дуңгызларын очратырга була.

Музей экспонатлары бу төбәкнең табигате, урманчыларның династияләре белән таныштыра, урманга, андагы җәнлекләргә һәм үсемлекләргә сакчыл караш тәрбияли. Тукай урманчылыгы осталарының талдан үреп ясалган хуҗалык кирәк-яраклары, чыпта сугу өчен кулланыла торган станок игътибарны җәлеп итә. Җеп эрләү машиналары, ат арбалары, көпчәкләр, чаналар... – шулай ук урманчыларның хезмәт җимеше.

Агач үстерү – авыр эш. Аның мәшәкатен, мөгаен, урманчы гына аңлыйдыр. Чәчү орлыклары тупланмасында савыр, нарат, монгол имәне, шомырт һәм күп кенә башка төр агачлар. Шунда ук озак еллар Арча урман хуҗалыгын җитәкләгән, хәзер Татарстан урман хуҗалыгы министры Алмас Нәзировның «Урманнар – җирнең матурлыгы», «Татарстан Республикасы Арча урман хуҗалыгы питомникларында утырту материаллары үстерү» дип исемләнгән китаплары.

Музей бинасының интерьерлары, агач материалларны кисеп, сәнгатьчә зур зәвык белән эшләнгән. Бу эштә Үрнәк бистәсе мәктәбе укучылары да актив катнашкан. Экспонатлар арасында каен суы җыю җайланмалары, урман хезмәткәрләре тамгалары, кием формалары үрнәкләре. Кош оялары, урман чәчәкләреннән гербарийлар, гөмбәләр, бөҗәкләр тупланмасы биредә булучыларны сокландыра, табигатькә мәхәббәт уята.

Урман хуҗалыгы хезмәткәрләре себеркеләр дә бәйли, стеналарны бормалы болан мөгезләре белән дә бизи, буралар да сата. Музейда урмандагы ял почмаклары да күрсәтелгән. Шунда ук агач кашыклар, бал, прополис, маринадланган гөмбә, каен суы, төрле максатлар өчен әзерләнгән librтакталар урын алган. Гаҗәеп бай шул бу якларның урманнары.

Музей ишекләре балалар өчен дә, олылар өчен дә һәрвакыт ачык. Бу исә бирегә килүчеләргә табигать белән якыннан аралашырга, аның серләрен өйрәнергә мөмкинлек тудыра.

***

Арча шәһәренең үзәк мәйданына иҗатлары милли хәзинәбезгә әйләнгән, бу изге туфрактан көч алган, туган ягының саф һавасын күкрәк киереп сулап үскән, чын мәгънәсендә халык шагыйре һәм язучысы исемен йөрткән Габдулла Тукай, Галиәсгар Камал, Гомәр Бәширов, Гариф Ахунов, Мөхәммәт Мәһдиевләрең бронза бюстлары урнаштырылган.

Вакытында Арча район башкарма комитетын җитәкләгән кеше буларак, бүгенге Президентыбыз Рөстәм Нургали улына бу төбәкнең бөек шәхесләре белән бәйле урыннарны тәртипкә китерүдә үзенә дә турыдан-туры катнашырга туры килде. Шуңа күрә Арчаның тарихын да, халкының нәрсәгә сәләтле булуын да яхшы белә Президент. Арча районының 75 еллыгы билгеләп үтелгәндә, ул болай дигән иде: «Арча ягы – татар халкының сөйләм һәм әдәби телен саклаган, татар мәгърифәтенең һәм татар әдәбиятының Курсави, Мәрҗани, Күлтәси, Тукай кебек «алтын баганалары» үсеп чыккан данлыклы Казан арты үзәге. Биредә гомер-гомергә мул уңыш үстергән, һөнәрчелек белән шөгыльләнгән мәдәниятле халык яшәгән. Арча төбәгенең бәрәкәтле җирлегендә туып-үскән бөек мәгърифәтчеләр, күренекле фән һәм сәнгать эшлеклеләре, танылган белгечләр һәм җитәкчеләр, илебезнең төрле почмакларында яшәп, халкыбызга фидакарьләрчә хезмәт иткән. Арча районы халкы бу күркәм традицияне бүгенге көндә дә дәвам иттерә, үз туган ягының данын еракларга тарата».

Күп көч куеп музейларда тупланган материаллар белән республика мәктәпләрендә укучы һәр баланы таныштырырга кирәк. Урта һәм югары һөнәри уку йортлары студентларына да бу музейларны карау бик файдалы булыр иде. Бәлки, киләчәктә Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы, Мәдәният министрлыгы белән берлектә, музейлардан файдалану буенча махсус план да булдырыр.

**Әгъзам ФӘЙЗРАХМАНОВ**




*«Казан утлары» журналының редколлегия әгъзаларыннан бер төркем. Алгы рәттә (сулдан уңга): Шәйхи Маннур, Мирсәй Әмир, Гариф Ахунов, Ләбибә Ихсанова, Әмирхан Еники; басып торалар – Рәфик Нәфиков, Атилла Расих, Шәүкәт Галиев, Рафаэль Мостафин, Гали Халит. 1968 ел.*




*«Казан утлары»ның 1000 саны чыгу уңае белән. Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында узган тантанадан күренеш. Сәхнәдә – редакция коллективы. 2006 ел.*



*«Татмедиа» бинасы*




*«Казан утлары» журналының*
*95 еллыгы уңаеннан чыгарылган*
*буклетның тышлыгы*



*«Казан утлары»ның 70 еллык юбилей тантанасында. 1992 ел.*

# 95

# «БЕЗНЕҢ ЮЛ» ЖУРНАЛЫ ҺӘМ ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ

Төп әдәби журналыбыз булган «Казан утлары»на туксан биш ел тула. Димәк, бу зур тарихлы басмабызның беренче адымнарын 1922 елдан алып саныйбыз. Нәкъ шушы елның май аенда аның совет чоры элгәрләреннән берсе булган «Безнең юл»ның беренче саны чыкты. Әлбәттә, бу исемгә шул чор вазгыятенә туры килә торган мәгънә салына. Ник дигәндә, октябрь түнтәрелешеннән соң узган биш ел эчендә әдәбият-сәнгатьнең илдә урнашкан рәсми идеологиягә хезмәт итәргә тиешлеге төп юнәлеш буларак каралды. Бу әлеге басманың да ниндилеген билгеләдe, ул гыйльми-сәяси, әдәби-иҗтимагый айлык журнал булачак дип тәгаенләнде. Димәк, гыйльми-әдәби басма. Әмма шул ук вакытта сәяси-иҗтимагый нигездә икәнлеге дә билгеләнеп куелган. Хәер, аның Татарстан Үзәк Башкарма Комитеты һәм Халык Комиссарлары Советы органы булуы да моны ачык күрсәтеп тора (әле ярый фирка өлкә комитеты органы түгел, алай булган очракта аның йөзе бары тик сәясилек белән генә билгеләнер иде).

Шулай да җәмәгатьчелек журналны әдәби басма буларак күрергә тели. Инкыйлабка кадәр «Аң», «Шура» кебек журналлардан әдәби сулыш белән танышып барырга күнеккән татар укучылары мондый мөмкинлек булдырылуга нык зарыккан иде. Аны гамәлгә ашыру юлында Галимҗан Ибраһимовның башлап йөрүе дә очраклы булмады. Бу эштә яңа хакимият алдында абруй казанган, шул ук вакытта әдип һәм шәхес буларак ышанычлы, иҗатта, Г.Тукай әйтмешли, үзе дә ат уйната торган шәхес булуы мөһим иде. Дөресен әйткәндә, журналны Г. Ибраһимов җаваплылыгына ышанып ачалар да. Мөхәррирлекне үз кулына алуы да үзеннән-үзе аңлашыла. Беренче сан аның «Иҗтимагый-әдәби хәрәкәтләр тарихын тикшерүдә марксизм ысулы» дигән мәкаләсе белән ачыла. Бу зур күләмле хезмәтнең дәвамы алдагы санда урнаштырыла. Аңа «Татар әдәбияты тарихының мөндәриҗәсен билгеләү мәсьәләсе» дигән аныклык кертелүе авторның үткәндәге әдәбиятларны тикшерүдә һәм бәяләүдә совет идеологиясенең төп принципларыннан берсе турында гамьләнүнең үзәккә куелуы хакында сөйли. Димәк, бу әлеге басма үз эшчәнлегендә анда бәян ителгәннәрне истә тотарга тиеш дигән сүз иде, димәк, ул программа буларак тәгаенләнде. Әлеге мәкалә Г.Ибраһимовның «Имля, тел, әдәбият мәсьәләләре» (1924), «Әдәбият мәсьәләләре» (1960) китапларында өлешләп басылып киленгән иде, бары тик 1978 елда гына «Әсәрләр»нең 5нче томындаербөтен итеп бирелде. Бу, дөресен әйткәндә, сүз бара торган басманың гына түгел, тулаем сүз сәнгатебезнең үткәнен, хәзергесен өйрәнүгә күрсәтмә, ягъни методологик нигез хезмәтен үтәүче мәкалә буларак кабул ителде.

Сүз дә юк, Г. Ибраһимов яңа шартларда фикер сөрешен Шәрык әдәбиятлары белән бәйләнештә алып бара алмый. Кереш сүздә үк турыдан-туры рус әдәбиятын яңа нигездә тикшеренүдәге беренче тәҗрибәләрне барлаудан башлап китә. Ахырга кадәр шушы юнәлешне тайпылышсыз дәвам иттерә. Әле Г.Сәгъди, Г.Газиз һәм Г.Рәхимнәрнең бу мәсьәләләргә күп ачыклык кертәчәк әдәбият тарихы китаплары язылмаган, көндәлек килеп чыга торганнарына бүген үк җавап көтелә. Шулай да Г.Ибраһимов татар әдәбияты тарихындагы дәверләрне аеру мәсьәләсендә Г.Сәгъди лекциясендә бәян ителгәннәрне дә хәтереннән чыгармый. Ләкин мәсьәләнең төрле катламнарын аерып чыгару һәм аларны өйрәнүнең юлларын икърар иткәндә, ул нигездә үз карашларына

таяна. Шулардан башланган сүз егерменче еллар дәверенең иҗтимагый зәминнәре (нигезләре) тирәсенә килеп чыга. Бу мәсьәләдә, әлбәттә, Г.Ибраһимов, үзе әйткәнчә, «рус телендәге тарихи материализм хакындагы күп кенә әсәрләргә» таяна һәм башкаларны да шулай эшләргә өнди. Бу мәкаләгә шактый дәвамлы тукталуыбызның сәбәбе шул: «Безнең юл»ның «бисмилласы» шундый рухта булуы журналның гына түгел, бәлки матур әдәбиятыбызның үткәненә һәм бигрәк тә киләчәгенә нинди караштa булырга тиешлеккә дә ачыклык кертә иде.

Әлеге күрсәтмәләр укучыларга барып ирешкән очракта гына ниндидер кыйммәткә ия була. Димәк, бу басма, барыннан да элек, менә шушы максат өчен кирәк. Шулай да, күрәсең, журналны оештырып җибәрү төрле кыенлыклар белән бәйле булгандыр. Әйтик, аның беренче саны май аенда чыкса, икенчесе исә июнь-июль айларында, ягъни ике айга бер сан булып чыга. Г.Ибраһимов шул ук елның 27 июнендә «Татарстан» газетасында басылган «Татар җөмһүриятенең икенче елында әдәбиятыбызның язмышы» дигән мәкаләсендә «Безнең юл» журналын арттыру лазем», дип язып чыккан икән, димәк, болай фаразлау дөреслектән ерак тормый. Алай гына да түгел, инде, берничә ел үткәч тә, 1926 елда ул фирка өлкә комитетының матбугат бүлегенә журналның эшен яхшырту кирәклеге турындагы мәсьәләне көн тәртибенә куюны сорап мөрәҗәгать итә. Беренчедән, ул басманың эчтәлегеннән бик үк канәгать түгел. Икенчедән, тиражының кечкенәлеге дә киләчәккә өмет тудырмый. Өлкә комитетының шул вакытлардагы матбугат бүлеге мөдире Латыйф Гомәр сүзләренә караганда, шул болай ди:

– Аңа катнашучы, үзләренең әсәрләрен бастыручы бер төркем язучылар яисә журналистлар журналы гына түгел ул, республика журналы ул, партия журналы. Дөресе, бөтен Советлар Союзындагы татарлар өчен чыгарыла торган бердәнбер әдәби һәм иҗтимагый-политик журнал. Шуңа күрә аңа бик нык игътибар итәргә кирәк. Партия өлкә комитетының журналга игътибары җитәрлек түгел. Аның эчтәлеге, эше, торышы һәм планы белән чын-чынлап кызыксынмый. Хәтта аны тарату мәсьәләсе белән дә җитәрлек шөгыльләнми. Партия ячейкалары төрле журналлар яздыралар, ләкин шулар арасында «Безнең юл» юк.

Әлеге сөйләшүнең нәтиҗәсе буларак, 1926 елның 25 гыйнварында шушы бүлектә бу мәсьәлә махсус тикшерелә. Г.Ибраһимов до-

## БҮЛӘККӘ – ҖЫР

*1982 елда Чаллы шәһәренә «Казан утлары» журналының 60 еллык бәйрәменә чакыру килде. Шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Гөлсабира Хәкимова ул вакытта Язучылар берлегенең Чаллы бүлеге җитәкчесе Разил Вәлиевне, «Энергетик» мәдәният сарае директоры Шамил Закировны (Чаллыдан киткәч, ул Г.Камал исемендәге театр директоры булды), яшь композитор Илгиз Закировны һәм мине (үзем мәдәнияттә 50 елга якын эшлим. Чаллыга Казан театр училищесын тәмамлап кайткан идем) үзенә чакырып алды. Ни бүләк итәргә? Уйлаштык. Җыр бүләк итәргә булдык. Разил Вәлиев: «Сүзләрен язам», – диде, ә Илгиз Закиров – көен. Матур гына җыр туды. Кем җырлар? Бертавыштан: «Азат Хөсәенов җырлаячак», – дидек. Азат Хөсәенов бу эшкә зур теләк белән алынды, тик аны эштән азат итү генә авыр булды. Ул «Татэлектромаш» заводында эшли иде. Мин генераль директор Григоровичка, цех начальнигы Фәйрузовка кердем. Азат Хөсәенов (хәзер ул – Татарстанның халык артисты Азат Тимершәех), юбилей кичәсендә чыгыш ясап, «Казан утлары» дигән җырны бүләк итеп кайтты. Җыр гомерле булды, аны Газинур Фарукшин да җырлый. Хәзер дә бу җырны халык белә, онытмый.*

**Гөлзада РЗАЕВА**

кладыннан соң Г.Гали, Ф.С.-Казанлы, С.Атнагулов, Ф.Бурнашлар төрле тәкъдимнәр белән чыгыш ясыйлар. Барыннан да элек сүз журналның укучыларны йомшак җәлеп итүенең сәбәпләрен ачыклау тирәсендә бара. Алар түбәндәгеләргә кайтып кала дип исәплиләр: «Безнең юл», иҗтимагый-сәяси булудан бигрәк, әдәби-нәфис басма булырга тиеш. Аның эше белән элеккечә ТҮБК һәм ХКС түгел (аларның башка эшләре дә күп), Мәгариф Комиссариаты җитәкчелек итәргә бурычлы. Журналның үз вакытында чыгып баруын да тәэмин итәргә кирәк.

Утырышта тагын бер мөһим мәсьәләгә игътибар ителә – басмага язучыларның төрле агымнарын җәлеп итәргә, аларны «Безнең юл» тирәсенә тупларга. Ул шартларда менә бу соңгысын аеруча әһәмиятле дип санарга кирәк. Чөнки 1925 елның 18 июнь карары игълан ителгәннән соң, язучыларны пролетар, крестьян, юлаучыларга бүлеп йөртү башланды. Аларның пролетар дип аталганнарына өстенлек бирелеп, калганнарына, бигрәк тә «юлаучылар»га кырын карау гадәти хәл булып бара иде. Димәк, бу мәсьәләдә камыт бавын артыграк тарттырганлыкларын фирка өлкә комитетында бераз аңлый башлаганнар дигән сүз. Уйлап карасаң, исең китәрлек, әле бу вакытта хәтта Һ.Такташ та вак буржуазия катламыннан чыккан «юлаучылар» катламында гына дип карала иде бит. Пролетар рухлы язучы дип саналыр өчен 1924 елда «Гасырлар һәм минутлар» поэмасын язу гына җитмәгән, күрәсең.

Шул ук утырышта журналның яңа редколлегиясе дә раслана. Аңа Г.Ибраһимов, Гомәр Галиев һәм Гаяз Максудов кертелә. Янә шундый искәрмә дә ясала: редколлегиягә тагын ике кеше өстәләчәк, аларны партия өлкә комитеты секретариаты ачыклаячак. Димәк, составта фирка вәкилләре булмаган очракта журналның кирәкмәгән идеология ягына салулап китүе мөмкин икән. Г.Ибраһимов белән Г.Галиевкә дә ышанып бетмәгәч, башкаларга ни сан инде. Гомәр Галиев, журналның сәркатибе буларак, аның тиешле идеология юнәлешендә булуы һәм вакытында чыгып баруы өчен зур тырышлык куеп эшли. Басма тирәсенә төп каләм көчләрен тупларга тырыша. Әлбәттә, бу эштә Галимҗан Ибраһимовның үз үрнәге дә, аның ихласлылык һәм таләпчәнлек белән, халкыбызның төрле яклап үсеше кирәклегенә инанып, фидакярләрчә хезмәт куюы да оештыру вазифасын үти. Әйтик, ул адашы – күренекле галим Г.Нигъмәтинең даими катнашып килүен тәэмин итүне аеруча хуплый. Чөнки ул елларда Г.Нигъмәти бездә иң төп нәзари әзерлекле әдәбиятчыларның берсе булды, шуңа күрә Г.Ибраһимов аның фән һәм тәнкыйтьнең алга китүенә аеруча күп файда китерерлек шәхес икәнлеген дөрес бәяли. Аның китаплары Казанда да, Мәскәүдәге ил халыкларының үзәк нәшриятында да чыгып тора. Бер үк вакытта ул газета-журналларда, шул исәптән «Безнең юл»да да күтеп алынган авторларның берсе булып әверелә. 1927-1929 елларда гына да аның биредә дистәләрчә мәкаләсе дөнья күрә: «Ун ел эчендә безнең әдәбиятыбыз», «Кави Нәҗми», «Максим Горькийның беренче хезмәт еллары» (1927), «Туфан шигырьләрендә производство мотивлары» (1928), «Яңа башкорт әдәбияты» (Башкортстан җөмһүриятенең унъеллыгы уңае белән), «Үсү һәм тирәнәю елы», «Яңа үрләргә таба» (1929) һ.б. Г.Нигъмәтинең журналда бәхәс кузгатуга исәпләнгән чыгышлары да игътибарны җәлеп итә. «Җиңелчә» тәнкыйтькә «тирән» анализ турында» (1927), «Имзасыз һәм җавапсыз мәкалә турында» (1929) кебек мәкаләләрен шул җәһәттән карарга кирәк.

Г.Ибраһимов үзе дә биредәге бәхәсләрдә катнашудан читтә калмый. 1924 елда «Имля, тел, әдәбият мәсьәләләре» дигән китабына язган кереш мәкаләсендә ул бу хакта үзе дә әйтә: «Моннан ике-өч ел элек «Татарстан» битендә Җ.Вәлиди белән бер көрәш булып үткән иде. Ул аннан «Безнең юл»га күчте. Бу турыда тартышу идеалистлар белән материалистлар арасындагы көрәш иде. Бу мәсьәләне кискен рәвештә бөтен тәфсиле, барлык тармаклары белән өзеп куярга вакыт җитмәде». Шуннан чыгып, ул нәтиҗә ясый: «Татар әдәбиятын тәфсилле рәвештә язып, шул нигез өстенә бинаны корып, тәмам тарих итәргә кирәк булачак» *(Ибраһимов Г. Әсәрләр. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1978. – Б.472)*. Бу сүзләрдән шул аңлашыла: «Безнең юл» татар әдәбиятының үткәнен, бүгенгесен барлауда, бу хакта нигезле, зур хезмәтләр булдыруга һәм аның киләчәген

күрергә ярдәм итә торган басма буларак, үз вакыты өчен бик әһәмиятле бурыч үтәде. Журналның башка авторлары да Г.Ибраһимов белән фикердәш иде. Бу яктан Г.Гали дә җитәкчесенең иң тугрылыклы каләмдәше булды. Аның «Бер мәсьәлә тирәсендә», «Оешу алдыннан» (1927) кебек шул көннәр өчен аеруча үзәктә торган гамәлләр турында кайнарлык белән сүз кузгатуы үзе генә дә авторның чор сулышы белән яшәвенә мисал иде. Аларның беренчесендә «татар язучыларының оешмасын төзү»нең мөһимлеге турындагы төрле карашларга нигезле бәя бирелә. Ул 1923 елда «Октябрь» һәм «Сулф» төркемнәре арасындагы кайбер бәхәсләрне сагына, хәзер язучылар тынычланып калдылар, битарафлыкка ияләнеп баралар дип хәвефләнә. Әнә, ди ул, «Безнең юл»ның үткән номерларының берсендә Г.Нигъмәти нәрсә дигән иде: «Яшьләр арасыннан төрле имзалар, яңа талантлар чыга, матур-матур әйберләр язалар. Ләкин шуларга җитәкче булырлык, юл күрсәтерлек мәкаләләр күренми». Г.Ибраһимовның бу юнәлештә, мәкаләләр язу белән генә чикләнмичә, татар язучылары җәмгыяте төзү турындагы ниятен куәтли һәм үзе дә нәтиҗә ясап, «Татар совет язучылары оешмасы» төзергә кирәк дигән катгый фикерен белдерә. «Оешу алдыннан» дигән чыгышында исә канәгатьләнү белән, «Язучылар оешмасы төзелү хәзер беткән эш хәленә килеп бара», ди дә, бу оешманың нинди булырга тиешлеге турында үз карашын бәян итә.

Биредә бер нәрсәне ачыклап китү зарур. Г. Гали егерменче елларның беренче яртысында, аерым алганда, 1923 елда әдәбият мәйданында булган җанлылыкны (аныңча, активлыкны) юксына. Ни өчен өч-дүрт елда язучылар сабырланып калдылар дигән сорауга җавап бирә алмый, мондый кимчелекне каләмле кешеләрнең үзләреннән генә күрә. Дөресендә, безнең карашыбызча, башка сәбәп тә була. 1925 елның 18 июнендә ил күләмендәге фирка җитәкчелеге «Матур әдәбият өлкәсендә партиянең политикасы турында» дигән карар кабул итте. Анда язучыларны билгеле бер идеология кысаларына кертү буенча гына түгел, аларны оештыру ягыннан да күңеле иҗат иреге теләгән шагыйрьләргә, әдипләргә һәм драматургларга ят булып тоелган нәрсәләр тагы да бар иде. Аерым алганда, аларны социаль чыгышлары буенча ышанычлы яки чит төркемнәргә бүлеп карау үзе генә дә каләм әһелләренә тигез карамауга китерә. Алар инде талантлары буенча түгел, бәлки нинди катламнан булуларына карап бәяләнәләр. Болар,

## УКЫЙБЫЗ, ЯРАТАБЫЗ!

*«Казан утлары» – халкыбыз журналы. Аның һәр саны милли рух, милли гамь белән сугарылган, халкыбызның үткәнен, киләчәген чагылдыра. Журналны Татарстанда гына түгел, Россиянең башка бик күп төбәкләрендә, шул исәптән бездә – Урта Уралда да күтәреп алалар. Мин үзем Свердлау өлкәсе Берёзовск шәһәренең үзәк китапханәсендә эшлим. «Казан утлары» журналын 2012 елдан алдырабыз, журналны күбрәк өлкәннәр укый. Без – Татарстаннан читтә яшәүче укучылар буларак, каләм ияләренең өр-яңа әдәби әсәрләре: роман, повесть, хикәя, пьеса, шигырь-поэмалары белән әүвәл шушы журнал аша танышабыз. Безгә бигрәк тә «Шигърият һәм чәчмә әсәрләр», «Тарих» рубрикалары ошый.*

*Журналдагы өр-яңа әдәби әсәрне уку – җәйге челләдә салкын чишмә суын учыңа алып рәхәтләнеп эчү белән бер. Җан сафлана, күңел сафлана. Көн, дөнья яктырып китә.*

*Яраткан журналыбызны 95 яшьлек юбилее белән чын күңелдән котлыйбыз! Мөхәррирләргә, гамәли хезмәткәрләргә һәм каләм ияләренә иҗат уңышлары телибез! «Казан утлары» укучыларын киләчәктә дә сөендереп торыр диеп ышанып калабыз!*

**Гөлсия ГАРИПОВА**

әлбәттә, аларны сагайта, як-якка карап эш итә башлауга китерә. Мондый шартларда язучыларның күпчелеге күләгәдәрәк калуны хуп күрәләр икән, моңа гаҗәпләнергә кирәк идеме соң? Үзе дә шушы мохитне тудыруда катнашырга тиеш булган Г.Галигә мәсьәләнең бу ягын бәяләргә комачаулык итә торган нәрсә – ул да булса аның фиркаләләрчә уйлауны һәм эш итүне табигый дип санавы.

Г.Галинең «Бер мәдәни бәйрәм алдыннан» (1927) дигән мәкаләсенә аерым тукталасы килә. Ул Г.Ибраһимовның егерме еллык хезмәт бәйрәменә багышланган. Ягъни Г. Ибраһимовның «Әл-ислах» газетасында 1907 елның 10 октябреннән башлап басылган «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» әсәре дөнья күрүгә ике дистә ел тулуны зурлап билгеләп үтүгә әзерлек эше башлану – бу бер Г.Ибраһимовның гына түгел, бөтен татар әдәбияты-мәдәнияте һәм фәне өчен әһәмияте ягыннан бер олуг вакыйга буларак бәйрәм ителергә тиешлеген Г.Гали нигезле итеп дәлилләргә алына, аның бөтен татарлар өчен уртак тантанага әверелергә тиешлеген әйтә. Г.Сәгъди дә шушы уңайдан «Зур әдипләребездән берсе» дигән мәкалә белән чыга (1927). Бәйрәм өчен сәбәп булган әлеге хикәя тирәсендәге уйланулары рәвешендә язылган икенче бер мәкаләсендә дә Г.Сәгъди Г.Ибраһимов шәхесенә һәм каләм көченә олы бәя бирә *(Кызыл Татарстан. – 1927. – 20 ноябрь)*.

Г.Толымбайский да – журналның актив язышучысы. Мәсәлән, «Татар әдәбияты (2) (Еллык хисап урынына)» дигән мәкаләсендә Г.Ибраһимов игътибарны аның «Безнең юл»да басылган бер тәнкыйть мәкаләсенә юнәлтә. Гомәр иптәш Уфадагы язучы Г.Фәхринең тугандаш башкорт халкына мөнәсәбәттә урынсыз куелган исем белән басылып чыккан әсәрен сүтеп җыя. Г.Ибраһимов та бу әсәрнең исемен «гаҗәеп бер идеализм» дип атый, Г.Толымбайскийның бәясен хуплый.

Бу елларда, Гыйльми үзәк җитәкчесе буларак та, Г.Ибраһимов халкыбызның гомуми тарихын, шулай ук рухи тормышының төрле катламнарын өйрәнү мәсьәләләрен дә игътибар үзәгендә тота, башка каләмдәшләренең дә бу юнәлешләрдә кызыксынып эшләүләрен күрергә тели. Аның 1925 елда «Безнең юл»да басылган ике мәкаләсе моны ачык күрсәтә. Беренчесендә 1905 елгы революция вакытында татарлар хәрәкәтен өйрәнү өчен материаллар җыюның мөһимлеген искәртә (№1). Бу еллардагы хәл-әхвәлләргә татарларның төрле катламнарының мөнәсәбәте турында тулы бер роман язган әдип буларак (сүз «Безнең көннәр» романы турында бара), ул үзе дә әлеге мәсьәләләргә тирән үтеп кергән кеше. Шуңа күрә аның сүзе бу очракта белеп әйтүгә нигезләнгән булуы белән кызыклы иде. Икенчесендә исә, ул үзе әйткәнчә, «татар феодализм заманын өйрәнергә» ярдәм итүче материалларны барлый. Аерым алганда, Сәхипгәрәй ярлыгы, Хәзинә, Ибн Фадлан сәяхәтнамәләре тирәсендә сүз алып бара (№3).

Әдип һәм галим Г.Ибраһимов үзенең бу чордагы күпкырлы эшчәнлегенә бәйле гамәлләре һәм аларның нәтиҗәләре турында да журнал укучылары белән даими уртаклашып тора. Ник дигәндә, ул башкарган эшләр халкыбыз өчен генә түгел, гомумтөрки әһәмиятлелеге ягыннан да мөһим. Әйтик, 1926 елның гыйнвар ахыры-февраль башында Бакуда беренче тюркология съезды эшли. Г.Ибраһимов анда «Төрек телләре имлясы» турында доклад белән чыкты. Әлеге доклад төрки халыкларның гарәп графикасы нигезендәге имлясын тагын да камилләштерү, тугандаш төрки телләрнең үзенчәлекләрен генә түгел, бәлки уртак якларын да исәпкә алып, аларны бер-берләренә якынайтырга омтылу җәһәтеннән дә кызыклы иде. Ул болар хакында «Безнең юл»да журнал укучылары белән сөйләшә, «Беренче тюркология съезды нәрсә бирде?» дигән хисап белән чыга (1926. – №1, 2). Кайбер төрки халыклар латинга күчү турында уйласалар да, Г.Ибраһимов катгый рәвештә «бездә латинга күчәргә мөмкинлек юк», дип белдерә.

Әмма инде «Безнең юл»ның 1927 елгы 8нче санында ТҮБК һәм ХКСның татар язуына латин (яңа төрки) шрифты (хәрефе) кертү турында карары игълан ителә. Г.Ибраһимовның рәсми җитәкчелек сәясәте белән туры килеп бетми торган башка мәсьәләләрдәге карашларына да тискәре мөнәсәбәт белдерелә башлый. Бу әдипнең

Кырымда авырып яткан чакларына туры килә. Фирканең Татарстан өлкә комитеты аның «Татар мәдәнияте нинди юл белән барырга тиеш?» дигән хезмәтендәге кайбер тезисларына карата да өнәмәүчән фикерләр белдерә. Эш болайга китә башлагач, ул 1930 елдагы 3нче санында «Ике мәсьәлә уңае белән» дигән хат бастыра, «партия оешмасы тарафыннан күрсәтелгән бөтен хаталарны икърар итәм», дип әйтергә мәҗбүр була.

1927 елга әйләнеп кайтсак, Г.Ибраһимовның иҗаты башлануга бәйле бәйрәмгә әзерлекнең барышы журналда тәфсилле яктыртып барыла. Хәтта татарлар яши торган барлык төбәкләрдән моңа багышланган чараларның ничек үткәрелүе турындагы хәбәрләрне җибәреп торуларын үтенеп журнал махсус мөрәҗәгать баса әле. 1928 елдагы икенче сан тулысынча шушы вакыйгага багышлана. И.Рәхмәтуллин мәкаләсенең исеме аеруча күзгә ташлана – «XX еллык бөек әдәби-гыйльми хезмәт бәйрәме». М.Таһиров, Г.Алпаров, З.Бәшири, Х.Наум чыгышлары Г.Ибраһимов эшчәнлегенең төрле якларын яктыртуга багышланган. Бәйрәм үзе 1928 елның 10 мартында Дәүләт театры бинасында уза. Докладларны профессорлар Г.Нигъмәти белән Г.Линсцер ясый. Нык авыруы сәбәпле, Г.Ибраһимов үзенең хезмәт туенда катнаша алмый, Кырымда дәвалануын дәвам иттерергә мәҗбүр була.

Шуңа күрә ул 1927 елдан башлап журналга мөнәсәбәтле эш алып барудан да читләшергә тиеш була. Шул елның май аенда басманың чыга башлавына 5 ел тулуны билгеләп үтү чараларында да катнаша алмый. Бу вакыйгага багышлап бастырган мәкаләләрендә Ф.Бурнаш, Г.Сәгъди, Х.Вәли, М.Гали, Х.Кәрим, Г.Гали, Г.Кутуй һәм башкалар Г.Ибраһимовның әлеге матбугат чарасын гамәлгә куюдагы эшчәнлегенә югары бәя бирәләр, аны сагынуларын, юксынуларын белдерәләр. Июнь санында үткәрелгән «Язучылар үзләре һәм безнең әдәбият» дип исемләнгән анкетага алынган җаваплар Г.Ибраһимовны укучы буларак та канәгатьләндергәндер дип уйларга кирәк. Һ.Такташ, Г.Кутуй, Х.Туфан, К.Нәҗми, Г.Толымбай, Ш.Усманов, Х.Хәйриләрнең чыгышлары яшьләрдә нәкъ ул күрергә теләгән сыйфатларның шактый үсеш алганлыгын күрсәтә. Бу аеруча аларның иҗатларында күренә. Әлеге җәһәттән Һ.Такташ аеруча аерылып тора. Мәгълүм булганча, Һ.Такташ иҗатының чәчәк атуы егерменче елларга туры килә. Ул Казанга күчеп килгән елда «Безнең юл» журналы да яшәп китә. Шагыйрьнең Казан чоры иҗаты тулысынча диярлек әлеге басма белән бәйләнгән. Ул аның битләрендә «Нәләт» (1922), «Мәңгелек әкият» (1923), «Сыркыды авылы» (1925), «Нәни разбойник», «Җырланмаган җырлар турында» (1926), «Мәхәббәт тәүбәсе» (1927) кебек әсәрләрен бастыра. Димәк, Һ.Такташның шагыйрь буларак үсешен шушы басма саннары буенча да эзлекле күзәтү мөмкинлеге бар. Г.Ибраһимов Һ.Такташны «көчле, үткен талантлы шагыйрь», дип атаган. Аның бу бәясе шагыйрьнең шуннан соңгы иҗатында тулысы белән расланды. Әйткәнебезчә, аның үсеш баскычларын Г.Ибраһимов нигез салган «Безнең юл» сәхифәләреннән дә күрергә мөмкин. Шуны ук бик күп авторларыбызга карата да әйтергә була.

1929 елның июль аеннан «Безнең юл» чыгудан туктады. Аның урынына ТАППка кергән язучылар органы булган «Атака» журналы пәйда булды. Бераздан «Яңалиф» дигән басма да ике ел дәвамында чыгып килде. 1932 елдан әлеге ике журнал урынына оештырылган яңа басма исә «Совет әдәбияты» дип атала башлады. 1965 ел уртасында исә исеме «Казан утлары» дип үзгәртелде. Шөкер, «Казан утлары», яше арткан саен, һаман яшәрә, куәтләнә бара. Аңа алга таба да хәерле гомер телик.

**Фоат ГАЛИМУЛЛИН**



## «БЕЗНЕҢ ЮЛ»

1922-1930 ЕЛЛАРДА ЧЫГА

**ҖИТӘКЧЕЛӘРЕ**:
Г.Мансуров (1922-1923, №7), М.Бурундуков (1923, №8 – 1924) – җаваплы мөхәррирләр; редколлегия (Г.Гали, Ш.Камал, Г.Толымбайский, Х.Туфан, Г.Сәгъди) – 1925-1928, №5; редколлегия (Г.Гали, Ш.Камал, Г.Толымбайский, Г.Сәгъди) – 1928, №6 – 1929, №10; редколлегия – 1929, №11 – 1930, №4.

Шәриф
Байчура

# ПАТША ХӨКҮМӘТЕ ВАКЫТЫНДА ТӨРКЕСТАНДА ТАТАР МӨГАЛЛИМНӘРЕ

Татар шәкертләре вә мөгаллимнәре хәятында *(тормышында)* яз көннәрендә казакъ далаларына барып балалар укыту вә шуннан кыш көнендә мәдрәсәдә укырлык «хосуль» *(керем, акча)* җыеп кайту аерым бер дәвер тәшкил итә. 19 нчы гасырның соңгы яртысында, бәлки, соңгы чирегендә, татарның иске ысулы кадим мәдрәсәсе шәкертләре вә хәлфәләре тарафыннан ясала торган бу сәфәрләрдә, бер яктан, иң мөһиме, матди як – кыш көне мәдрәсәдә укырлык запас җыйнау булып, икенче яктан, ярым мөселман, ярым мәҗүси булган казакъ халкының балаларына дин өйрәтү рәвешендә булган. 5нче елдан соң бу агым тагын киңәебрәк «Галия», «Хөсәения» вә «Мөхәммәдия» шәкертләре тарафыннан якындарак казакъ далаларына гына тукталмастан, Төркестан өлкәсендәге казакъ-кыргыз, үзбәк вә хәтта төрекмәннәр эчендә йөри башлау юлына керә.

12-13нче елларда бу эш тагын да киңәя төшеп, Сырдәрья, Җидесу вилайәтләрендә татар мөгаллиме булмаган кышлак (авыл) юк дип әйтерлек бер рәвешкә керә; Фәрганә вә Сәмәрканд вилайәтләрендә дә татар мөгаллимнәренең саны арта.

Татар мөгаллимнәренең бу рәвештә Төркестанда күбәюләре ул вакытта Төркестан җир *(җирле)* халыкларының һәрбер хәрәкәтен, алар арасындагы һәрбер үзгәрешне нык тәгькыйб итеп *(күзәтеп)* бара торган жандармерия идарәләренең, Победоносцев кебек мәшһүр урыс миссионерларының күзенә бәрелми үтә алмый. Бу хәрәкәтне аерым бер җитдият вә игътибар белән тикшереп бару башлана. Бу тикшерү бары Төркестан күләмендә, Төркестан жандармерия идарәсе даирәсендә генә тукталып калмыйча, эшне төптән алып бару өчен, татар мөгаллимнәренең чыккан урыннары – Уфа, Казан, Оренбург жандармерия идарәләре белән дә мөнәсәбәт тотылып, әтрафлы тикшерү юлында бара. Ниһаять, 1913 нче елларда Төркестан жандармерия идарәсе вә миссионер Победоносцевларның күрсәтүләре буенча, мәшһүр кадет Милюков тарафыннан Думада бу хакта доклад ясалып, татар мөгаллимнәренә Төркестанда укыту катгыйян мәныг ителә *(катгый тыела)* вә татар мөгаллимнәрен нык тәгькыйб башлана.

Төркестанның уйгану тарихында вә ул дәвер татар мөгаллимнәренең хәятында зур әһәмиятле урын тоткан бу вакыйгаларның бер читен ачып бирә торган Төркестан жандармерия идарәсеннән алынган түбәндәге документны без «Безнең юл» укучыларына гарыз *(тәкъдим)* итәргә уйладык.

Бу мәсьәлә артык ачык булганга, бу документка тәфсыйль биреп торырга хаҗәт күрелмәде.

* * *

**«Рәкым (номер) 5809 (Махсус шәгъбәнең *(бүлекнең)* полиция департаментына җибәргән доклады)**
**ЯШЕРЕН**
**4 август, 1913 ел.**

## Төркестан генерал-губернаторына

Шуның белән бергә Төркестан өлкәсендәге мәктәпләр Назиренең *(инспекторының)* 1912 нче елдагы 11898 нче рәкымле доклад копиясен тәкъдим итеп, зате галиләрегезгә *(бөек затыгызга)* белдерәмен ки, махсус агентларның биргән хәбәре буенча, бөтен Төркестанда кыргыз-казакъ вә үзбәк халыкларының Русиядән килгән татар мөгаллимнәре тарафыннан яңа ысул белән хөр вә мөстәкыйль рәвештә укытылганлыклары мәгълүм булды. Хосусан, Сырдәрья вилайәте, Акмәсҗед, Казалы өязләрендә Русиядән килгән татар мөгаллимнәре булмаган казакъ авылы һич юктыр.

Татар мөгаллимнәренең бу муаффәкыятьләренә *(уңышларына)* түбәндәге эшләр сәбәп булса кирәк: җирле халык яңа ысул белән укытканда, иске мәктәпләргә караганда балаларның җиңел рәвештә уку-язуга өйрәнеп, укыган нәрсәләренең җиңел төшенгәнлекләрен беләләр. Кыргызлар балаларын «русско-туземный» мәктәпләргә бирергә куркалар. Чөнки муллалар, балаларны «русско-туземный» мәктәпкә биргәндә, аларның христиан рухы белән рухланып, бөтенләй христиан диненә чыгып китәчәкләрен сөйләп халыкны куркыталар.

Кыргызларның татарларга булган мөнәсәбәтләре дә ул чаклы ышанычлы булмыйча, Яурупа киемендә килгән кайбер татарлардан, балаларыбызны аздыралар, аларда ислам диненә булган кадер-хөрмәт калмас дип, ибтидаи *(башлангыч)* мәктәп бетергәннән соң балаларын яңа ысул белән укыттырмыйча, ысулы кадим мәктәпләренә бирәләр.

Мөгаллимнәр байлыгы булган кыргыз яисә үзбәкләр тарафыннан махсус чакырылып, бер гаиләдә булган берничә баланы укыталар һәм моның өчен вазифа итеп алты ай мөддәтенә *(вакытына)* 90 белән 150 сум арасында акча алалар. Артык байлыклары булмаганнары байлар кулындагы мөгаллимнәр белән сөйләшеп, аларга мәзкүр *(әйтелгән)* мөддәт өчен 25-30 сум биреп, балаларын укырга йөртәләр. Укыту, гадәттә, мөгаллимне чакырып китергән кешенең өендә була. Әгәр дә мөгаллимне мулла яхуд *(яки)* башка рухани сыйныфыннан булган кеше китерсә, ул вакытта укыту мәсҗедтә булып, мөгаллим һәр бала башына айга бер сум илле тиеннән биш сумга чаклы акча ала.

Казакълар эченә килә торган мөгаллимнәр, гадәттә, 5нче мартларга килеп җитәләр. 5нче марттан 20нче мартка кадәрле вакыт мөгаллимнәрне тәгаен итү эшенә сарыф ителеп, аннан соң казакълар Сарысу буе, Каратау һәм Акмулла областьләренә җәйләүгә китәләр (Акмулла областена азрак китәләр). Мөгаллимнәрне тәгаен итү, гадәттә, түбәндәге рәвештә була: мөгаллим кирәк булганда, волость һәм авыл башлыклары аркылы ишаннарга мөрәҗәгать итәләр, килгән мөгаллимнәр дә ишаннарга җибәреләләр. Халык тарафыннан булган мөрәҗәгать буенча, ишан килгән мөгаллимнәрне тәгаен итә. Казалы өязендә бу эш белән мәшгуль кеше мәшһүр ишан Хуҗамбирде ахундыр ки, аның Казалы шәһәрендә вә өязендә берничә мәсҗеде бардыр. Акмәсҗед өязендә мөгаллимнәр тәгаен итү эшен Әхмәд ишан Уразаев башкарадыр. Бу ишан шул өязнең Төгелем дигән бер урынында торып, җирле халык арасында һәртөрле могҗизалар күрсәтә торган изге кеше дип санала. Мөгаллимнәрнең күбрәге Уфадагы «мәдрәсәи Галия», «мәдрәсәи Госмания», Оренбурдагы «мәдрәсәи Хөсәения» вә Казандагы «мәдрәсәи Мөхәммәдия»нең мөгаллимнәре вә шул мәдрәсәләрнең югары сыйныф шәкертләреннән булалар. Бу шәкертләр эчендә җирле халыктан булганнары да очрый.

Истанбул, Бәйрут, Мәдинә вә Төркиянең башка мәшһүр шәһәрләрендә Русия мөселманнарыннан берничә уннар *(дистәләр)* белән хисапланырлык санда шәкертләр укыйлар. Алар, анда укуларын тәмам иткәннән соң, югарыда күрсәтелгән мәдрәсәләргә кайтып, мөгаллимлек итәләр ки, аларның тәрбиясе гаять тар милләтчелек

вә панисламизм рухында була. Шулай итеп, югарыда күрсәтелгән мәдрәсәләрнең панисламизм рухы белән сугарылган мөгаллим вә шәкертләре Төркестанга мөгаллим сыйфаты белән килеп, шунда бу мәсләкне таратучы булып хезмәт итәләр һәм балаларны Русия мәмләкәтенә каршы тәрбиялиләр.

Мәзкүр мәдрәсәләрнең эчендә Уфадагы «мәдрәсәи Галия» аерым урын тота. Анда дини гыйлемнәргә башка дөньяви гыйлемнәр дә бүтән мәдрәсәләрдән күп киң рәвештә укытыла. Шул сәбәпле бу мәдрәсәдә укып чыккан шәкертләр, башка яңа мәдрәсәләрдән чыгучыларга караганда, галимрәк вә тугры фикерлерәк булалар. Шуның өчен «мәдрәсәи Галия»дә укыган кешеләрнең тәэсире, бигрәк тә кыргызларга булган тәэсире, бик зур. Шуны да әйтергә кирәк ки: кыргызлар (казакълар) татар халкын үзләренә караганда югары күрәләр, шул сәбәпле кыргызларның татарлашулары бик тизлек белән бара.

Уфа вилайәте жандарма идарәсе начальнигының хәбәр итүенә караганда, «мәдрәсәи Галия»дә Төркестан өлкәсеннән түбәндәге шәкертләр укыйлар. Сырдәрья областе Акмәсҗед өязе Городов волосте Унынчы авылдан: 1) Баймөхәммәд Карнаин, 13 яшьтә, 2) Галибай Мөхәммәдев, 18 яшьтә, 3) Бирҗан Торсынов, 19 яшьтә, 4) Тынбай Калышев, 18 яшьтә, 5) Йосыфбай Исмәгыйлев, 18 яшьтә, 6) Мөхәммәдгали Уразаев, 24 яшьтә; Алтынчы авылдан: 7) Иргали Сәедбаев, 14 яшьтә; Сарский волость Унынчы авылдан: 8) Ширмөхәммәд Канчыкбаев, 20 яшьтә; Алтынчы авылдан: 9) Иргали Йосыпов; Телетол волосте Бишенче авылдан: 10) Колмөхәммәд Уразаев, 21 яшьтә; Җидесу вилайәте Епшен өязе Беренче авылдан: 11) Әбелгазый Юлчыбиков, 22 яшьтә, 12) Әбелгазый Чумиков, 21 яшьтә; Капал өязе Горно-Аксуский волость Бишенче авылдан: 13) Миһран Ирмакташев, 23 яшьтә, 14) Нигъмәт Мортазин, 20 яшьтә; Арасан волосте 5нче авылдан: 15) Әбүбәкер Чапчибиков, 21 яшьтә; Семипулат областе Павлодар өязе Анакузин-ский волость, 4нче авылдан: 16) Нигъмәтулла Күзәмбаев, 20 яшьтә, 17) Шәех Хаҗибиков, 26 яшьтә.

Оренбург вилайәте жандарма идарәсенең хәбәр итүенә күрә, яз көннәрендә мәдрәсә шәкертләренең бер бүлеге, хосусан, югарыгы сыйныф шәкертләре киң казакъ-кыргыз сахрасына таралып, анда аз вазифа бәрабәренә балалар укыталар. Аларның укытулары яңа тәртип белән булып, күп урыннарда яңа тәртип иске ысул укытуны җиңгән.

Казан вилайәте жандарма идарәсе начальнигының хәбәренә бинаән *(караганда),* Казан мәдрәсәләренең кайбер шәкертләре (шулар эчендә казакъ-кыргыз шәкертләре дә булганы хәлдә) яз көннәрендә казакъ далаларына таралып, анда казакъ-кыргыз балаларын укыталар да, шул хезмәтләренә каршы алган вазифалары белән кыш көннәрендә уку өчен үзләрен тәэмин итәләр.

Казакъ-кыргызлар эчендә таратыла торган казакъ телендәге китапларга килсәк, алар ике фирма тарафыннан нәшер ителә: берсе – Кәримевләр, икенчесе – Хөсәенев варисларының фирмасы. Бу ике фирма тарафыннан хәзергә чаклы житмешләп китап нәшер ителгән. Жандарма идарәсе тарафыннан бу китапларның һәммәсе каралып чыкты вә аларның эченнән әһәмияткә малик *(ия)* булганнары хакында Казандагы Матбугат эшләре комитетына хәбәр ителде. Бу китапларның спискы ошбуларга гыйлавә ителәдер *(беркетелә)* .

«Уян, казакъ!» исемле китапның таратылуы Казандагы Матбугат эшләренең вакытлы комитеты тарафыннан мәныг ителде *(тыелды)* һәм моның мөхәррире Миръягкуб Дулатов Омски судебный палатасы тарафыннан бер ел мөддәткә хәбескә *(кулга алынып ябылуга)* хөкем ителде.

Яшерен тикшерүләрнең нәтиҗәсендә, Русиядән килеп казакъ, үзбәк балаларын укытып яткан түбәндәге татар мөгаллимнәренең барлыгы мәгълүм булды.

Пишпәк өязе Тинай волостендә Даса Уранбаев дигән кешенең карамагында Нәҗметдин Шиһабетдин угылы Ишмөхәммәдев-Салихов казакъ балаларын укытмакта һәм Тинайдагы русско-туземный школада дин укытмактадыр. Ул үзе Уфа вилайәте Эстәрлетамак өязе Кармыш волостеның бер крәстиян баласы. Пишпәк шәһәрендә вә ярминкә мәсҗедләрендә татар мөгаллимнәре үзбәк вә кыргыз балаларын татар телендә укыталар. Пишпәктә яңа ысул белән укытыла торган мәктәпнең мөгаллиме Әхмәд Габделбәдыйгов, Мамадыш өязе Нижний Сөн волосте татарыдыр. Шулай ук Пишпәктә мөгаллимлек итүче Хәсәнҗан Галимҗан угылы Баязитов та Уфа вилайәте

Бирски өязе Әсән волосте Суык Күл авылы татары булып, «мәдрәсәи Галия» тәмам иткән кешедер.

Ташкәнд тимер юлы өстендәге «Бер Казала» стансасына якын авылда Госманбик Хуҗатов дигән казакъ өендә Садретдин дигән бер татар балалар укытмактадыр.

Шул ук юл буенда Чиле стансасыннан дүрт чакрым ераклыкта булган Скоблов авылында Харис Фәтхуллин дигән бер мөгаллим бар. Ул үзе Самар вилайәте Бозаулык өязеннән булып, «мәдрәсәи Галия» шәкерте.

Мөгаллимнәр билгеләү эшендә Скоблов кышлагында сәүдә итеп торучы Вятка вилайәте, Малмыж өязе Кокшин волосте вә Кокшин (хәзерге Кукмара районындагы Күкшел) авылының крәстияне Хәбибрахман Гыйбадуллинның күп хезмәте тиеп, бу кеше яңа килгән мөгаллимнәрне элек үз өенә кабул итеп, аннан акрынлап мөрәҗәгать иткән урыннарга аларны җибәреп тора. Хәзерге көндә Скоблов волостенда Гыйбадуллинның күрсәтүе белән тәгаен ителгән мөгаллимнәр бик күп булып, мәшһүррәкләре түбәндәгеләр: мөгаллим Габдессабур Дистанов – Уфа вилайәте Бәләбәй өязе Аксаков волостеннан булып, 3нче авылда тормактадыр. Скоблов кышлагыннан унбиш чакрымлык җирдә Малый Кутум авылында «мәдрәсәи Галия»дән килгән мөгаллим Исмәгыйль Кибилов торадыр.

Ташкәнд тимер юлы буендагы Солы түбә стансасына якын җирдә татар мөгаллиме Закир Рәшидев бар. Аның хатыны Мөнәүвәрә дә мөгаллимә булып, Кабил Иркәбаев дигән бер кыргыз *(казакъ)*да торадыр ки, бу кыргыз сәясәттән хәбәрдар, Төркия файдасына һәртөрле ярдәмнәр җыя торган кешедер. Май ае уртасында Ташкәндтән Акмәсҗед һәм аның өязенә алты татар мөгаллиме үтеп китте.

Чиназ ягында татар мөгаллимнәреннән Хәеров һәм Һади Даутовлар мөгаллимлек иттеләр. Боларның соңгысы Иске Ташкәндтә Пагахан дигән кешегә күчеп килде.

Богородский кышлагына якын бер кыргыз авылында татар мөгаллимәсе Бибимәрьям Исхакова торадыр.

Хөҗәнд өязе Далвирзин дигән урында Бикбулат атлы татар мөгаллиме бар. Бу – Әстерхан вилайәтеннән килгән кеше.

Хуканд өязендә – 6, Нәмәнган өязендә – 4, Широв стансасыннан 8 чакрымлык урында – ике татар мөгаллиме тора. Серов өязе Атамыш районы Кабил авылында ике татар мөгаллиме торып китте. Боларның берсе – Гыйбадулла Габидов, икенчесе – мулла Солтан Абдин Хуҗа угылы.

Бакаш күле буендагы мәҗүси кыргызлар арасында татар мөгаллимнәре кыргыз балаларын укыту белән мәшгуль булып, аларның фикере – мәҗүси кыргызларны мөселман итүдер.

Пишпәк өязе Тимербулат волостенда «мәдрәсәи Галия» тәмам итеп кайткан кыргыз мөгаллимнәре, рөхсәт алмастан мәктәп ачтылар. Лакүл волостенда «мәдрәсәи Галия» тәмам иткән Ишангали Арабаев дигән кыргыз мөгаллим рөхсәтсез мәктәп ачты.


Соңгы вакытларда хөкүмәтнең нык тикшерүен игътибарга алып, татар мөгаллимнәре бераз саклык белән хәрәкәт итә башладылар һәм алар акрын-акрын Сырдәрья областеннан Фәрганә, Сәмәрканд, Закаспий областьларына юнәлә башладылар.

Югарыда саналган кешеләрнең һәркайсы электән шөгъбәгә мәгълүм булган кешеләр түгел һәм аларның сәяси ышанычлыклары хакында һич мәгълүмат булганы юк.

Югарыда әйтелгәннәргә гыйлавә *(өстәмә)* итеп шуны әйтәмен ки: яшерен тәфтиш *(тикшерү)* эшләре, статский советник Миллерның тикшерүеннән хасил булган нәтиҗәләрне тасдыйк итәдер (раслый) һәм Сез җанәбе галиләрегез тарафыннан 1912 елның 25 гыйнварында Сырдәрья вилайәте мәктәпләр директоры вә халык мәктәбе инспекторларына бирелгән 844 рәкымле әсаси *(төп)* кагыйдәләргә хилаф булган эшләр белән көрәшмәклек кайбер мәэмүрләрнең *(чиновникларның)* ул эшләргә яхшы караулары вә бигрәк тә җирле халыктан булган Тәрҗеманнарның һәртөрле яңа планнарны халыкка белдереп торулары сәбәбеннән бик авырлашадыр.

Асыл нөсхәсенә имза иттем: подполковник Сизых. Тугры: ротмистр (имза)».

*1922, №5*




# «ЯҢАЛИФ»

1927-1932 ЕЛЛАРДА ЧЫГА

**ҖИТӘКЧЕЛӘРЕ**:
Ф.Сәйфи-Казанлы (1927, №1-7, 1928, №3-4, – мәсьүл (җаваплы) мөдир; 1929, №7-9, 12-15, 21-24, 1930, №1,2 – җаваплы редактор); Г.Әлми (1927, №8-9 – вакытлы мәсьүл мөдир, 1928, №1,2 – мәсьүл мөдир, 1928, №15 – вакытлы редактор), Ф.Сәйфи (1927, №10-12 – мәсьүл мөдир), 1928, №16 – 1929, №6 – редакторлары Ф.Сәйфи, Г.Әлми, И.Рәми, С.Борһан (1929, №10 – вакытлы редактор), И.Рәми (1929, №11 – техник редактор), Г.Нигъмәти (1929, №16-20 – вакытлы редактор, 1930, №3 – 1932, №10 – җаваплы редактор).

Мөхәммәт Яушев*

# БОЗ КУЗГАЛДЫ

*Бу «Боз кузгалды» мәкаләсе үзенең эченә татар музыкасының үткәннәреннән хәтергә алынырлык һәм, мәкаләнең авторы әйткәнчә, татар музыкасы тарихын яза башлаганда бер материал булырлык хәлләрне алганлыгын искә алып, асыл нөсхәсеннән берникадәр кыскартылып басылды. Мәкалә иясе татар музыкасының тарихын яза башлау мәсьәләсен күтәрә. Бу турыда, әлбәттә, ике фикер булмас, эшләнергә тиеш эш. Әлегә, тик, идарә татар музыкасының үткәне, хәзергесе, киләчәге турында язучыларга журнал битләре ачык икәнен белдерә.*

**Идарә**

Бу ел «Красная Татария» гәзитендә Украина культурасы турында «Боз кузгалды» дигән мәкаләне укысак, хәзер татар музыкасы һәм музыкантлары турында – 28-29нчы елда язылган С.Фәйзуллин, Г.Кутуй, Госманов һәм башка иптәшләрнең мәкаләләрен укыган соңында да татар музыкасы һәм музыкантлары турында «боз кузгалды» дисәк, дөрес булыр кебек сизелә. Музыка яратучы кечкенә генә бер музыкант булу сыйфатым белән һәм элегрәк заманнарда карт татар музыкантлары арасында булып, утырышып, алар белән татар музыкасы, музыкантлары турында сөйләшкәләгәнем дә булганга күрә хәтергә калганнарны язып үтүне тиешле таптым.

* Мөхәммәт Яушев (1893-1969) – скрипкачы. 1912 елдан милли музыкаль ансамбльләрдә, 1939-1959 елларда театрларыбыз һәм Татарстан радиосы оркестрларында уйный.

## Татарда музыканың таралуы һәм татар музыкантлары турында

Татар музыкасы качып-посып яшәгән, яшерен почмакларда сакланып килгән музыка ул. 1905-1906 елларда яшьләр тарафыннан сирәк-сирәк кенә ясала торган театр-кичәләрдә татарның иң борын заманнан килгән моңнарын уйный башлаганнар. 1907-1908 елларда Шәрык клубларында, әдәбият кичәләрендә уйный торган булганнар. 1907 елда әдәбият кичәсендә Гали Зайпин кечкенә генә бер салон оркестр да уйнатып караган. Ләкин татар музыкасына әһәмият бирелмәгән, татар халкын музыка сәнгатенә төшендерү кыен булган.

Шулай да, заманында булган татар музыкантлары, музыка осталары музыка сәнгатен халык арасына кертергә тырышканнар. Гариф Минкин, аның энесе һәм Гыйлаҗ Сәйфуллиннар тарафыннан татар көйләре калай пластинкаларга кисеп таралганнар. Татар көйләре граммофон пластинкаларына да кергән. Әнә шул калай һәм граммофон пластинкалар аркылы татар музыкасының таралуын белсәк, Минкин, Зайпин, С.Рәхманколов, Сәйфуллин, Ахун, Шаһиәхмәтев, Әхмәдуллин, Хөсәеневләр онытылмаслык нәрсә калдырганнар дип әйтми китеп булмый.

Татарда музыка сәнгатенең күзгә күренеп таралуы 1909-1910 елларда башлана. Татарлар яши торган районнарда ачылган кинотеатр «Свет», «Буф» театрларында өзлексез рәвештә татар музыкантлары татар көйләрен уйныйлар. Музыка әкренләп гармун, пианино, скрипка, мандолина, гитара шикелле уен кораллары аркылы тарала. Татар яшьләре арасында музыкага мәхәббәт арта бара. Яшереп-яшереп кенә музыкага өйрәнә башлыйлар: чөнки музыка коралын кулга тоткан килеш Печән базарыннан, «Көфер почмагы»ннан үтеп китү кыен, арттан төрле кабахәт сүзләр белән сүгеп калалар. Шуңа карамастан, уйнарга иң җиңел булган уен коралы – мандолинага өйрәнү көннән-көн алга китә. 1912-1913 елларда «Сәйяр» труппасы башлыгы Г.Кариев музыка аркылы халыкны театрга җәлеп итүне үзенең алдына көндәлек бурыч итеп куя, татар музыкантларын еш-еш үзенә чакырып уйната торган була. Театрга музыка керү аркасында, электә 30-40 кешедән артмаган тамашачы, театрга килүче арта башлый. Шул ук елларда концерт һәм танцы кичәләре дә куела башлый. Татарның музыкант, җырчылары аерым-аерым номерлар үти башлыйлар. Шул ук елларда һәвәскәрләр труппасы дөньяга чыга. Яшьләр арасында музыкага омтылыш тагы да арта. 1915-1916 елларда укучылардан «Берек», яшь хезмәткәрләрдән «Тукай» исемендә түгәрәкләр төзелеп эшли башлый. Шулай итеп татар музыкасы, татар сәхнәсе белән берлектә татар дөньясына керә.

*1929, №12*

## Татар көйләрен чыгаручылар-язучылар

Скрипкәче карт Мөхәммәтша абзыйның сөйләве буенча, көйләрнең күбесе авылларда, җыеннарда, моңсу җирләрдә чыксалар да, аларны чыгаручылар да, чыгарырга тырышучылар да заманында булган. Бу карт хәтерендә калган Нижнийнең Хәбибуллине, аның сакланып калган «Хәбибулкин маршы», Саратовның Усмановы, Уфаның Ижбулдиннары сөйли.

1914-1915 елларда Казандагы көй чыгаручылардан Г.Сабитов һәм

Яруллиннарны да искә алып үтәргә кирәк. Алар тарафыннан язылган көйләр татар музыкачылары тарафыннан уйнала, җырчылары тарафыннан җырлана.

Бу турыда надан татар муллаларының һәм татар фанатикларының йогынтысы астында татар халкы музыкага салкын караган дияргә кирәк. Гәзитләрдә язучы-рецензиячеләребез дә татар музыкасына игътибар бирмәгәннәр, музыканың халыкка булган тәэсирен аңламаганнар. Югарыда язылган концерт кичәләре турында гәзитләргә гомуми рәвештә язылса да, аерым татар музыкасы һәм музыкантлары турында кыйммәт, (бәя) бирелми иде. Гомумән алганда, татар матбугаты музыкага әһәмият бирми иде. 1916-1917 елларда «Зөләйха» пьесасының фәрештәләр пәрдәсе өчен язылган Габәши музыкасы кайбер драматургларны уятты дияргә кирәк. Шул көннән башлап Мирхәйдәр Фәйзи, Тинчурин, Бурнашлар музыканың театр пьесасына кирәк бер нәрсә икәнен аңлап эшкә керештеләр.

Советлар Җөмһүриятенең 11 елы эчендә татар музыкасы үзенә бөек бер урын алды. Татар музыкасының кирәклеге һәм халыкка биргән тәэсире аңлашылды.

Патша хөкүмәте вакытындагы музыка мәктәпләренә татарның кабилиятле һәм яхшы музыкант булу теләге белән янган татар җегетләре, югарыда сөйләнгән муллалар коткысы аркасында, керә алмадылар. Шул ук мәктәпләр эшче-крәстиян балаларына ябык булганлыктан, соңгылары да чын теләкләренә ирешә алмадылар. Тик аларның уттай ташкан йөрәкләреннән чыккан теләкләре Татарстан Советлар Жөмһүрияте барлыкка килү белән генә вөҗүткә чыкты (тормышка ашты).

Татарстан Советлар Җөмһүриятенең музыка мәктәбе, техникумында татар эшче-крәстиян балалары укып ята. Татарстан Мәгариф Комиссарлыгы тарафыннан җибәрелеп, Мәскәү консерваториясендә укып ята торган яшьләребез бар.

Татар музыкантлары арасыннан атылып чыккан пианист Салих Сәйдәшев зур бер талант иясе [булып] танылып, композитор исемен алды. Арабыздан чыккан бу яшь өметле композиторның тагын да зур адымнар белән алга китүен көтәргә кала.


Татарда сәхнә тарихы эшләнде.

Инде татар музыкасы тарихын язу чараларын да күрергә кирәк. Ияләре (белгечләре) бу зур эшкә әһәмият биреп керешерләр һәм Гыйльми Үзәк якыннан торып ярдәмләшер дип уйлыйбыз.

*1929, №12*

# «АТАКА»

1930-1932 ЕЛЛАРДА ЧЫГА




**ҖИТӘКЧЕЛӘРЕ:**

Г.Гали (1930, №1-7), К.Нәҗми (1930, №8 – 1931, №4), З.Гали (1932, №9-10) – җаваплы редакторлар; редколлегия (1932, №11 – 1932, №20).

# ДОНБАССТА ТАТАР МАТУР ӘДӘБИЯТЫ

Донбасста татар телендә чыга торган «Пролетар» гәзите системный рәвештә әдәбият сәхифәләре урнаштырып, шахтёрлар арасыннан дистәләрчә яңа каләмнәрне матбугатка чыгарды. Хәзер инде бу гәзит каршында татар шахтёрларының әдәби оешмасы да төзелеп эшкә кереште. Бу оешманың беренче альманахы җәй актыкларында Казанда басылып чыгачак.

Хәзерге көндә Донбасс шахталарында 40 меңгә якын татар пролетариаты социализм төзелешендә эшли. Шуларның күп өлеше – авыллардан килгән вакытлы эшчеләр. Бу шахтёрлар арасында башка өлкәдәге эшләр белән бер яктан культура эшләре дә үсә.

Инде шахтёрлар арасында матур әдәбият эшенең үсешенә килсәк, бу өлкәдә әле эшнең йомшак баруын күрәбез.

Шахтёрлар арасында әдәбият белән кызыксынып, аңар катнашырга теләүчеләрнең саны байтак кына. Ләкин моңа чаклы аларны оештырып, тиешле юлбашчылык биреп баручы юк иде. Шуңа күрә алар күренекле рәвештә күтәрелеп, үсеп китә алмадылар. ТАПП һәм МАПП татар секциясе тарафыннан конкрет рәвештә даими ярдәм булмады дәрәҗәсендә.

Хәзер Донбасста татар шахтёрлары өчен татар телендә «Пролетар» гәзите чыга. Менә бу гәзит забой төпләреннән күтәрелгән яшь шахтёр язучыларны үз кочагына алып тәрбияли башлады. Аларның иҗатларын үстерүдә күп ярдәм итте. Әдәбият битләрендә яшь шахтёр язучыларның әсәрләренә киң урын бирелеп, тиешле тәнкыйтьләр дә булгалады.

Менә шул «Пролетар» гәзите тирәсенә оешкан язучылардан күптән түгел генә татар пролетариат язучылары секциясе төзелде. Ул хәзер урыннарда түгәрәкләр төзеп җитәкчелек итү эшенә кереште.

Шахтёр язучыларның пролетар гәзитендә басылган әсәрләре әле художество ягыннан башлап үсү баскычында гына булса да идеология ягыннан нык тотнакчылар, үзләренең бөтен көчләрен бүгенге көннең бурычларын – күмер планын арттырып үтәүгә юнәлдергәннәр.

Мисал өчен «Пролетар» гәзитенең 24нче санында чыккан яңа күтәрелеп килүче шахтёр Ш.Халикъ иптәшнең «Үсәбез» дигән шигырен алсак, ул үз шигырендә реконструкция чорының үзәк мәсьәләләреннән булган шахталарның машиналашуын күрсәтә. Шигыренең беренче юлларын ук: *«Шахта, синең тормыш / Тиз арада үсте, үзгәрде»,* – дип башлап китә. Машиналар эшләвен: *«Конвейерлар забойда / Сал-сал, диеп күмер ташыйлар, / Машиналар күмер тауларын / Корыч тешләр белән ашыйлар»*, – дип күрсәтә.

Гомумән, «Пролетар» гәзите забойлардан күтәрелеп килгән язучыларга төрле яктан ярдәм итә. Ләкин безгә ТАПП һәм МАПП татар секцияләренең бик зур ярдәмнәре кирәк әле.

**Ж.ИРТУГАНОВ**
*1932, №5-6*




# «СОВЕТ ӘДӘБИЯТЫ»

1933-1965 ЕЛЛАРДА ЧЫГА

**ҖАВАПЛЫ РЕДАКТОРЛАР:**

Г.Нигъмәти (1933, №1), К.Нәҗми (1933, №2-9, 1934, №1-11, 1947, №11 – 1949, №4), Г.Гали (1933, №10, 1935, №1-3; 1933, №11-12 – вакытлы җаваплы редактор), Г.Разин (Г.Бәширов) (1937, №6-10, 1941, №7-11, 1942, №4-6, 9-10; 1937, №3, 11, 1938, №1-2, 1945, №1-4 – вакытлы җаваплы редактор; 1942, №3 – җаваплы редактор өчен), Г.Иделле (1937, №4-5, 1945, №5 – 1947, №6) Г.Ильяс (1937, №12), Т.Имаметдинов (1938, №3 – 1941, №6), И.Гази (1942, №7-8 – вакытлы җаваплы редактор), Г.Кашшаф (1942, №11 – 1944, №4, 1944, №10-12; 1950, №5 – 1958, №2 – вакытлы җаваплы редактор), Х.Хәйри (1944, №5-9 – вакытлы җаваплы редактор), А.Шамов (1949, №5 – 1950, №4 – вакытлы җаваплы редактор), А.Гомәров (1958, №3 – 1963, №3), Г.Мөхәммәтшин (1963, №4 – 1965, №5); 1947, №7-10 – редколлегия.

# ФРОНТ ГАЗЕТАЛАРЫ

Май ае безнең илебездә – олы бәйрәмнәр ае. Беренче май – бөтендөнья хезмәт ияләренең бәйрәм көне, бишенче май – большевистик матбугат көне, тугызынчы 1 май – Бөек Җиңү көне. Безнең халкыбызда, киләчәктә тагын да зуррак җиңүләргә ирешү өчен, бөек бәйрәм көннәрендә үзенең үткән данлы эшләренә борылып карап, аларны искә төшереп үтү гадәте бар. Шул яхшы гадәтне дәвам иттереп, без журналыбызның бу номерында Бөек Ватан сугышы чорында чыккан фронт газеталары турында кыска гына белешмә биреп үтәбез.

1941-1945 елгы Бөек Ватан сугышы кебек дәһшәтле сугышны кешелек тарихы белми әле. Бу тиңсез сугышның төп авырлыгын безнең илебез – Советлар Союзы үз иңендә күтәреп чыкты. Фашизмның тешләренә кадәр коралланган урдалары искәртмәстән, сугыш игълан итмичә, юлбасарларча безнең илебезгә һөҗүм иттеләр. Советлар иленә үлем куркынычы янады. Йә яшәү, йә үлем – мәсьәлә менә шулай катгый куелды. Бүтән юл юк иде.

Бу коточкыч сугышта җиңеп чыгар өчен Совет кешеләре үзләренең барлык материаль һәм корал көчләренә генә түгел, бәлки барлык рухи көчләренә дә тулы мобилизация ясарга тиеш булдылар. Совет Армиясе шартларында сугышчыларны һәм офицерларны рухи яктан, идея ягыннан тәрбияләү эше аның политуправлениеләре өстенә төште. Ә политуправлениеләрнең эшләрендә фронт газеталары иң үзәк урында тордылар.

Фронт газеталары үзләренең битләре аша сугышчылар массасына большевиклар партиясенең ялкынлы сүзләрен, иптәш Сталинның приказларын, докладларын, чыгышларын җиткереп тордылар; алар совет сугышчылары алып бара торган сугышның гадел сугыш икәнен төшендерделәр; сугышчылар массасында Ватанга, большевиклар партиясенә, Бөек Сталинга изге бирелгәнлек, олы мәхәббәт, ә дошманнарга көйдергеч нәфрәт тәрбияләделәр. Фронт газеталары, үзләренең битләре аша бөтен совет халкының теләген белдереп, сугышчылар массасын Ватан өчен яңадан-яңа батырлыклар, каһарманлыклар күрсәтергә, көрәштә кыюлыкка, тапкырлыкка, чыдамлыкка чакырдылар. Сугышчыларның политик аңнарын күтәрү белән бергә, фронт газеталары, сугышчыларны һәм офицерларны хәрби осталыкка өйрәтү буенча да, бигрәк тә, бөек Ватан сугышы тәҗрибәсен туплау, гомумиләштерү

һәм өйрәнү буенча чиксез зур эш алып бардылар. Алдынгы, батыр сугышчыларның сугыш тәҗрибәсе шунда ук, фронт газеталарының битләре аша, барлык сугышчыларга җиткерелеп киленде. Кыскасы, фронт газеталары дошманны тар-мар итүдә бик җитди роль уйнадылар.

Кызыл Армия Баш Идарәсенең махсус боерыгы буенча, 1942 елдан башлап, фронтларда милли телләрдә дә – украин, казакъ, үзбәк, грузин, азәрбайҗан, татар һ.б. телләрдә дә фронт газеталары чыгарыла башлады. Аларның гомуми бурычы – дошманны җиңү эшенә хезмәт итүдән гыйбарәт иде.

Ватан сугышы чорында татар телендә унбишләп исемдә фронт газетасы чыкты. Аларда татар совет язучыларының һәм журналистларының иң яхшы көчләре катнаштылар.

1942 елның июнендә Төньяк-көнбатыш фронтта «Ватан өчен» газетасы чыга башлады. Ул 1944 елның мартына кадәр дәвам итә һәм, фронт гаскәрләре белән бергә, Старая Руссадан Житомирга кадәр данлы юл үтә. Аның редколлегия составында редактор урынбасары булып майор Гани Гыйльманов, хәрби корреспондентлар булып А.Әхмәдиев, Хатип Госман, Шәрәф Мөдәррис, Нәфикъ Яһудин иптәшләр эшлиләр. Бу редакциядә танылган язучыларыбыз Гомәр Разин һәм Мирсәй Әмир озак вакытлы иҗат командировкасы үткәрәләр һәм үзләренең очерклары, хикәяләре белән турыдан-туры газета эшенә катнашалар.

1942 елның декабрендә 1нче Украин фронтында (элек Воронеж фронты) «Ватан намусы өчен» дигән газета чыга башлый һәм 1946 елның июленә кадәр дәвам итә. Воронеж – Киев – Берлин – Вена – менә «Ватан намусы өчен» газетасының үткән данлы юлы. Башта бу газетаның редактор урынбасары булып шагыйрь капитан Әхмәт Ерикәй, соңыннан драматург майор Риза Ишморат эшли. Хәрби корреспондентлар булып Гали Хуҗи, Мөхәммәт Садри, Зәйни Шаһиморатов, Госман Бакиров, Әнвәр Ямангулов һәм Габдулла Шәрипов иптәшләр эшлиләр. Язучы Газиз Иделле һәм журналистка Фатыйма Галиева бу редакциядә озак вакытлы иҗат командировкасында була һәм үзләренең очерклары, хикәяләре белән газета эшенә актив катнашалар. Фронт бүлекләренең берсендә хезмәт иткән яшь шагыйрь Г.Рамазанов газетага актив катнаша һәм шул газета битләрендә каләмен чыныктыра. Гази редакциясе татар халкына җавап хатын оештыра һәм «Җиңү юлы» исемле әдәби җыентык чыгара. Газетаның редактор урынбасары Риза Ишморат Берлин өчен барган сугышларда яралана.

1942 елның ноябрендә Калинин фронтында (соңыннан 1нче Балтыйк буе фронты) «Алга, дошман өстенә» газетасы чыга башлый һәм 1945 елның июненә кадәр дәвам итә. Бу газета Калинин шәһәреннән Кенигсбергка кадәр барып җитә. Редакторның урынбасары булып майор Минһаҗ Гыймадиев эшли. Хәрби корреспондентлар булып Шәйхи Маннур, Афзал Шамов, Абдулла Әхмәт, Котдус Әхмеров, Колмөхәммәтов, Фазыл Басыйров иптәшләр эшлиләр. Фронт частьларында хезмәт итүче яшь шагыйрьләрдән Мансур Гаяз, Исхак Закиров һәм Рахман Хөсәенов иптәшләр бу газетага актив катнашалар. Соңыннан бу иптәшләр дә дошманга каршы көрәштә батырларча һәлак булалар.

Бу газета редакциясендә художник Байназар Әльменев иҗади командировкада була һәм ул ясаган күп кенә рәсемнәр газета битләрендә басыла.

1943 елның январенда Көньяк фронтта, данлы Сталинград янында, «Сталин байрагы» исемле газета оештырыла һәм Кырым операциясе тәмам булгангача – 1944 елның июненә кадәр чыгып килә. Газетаның редактор урынбасары булып майор Гани Клеблеев хәрби корреспондентлар булып Ибрай Гази, Әхмәт Фәйзи, Кыям Хисмәтуллин иптәшләр эшлиләр. Озак вакытлы иҗат командировкасына барып, бу редакциядә язучы Фатих Хөсни эшли һәм үзенең очерклары, хикәяләре белән газетага катнаша.

1943 елның январенда Карелия фронтында «Ватан өчен сугышка» исемле газета чыга башлый һәм Ерак Төньякта акфин һәм немец илбасарларын тәмам тар-мар иткәнчегә – 1944 елның ноябренә кадәр дәвам итә. Редакция поезды Акдиңгез, Кайдалакша, Кола шәһәрләрендә тора, ә газетаның номерлары Ладога күленнән алып бөтен Көньяк һәм Төньяк Карелия буйлап, Заполярье һәм Петсамо өлкәсе буйлап Норвегиянең Керкинес шәһәренә кадәр тарала.

Бу газетаның беренче редактор урынбасары булып майор Александр Герасимов эшли (соңыннан батырларча һәлак була). Ул икенче эшкә күчерелгәч, майор Бари Корбанов, ә 1944 елның мартыннан майор Габделхәй Хәбиб эшли башлый. Хәрби корреспондентлар булып Габдрахман Әпсәләмов, Минһаҗ Җамалиев, Мөхәммәтша Сабельев, Гиз Габидуллин (Гиз Эль-Габид), Каюм Иманкулов иптәшләр эшлиләр.

1943 елның январенда Волхов фронтында «Фронт правдасы» исемле газета чыга башлый һәм Волхов фронтында сугыш операцияләре тәмам булгангача – 1944 елның февраленә кадәр дәвам итә. Волхов – Кириши – Новгород – газетаның фронт гаскәрләре белән үткән дан юлы.

«Фронт правдасы» газетасының редактор урынбасары булып майор Габделхәй Хәбиб эшли (соңыннан Карелия фронтына күчерелә). Хәрби корреспондент булып Әхмәт Фәйзи эшли.

Героик Ленин шәһәрендә (Ленинград фронтында) «Ватанны саклауда» газетасы чыга. Бу газета 1943 елның башыннан 1946 елның июненә кадәр дәвам итә. Газетаның редактор урынбасары булып капитан Заур Исхаков эшли. Хәрби корреспондентлар булып Ирек Аргынбаев, Кадыйр Юлдашев, Ильяс Сәйфетдинов иптәшләр эшли. Бу газетага Ленинград фронты частьларының берсендә хезмәт итүче яшь шагыйрь Мәхмүт Хөсәен актив языша һәм шунда үзенең каләмен чыныктыра.

Москва хәрби округында 1943 елның январеннан 1944 елның июненә кадәр «Кызыл сугышчы» исемле газета чыга. Аның редактор урынбасары булып капитан Ярулла Ярмәкиев эшли. Редакция сотрудниклары булып Мәхмүд Максуд, Гариф Галиев, Мөхәммәт Садри иптәшләр эшли. Якыннан торып Гадел Кутуй языша.

3нче Украин фронтында 1943 елның маеннан 1946 елның февраленә кадәр «Совет сугышчысы» исемле газета чыга. Бу газета фронт частьлары белән бергә Ворошиловград өлкәсеннән Одесса аша Румыниягә, аннары Болгариягә (София), Югославиягә (Вршац) һәм Австриягә (Вена) кадәр житә. Газетаның редактор урынбасары булып майор Мәхмүд Максуд, хәрби корреспондентлар булып Мостай Кәрим, Г.Әхмәтшин, А.Әсәдуллин һәм В.Вәлиев иптәшләр эшли. Бу газета редакциясендә иҗат командировкасында язучы Хәсән Хәйри була һәм үзенең әсәрләре белән газетага катнаша. Шулай ук фронт частьларының берсендә хезмәт итүче Әсгать Айдар иптәш тә бу газетага үзенең язмалары белән катнаша.

2нче Балтыйк буе фронтында 1944 елның февраленнән 1945 елның урталарына кадәр «Суворовчы» исемле газета чыга. Аның сугышчан юлы Великие Лукидан Ригага кадәр сузыла. Редактор урынбасары булып, майор Мөхәммәт Шәйми, хәрби корреспондентлар булып, Рим Баһау, Мәҗитов, И.Гурьев иптәшләр эшлиләр. Рим Баһау, редакция тарафыннан куелган сугышчан бурычны үтәгән чагында, батырларча һәлак була.

1нче Белоруссия фронтында 1944 елның ноябреннән 1946 елның февраленә кадәр «Кызыл Армия» исемле газета чыга. Аның сугышчан юлы – Обруч – Берлин. Газетаның редактор урынбасары булып капитан Ярулла Ярмәкиев, хәрби корреспондентлары булып, Гадел Кутуй, Ибрай Гази, Гариф Галиев, Закәрия Әхмеров, Кыям Хисмәтуллин иптәшләр эшлиләр. Якыннан торып газетага Ш.Абилов иптәш языша.

Берлин юлында барган каты сугышлар вакытында Гадел Кутуй бик каты салкын тидерә һәм, электән килгән авыруы көчәеп китеп, госпитальдә үлә.

2нче Белоруссия фронтында 1944 елның маеннан 1945 елның июненә кадәр «Фронт хакыйкате» исемле газета чыга. Аның сугышчан юлының этаплары: Смоленск – Белоруссия – Польша – Көнчыгыш Пруссия – Померания. Газетаның редактор урынбасары – майор Гани Гыйльманов, хәрби корреспондентлары: А.Әхмеров, Шәрәф Мөдәррис, Гамир Насрый, А.Салеев. Фронт частьларының берсендә хезмәт иткән А.Расих газетага якыннан катнаша. Бу редакция 2нче Белоруссия фронты сугышчыларыннан татар халкына җавап хаты оештыра.

Германиядә сугыш хәрәкәтләре беткәннән соң, 1945 елның июнендә, бу газета үзгәртелеп, Гаскәрләрнең төньяк группасы каршында «Җиңү байрагы» исеме астында чыга башлый һәм 1947 елның февраленә кадәр дәвам итә. Сугышчан эшләре өчен

«Кызыл йолдыз» ордены белән бүләкләнгән әлеге газета Польшада һәм Силезиядә басыла.

Ерак Көнчыгышта 1944 елның июненнән 1945 елның октябрена кадәр «Тревога» исемле газета чыга. Ерак Көнчыгышта япон империалистларына каршы сугыш хәрәкәтләре башланганчыга кадәр ул Хабаровскида басыла. Сугыш хәрәкәтләре башлану белән аның корреспондентлары Сахалинга, Курил атауларына, Манчжуриягә барып җитәләр. Редактор урынбасары булып майор Бари Корбанов, корреспондентлар булып Хәниф Кәрим, Мөхәммәтша Сабельев, Мөнир Мазунов иптәшләр эшли. Ерак Көнчыгыш авиациясендә хезмәт иткән шагыйрь Салих Баттал һәм яшь каләмнәрдән Әдип Маликов, Сафа Сабиров иптәшләр бу газетага актив язышa.

1945 елның маеннан 1945 елның ноябренә кадәр Інче Ерак Көнчыгыш фронтында «Сталин сугышчысы» исемле газета чыга. Аның үткән сугышчан юлы Ворошилов – Уссурийск – Мудань-цзян – Харбин. Редакторның урынбасары булып майор Габделхәй Хәбиб, хәрби корреспондентлар булып Габдрахман Әпсәләмов, Гиз Габидуллин, Каюм Иманкулов иптәшләр эшли.

Япон империалистларына каршы сугыш хәрәкәтләре башланыр алдыннан Байкал арты фронтында «Суворовча кысрыклау» газетасы оештырыла. Бу газетаның корреспондентлары Читадан башлап Монголия далалары, Хинган таулары аша Манчжуриянең башкаласы Чанчуньга кадәр барып җитә һәм газета шунда чыга башлый. Газетаның редактор урынбасары – майор Минһаҗ Гыймадиев, корреспондентлары булып Афзал Шамов, Абдулла Әхмәт, Котдус Әхмеров һәм Фазыл Басыйров иптәшләр эшли.

***

Бөек Ватан сугышы чорында татар телендә чыккан фронт газеталарының исемлеге менә шулар. Алар безнең Бөек Җиңүебезгә гаять зур ярдәм күрсәтте. Аларда татар халкы улларының һәм кызларының Бөек Ватан сугышы фронтында күрсәткән батырлыклары документаль дөреслек белән чагыла. Тарихның Ватан сугышы чорын өйрәнүчеләр өчен монда иксез-чиксез материал тупланган. Бу газеталарның битләрендә безнең күп сандагы хәрби журналистларыбыз, газетачы кадрларыбыз үсте, хәрби телебез, хәрби очерклар жанры барлыкка килде. Боларның барысын да тирәнтен өйрәнү – әдәбиятчыларыбыз, телчеләребез алдында торган мөһим һәм кичектерелмәс бурыч.


**Г.КАМИЛОВ**
*1947, №5*

# Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары

## «Муса Җәлил» – Прага сәхнәсендә

Прага Милли театры быелгы яңа сезонын Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, СССР халык артисты, композитор Нәҗип Җиһановның «Муса Җәлил» операсы белән ачты. Татар композиторының бу әсәрен Чехословакия җәмәгатьчелеге бик җылы каршылады. Беренче спектакльне Чехословакия Коммунистлар партиясе Үзәк Комитеты секретаре И.Генрих, Мәктәпләр һәм культура министры Ф.Кагуда, Чехословакиядәге совет илчесе М.В.Зимянин, Чехословакия җәмәгатьчелегенең башка вәкилләре карады.

*1960, №11*




# «КАЗАН УТЛАРЫ»

1965 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

**ҖИТӘКЧЕЛӘРЕ**:
С.Хәким (1965, №6 – җаваплы редактор); Р.Мостафин (1965, №8 – 1968, №4 – җаваплы редактор); З.Нури (1968, №9 – җаваплы редактор, 1968, №10 – 1971, №10, 1974, №1 – 1982, №12 – баш редактор); Г.Ахунов (1971, №11 – 1974, №10 – баш редактор); Р.Харис (1983, №1 – 1989, №12 – баш редактор); Р.Фәйзуллин (1990, №1 – 1990, №6 – баш редактор, 1990, №7 – 2013, №12 – баш мөхәррир); И.Ибраһимов (2014, №1 дән алып – баш мөхәррир).

# ТАТАР ДИАСПОРАСЫ ҺӘМ ТУКАЙ

Бай тарихка ия булуларына карамастан, татарларның соңгы йөз елда, аеруча совет чорында, үзләренең үткәннәре белән бәйләнешләре шактый йомшарды. Режим мөмкинлек биргән кадәр милли гореф-гадәтләрен, әдәбиятларын һәм тарихларын өйрәнгән, тикшергән һәм яшь буынга җиткерергә тырышкан татарлар һәм алар хәлендә калган башка милләтләр, этник җыелмалар, үз-үзләрен саклап калыр өчен, бик еш кына бер төркем символлар кулланырга мәҗбүр булдылар. Бәйсезлек алганнан соң кыргызларның «Манас» дастанына, үзбәкләрнең (Әмир) Тимурга, казакъларның Абай Кунанбаевка, башкортларның профессор Зәки Вәлиди Туганга, төрекмәннәрнең Мәхтум Кулигә һ.б. сарылып, бу шәхес һәм дастаннарны гадәттән тыш идеаллаштырулары, алар белән бәйле юбилейларны милли бәйрәм дәрәҗәсенә җиткереп үткәрүләре, алар исемендәге премияләр оештырулары, һәйкәлләр куюлары асылда шул – милләтнең аерымлык билгесе булган милли символларга ихтыяҗлары белән аңлатыла ала. Милләт булып формалашу яки бәйсезлек алу чорында ул дәүләтнең яки милләтнең барлыгын күрсәткән байрак, гимн кебек заманча символлардан мәхрүм милләтләр исә үзләренә генә хас символларга таяна. Бу күренеш аңлы рәвештә дә, аңсыз рәвештә дә яшәп килә.

Менә 444 елдан бирле рус хакимияте астында яшәгән һәм чит илләрдә, бигрәк тә Төркиядә «Казан төрекләре», «Идел-Урал төрекләре» кебек төрле-төрле исемнәр белән аталса да, үзен «татар» дип атап йөрткән бу төрки милләт, үзенә генә бер төрле моң-сагыш белән, үзенчәлекле символлар җыелмасы барлыкка китерде. Гәрчә 1992 елдан бирле Татарстан Җөмһүриятенең дәүләт символы буларак «канатлы ак барс» фигуралы тугра һәм яшел, ак, кызыл төсләрдән гыйбарәт булган байрак кулланыла башласа да, боларның халык тарафыннан тулысынча кабул ителүенә шактый озак вакыт кирәк булачак. Башка төрки җөмһүриятләрдәге кебек, Татарстанда да бу төр яңа рәсми милли символларны кабул итү «булды-бетте»гә әйләндерелде. Чынлыкта һаман һәр татар өчен аңлаешлы милли символлар буларак, беренче урынны Казан Кремлендәге Сөембикә (Хан мәчете) тотса, икенче урында милли шагыйрь Габдулла Тукай (1886-1913) тора дип әйтергә була. 1988 елда башланган бәйсезлек өчен көрәштә «Тукай маршы (гимны)» буларак билгеле «И туган тел» исемле шигыре милли җыелышларда, Төркиядәге «Истиклял маршы» кебек, аягүрә басып җырлану дәрәҗәсенә җитте. Хәтта ул вакытка кадәр бу шигырьнең тыелган соңгы дүрт юлының да аерым бер горурлык белән җырлануы, белмәгәннәргә өйрәтелүе, режимның

күрсәткән золымына һәм кысуларына карата татар халкының бер протесты буларак та аңлашыла ала. Табигый ки, монда шул хакыйкатьне дә ассызыклау урынлы булыр: совет режимы милли шагыйрьне тыймады, киресенчә, аңа атап һәйкәлләр салуга, музейлар ачуга, премияләр бирүгә рөхсәт итте, ләкин аның «Васыятем», «Тәэссир», «Аллаһы Тәбарәкә Тәгалә» кебек дини мотивлы шигырьләрен яки «И туган тел» шигырендәге кебек аерым юлларны бастырмыйча, аларга карата цензура булдырды. Икенче төрле әйткәндә, режим татар халкы өчен сөекле улын тыймады да, әмма аның әлеге темага багышланган шигырьләрен үзе теләмәгән формада төшендерелүе өчен мөмкинлек тә бирмәде.

Диаспорадагы татарларга килгәндә исә, аларны якын һәм ерак диаспора дип икегә бүләргә мөмкин. Беренчесенә – Татарстанның тышында элекке СССРның төрле җөмһүрият һәм өлкәләрендә яшәүчеләрне, икенчеләренә исә, болардан кала, чын аңламдагы чит илләрдә яшәүчеләрне кертергә була. Без хәзер тикшерергә теләгән тема – ерак диаспорадагы, ягъни 1950 елларга кадәр башлыча Кытайда, Япониядә, аннан соң Төркия, Финляндия, АКШ кебек дәүләтләрдә яшәгән аз сандагы татарлар һәм аларның Тукайны танып белүләре мәсьәләсе. Югарыда саналган дәүләтләр демократик яки советларга каршы позициядә торганга күрә, анда яшәүчеләр Тукайны үзләре теләгәнчә искә алу (яки искә алмау) ирегенә чын мәгънәсендә ия иде. Бу ирекtән файдаланып, алар, ниндидер режимның рөхсәт итүен яки итмәвен көтеп тормыйча, Тукайны һәр җәһәттән теләгән кадәр искә алып тордылар. Хәтта чит илләрдә җитешкән яшь нәсел, «бәгъзан татарларның башка шагыйрьләре әллә бер дә юкмы?» дип шөбһәләнеп тә карый башлады. Ватанны сагыну газабы тойган карт буын үз балаларына Тукай шигырьләре аша туган илгә мәхәббәт тәрбияләргә, аның шигъри юллары (мәсәлән, «И туган тел» шигыре) белән ана теленә игътибар уятырга тырышты. Икенче сүз белән әйткәндә, Тукай милли телне, милли әдәбиятны, ватан тойгысын, кыскасы, татарлыкның мәдәни кыйммәтләрен чагылдыручы бер исем булып торды.

Тукайның мондый көчкә ия булуын, бәлки, шул рәвешле аңлату дөрес булыр. Сәбәп аның шигырьләренең теле гаять гади, ягъни ана телен бөтен нечкәлекләре белән белмәгән, чит илләрдә, чит мохиттә туган кешеләр дә җиңел аңлый алырлык дәрәҗәдә садә булуында, әсәрләрендә күтәрелгән мәсьәләләрнең халык әкиятләреннән башлап, иҗтимагый һәм милли проблемаларга кадәр киңәеп китүендә. Социаль яраларны, мәгънәсез кебек күренгән, ләкин турыдан-туры халыкны кызыксындырган көндәлек вакыйгаларны, азатлык тойгыларын чагылдыруы, кешенең туган теле, тарихы белән горурланырга тиешлеген саф һәм җиңел аңлаешлы телдә аңлатуы үз илендә дә, диаспорадагы татарлар арасында да Тукайны баш таҗы итте. Үз дәвере шагыйрьләре Мәҗит Гафури, Сәгыйть Рәмиев, Дәрдемәнд, Зариф Бәшири, Нәҗип Думави, Укмасый, Зыя Ярмәкиләрдән аерылып торуының бер сәбәбе дә, бәлки, аның һәр иҗтимагый сыйныфка, һәр буынга атап, аерым дәшеп иҗат итүендәдер.

Менә бу үзенчәлекләре ерак диаспорадагы татарларның Г.Тукайны туган һәм үлгән көннәре туры килгән апрель аенда искә алулары өчен сәбәп булды. Кайда гына, кечкенә булса да бер татар якташлыгы оешмасын, кайда гына мәдәни фәгалият (чара үткәрү) форсаты тумасын, анда «Тукай кичәсе» үткәрү традициягә әверелде. Бу милли кичәләрдә Тукайның тормыш юлын сөйләнгәннән соң, аның шигырьләреннән берничәсен үрнәк итеп китерү мәҗбүри. «И туган тел» яисә икенче исеме белән «Тукай маршы» хор белән җырлана. Гомумән, Тукай кичәсе булсын, башка милли кичәләр булсын, бу җырның җырланмый калуы бик сирәк була иде. Чөнки бу марш (гимн) азатлыктан мәхрүм татар халкының бәйсезлеккә омтылышы кебек тоела иде. Бу «Тукай кичәләренә» өстәмә рәвештә махсус китап-журналлар да нәшер ителә иде. Шул рәвешле, диаспорада да Тукайның үлемсез калуы тәэмин ителә иде.

Башта ерак диаспорада яшәгән татарларның Тукайга мөнәсәбәтле эш-гамәлләренә күз салыйк. Иң әүвәл Япониядә Тукайның вафатына 20 ел тулу уңае белән басылган мөһим бер басмага тукталыйк. «Токио Матбага-и Исламия» 1933 елда, ягъни шагыйрь үлеменең 20 еллыгында Тукайның бөтен әсәрләрен эченә алган «Габдуллаһ Тукай. Мәҗмуга-и Асары» исеме белән 4 томлык бер җыентык бастырды. Барлыгы 543 битлек бу җыентык ул чакта татарлар тарафыннан кулланылган гарәп хәрефләре белән нәшер

ителде. Бу мөһим юбилей мөнәсәбәте белән, Япониядә яшәгән бик аз санлы татар-башкортның искиткеч зур тырышлыгы белән мәйданга чыккан 4 томлы җыентыкны хәзерләү бер дә җиңел булмый. Моның шулай икәнен Токиода чыккан «Япон мөхбире» исемле журналда басылган язмадан да күрергә була. Японияддәге мөселманнарның дини лидеры ролен үтәгән Габделхай Корбангалинең әлеге журналда басылган мәкаләсеннән һәм башка хәбәрләрдән Тукайның үлеменә 20 ел тулуны билгеләп үтү өчен зур күләмле чаралар үткәрелүе аңлашыла. Бер елдан соң исә Тукайның нибары бер шигыренең генә басылуын күрәбез.

Ерак Көнчыгышта Тукай белән бәйле, дөресрәге, аның үлеменең 25 еллыгын искә алу өчен басылган икенче бер әсәр исә 20 мәкалә һәм аңа багышланган шигырьләрне эченә алган 98 битле «Габдулла Тукай (1913-1938) (Вафатына 25 ел тулу белән)» исемле җыентык иде. «Ерак Шәрык Идел-Урал төрек-татар мөселманлыгының дини милли мәркәз мәгариф шогъбәсе» тарафыннан 1938 елда Мукдендә нәшер ителгән. Шул ук вакытта Мукдендә 1935-1945 еллар арасында чыккан «Милли байрак» газетасы төрле уңайдан аның шигырьләреннән үрнәкләр биреп бара, Тукай хакында төрле мәкаләләр яки аңа багышланган шигырьләр бастыра. Исхакый мөхәррирлегендә чыккан (башта «Милли юл» буларак) «Яңа милли юл» исемле айлык журналда да Тукайга бик еш урын бирелә.

Ерак диаспорадагы татарларның икенче бер мәркәзе булган Финляндиядә шагыйрьне искә алу кичәләре үткәрелеп килсә дә, беренче басма эше 1953 елда Төрек халык мәктәп һимая корумы тарафыннан Хельсинкида Тукайның «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» исемле әсәрен нәшер итү булды бугай, һәм 1969 елда Хөсәен Садыйкның «Габдулла Тукай шигырьләре» исемле 102 битле җыентыгы шулай ук Хельсинкида, элек Кытай һәм Японияддә чыккан җыентыкларның латин хәрефләренә күчермәсе рәвешендә басылды.

Ерак диаспорадагы татарларның иң тыгыз утырган җире булган Төркиягә килгәндә, монда Тукай һәм Тукайны таныту буенча алып барылган эшләр түбәндәгечә. Төрек укучысы беренче тапкыр буларак Тукай исемен «Төрек йурду (йорты)» журналының 1913 елдагы «Габдуллаһ Тукаевның вафаты» исеме астында басылган хәбәрдән белде. Аннан соң журнал «Тукаевның җеназасы» хакында мәгълүмат бирде. Иң әһәмиятлесе, һичшиксез, Фуад Көпрүлүнең Тукай хакында язган мәкаләсе булды. Ләкин Фуад Көпрүлүнең күләмле мәкаләсендә «бары тик «Тасвир-и Әфкар» белән «Ислам дөньясы»нда гына Тукаевка берничә колонка язма бирелде» дип хәбәр итүе ул вакытларда Төркиядә Габдулла Тукаевның әле танылмавына ишарә иде. «Төрек йурду» ул санында «Төрекләрнең яшь халык шагыйре (Габдулла Тукаев) мәрхүм») дип язып, нәкъ бер битлек фотографиясен һәм румынияле Нуман Байбуриның аңа атап язган «Габдуллаһ Тукаев» исемле шигырен бастырды. Биш ел узганнан соң, «Кырым» журналында бик кечкенә генә бер мәкалә чыкканын беләбез. Ягъни Көпрүлүдән соң Тукайга җитди игътибар күрсәткән кеше булмады. Монда шигырьләренең төрекчә тәрҗемә ителмәвенең дә йогынтысы булган, күрәсең. Озак вакытлардан соң Җөмһүрият дәверендә яңадан чыга башлаган «Төрек йурду» 1926 елда «Габдуллаһ Тукайның «Мәҗмугаи асары» дигән баш астында төрек укучысына Казанда аның сайланма әсәрләре басылуын хәбәр итсә дә (IV, №20, август, 1926, 189 б.), бу да тәэсирле булмады. Гаяз Исхакый 1933 елда (ягъни Тукайның 20 еллыгында) «Азәрбайҗан йорт билгесе» журналында Тукай турында тагын язып чыкса да, моның да әллә ни йогынтысы булмавы аңлашыла. Нәтиҗәдә, төрек матбугатындагы бу бер-ике мәкаләдән соң ярты гасыр буена Тукай турында һичбер нәрсә басылмавын, тулы бер бушлык хөкем сөрүен күрәбез. Бары 50 елдан соң гына Тукайның үзләре татар нәселле булган тикшеренүче һәм галимнәр тарафыннан көндәлек тормышка кире кайтарылуына шаһит булабыз. Болар – тарихчы Габдуллаһ Баттал Таймас, профессор Рәшид Рәхмәти Арат, профессор Әхмәт Тимер иделәр. Алардан соң өч ел узгач, профессор Хәмзә Зөлфикар шул ук журналда «Габдулла Тукай (1886-1913)» исемле җитди гыйльми бер мәкалә бастырганын күрәбез.

Шул ук елларда, ягъни 1963 елда Истанбулдагы татар-башкорт яшьләре «Тукай яшьлек клубы»н оештырганнар иде. Бу яшьләр оешмасы 1965 елның мартыннан

башлап 1968 елның сентябрь-ноябренә кадәр барлыгы 24 сан – һәр саны якынча 10-12 битлек – «Тукай бюллетене» чыгарды. Бу бюллетеньнең 1965 ел апрель (№2) санында профессор Әхмәт Тимернең «Габдулла Тукай» исемле (3–7 битләр) мәкаләсе басылды. Әлеге бюллетеньнең 4нче саныннан алып иң соңгы санына кадәр (ләкин 1965 елның ноябрь нөсхәсе «Рәшид Рәхмәти Арат хөрмәтенә махсус сан» булып чыкканга, бу саннан калганнары барысы) Надир Дәүләт оештырган «Тукай почмагы»нда Габдулла Тукайның шигырьләреннән шактые татарча оригиналы һәм төрекчә тәрҗемәләре белән басылды.

Шул ук «Тукай бюллетене» 1966 елда Наилә Бинарк тарафыннан иҗат ителгән «Тукайның хәяте» исемле балалар өчен дүрт пәрдәле пьесаны 16-19 саннарында бастырды. Соңрак бу спектакль Анкарада сәхнәгә дә куелды. Шул араларда Гали Акыш, Сәгыйдә Арысланбәк, Наилә Бинарк тарафыннан хәзерләнгән «Тукай брошюрасы» дигән 8 битлек бер хезмәт дөньяга килде. Бу брошюрада Арысланбәк һәм Бинаркның «Габдулла Тукай», шул ук шәхесләр тәрҗемәсендә Тукайның «Туган тел», «Гомер юлына керәчәкләргә», «Таз» шигырьләре, Гали Акышның «Бөек төрек-татар шагыйре Габдуллаһ Тукайның халыкчылык вә милләтчелек җәпһәләре» исемле мәкаләсе урнаштырылган иде. Бу нәшрият эшләреннән тыш, «Тукай яшьлек клубы» тарафыннан 1964, 1965, 1966 һәм 1967 елларның апрель аенда «Тукай бәйрәме» дип аталган милли кичәләр оештырылды. Бу милли кичәләрдә Тукайны искә алу белән бергә, аның шигырьләре укыла, кечкенә спектакльләр күрсәтелә һәм фольклор уеннары уйнала торган иде. 1967 елгы «Тукай бәйрәме»нең башка еллардагыдан аермасы Гаяз Исхакыйның (Иделле) «Жан Баевич» исемле 4 пәрдәлек зур пьесасын Истанбулдагы Чагалоглунда Милли төрек студентлар берлеге сәхнәсендә кую булды. Бераз соңрак (28 октябрь) «Тукай бәйрәмнәре» «Казан төрекләре шәнлиги (шатлыгы)» исеме астында дәвам иттерелде. Ләкин бу әле Тукайның онытылмавын тәэмин итә дигән сүз түгел.

Чөнки 1968 елда «Тукай яшьлек клубы», «яшьлек срогын тутырып», «Казан төрекләре культура (мәдәни) һәм ярдәмләшмә җәмгыятенә» әйләнгәч, мәрхүм Әхмәт Вәли Мәңгәрнең матди булышлыгы белән өч айга бер мәртәбә «Казан» журналы чыгарыла башлады. Бу журнал да Тукайны укучыларга таныту эшеннән ваз кичмәде һәм «Тукай бюллетене»нә караганда да киң күләм укучыларга таралганга күрә, тагын да үтемлерәк булды. «Казан» журналы беренче санында ук Тукайның Надир Дәүләт тәрҗемәсендәге «Сак-Сок бәете» исемле әсәрен бастырып чыгарды. Тукайның тууына 85 ел туры килгән өченче санында исә (1971, март) «Казан» үз сәхифәләренең күп өлешен Тукайга багышлады.

Татарлар Тукайны һәртөрле уңайдан искә алырга тырышканга күрә, «Казан» журналы да Габдулла Тукайның үлеменә 60 ел тулу уңаеннан 10нчы санын (1973) тулысы белән аңа багышлады.

Моннан соң да «Казан» журналының 11нче санында (1974) «Таз», «Теләнче», «Нәсихәт», 12 санында (1974) «Мөхәрриргә», 14 санында (1975) «Театр», 17 санында (1976) (бу санда 90 еллык юбилее котлана) «Су анасы» белән «Кадер кич» шигырьләренең Наилә Бинарк тәрҗемәсендә нәшер ителүен күрәбез. 17нче санда шул ук вакытта Сания Ишыкайның шагыйрьгә атап язган «Габдуллаһ Тукайның 90 еллыгы» исемле шигыре дә урнаштырыла. Аннан кала 18нче санда (1976) Нәркиз Деуш-Гиелингнның «Тукайга хөрмәтләр белән» һәм 22нче санда (1978) Минһаҗның «Даһи Тукайны искә алу» дигән шигырьләре бирелә.

Ләкин 1978 елның 10 ноябрендә журналны матди яктан яшәткән Әхмәт Вәли Мәңгәрнең вафат булуы «Казан» журналының басма хәятына чик куелуга, 1980 елның 12 октябрендәге хәрби переворот исә Истанбулдагы «Казан төрекләре культура һәм ярдәмләшмә җәмгыятене»ң ябылуына сәбәп булды. Бу үзгәрешләр Тукайны төрек җәмәгатьчелегенә таныту эшен тагын да кыенлаштырды һәм бу вазифаны чикләнгән мөмкинлекләргә ия аерым шәхесләр үз өсләренә алырга мәҗбүр булдылар.

Төркия тышындагы төрки милләтләрнең әдәбиятларына төрле сәбәпләр аркасында игътибарның артык зур булмавына карамастан, әлеге вазифаны, мөмкинлекләре чикле булса да, фидакарь рәвештә үз өстенә алган «Кардәш әдәбиятлар» журналы 1982 елда Тукай исемен яңадан төрек укучысына җиткерә. Дүрт елдан соң, 1986 елда, ягъни

Тукайның тууына 100 ел тулганда исә, бу юллар авторының бер төркем танытма мәкаләләре басылып чыга.

Югарыда күрсәтелгән журналлардагы мәкаләләрдән тыш, «Кардәш әдәбиятлар» журналының да 16нчы санын (1987) Тукайга багышлау татар шагыйренең тагын да киңрәк территориядә танылуы булды.

Тукайның 100 еллык юбилеен шулай билгеләп үтәргә тырышканнан соң, 1988 елда Гали Акышның «Төрек йурду» журналында басылган, Тукайны хәтерләтү фикере белән язылган бик кыска (бер битлек) кечкенә мәкаләсеннән башка, 3-4 ел буена бернинди дә җитди хезмәт чыкканы күренми. Тукайның 100 еллыгына хәзерләнеп тә, университетларның матди мөмкинлекләре булмавы аркасында, үз вакытында басылмый калган ике гыйльми эш бары тик 1991 һәм 1993 елларда тар аудитория укучыга барып иреште. (М.Өнәр һәм Н.Дәүләт хезмәтләре).

Төркиядә Габдулла Тукай белән бәйле иң зур алга китеш, һич шөбһәсез, Фатма Өзканның кандидатлык диссертациясе (докторлык тезисы) булды. Шул рәвешле, Фуад Көпрүлү, Хәмзә Зөлфикар һәм Мостафа Өнәрдән соң һәм татар нәселеннән чыкмаган төрек галиме Тукай темасына академик хезмәт яза һәм Төркиянең мәдәни тормышына, «Гомуми төрек әдәбияты»на гаять әһәмиятле өлеш кертә. Әлеге диссертациянең төрек культурасын өйрәнү институты тарафыннан «Габдулла Тукайның шигырьләре. Анализ. Текст. Тәрҗемә» (Анкара, 1994) исеме белән басылып чыгуы исә аның тагын да киңрәк күләм укучы тарафыннан танылуына сәбәпче була. Бу – бөек казаныш булып хисапланырга хаклы күренеш. Мостафа Акбаш тарафыннан язылган «Татар шагыйре вә язучысы Габдуллаh Тукайның әсәрләреннән сәчмәләр (сайланма әсәрләр) вә алардагы тел үзенчәлекләре» дигән темага кандидатлык диссертациясе исә яклау өчен Истанбул университеты Иҗтимагый фәннәр институтының иске төрек теле бүлегенә тапшырылуын да ишеттек.

1991 елда, ике арадагы «тимер пәрдә» юкка чыгып, нибары биш ел вакыт узганнан соң, Төркиядә ике кандидатлык диссертациясе язылу – гаять зур алга китеш. Бу төр академик хезмәтләр белән Төркия тышындагы төрле төрки кавемнәрнең (халыкларның) әдәбиятларын да фәнни юнәлештә өйрәнү һәм бәяләү мөмкинлеге ачылды. Табигый ки, Төркиядәге бу үсешкә 1991 елда Советлар Берлегенең таркалуы һәм төрек дөньясының яңадан берләшә башлавының зур йогынтысы булды. Аеруча Төркиядә яшәгән һәм нигездә артык вәкаләтләре булмаган шәхесләр үз нәсел-нәсәпләре белән бәйле мәгълүматларны эзләргә тырышулары тиешле нәтиҗәне бирмәгәнен дә искә алсак, университетларыбыздагы яшь галимнәребезнең, академикларыбызның һәм ирекле (шәхси) тикшеренүчеләрнең мондый темаларга алынулары кардәш халыклар белән элемтәләребезнең ныгуына уңай йогынты ясаячак дип өметләнергә кирәк.


Соңгы елларда яшь галимнәребез арасында Тукай исеме тагын да көчлерәк ишетелә башлады. «Кардәш әдәбиятлар» журналы 1994 елда (28нче сан) Мостафа Өнәр тәрҗемәсендә Әмди Гәрәйбәйнең «Тукайга» исемле шигырен һәм 1995 елда (32нче сан) доктор Фатма Өзкан тәрҗемә иткән Габдулла Тукайның «Исемдә калганнар» әсәрен бастырып чыгарды. «Төрек культурасы» журналы исә быелгы 395нче санында (март, 1996) Тукайның тууына 110 ел тулу уңае белән тагын Фатма Өзканның «Гомеренең язында вафат иткән бөек бер шагыйрь: Габдуллаh Тукай» исемле мәкаләсен бастырды.

Кыскасы, үз илендә бик мәшһүр булган татар халык шагыйре Габдулла Тукай әкрен-әкрен Төркиядә дә таныла башлады. Бу исә тугандаш халыкларның якынлыгы аеруча мәдәни чаралар ярдәмендә артачагына инанган безләр өчен бик зур сөенеч. Бу хәлдә Тукай, бары ерак диаспорада яшәгән татарлар өчен генә түгел, ә бәлки Татарстан белән Төркия арасында да мөһим бер мәдәни элемтә юлы салынуга этәргеч булып торыр.

**Надир ДӘҮЛӘТ,**
*Истанбулдагы Мәрмәрә университеты профессоры*
*Истанбул, июнь, 1996*

*Язманы матбугатка* **Әлфинә СИБГАТУЛЛИНА** *әзерләде.*
*1997, №5*

# СЕР САКЛАУЧЫ ФОТОЛАР



Журналда менә шундый яңа сәхифә ачып җибәрергә булдык әле.

Кайбер фоторәсемнәрне маңгай күзе генә түгел, күңел күзе дә күреп җиткерә алмый. Аңлап бетерер өчен ниндидер сер ачылырга тиеш.

1913 елның 1 апрелендә, ягъни Тукайның вафатына ике атна кала Клячкин хастаханәсендә төшерелгән менә бу фотоны күргәч тетрәнми калган татар кешесе булды микән? Үлем суыгы кочып алган кебек бит бөегебезне...

Юк, алай ук түгел икән шул. Астындагы мендәрләр аңа тән җылысы гына түгел, күңел җылысы да биреп торганнар икән бит.

Ошбу мендәрләр фоторәсемне беренче күрүемдә үк гаҗәпләндергән иде. Ул заманда хастаханә мендәрләре шулай зур булды микәнни? Бер генә дә түгел, ике бит әле алар. Моның серенә «Казан утлары»ның 1000нче саны чыгу уңаеннан «Сүнмәс утлар балкышы» дигән китап әзерли башлагач юлыктым мин. Журналның 1944 елгы 4нче санында Тукайның җиңгәсе Рабига Әмирова хатирәләре басылган... Җиңги дип, Габдуллабызның яшьтәше генә булган әле ул. Аның ире Кәбир исә Габдуллага әнисе Мәмдүдә ягыннан бертуган абый тигән һәм ул да нибары бер генә яшькә олы. Арча районының Өчиле авылында яшәгәннәр алар. 1912 елның декабрь урталарында Габдулла хат язып абыйсын чакырып ала. Һәм: «Җиңги нинди табигатьтә, әгәр дә беркадәр вакыт мин сезгә кайтып ятсам, тарсынмасмы?» – дип сорый. Абыйсы исә: «Кайт, бер дә тарсынмас», – дигән. Атлы чанада кайтып төшкәч, икәүләп күтәреп керткәннәр үзен. Бер атналап хәрәкәтсез яткан. Аннары торып утыра һәм аз-маз гына йөри дә башлаган. Ашавы да яхшырган. Бер айлап үткәч, нык кына төренеп караңгыда ишегалдына чыгып йөри башлаган. «Ләкин үзе бер дә кешегә күренмәскә тырыша иде һәм абыйсына беркемне дә янына кертмәскә куша иде», – дигән җиңги кеше. Гомеренең азагында бөегебез өстендә кара болытлар куера башлаган дигән сүз кереп калган иде шул хәтеремә.

Сәхифәне җиңги сүзләре белән очлап куйыйк. «Бездә барлыгы өч ай ярым чамасы торды. Яхшы гына тазарды, рухы күтәрелде. Төннәр буена утырып бик күп яза башлады... Без җәйгә кадәр тор дип кыстасак та, тормады. «Җәйгә яңадан кайтырмын», – диде... Ятырга рәтле мендәре юклыгын белеп, киткәндә үзенә ике мамык мендәр биреп җибәрдем... Март ахырларында абыйсы Казанга үзе илтеп куйды. Киткәндә миңа бик рәхмәт укып китте. Ләкин Казанга кайткач, салкын тидереп, яңадан авырган. Шуннан соң озакламый үлде».

Рабига Әмированың хатирәләре «Сүнмәс утлар балкышы»на кертелде. Шуннан да укый аласыз.

Авторлар һәм укучыларыбызга үтенеч шул: сер катышлы фотоларны белсәгез, җибәрегез яки бу хакта безгә хәбәр итә күрегез.

**Рәфикъ ЮНЫС**
*2016, №4*

## Миргазиян Юныска – 70 яшь

Күренекле прозаик һәм публицист Миргазиян Юныс 1927 елның 25 маенда Татарстанның Баулы районы Исергәп авылында крестьян гаиләсендә туган. Авыл мәктәбенең алты классын тәмамлаганнан соң, ике ел колхозда эшли. 1944 елның августында армиягә алынып, хәрби авиация мәктәбенә укырга җибәрелә, аннары укчы-радист сыйфатында бомбардировщикларда оча. 1950 елда экстерн тәртибендә Харьков хәрби-авиация училищесын тәмамлагач, авиаэскадрильяларда элемтә начальнигы булып хезмәт итә, бер үк вакытта кичке мәктәптә укып гомуми урта белем ала.

1955 елда сәламәтлеге начараю аркасында очу эшеннән азат ителгәч, М.Юныс демобилизацияләнә һәм М.Ломоносов исемендәге Мәскәү дәүләт университетының филология факультетына укырга керә. Бераздан университетның читтән торып уку бүлегенә күчеп (аны ул 1961 елда тәмамлый), Кара диңгез дәүләт пароходчылыгында навигатор булып эшли башлый. 1957 елда кыска сроклы курсларны тәмамлагач, М.Юнысны чит илгә йөри торган сәүдә карабы капитанының политик тәрбия эше буенча беренче ярдәмчесе итеп билгелиләр. Бу эштә ул 1968 елга кадәр була. 1968-1977 елларда М.Юныс Мәскәүдә Бөтенсоюз диңгез транспорты фәнни-тикшеренү институтында өлкән белгеч, СССР Диңгез флоты министрлыгында бүлек начальнигы һәм «Наука и религия» журналы редакциясендә бүлек мөдире вазифаларын башкара. 1977 елдан бирле ул яңадан әүвәлге хезмәтендә – Кара диңгез һәм Азов диңгезе дәүләт пароходчылыгында сәүдә карабы капитанының беренче ярдәмчесе булып эшли.

М.Юныс – әдәбиятка зур тормыш тәҗрибәсе туплап килгән прозаикларның берсе. Ул алтмышынчы елларда яза башлый. Диңгезче хезмәтенә, чит илләрдә яшәүче халыкларның тормыш-көнкүрешенә, гореф-гадәтләренә бәйле кызыклы һәм гыйбрәтле вакыйгаларны тасвирлаган «Безнең өй өянке астында иде...», «Тимер фил», «Кочегар», «Әти оҗмахка киткәч», «Ямәнгә сәяхәт», «Зәңгәр дөнья», «Яңар таулар», «Диңгез чакыра» кебек беренче хикәя, очерклары һәм романтик рухлы «Занзибар зәңгәр болытлар артында» исемле повесте белән ул укучыларның һәм әдәби җәмәгатьчелекнең игътибарын үзенә җәлеп итә. Авторның шуннан соң язылган әсәрләре – «Тозлы җил» (1973), «Теләп алган давыл» (1975) повестьлары һәм «Энҗе эзләүчеләр», «Табу һәм югалту», «Биектә калу» һ.б. укучылар тарафыннан җылы каршылана.

М.Юныс, язучы-художник буларак, темаларның колачы, чынбарлыкны заманның олы проблемалары, тарихи тенденцияләре җирлегенә куеп яктыртырга омтылуы, вакыйга-хәлләрне, кеше характерларын ачуда, тормыш конфликтларын чишүдә психологик, әхлакый-фәлсәфи анализга киң урын бирүе белән бүгенге татар прозасында үзенчәлекле урын тота.

Әдипне олы юбилее белән кайнар котлыйбыз!

*1997, №5*

Миргазиян
Юныс

# СОҢГЫ СУЛЫШ*

## «ЮЛДА УЙЛАНУЛАР» ӘСӘРЕНЕҢ ӨЧЕНЧЕ КИТАБЫ

**6**

– Күптәнме? – диде баш врач тәҗрибәле табибларга хас тышкы кызганусыз, ихлас мәрхәмәт белән. – Моннан ике ел элек. Мин операция өстәлендә ятканда, Әрмәнстанда җир тетрәү башланды.

– Кайда ясадылар?

– Мәскәүдәге Трансплантология институтында.

– Институттан чыкканда бирелгән кәгазь үзегез беләнме?

– Аны кайдадыр алып калдылар. Поликлиникада булса кирәк, – дидем мин, эшнең һаман җитдиләнә, өметемнең кечерәя баруын сизеп. Йә Хода! Мәрхәмәтеңнән ташлама!

– Ятыгыз.

Яттым. Үземне тыныч тотарга тырышам.

Баш врач мине бик озак як-якка әйләндерә-әйләндерә тыңлады. Тыңлап бетергәч, күкрәк сөякләре астына бармакларын тыгып бавырымны тикшереп карады.

– Озак басып торганда аякларыгыз бүртенәме?

– Юк, бүртенми.

– Торыгыз.

Тордым. Баш врач кан басымын үлчәде.

– Йөз һәм алтмыш, һәрдаим шулаймы?

– Монда килгәч бераз төште. Гадәттә, йөз егерме һәм сиксән, – дидем мин.

– Кан басымы төшүен каян беләсез.

– Миләр томаланып киткәндәй итә. Тәндә сүлпәнлек башлана. Андый чакларда каты чәй, кофе эчәм. Бүген эчмәдем.

– Киенегез.

Ашыкмыйча гына майкамны, күлмәгемне кидем. Күлмәк итәген эчкә кертеп, чалбар каешын тыгызлагач, курткама үрелдем. Хәзер минем язмышыма кагылышлы сүзләр яңгырарга тиеш иде. Шул сүзләрдән соң миңа йә күк капусы ачылачак, яисә поликлиникадан чыгып, туры вокзалга билет алырга юнәлергә туры киләчәк. Хөкем мизгелен ерагайтасым килә. Йә Хода! Бу юлы да барып чыкмасмы икән?

**7**

– Ялгышмасам, ясалма клапан аорталь клапанда.

– Әйе, шунда, – дидем мин, ашыгып.

* Әсәрдән өзек.

– Митраль клапандагы кан юлын киңәйтеп чистарттылармы?
– Әйе, киңәйттеләр.
– Тагын нәрсә эшләделәр?

Бер генә мизгелгә калганнарын яшерәсе, башка берни эшләмәделәр, дип әйтәсе килү вәсвәсәләп алды. Ялганлыйсы килүне җиңдем. Мондый мизгелдә, бигрәк тә сиңа ихласлык һәм шәфкать белән караган кешегә бер генә микъдар ялган, ярымдөреслек, күз буяу да булмаска тиеш. Ялган – һәр очракта гөнаһ. Мондый мизгелләрдә тәмуг уты да чистарта алмаслык каты гөнаһ. Безне күнектерделәр. Көчләп. Сизми башладык без ялганны. Күнектек...

– Сыйрактан тамыр алып ике шунт куйдылар, – дидем мин, тыныч калырга тырышып. – Сул як карынчык чиктән тыш тузган, зурайган иде. Шуны бәләкәйләтеп тектеләр.

– Шушындый катлаулы операциядән соң сезгә ерак юлга чыгу кирәкме икән соң? Сакланганны Алла саклый диләр бит?

«Катлаулы операциядән соң...»

**8**

Ул көннәрне мин онытырга тырышам. Мавыктыргыч, иҗат уты таләп итә торган эш белән мавыккан чакларда күпмегәдер оныткандай итеп торам. «Иҗат уты» дигәнне башкача аңлаулары мөмкин. Иҗатның иң кайнар уты җир белән эш иткәндә, бәрәңге утыртканда, кыяр үсентеләрен тиреслəгәндә кабына, һәм сыйфатлы агач табып, шул агачка яшеренгән сурәтне үткен пычак белән уеп күзгә күренерлек иткәндә. Бу очракларда да оныту тулы була алмый. Аңның ерак бер почмагында 1988 елның көзендә булган хәл сизелер-сизелмәс кенә әрни, моң биреп тора.

Халык Бөек Октябрьнең (кайсы ягы белән бөек икәнлеген мин үтерсәләр дә аңлый алмыйм!) җитмеш бер еллыгын бәйрәм итәргә әзерләнә. Мин сумкама фарфор кружкамны, Шарль Бодлерның «Явызлык чәчәкләре»н, пыяла банкага тутырган балны һәм кәгазь-каләмемне салып соңгы тапкыр фатирыма күз йөртеп чыктым. Әнә, агачтан ясаган сыннарым. «Казан ханлыгы тарихы». Шул сынны ясар өчен кара агачны мин Калькутта базарыннан соңгы валютамны түләп алган идем. Бу сын өч символ берләшүдән барлыкка килде: Казан ханлыгы турындагы шома ялган, җир астыннан дүрт гасыр аваз биреп ятучы хакыйкать һәм дүрт гасыр дәвам иткән кан елау[1]. Иерусалим каласында яһүдләрнең җимерелгән гыйбадәтханәләреннән калган бер таш дивар бар. Шул ташларны яһүдләр «елау-сыктау дивары» дип атап йөртәләр. Безнең Казанда да шундый урын булырга тиеш. Инде менә ярты гасырга якын шундый диварны булдыру турында хыялланып йөрим. «Казан ханлыгы тарихы» дип аталган сыннарның бер кырына мин тарихны күз яше белән юарга килүчеләрнең сурәтләрен ясадым.

Әдәби әсәргә кертергә ярамаган, миңа төрмә китерәчәк һәр уй-фикеремне мин агач сыннарга урнаштыра килдем. Әнә алар бүлмәнең стенасын каплап торалар. «Ирдәүкә». «Карагруһлык». «Кол Гали». «Самодержавие». «Урыс фашистлары». «Сәясәт»...

Чит илләргә йөрү Барселона портында өзелде. Әнә Каталониянең башкаласында соңгы тапкыр булуым истәлегенә соңгы рейста бирелгән барлык валютама алган ат сыны. Мин аны Манжуик тавындагы кибеттән алдым.

Киштәләрдә – яраткан китапларым. Сез мине кабат күрә алырсызмы икән?

[1] Хәзер ул сын Президент Шәймиевтә саклана.

Бу бүлмәгә кабат керергә язганмы икән? Аллаһы Тәгалә! Юк, ул сиңа сүз белән әйтми. Ходай әйтәсе фикерен турыдан-туры синең күңелеңә китереп сала. Билгеле, ихлас инанган бәндәсенә...

Тапшырдым Синләрнең кодрәтенә... Бисмиллаһи...

Үлемтеккә акча әмәлләү. Менә нәрсә кайгырта иде мине ул чакта. Карачи портында алган күн пальтомны комиссионкага илтеп тапшырдым. Пальтога магнитофон өстәлде. Кувәйт портыннан алган аппаратура...

Бәлки, ясаласы операциянең уңышлы тәмамлануына өмет баглап азапланасы да булмагандыр? Ул чакта мин рәттән йөз адым атлый алмый башлаган идем инде. Икенче катка ярты сәгать менәм. Басма аралаш туктап хәл җыям... Кан басымының өскесе алтмышка якынлашып килә. Аскы өлешен тыңлап та булмый диярлек. «Туши фонари!» – диләр диңгезчеләр мондый очракта. Ә мин көрәшеп азапланган булам. Йә, кемнең тора салып якты дөнья белән саубуллашасы килсен?

Врачларның күбесе шушы хәлгә җитеп таушалган йөрәкне ремонтлап булуга ышанмыйлар иде. Бары тик бер генә нәрсә бәхәссез – озакламый Газраилнең килеп ишек шакуы... Кулдан килгән кадәр гаиләгә мәшәкать калдырмаска тырышырга кирәк. Ә колагыма кемдер пышылдап белгертеп тора: «Өзмә өметеңне! Өзмә!»

Операция өстәле шыксыз. Мин бит инде аны өч тапкыр татып карадым. Бәлки, соңгы юлга җылы түшәктән кузгалу хәерлерәктер? Соңгы юлның беренче адымы? Аңа күпме калган икән? Биш ай? Өч? Ике атна? Бер тәүлек?..

**9**

Мин баш врачның хөкем чыгарганын көтеп утырам. Аңа да авыр бит. Җаваплылык. Өстә утыручы астагыны җавапка тарттыра, ә үзе җаваплылыктан читтә калырга тырыша. Иң өстәгеләр җаваплылыкны белмиләр дә. Теләсә нинди эш, теләсә нинди җинаять эшли ала иң өстә утыручы.

Баш врач чыгарганчы минем операция хәлләренә кабат кайтыйк әле.

Мине биш кешелек палатага урнаштырдылар. Җыештыручы хатын урын җәйгәндә әйтергә өлгерде:

– Бу караватта сезгә кадәр яткан кеше шундый әйбәт иде.

«Иде». Менә шушы өч хәрефтән торган сүз ул әйбәт кешенең кайда икәнлеген ачыклады. Бу хакта җыештыручыдан сорарга курыктым да, базмадым да.

Палатадагы биш кешенең икесе – авар егете Рамазан, Коломна заводының конструкторы Павел Лазутин мәеттән кисеп алган донор йөрәк килгәнен көтәләр иде. Керчь шәһәрендә туып-үскән яшьтәшем Вадим Григорьев белән беренче көнне үк уртак тел таптык. Ул минем татар икәнлегемне ачыклагач, Кырым татарларын туган туфракларыннан ничек куулары турында сөйләде. Аларны туган җирләреннән сөргәндә, Керчь шәһәрен өч катлы бөҗра белән уратып алган булганнар. Иң эчтә НКВД җәлладлары. Уртада гаскәрләр, ә тышкы яктан армиягә озатырга әзерләнгән допризывникларны куйганнар. Шулар арасында Вадим да булган.

Урыслар сан ягыннан гына да йөз кырык биш миллион. Бу – аларның күплегенә, зур саннар кагыйдәсе (теория больших чисел) күзлеге аша караганда, бик күп өстенлекләр бирә. Көчле дәүләт булып укмашкан зур милләт кенә Лев Толстой масштабындагы гигантларны бирә ала. Коллык шартларында яшәгән милләтләрнең Мәрҗани зурлыгындагы даһи шәхесләрен ирек юклык, кысынкылык һәм хакимият оештырган эзәрлекләүләр имгәтә.

Вадим Григорьев кан тамырына зонд тыгып тикшерүне күтәрә алмады.

Хатыны, балалары килеп мәрхүмне алып киттеләр. Аның урынына Одесса киностудиясендә режиссёр булып эшләүче кырык яшьлек Александр Васильевич Гришинны салдылар. Гришинның йөрәгенә бер тапкыр операция ясаганнар инде. Ул операциядән исән котыла алуына ышанмый. Әллә чыннан да аның хәле авыр иде, әллә шул ышанмау алып китте аны.

Авар егете Рамазан йөрәк авыруын армия хезмәтендә эләктергән икән. Тикшереп карасак, палатадагы биш авырудан дүртесенең сәламәтлеген армия сындырган булып чыкты. Ә без күпме мәдхия җырладык Кызыл Армиягә, күпме еллар аны күкләргә чөеп мактадык!

Бер көнне Рамазан иртүк торды, палатадан чыгып тәһарәт алып керде, караватына намазлыгын җәеп озак кына намаз укыды. Әйберләрен җыеп сумкасына тутырганнан соң, минем караватыма килеп утырды.

– Габдрахман ага[2],– диде ул, урыс телен вата-җимерә. – Саубуллашыйк. Сез миңа шәригать кагыйдәләре турында сөйләдегез. Урыныгыз җәннәттә булсын. Кяферләрнең пычагына язмышымны тапшырасым килми. Тәкъдир – Аллаһы Тәгалә кулында. Аның үзенә тапшырам. Бәхилләшик.

Ишек ачылып ябылды. Рамазан яткан караватбушап калды. Төштән соң ул караватка Кубадагы сугышка катнашкан пенсиядәге артиллерия капитаны Валерий Ушаковны салдылар. Казакъстандагы Павлодар шәһәреннән иде Ушаков... Мурманга китәргә җыенып йөргәндә, Валерийның хатыны Нина минем өемә чылтыратып хәбәр тапшырды:

– Иртәгә Валерийның кырыгы. Сез аның белән сердәш идегез. Җан бирер алдыннан Валерка сезнең исемегезне телгә алды.

Рамазаннан гына хәбәр юк. Минем палатадашларымның барысы да киләчәктә без барасы җирдә. Беләм, мине дә тиздән урын көтә. Бәлки, шуңа күрә ерак диңгезләрдә калган эзләремне карап кайтырга ашыга торганмындыр?

## 10

«…Катлаулы операциядән соң ерак юлга чыгу кирәкме икән сезгә?» Мин операция маҗаралары турында уйлаганда, шушы сорау әрнетеп җавап көтеп торды. Баш врач белән минем арада һаман шушы утлы сорау. Ышандырырлык, шул ук вакытта минем теләгемә юл ачарлык дәлилле җавап кирәк. Әйе, дәлилле җавап. Каян алыйм соң мин андый дәлилне?

Сорауның төрлесе була. Кайбер сорау – үзе җавап. Сорау – сөаль, сорау – эз яшерү, сорау – өмет, сорау – пычрак ату... Санап бетерерлекмени сорауларның төрләрен. Баш врачның соравы минем язмышымны бугазын кысып тотты. Бу сорау Мөнкир-Нәкир сөаленә тиң иде. Ялган да, хәйлә дә катнашмаска тиеш минем җавабыма. Мөнәсәбәтләр, мин сизмерлим, әлеге саф, эчкерсез, хәтта күпмедер дәрәҗәдә изге. Шул килеш калсын иде минем җавабымнан соң да...

– Бу хакта күп уйладым, – дип башладым мин. – Бу сорауны үземә-үзем ничә тапкырлар биреп карадым. Кирәк миңа сәяхәткә барып кайту. Бик тә кирәк. Миңа хәзер ансыз рәтле яшәү юк. Мин үземә ышанмый башладым. Мин бит инвалид. Инвалид хәлен сәламәт кеше белми. Аяк атлаган саен кимсетелүгә һәм кимсенүгә килеп абынып торасың. Сәламәт чакта минем күз алдымда берәр бәндәне җәберләсәләр, шул нахалның якасы шундук минем кулымда була иде. Ә хәзер... минем хәлне сез беләсез инде. Диңгезне сагынам мин. Диңгезгә чыгып бер йөреп кайталмасам, үләрмен дип куркам.

[2] Автор әсәрдә үзен Габдрахман Рахманкулов исеме белән биргән. *Ред.*

Павел Коганның нәкъ сугыш алдыннан иҗат ителгән «Бригантина» исемле җырын беләсезме икән сез? Минем буын, юк, минем буынның кечкенә бер өлеше, шул җыр тәэсирендә тәрбияләнде. Мәсәлән, минем өчен романтика яңгыравыклы матур сүз генә түгел. Романтика минем өчен күпмедер дәрәҗәдә дин дә, яшәү максаты да, бәхет тә. Озын, авыр сәяхәттә йөреп кайта алсам, инвалидлыгымнан арынырмын, кабат яшәреп китәрмен дип ышанам мин...

Нәрсә иде икән баш врачның күзләрендә сурәтләнгән билге? Сагыш микән, әллә курку идеме? Бәлки, икеләнү һәм шуны яшерергә тырышу булгандыр?

Тирән итеп сулыш алды баш врач. Көрсенгәндәй итте. Тыштан тыныч күренә иде бу хатын. Вентспилс портындагы поликлиниканың баш врачы әйткән сүзләр исемә төште. Кырык яшьләрдәге таза, матур ир иде ул. «Әгәр сез сәяхәттә үлсәгез, мине төрмәгә утыртачаклар, – диде ул минем беренче килүемдә. – Минем хатыным, балаларым бар. Инвалид үзен инвалидча тотарга тиеш. Диңгезне сагынам, дисез? Җәйге кызу сүрелгәч, Кырымгамы, Кавказгамы барыгыз да көннәр буе ярдан диңгезгә карап утырыгыз».

– Сез утырасы карабның кая баруы билгелеме? – диде баш врач, ниһаять. – Күпмегә?

– Мине Япониягә барасы карабка утыртмакчы булалар, – дидем мин. – Караб әлегә диңгездә.

– Мин бит сезне диңгез белән танышу өчен генә Мәскәүдән килгәнсездер дип уйлаган идем. Язучылар, журналистлар еш киләләр монда. Өч-дүрт көнгә, берәр атнага диңгезгә чыгып урап кайталар. Кайткач, диңгезчеләр турында язалар. Андый язмаларны без кызыксынып укыйбыз. Ә сез Япониягә кадәр бармакчы икәнсез, – баш врач, кинәт өшеп киткәндәй, учлары белән җилкәләрен каплады.

– Әйе, – дидем мин, ашыгып. – Озын һәм авыр рейска чыгасым килә. Нәкъ шундый рейс җан кертер дип өметләнәм. Бары тик шундый сәяхәттә генә инвалидлыгымны оныта алырмын дип уйлыйм.

– Озын һәм авыр? – дип сорады баш врач, миңа карамыйча. – Мин сезне аңлыйм шикелле. Мәскәүдә туып үстем мин. Әтием – проректор, әнием – кафедра мөдире. Икесе дә профессор, икесе дә медиклар. Мин аларның фәнни эзләнүләрен дәвам иттерергә тиеш идем. Мединститутны кызыл диплом белән бетердем. Аспирантурада миңа урын әзер иде инде. Ә мин тоттым да Котыпта йөрүче бозваткычка врач булып киттем. Әтием дә, әнием дә инфарктка юлыга яздылар. Ирем – диңгездә. Елына күп дигәндә ике-өч тапкыр күрешәбез. Тугызынчы класстагы бердәнбер улым мореходкага керү турында хыяллана. Мин каршы. Елый-елый үгетлим. Тыңламый. Мин сезне кисәтергә тиешмен. Диңгезчеләр «романтика» сүзен өнәмиләр. Шул сүзне ишетү белән, аларның чырайлары сытыла.

– Ул сүзне пропаганда пычратты, – дидем мин. – «Романтика» сүзен ишетү белән, палаткаларда туңып ревматизм эләктерү, баракларда бет ашату күз алдына килеп баса. – Баш врач мине аңлый иде. Мин ашыгып зарланырга тотындым: – Инвалидлыктан да мәсхәрәле нәрсә юк икән бу дөньяда. Бигрәк тә кызым каныга. Кибеттән азык-төлек күтәреп кайтсам, шундук үлчәп карый. Ярамый сиңа авыр күтәрергә, – дип ачулана башлый. Әгәр төнлә ютәлләп җибәрсәм, кызым шундук минем янымда. Әтием, әллә салкын тигердеңме? Ярамый бит сиңа салкын тигерергә. Әллә сөт кайнарлап китеримме? Әллә дару биримме? Инде түзәр хәлем калмады.

Баш врач миңа кәгазь кисәге сузды:

– Кардиограммагызны ясатып килегез, – диде ул һәм шәфкать туташына чираттагы авыруны чакырырга кушты.

## 11

Кардиограмма кабинетының ишеге янына чират тезелеп өлгергән иде. Мин дә барып бастым. Көтә башладым. Авыр, газаплы уйларның күбесе чиратта торганда килә. Медкомиссия вакытындагы врач белән пациент арасындагы көрәш турында уйлый башладым. Министрлыкта эшләгәндә, диңгезчеләр тормышының статистикасын өйрәндем мин. Сәүдә флотында эшләүче җитмеш меңгә якын диңгезченең һәр айда егерме биш-утызын каютага бикләп алып кайталар. Диңгез тормышының кырыслыгына түзә алмыйча акылдан язганнарның саны бу. Елына өч йөздән артык морякны, ике тимер мичкәне сварка белән бергә ябыштырып, шуның эченә салып алып кайталар. Бусы – юлда авырып үлүчеләр саны.

Җилкәнле караблар чорында диңгездә вафат булганнарны брезентка төреп, аякларына авыр тимер тагып суга җирли торган булганнар. Мин озак еллар су асты авы белән шөгыльләндем. Суга җирләнгән мәетне күз алдыма китерә алам: акулалар килеп эшкә тотынганчы, ул мәрхүм агымда аягүрә торып, чайкала-чайкала әкрен генә соңгы юлында баруын дәвам итәдер инде?

Мәетне мичкә эченә урнаштырып, автоген белән ябыштыргач, рефрежераторның бер камерасыннан азык-төлекне чыгаралар да мәрхүмне шунда урнаштыралар. Чайкалу вакытында тәгәрәп йөрмәсен өчен, бау белән тарттырып палубага беркетәләр. Шуннан соң карабның флагы флагштокның ярты өлешенә кадәр төшерелә. Карабта мәет барлыгын һәр диңгезче нервылары белән, бәгырь әрнүе аша тоеп тора. Шулкадәр авыр, ялыктыргыч тоела флагы яртылаш төшерелгән карабта йөзүе!

Яртылаш төшерелгән флагны көч-хәл белән күз алдымнан куып җибәрдем. Баш врач турында уйларга тотындым. Матур иде бу хатын. Мондый тәэсирле матурлык ана булу бәхетенә ирешкән, иреннән уңган, күңеленә ятышлы эш башкаручы хатыннарда гына очрый. Гәүдә һәм йөз-бит матурлыгына тышка бәреп чыгып торган акыл көче өстәлгәндә, гүзәллекнең тәэсире бермә-бер арта. Хатын-кыз акылы, әгәр дә ул акыл чын хатыннарныкы икән, бөтенләй башка төрле акыл. Ул ирләрдә сирәк очрый торган кылычтай үткен, кырыс мантыйк акылына охшамаган. Хатын-кызда – аналар акылы. Йомшак, җылы акыл. Ул сине юата, инандыра, көч бирә, тәвәккәллек уята. Хатын-кыз акылына наз да катнашкан була. Тән назы – секс түгел, анысы акылсызларда да очрый. Җанны, күңелне рәхәтләндерә, хозурлый торган җан эреткеч нечкәлек назы. Урта гасырлардан башлап җәмгыять менә шушы сирәк очрый торган хәзинәне – хатын-кыз акылын юкка чыгару өстендә армый-талмый эшләде. Көнбатыш тәрәккыяте шул бөек сыйфат урынына түшәктә кирәкле сыйфатлар тәрбияләде. Бездә, социализм төзү дәверендә, хатын-кыздагы йөк аты сыйфатларын гына калдырып, калганны төрле чаралар белән юкка чыгара килделәр. Әнә, минем янымда нәкъ йөк атына охшашлы хатын утыра. Беләкләр кыска, юан. Ботлар да шундый. Бил юк. Муен да юк. Баш турыдан-туры җилкәгә утыртылып куелган. Ул мескен тумыштан андый булмаган, билгеле. Менә аны кабинетка чакырдылар. Ишекне шапылдатып япканда стеналар дер селкенеп куйды.

«Йөк аты» чыккач, мин керергә тиеш. Һаман уйландыра. Мин бит инде өйләнгән кеше. Кызым үсеп җиткән. Гаиләмнән зарланырга хакым юктыр дип уйлыйм. Ә нигә соң күңел түрендә тонык кына, сизелер-сизелмәс ниндидер яшерен аңлашылмас бер билгесез өмет яши. Егет булып өлгерә башлагандагы беренче мәхәббәт белән бергә туган тынгысыз, сукыр бер омтылыш. Кайдадыр күңел түрендә бер матурның сурәте мыштым гына качып яши бирә. Инде күптән, алтынчымы, бишенчеме класста укып йөри башлаганнан бирле. Җир шарының

беренче гүзәле ул. Мин аны «Бөек Идеал» дип атап йөртәм. Матур кыз-хатын очраганда, шул Бөек Идеал ипләп кенә сорый: «Кем матуррак, улмы, минме?» Шушы көнгә кадәр Бөек Идеал белән ярыша алырлык хатын-кыз очраганын хәтерләми идем. Ә менә бүген баш врач кабинетында өстәл аша миңа каршы Бөек Идеал белән ярыша алырлык хатын утыра иде... Аның һәр сүзе, ымы, күз карашы, һәр хәрәкәте зур вакыйга булып минем хәтеремә сеңеп калды.

Эчемне ачыттырып, йөрәгемне әрнетеп «йөк аты» кабинеттан чыкты. Елый иде мескен. Димәк, социализм төзүдә мескенкәемне көне-төне камчылап куып, аны да имгәткәннәр. Без бит «якты киләчәк, бәхетле тормыш»ны төзүдә эштән чыгарылып ташланганнар – миллионнар…

Кабинетка үттем. Чишендереп, салкын клеёнка җәйгән ятакка яткырдылар. Беләкләремә, сыйракларга кургашын электрод бәйләделәр. Кардиограф эченнән бүселеп чыккан кәгазь тасмага йөрәгемнең тибеше языла башлады. Приборның тавышы мине кабат операция көненә кайтарды…

**12**

Үлгәнче котыла алмам шикелле бу сораудан: «Операция барышында мин яшәгәнменме, юкмы?» Йөрәге тибүдән туктагач, кеше үлә. Сигез сәгатькә якын минем йөрәгем тибүдән туктап торган. Димәк, сигез сәгатькә якын мин үлем кочагында булганмын. Дөрес, ул чакта йөрәк урынына канны тимер насос куып торган. Насос бит ул, моны сабый да белә, җансыз металл. Аның адәм баласына, кешенең яшәвенә бернинди катнашы юк. Юк, йөрәк кенә түгел, баш мием дә эшләүдән туктаган булган. Бусы инде катгый рәвештә минем Теге дөньяда булуымны раслый. Шул ук вакытта, врачлар миңа: «Син бөтенләй үлеп бетмәдең, кан әйләнеше эшли иде бит», – дип ышандырырга тырышалар. Ә мин аларга менә нинди сорау бирәм: «Әгәр адәм баласының йөрәген кисеп ыргытып, йөрәк урынына тимер насос тегеп куйсаң, ул кеше саналамы, әллә робот дәрәҗәсендәге механизмга әйләнәме?» Төрлесенең җавабы төрлечә.

Испаниянең Таррагона портында торганда, мин телевизор экраныннан йөрәккә операция ясаганны күргән идем. Америкада төшерелгән документаль фильм. Пациентны наркоз белән йоклаттылар. Дөресе, мәрткә җибәрделәр. Кырылган шәрә күкрәген бик озак спирт белән юдылар да йод сөрттеләр. Хирургның ассистенты җыйнак кына циркуляр электропычкы белән күкрәк сөякләрен нәкъ бугаз турыннан кендеккә кадәр ярып җибәрде. Ярадан ургып чыккан канны резин көпшә аша насос белән суыртып торалар иде. Махсус тиски белән күкрәк сөяген ике якка аерырга тотындылар. Хирург, кулын пациентның астына тыгып, умыртка сөяге турыннан кабыргаларны тикшереп тора иде. Белмим, кабыргалар чатный башладымы, ул ымлап аеруны туктатырга кушты. Күкрәк эченә җыелган кан эчендә пациентның йөрәге тыпырчынып тибә иде. Йөрәкне сак кына тышка чыгардылар һәм зур дикъкать белән кан тамырларын өзеп, «ясалма йөрәк»кә тоташтыра башладылар. Бераздан йөрәк тибүдән туктады. Хирург, аның ярдәмчесе һәм инструмент биреп торучы шәфкать туташы операциягә керештеләр.

Адәм баласының иң кадерле, иң газиз әгъзасы, кешегә җан өреп, аны кешелек сыйфатында тотып торучы йөрәкне скальпель белән яргалап, нәрсәнедер кисеп алалар, аңа нәрсәдер тегәләр иде. Йөрәксез калган бәндә ята бирә. Аның гәүдәсе җансыз. Ясалма сулыш аппараты пациентның үпкәсенә һава өрә һәм кире суырып чыгара.

Ул чакта операцияне азагына кадәр карарга түземем җитмәде минем. Телевизорны сүндереп, кают-кампаниядән чыгып киттем. Пациент яткан өстәл,

аның өстенә япкан көрәнсу җәймә, хирургларның перчаткалары – барысы да канда йөзә иде. Операциягә әзерләнгәндә дә, операциядән соң торып йөри башлагач та, шул канга батып яткан пациент урынында үземне күреп күп тапкырлар газапландым мин. Менә әле дә, Мурман дигезчеләренең поликлиникасында кардиограмма ясатканда, нәкъ шул йөрәкне телгәләү күз алдымда тора иде.

Торып киендем. Врач кардиограмма тасмасын кулыма тоттырды. Мин баш врач кабинетына юнәлдем.

**13**

Кардиограмманы карап чыккач, баш врач өстәл тартмасыннан кәгазь алып язарга кереште. Кәгазьнең өске өлешенә ташка басылган хәрефләр белән поликлиниканың баш врачы биргән рәсми документ расланган иде. Аста имза һәм мөһер урыннары билгеләнгән. Совет кешесенең язмышы кәгазьдә. Хакимият кирәк-ярагын үти торган мең төрле рәсми кәгазь бар бездә. Баш врач яза. Мин көтәм.

Язып бетергәч, баш врач кул куйды. Өстәл тартмасын кабат ачып, мөһер чыгарды. Мөһерне имзасы янына басып бер тын тотты да кәгазьне миңа сузды:

– Хәерле юл, Рахманкулов, – диде ул, миңа аңлашылмас караш ташлап. – Карабыгыз астында җиде фут тирәнлек булсын.

Нигә соң ул миңа рөхсәт бирүнең җаваплылыгы турында киная ясамады. Нигә куркуын яшерде? Ә бит беренче килүемдә Вентспилс поликлиникасының баш врачы – баһадир кыяфәтле мыеклы ир мине бүре куган шикелле итеп кабинетыннан куып җибәргән иде.

Язуны кулыма алгач, сүзсез калдым мин. Әйтергә сүз табып булмый иде. Рәхмәт? «Спасибо в рюмку не нальеш», – дип кенә җибәрәләр урыслар бу сүзне ишетү белән. Югалып калдым. Бәлки кирәк булыр дип сумкама бер тартма кыйммәтле конфет салып килгән идем. Әгәр шуны чыгарып баш врачка тәкъдим итә башласам, ике арада барлыкка килгән изге тойгылар пычраначак. Бәлки, тиз генә базарга барып чәчәк алып килергәдер? Кызганычка каршы, чәчәк бәйләме дә инде күптән ришвәткә манчылып пычранды. Чәчәкне бит арада рәсми мөнәсәбәт булмаган очракта гына бүләк итәргә була. Онытырга тырышабыз без бу кагыйдәне. Акыллы хатын бу турыда белә торгандыр. Мондый изге, пакь мохиткә бернинди матди нәрсә катнашмаска тиешлеге ярылып ята иде. Шул ук вакытта, нәрсәдер эшлисе, үземнең шушы бөек һәм изге гамәлгә лаеклы булуымны күрсәтәсем килә иде. Урта гасырлар, Ләйлә һәм Мәҗнүн чоры, Артур корольнең рыцарьлары чоры искә төшә. Җан сыкрый...

Бугазга тыгылган төерне, күздәге кайнарлыкны яшерергә тырышып, тыныч кына саубуллаша башладым. Баш врач миңа кулын сузды һәм...

– Сез, Рахманкулов, Кырым татарымы, әллә Казанныкымы?

– Казан татары мин, – дидем, сорауның мәгънәсенә төшенеп җитмичә.

– Минем әбием, әтиемнең әнисе, Кырым татары кызы иде. Шуның тәрбиясендә үстем мин. Искиткеч матур иде. Затлы нәселдән. Әбиемнең туганнары егерменче елларда чит илгә киткәннәр.


Мондый сүзләрне мин инде күпме еллар, ничә тапкыр ишетәм. Ишетәм һәм югалып калам. Җавап юк, аңлатма да юк бу сүзләргә. Бәгырь ачытканын сизәсең. Милләтнең иң матур, иң акыллы, иң таза вәкилләре сазлыкка суга ыргытылган асылташ шикелле шул тарафка китеп бара, югала тора. Туктатырга көч тә юк, чара да... Каршы чыгарга, туктатырга теләүче дә юк – битарафлык. Урамда күкрәгемне тутырып һава суладым, һәм озак тыелган күз яшьләре тышка бәреп чыкты…

*1997, №8*

# НИНДИ ҖИР УЛ СУСЛОНГЕР?

Сталинград өчен барган сугышларда 1942 елның җәй башларында каты яраландым. Казан госпиталендә өч ай буе дәваланырга туры килде. Шуннан соң безне, берничә кешене, Мари АССРның Суслонгер тимер юл станциясенең ике-өч чакрымлы урман эчендәге запас полкка җибәрделәр. Хәер, анда берничә полк булган икән.

Безне гаҗәпләндергәне шул: ни өчендер солдатлар кәефсез йөри. Үзләре бик ябык, хәлсезләр, барган җирләрендә сөртенеп егылалар. Килү белән 2нче батальонның 4нче ротасына беркеттеләр. Кичен яртылаш җир астына иңгән ашханәгә алып бардылар. Ике такта киңлегендәге озын өстәлгә иллешәр кеше утырдык. Ун кешегә биш литр сыешлы кәстрүл белән кәбестә шулпасы, дөресрәге, кайнаган су, 200 грамм дип исәпләнсә дә, 100 граммнан артмаган икмәк сыныгы – башка нәрсә юк. Бер рота солдатлык землянкага 240-250 кеше шыплап тутырыла. Иртәнге физзарядка дигәне: 3 чакрым йөгереп барып, берәр метр итеп киселгән ике утын пүләнен бил каешына бәйләп алып кайтасың. Кәбестә баландасыннан соң – тагын урманга. 3-4 километрга дүртәр тапкыр барабыз. Кайбер ротадагыларны 15-17 километрга да йөртәләр. Алты кеше бер бүрәнәгә ябышасың. Озынлыгы 6,5 метр, юанлыгы 25-30 сантиметрлы агачны иңбашына күтәреп ташыйсың. Кешеләр барган җирдән егылып та үлә.




Ашау-эчү начар дигән идем. Без ит, май, шикәр ише әйбер күрмәдек. Икмәккә туймадык. Шул сәбәпле кырылды солдатлар. Иртә торышка землянкадан һәр көнне 4-5 мәет чыгарылды. Ә бит землянкалар саны 23 иде бугай. Димәк, көн саен йөздән артык кеше үлеп торган.

Моң-зарыбызга колак салмадылар. Ашханә янындагы черегән бәрәңге кабыгын җыеп ашаган өчен дә җәзалыйлар иде. Мондый гөнаһым өчен мине дә штабка алып кайтып, өч тәүлек гауптвахтада утырттылар. Хатларыбыз бик нык тикшерелеп кенә чыгарылды. Үзебезгә килгәннәрен дә энә күзеннән үткәрделәр.


Шулай бервакыт безне урман эчендәге станциягә продуктлар бушатырга алып киттеләр. Бик куаныштык, тамак туяр дип өметләндек. Кая ул! Тимер әрҗәләргә, капчыкларга тутырылган әйбер брезент белән яхшылап томаланган. Алып та, эчендә ни барын белеп тә булмый. Үткен генә бер рус егете качып-посып кына капчыкны тешләп тишкән. Киптерелгән икмәк, ди. Күгәрә дә башлаган. Булдыра алганча тутыра бу сохариларны. Безне шуның белән сыйлады. Соңыннан солдатларга дигән әлеге сохарины җиргә күмделәр.

Мин үзем Суслонгер лагеренда 28 көн тордым. Әгәр тагын бераз яшәсәм, аяк сузган булыр идем. Сугышка дигәч, шатланып киттем. Юлда хәлсез солдатларны өстәмә паёк биреп тергезделәр. Мәскәү янындагы урманлыкта унбиш көн буе өстәмә норма белән тукландырдылар. Шуннан соң гына Көнбатыш фронтка җибәрделәр.

Суслонгер турында соңыннан ишеткәләдем. Әгәр хак булса, анда К.Е.Ворошилов килгән икән. Чөнки лагерьда калган солдатлар безнең аша югарыгы оешмаларга хат язып җибәргәннәр иде. Комиссия шул нигездә килгән. Корткычлык булган икән. Күп офицерлар атылган. Ләкин бу чакта чутсыз гына солдатлар да якты дөнья белән бәхилләшкәннәр иде шул инде... Исән калуыбызга куанып явыз дошманны ачу белән кыйнадык һәм җиңдек.

Шулай да Суслонгер хәлләре һич истән чыкмый. Дошманга сатылган явыз җаннар безнең халыкны күп кырды анда.

**Мөхәррәм ШӘРИПОВ**



*Сугыш фронтын да, тыл «фронтын» да исән кичә алган М.Шәрипов. Сугыштан соң төшкән фоторәсем.*

**Редакциядән:**

Бу тетрәндергеч хәлләрне сугыш ветераны кәгазьгә төшергән. Гомеренең төп өлешен Биектау районының Зур Көек авылында үткәргән Мөхәррәм агайны күп еллар дәвамында әлеге хәлләрнең сер булып кала килүе дә борчыган. «Төп әйтәсе килгән сүзем шул: Суслонгер вакыйгасын матбугат битләрендә киңрәк яктыртасы иде, – дигән ул. – Андагы «сират күпере»н кичкән һәм исән калган солдатлар бүген дә бардыр бит әле? Аларның сүзен дә ишетәсе килә». Ошбу теләк Мөхәррәм агайның вафатыннан соң да мөһимлеген җуймагандыр.

Чыннан да, бу төбәктәге фронтка кадрлар әзерләү лагере турында мәгълүматларның рәсмиләре генә түгел, рәсми булмаганнары да бик аз икән шул.

Гаҗәп хәл, хәбәрсез югалган сугышчыларның язмышын, һәлак булганнарның күмелү урыннарын ачыклау, бу хакта аларның туганнарына хәбәр итү дәүләт органнарына бөтенләй кагылмый диярсең! Хәер, кешенең кадере булмаган, халкын йөзәрләп-меңәрләп дәүләт үзе юк иткән илдә гаҗәп үк тә түгелдер.



*Суслонгер урманнары*

Шөкер, моның белән, бер катышлары да булмаган килеш, үзләре теләп шөгыльләнгән фидакарь затлар да бар әле. Михаил Черепанов кырык елдан артык бу эшнең башында тора. (Әлеге изге «чир»нең аңа инде Казан университетының тарих-филология факультеты студенты чагында ук йокканын беләбез.) Унбиш еллап элек Казан һәм Яшел Үзән фидакарьләреннән торган эзләнү төркеме Суслонгерга да килеп чыга. Михаил язганнардан («Отечество» журналы, 1999, №3) тәрҗемәдә берничә өзек китерик әле.

«Бу лагерь 1941 елның июленнән 1943 елның ноябренә кадәр генә эшли. Ачлыктан, суыктан, төрле чирләрдән меңнәрчә кеше үлә. Һәм алар хәзергәчә хәбәрсез югалганнар исәбендә... 1943 елның ноябрендә Суслонгерга инспекция белән К.Е.Ворошилов килә. Лагерьның шундый хәлдә булуына гаепле кешеләр каты җәзага тартыла, лагерь үзе исә бетерелә». «Лагерьның төп бурычлары пулемёт взводы командирлары әзерләү һәм урыс булмаганнарны фронт өчен урыс теленә өйрәтү була. Шуңа күрә лагерь курсантларының төп өлешен татарлар, башкортлар һәм Идел буеның башка халыклары тәшкил итә». «Күршедәге (Кундыштагы һ.б.) шундый лагерьларда исә мондый хәлнең әсәре дә булмый».

Шаккатмалы хәл! Совет солдатларын үтерү лагере (Сталин заманында!) 28 ай буена эшләп тора алсын әле! Ихтыярсыздан башка шундый бер уй килә: моның халыкка беркайчан да җиткерелмәячәк яшерен максаты булмады микән? Мәскәүнең үз сәясәтенә, ә бәлки, милли сәясәткә дә кагылышлы максат?

*2013, №12*

Булат
Солтанбәков

# ТАТАРЛАР һӘМ ИГНАТЬЕВ*

…Без, гади партия әгъзалары, партия өлкә комитетының беренче секретаре З.И.Моратовның эштән алынуын авыр кичердек. Ул гадилеге, кешеләрне тыңлый белүе, эчкерсезлеге белән хәтердә уелып калды. Югары түрәләр алдында бик бил бөгәргә дә яратмый иде. Аңа алмашка Семён Денисович Игнатьев килде. Татарстан тарихында гаять тирән эз калдырып киткән олуг шәхес ул.

1957 елның июнендә үткән өлкә комитеты пленумында А. Б. Аристов ҮК исеменнән С.Д.Игнатьевны беренче секретарь вазифасына тәкъдим итә һәм, гадәткә кергәнчә, ул бертавыштан раслана…

* * *

…Язмабыз каһарманының мәктәпләрдә татар теле статусын яңадан торгызуга уңай карашын онытасыбыз юк. Ул вакытта мин өлкә комитетында фән һәм мәктәпләр бүлеге инструкторы булып эшли идем. Әлеге олуг мәсьәләне хәл итүдә миңа да беркадәр катнашырга туры килде. Чөнки киеренкелек тулы бу хәлләр документларда тулы килеш теркәлмәгән, өстәвенә, матбугатта чынбарлыктан ерак торган мәгълүматлар да басылгалый.

Ул чактагы вазгыятьне кыскача болай дип аңлатырга мөмкин. Татар халкының рухи тормышын мәҗбүриләп дигәндәй «интернациональләштерү» телнең йотылуына китерде. Ул укыту, фән һәм эшлекле аралашу даирәсеннән ерагайды, 20нче – 30нчы еллар башындагы татар теленә җентекләп өйрәтүче байтак кына милли сәясәт казанышлары юкка чыкты. Ул чакта бит югары уку йортларында татар телендә укыту группалары бар иде. Кайбер структураларның җитәкчеләре тикшерелгән нәрсәләрне аңлау кимәлендә булса да татар телен белергә тиеш иде. 30нчы еллар ахырында да әле өлкә партия конференциясендә отчёт докладлары ике телдә ясала иде...

1954 ел ахырында республика мәгариф министры Әминә Вәлиуллина татар мәктәпләрендәге хәлне пленумда карыйк дигән үтенеч белән Игнатьевка мөрәҗәгать итә. Бу уңайдан Игнатьевның үзен ничек тотуы хакында хәзер тәгаен нидер әйтү кыен. Ләкин өлкә комитетының ул чакта татар теленең элекке статусын кайтаруның аңардан да активрак пропагандисты булмый. Игнатьевны КПСС ҮКның бүлек мөдире урынбасары В.Н.Дербинов та яклап чыга, Казанга килгәч, өлкә комитетының бу җәһәттән тырышлыгын ленинчыл милли сәясәтне гамәлгә ашыруның тарихи үрнәге дип бәяли.

Партия өлкә комитетының 1958 елның 21 маенда үткән пленумы бу эшнең иң югары ноктасы була. Аның көн тәртибенә «татар гомуми белем бирү мәктәпләрендә эшнең торышы һәм аны яхшырту чаралары турында»гы мәсьәлә куела.

---

* Басылган мәкаләдән өзекләр бирелә.

Доклад белән өлкә комитеты секретаре К.Ф.Фасеев чыгыш ясый...

Татар мәктәпләре турындагы мәсьәләне пленум тикшерүенә куйганда, Фасеев «татарлаштыру» процессын – аның ин тыйнак вариантында – элекке хәлгә кире кайтып булмаслык итәргә омтылды. Баштарак хәтта Игнатьев үзе дә моны әүвәлге милләтчелек шаукымы димәсләрме дип шикләнеп калды. Чөнки «милли мәдәният» төшенчәсен реаль эчтәлек белән баетырга омтылганнары өчен система тарафыннан юк ителгән Солтангалиев, Мохтаров, Брундуков, Мансуров һәм Галимҗан Ибраһимов кебек каһарманнарның күзгә күренмәс сыннары 40 елдан соң янә шушы эшкә тотынучыларның аңында яңарды. Ләкин сәяси «җепшеклек» рухы өметкә дә урын калдыра иде...

Фасеевның татар мәктәпләрендәге хәлнең торышы, киңрәк мәгънәдә тел һәм мәдәният язмышы турындагы докладын бүген дә кызыксынып укыла. Аны Лениннан күпләп китерелгән өземтәләргә таянып, татар мәктәбенең үлеменә китерүче вазгыятьнең түзеп тормаслык булуын виртуозларча осталык белән исбатларга тырышу дип әйтергә кирәк. Фасеев тарафыннан китерелгән мәгълүматлар чәчләрне үрә торгызырлык... Әгәр 1947-1948 елларда татар балаларының 95 проценты туган телендә укыса, 1958 елда бу – 70 процентка, Казанда исә 16 процентка кала. Шәһәрдә 16 татар мәктәбенең нибары икесе исән, алары да соңгы көннәрен яши...

Язучы Гомәр Бәширов шактый кискен чыгыш ясый. Хакимият ияләренә һәм татар зыялыларының үзләренә шелтә белдерә. Туган телебезгә югарыдан түбәнсетеп караудан туктарга вакыт, дип кисәтә...

Иң мөһиме, башка ораторлар да тәнкыйть күзлегеннән чыгыш ясадылар. Әмма барысы да Дербинов белән Игнатьевның чыгыш ясауларын көтә иде. КПСС Үзәк Комитетының бүлек мөдире докладның тәнкыйди рухын саклап, хәтеремә уелып калган мондый мисал китерде – татар мәктәпләрендә укучыларның нибары 12 проценты гына 10 класска хәтле барып җитә икән, бу рус мәктәпләрендәгедән ике тапкыр кимрәк. Әмма иң үткен, иң аяусыз чыгыш Игнатьевның кыскача йомгаклау сүзе булды: «Эшләр түзеп тормас дәрәҗәдә начар бара. Без чынлыкта татар мәктәпләренең бетү куркынычы алдында торабыз... Мин Фасеев докладындагы һәм карар проектындагы фикерләр һәм нәтиҗәләрне тулысынча хуплыйм». Игнатьев үзенә манёвр өчен урын калдырмый, ул киләчәктәге карьерасы язмышын кузнага куя... Мөгаен, Г.Бәширов аның хакында: «Шушы рус җитәкчесе теләсә кайсы татарга караганда безгә күбрәк эшләде», – дип әйтүе белән хаклыдыр да. Игнатьевның татар иҗат әһелләре белән очрашуыннан соң Нәкый Исәнбәт тә шундыйрак фикер әйтте. Игнатьев бик кыю адымга барды. Г.Тукай исемендәге премия булдыруга рөхсәт бирде. Бу исә Мәскәүгә бер дә ошамады. Чөнки үзәктәге кайбер идеологлар фикеренчә һәм Мәскәүнең җирле куштаннары әйтүенчә, шагыйрь әсәрләреннән милләтчелек рухы бөркелеп тора икән.

Йомгаклау сүзендә Игнатьев милли үсеш һәм тел проблемалары аны күптәннән борчуын, ләкин бүген бу хакта инде барысы да ишетерлек итеп әйтергә мөмкинлек тууын бәян итте һәм бик ачынып болай дип өстәде: «Мин шундый нәтиҗәгә килдем: эшләр чынлап та бик мөшкел. Без татар мәктәбенең асылда юкка чыгарылу куркынычы алдында торабыз.» Кайдадыр кухняда яисә дус-ишләр арасында түгел, ә өлкә комитеты пленумы трибунасыннан әйтелгән шушы сүз өчен генә дә С.Д.Игнатьев исеме татар мәдәнияте тарихында калырга тиеш...

***

Мәскәүдә бик тә югары кимәлдә, уйлавымча, Сусловтан түбәндәрәк булмас, «татар экспериментын» туктатырга дигән карар кабул ителә...

Фасеевның фаразына караганда, барысы да Моратовның өлкә комитетына юллаган вәрәкасеннән (записка) башланган. Ул анда Фасеевны милләтчелектә, өлкә комитеты бюросын исә аның кубызына биюдә гаепли. Хәлбуки, бу кәгазьнең һәм шуңа ияртеп җибәрелгән, өлкә комитеты карарын яңадан тикшерергә тәкъдим иткән хатның һаман табылганы юк әле...

Игнатьевның сәяси карьерасы ахырына якынлашты. Монда инде Аристов та ярдәм итә алмый иде, бәлкем, теләмәгәндер дә... Игнатьевка кешечәрәк китү, әйтик, Монголиягә илче булып бару вариантын тәкъдим итәләр. Ләкин ул сәламәтлеге аркасында отставкага чыгуны артыграк күрә. Юкса аңа 56 гына була әле.

Шул рәвешчә, татар телен һәм татар мәктәбен җәмгыять тормышының тулы хокуклы компоненты итәргә тырышудагы икенче омтылыш та (беренчесе 20нче еллар башында ясалды) һәлакәткә дучар булды…

Тормыш исә ага бирә: өлкә комитетның яңа җитәкчелеге Тукай бүләге тапшыруны туктата (туктатып тора. – *Ред.*) һәм «тугрылыклы хезмәт итүнең» башка төрле адымнарын да ясый. Фасеев әнә Табиевның әхлак кагыйдәләрен бозуы турында яза. Нәрсәгә ишарәләвен әйтә алмыйм, әмма беренче секретарь Мәскәү алдында тәлинкә тотуда ай-яй оста һәм елгыр булды. Республиканың Игнатьев чорында «тапланган» абруен «аруларга» кирәк була бит. Шул җәһәттән өлкә комитетының 1960 елның октябрендә үткәрелгән пленумында Табиев, «Татар теленең ролен һәм әһәмиятен күпертеп күрсәтүнең мәгънәсе юк, шулай эшләргә маташучыларны гаепләргә кирәк», – дип искәртте. Фасеев язуынча, Табиев тагын 15-20 елдан татар теле бетәчәк дип фараз кылган, моны ул тар даирәдә түгел, өлкә комитеты пленумнарының берсендә әйткән...

*2008, №12*

# БЕРДӘМ БУЛЫЙК!*


...Әмма быелгы халык санын алу республикаларның болай да юк дәрәҗәсендәге мөстәкыйльлеге тәмам бетерелеп, милли мәгариф бик нык тарайтылган бер чорда үткәрелә. Халык исәбен алуны да шушы максатка ярашлы итеп үткәрү куркынычы бар. Коткыга да, басымга да, мәкер-хәйләгә дә бирешмик, газиз милләттәшләр! Тарихи бергәлегебезне, бердәмлегебезне саклыйк! Җавап бер һәм аермачык булсын: без – татарлар, туган телебез– татар теле. Шуны тирән аңларга кирәк: бербөтен татар милләтенеке булу үз кавемеңнең этник-этнографик төркеменнән йөз чөерү түгел ул. Без бергә булганда гына үзенчәлекле тарихи этник-этнографик йөзебезне, ягъни туган телебезне, мәдәниятебезне һәм гореф-гадәтләребезне саклап калачакбыз. Моны балаларыбыз-оныкларыбызга да аңлатыйк. Безне олы тарих, уртак әдәби тел, уртак культура, уртак яшәү рәвеше берләштерә.

«Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар», ди милли уртак мәкалебез. Аң булыйк: киләчәгебез кыл өстендә торган бу чорда безне берәү дә сакламаячак та, якламаячак та. Моны без бары үзебез генә, бер йомгак булып тупланып кына эшли алабыз. **Бергә булыйк! Бердәм булыйк!..**

*2010, №6*

---

* Октябрь аенда үткәреләчәк халык исәбен алу уңаеннан Татарстан язучыларының татар халкына мөрәҗәгатеннән өзек.




# «Рухи тормышыбыз энциклопедиясе»

*«Казан утлары»ның меңенче саны чыгу уңаеннан «Сүнмәс утлар балкышы» дигән китабыбыз нәшер ителүгә (2006 ел, декабрь) җиде ел тулды. Бу вакыт эчендә китап Татарстан һәм Россиянең барлык төбәкләренә дә диярлек барып иреште, Төркия, Англия, Америка, Австралия, Кытай кебек илләргә дә юл тапты. Аның турында матбугатта бик матур фикерләр әйтелде. Менә аларның кайберләре.*

**Айдар Хәлим,**
**язучы:**

– Үткән һәм килгән еллар чигендә төрки-татар халкы тарихында, юк, бөтен дөньяның мәдәни харитәсендәдер, чын-чынлап кабатланмас, гаҗәеп вакыйга булды: бик шәп проза, новеллистика, поэзия, публицистика, фотоиллюстрацияләрнең һәм иҗади фикер документларының яраткан журналыбыз «Казан утлары»ның бер түбә астында берләштерелгән бик зур, 90 табаклы томы дөнья күрде...

*Звезда Поволжья. 2007, 7 март*

**Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ,**
**филология фәннәре докторы, профессор:**

– Китапларның төрлесен күргән, «Казан утлары»н да бик күптәннән укып барган кеше буларак, бу басманы мин, йә, ни майтардылар икән дигәндәй, скептик рәвештәрәк кулга алдым һәм... исләрем-акылларым китте. Чын мәгънәсендә бер хәзинә бу...

Журналның гына түгел, ә гомумән, татар рухи тормышының, милли яшәешенең бер белешмәсе, чыганагы, энциклопедиясе, хрестоматиясе кебек тә ул.

*Мәдәни җомга. 2007, 2 март*

**Рафаэль МОСТАФИН,**
**әдәбият белгече, тәнкыйтьче:**

– Татар әдәбиятының бу үзенчәлекле антологиясен укыганда тулы бер дәверне яшәп чыккан кебек буласың, еш кына катлаулы һәм авыр, кайчакта исә фаҗигале дә булган вакыт сулышын тоясың.

*Звезда Поволжья. 2007, 31 май*

**Адлер ТИМЕРГАЛИН,**
**язучы:**

– Теземдә кызыл мәрмәрдәй саллы том – үзе бер китапханәгә бәрабәр «Сүнмәс утлар балкышы». Мин бу утларның саллы җылысын тезләрем белән дә, күңелем белән дә тоям... Әгәр дә мәгәр бер мәлне мине адәм заты яшәми торган утрауга озатасы булып, үзем белән ун китап алырга рөхсәт итсәләр, шуларның берсе, һичшиксез, «Сүнмәс утлар балкышы» булыр иде.

*Казан утлары. 2008, №1*

**Булат СОЛТАНБӘКОВ,**
**тарихчы:**

– Дәвер тарихы – бу уникаль басманы шулай дип атыйсы килә... Аның гомере озын буласына һич шикләнмим. Татар мәдәниятенең үзенчәлекле бер энциклопедиясе булган ошбу китап бөтен уку йортларыбызда һәм китапханәләребездә булырга тиеш.

*Республика Татарстан. 2007, 29 май*

**Китапның төзүчесе – Рәфикъ ЮНЫС,**
**шеф-мөхәррире – Равил ФӘЙЗУЛЛИН**
*2013, №12*

## Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белән Татарстан Республикасы Язучылар берлеге игълан иткән иҗади конкурсның НИЗАМНАМӘСЕ

Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белән Татарстан Язучылар берлеге бүгенге авыл тормышын, авыл хуҗалыгы һәм эшкәртү сәнәгате хезмәтчәннәре эшчәнлеген, җир кешесенең рухи-әхлакый дөньясын һәм авылда бара торган иҗтимагый-социаль процессларны яктыртуга багышланган чәчмә әсәрләргә конкурс игълан итә.

Бәйге ябык тәртиптә үткәрелә. Псевдоним-тәхәллүс белән имзаланган әсәрләр компьютерда җыелган һәм электрон вариантта булырга тиеш. Автор турындагы белешмә (фамилиясе, исеме, атасының исеме; туган елы; яшәү урыны һәм телефоны) аерым конвертта җибәрелә. Конкурска моңарчы матбугатта басылмаган яңа әсәрләр кабул ителә.

Бәйгедә Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы булмаган, авыл җирлегендә яшәп иҗат иткән каләм ияләре дә катнаша ала. Андый авторлар үз тәхәллүсләре янәшәсендә (җәяләр эчендә) «Авыл» дигән шартлы билгене дә өстәп язарга тиеш.

Конкурс өч номинациядә үткәрелә:

**1. Повесть.**

**2. Хикәя.**

**3. Әдәби очерк.**

Бәйге портфелендәге әсәрләргә Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Язучылар берлеге вәкилләре катнашындагы махсус жюри бәя бирәчәк.

Һәр номинациядә өчәр урын билгеләнә.

Җиңүчеләргә түбәндәге акчалата бүләкләр каралган:

**«Повесть» номинациясендә**
I урын – 150 000 сум
II урын – 100 000 сум
III урын – 50 000 сум


**«Хикәя» номинациясендә**
I урын – 100 000 сум
II урын – 70 000 сум
III урын – 30 000 сум

**«Әдәби очерк» номинациясендә**
I урын – 50 000 сум
II урын – 30 000 сум
III урын – 20 000 сум

Конкурска тәгаенләнгән әсәрләр Татарстан Язучылар берлегенә (420012, Казан шәһәре, Мөштәри урамы, 14нче йорт) 2017 елның 31 августына кадәр җибәрелә.

Җиңүчеләргә бүләкләр Авыл хуҗалыгы һәм эшкәртү сәнәгате хезмәтчәннәре көнендә тапшырылачак.

Бәйге турында өстәмә мәгълүматларны Татарстан Язучылар берлегеннән (843) 236-97-71 телефоны аша алырга мөмкин.



# Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## ТАТАРСТАН ХАЛЫКЛАРЫ СЪЕЗДЫ

Казанда Татарстан халыкларының III съезды булып узды. Мең кеше катнашындагы әлеге зур чарада Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов, Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан халыклары ассамблеясы советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Дагыстан Республикасы башлыгы Рамазан Абдулатыйпов, Россия Федерациясе Президенты администрациясе җитәкчесе урынбасары Магомедсалам Магомедов, РФ Дәүләт Думасы Рәисе урынбасары Владимир Васильев, Россия халыклары ассамблеясы советы рәисе Светлана Смирнова катнашты. Съездда тынычлыкны, милләтләр дуслыгын, халыкларның телен, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен саклау турында зур сөйләшү булды.

## МИНТИМЕР ШӘЙМИЕВ – РОССИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ ГЕРОЕ

РФ Президенты Владимир Путин Указы белән дәүләт һәм халык алдында хезмәттәге казанышлары өчен ТР Дәүләт Киңәшчесе, «ТРның тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне торгызу фонды» Попечительләр советы рәисе Минтимер Шәймиевкә Россия Федерациясенең Хезмәт Герое исеме бирелде. Минтимер Шәймиевне ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов котлады.

## ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ ТУУЫНА – 131 ЕЛ

Г.Тукайның туган көнендә Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов Казандагы Тукай скверында шагыйрьнең һәйкәленә чәчәк салды. Чәчәк салу тантанасында ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, ТР Президенты аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәров, Казан мэры Илсур Метшин, ТР хакимияте әгъзалары, министрлыклар, ведомстволар җитәкчеләре, Дәүләт Советы депутатлары, әдәбият, сәнгать әһелләре, фән эшлеклеләре һ.б. катнашты.

***

Казанда М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында Туган тел көненә һәм Г.Тукайның тууына 131 ел тулуга багышланган бәйрәм булды. Тантанада Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенең быелгы лауреатлары игълан ителде. Олуг бүләккә роман, повесть, хатирәләрне үз эченә алган «Арыш тәме» китабы («Ихлас» нәшрияты, 2014) өчен – Мәдинә Габделхак кызы Маликова , «А.Пушкин, Г.Тукай иҗатында дөньяви һәм дини мотивлар һәм бүгенге көндә әхлакый тәрбия бирү проблемалары» («Идел-пресс» нәшрияты, 2008), «Дин һәм фән (дөньядагы дини һәм дөньяви мәдәният нигезләре)» җыентыклары («Идел-пресс» нәшрияты, 2015) өчен – Харис Салих улы Салихов, Татарстанның милли-мәдәни мирасы турындагы «Мәңгелек гөлчәчәкләре: татар һәм рус телендәге язмалар» дип аталган хезмәте («Заман» нәшрияты, 2015) өчен Розалина Гомәр кызы Шаһиева лаек булдылар. ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов аларны ихлас котлады, һәркайсына диплом һәм күкрәк билгесе тапшырды. Тантанада ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, ТР Президенты аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәров, ТР Дәүләт Советы депутатлары, хөкүмәт әгъзалары, министрлыклар, ведомстволар җитәкчеләре, әдәбият, сәнгать әһелләре, Казан кунаклары катнашты.

***

Г.Тукайның Татар дәүләт опера һәм балет академия театры янындагы һәйкәле каршында Шигырь бәйрәме булып узды. Башта язучылар, бәйрәм кунаклары шагыйрь һәйкәленә чәчәкләр салды. Аннары Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенең быелгы лауреатларын котладылар. Шигырь бәйрәмендә кунаклардан Башкортстан Фәннәр академиясе президенты Әлфис Гаязов, Башкортстан Язучылар берлеге рәисе Зәки Алибаев, шушы берлекнең әгъзасы, шагыйрә Лариса Абдуллина, Удмуртия Язучылар берлеге рәисе Пётр Захаров, Марий Эл Язучылар берлеге рәисе Светлана Архипова, Кыргызстан Язучылар берлеге әгъзасы Гөлҗегет Соронкулов, Кырым Язучылар берлегенең җаваплы сәркатибе Диләвер Осман, шагыйрьләр Разил Вәлиев, Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Рәдиф Гаташ, Гәрәй Рәхим, Роберт Миңнуллин, Зиннур Мансуров, Мөхәммәт Мирза, Ркаил Зәйдулла, Газинур Морат, Ләбиб Лерон, Рәмис Аймәт, Шәмсия Җиһангирова, Флёра Тарханова, Рифә Рахман, Рифат Җамал, Хәнәфи Бәдигый, Наил Касыймов, Борис Вайнер, Нәҗибә Сафина, Рүзәл Мөхәммәтшин, Булат Ибраһимов, Фәнил Гыйләҗев, Альбина Әпсәләмова һ.б. чыгыш ясады. Шигырь бәйрәмен Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов белән Флёра Абдуллина алып бардылар. Г.Тукайның тууына 131 ел тулу уңаеннан тантаналар Арча, Балтач районнарында да булды.

## ТУГАН ТЕЛ ФОРУМЫ

Казанда, Баскет-холлда татар теле форумы булып узды. Ул быел Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы инициативасы белән үткәрелде. Тантананы 3500дән артык кеше тамаша кылды. Форум кысаларында татар теле һәм әдәбияты буенча V халыкара олимпиадада җиңүчеләр бүләкләнде. Бу бәйгедә дөньяның 15 иленнән, Россиянең 25 төбәгеннән һәм республикабыз районнарыннан 500ләп укучы катнашты. Гран-прига Накамура Мидзуки (Япония) һәм Ризәлә Юсупова (Татарстан, Саба, Эзмә) лаек булды. Аларга бүләкләрне ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов тапшырды һәм җиңүчеләрне котлады. Аннары сәхнәгә яшь каләм ияләренең «Илһам» иҗат бәйгесендә җиңүчеләр күтәрелде. Аларны ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Журналистлар берлеге рәисе Римма Ратникова белән Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов котлады. Гран-прига Азнакайдан Инзилә Хөсәенова лаек булды. Бәйрәмдә милли белем һәм тәрбия бирүдә иң яхшы эшләүче укытучыларны, тәрбиячеләрне, мәктәпләрне һәм балалар бакчаларын да игълан иттеләр. Сәхнәдә котлау сүзен ТР мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттахов һәм Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Ренат Закиров ирештерде. Тантанада «Татар теле-онлайн» бәйгесендә җиңүчеләрне дә котладылар.

## КОНФЕРЕНЦИЯ

ТР Фәннәр академиясендә татар әдәбияты классигы, сәясәтче, җәмәгать эшлеклесе, педагог Галимҗан Ибраһимовның тууына 130 ел тулуга багышланган халыкара конференция үткәрелде. Аны ТР Фәннәр академиясе президенты Мәкъзүм Сәләхов ачты. Пленар утырышта ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова, Халыкара Төрки академиядән галим Тимур Козырёв, Башкортстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты Әлфис Гаязов, Кырымтатар Язучылар берлегенең җаваплы секретаре, «Йолдыз» журналының баш мөхәррире Диләвер Осман, Кыргызстан Язучылар берлеге әгъзасы, КР Фәннәр академиясенең Тел һәм әдәбият институты баш гыйльми хезмәткәре Гөлҗегет Соронкулов, Башкортстанның Авыргазы районы мәдәният бүлеге мөдире Риф Вәлиев, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, Г.Ибраһимовның бертуган энесенең кызы Сания Ибраһимова – сәламләү сүзе, ТР Фәннәр академиясенең вице-президенты Дания Заһидуллина, академик Индус Таһиров, Казакъстан Республикасының Л.Гумилёв исемендәге Евразия милли университеты профессоры Жантас Жакупов, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры Ким Миңнуллин, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Илфак Ибраһимов, Уфадан «Кызыл таң» газетасының баш мөхәррире Фаил Фәтхетдинов, КФУ доценты Марсель Ибраһимов докладлар белән чыктылар. Аннары конференция эшен секцияләрдә дәвам иттерде. Бер утырыш «Казан утлары» журналының 95 еллыгына багышланды. Әлеге басманың үткәне һәм бүгенгесе турында галимнәр Фоат Галимуллин, Флёра Сәйфуллина, Фәрит Яхин, Рифә Харрасова, Гүзәл Төхвәтова, Гөлфия Гайнуллина, Фәния Фәйзуллина сөйләделәр. Секция утырышын «Казан утлары»ның баш мөхәррире Илфак Ибраһимов алып барды.

## ТӨРКИЯДӘ ТУКАЙНЫ ИСКӘ АЛДЫЛАР

ТР Дәүләт Советының мәгариф, фән, мәдәният һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев Төркиянең Анкара, Истанбул шәһәрләрендә Габдулла Тукайны искә алу чараларында катнашты. Ул Тукай һәйкәленә чәчәкләр салды, шигъри митингта чыгыш ясады. Разил Вәлиев галим Надир Дәүләтнең «Россия мөһаҗирләре» китабын тәкъдим итү кичәсендә дә чыгыш ясады.

***

Яңа Кырлай урта гомуми белем бирү мәктәбендә VI республикакүләм Габдулла Тукай укулары үткәрелде. Быел иҗади бәйгеләргә 325 эш кабул ителде. Республикабызның 25 районыннан килгән укытучылар һәм укучылар сигез номинациядә көч сынашты. Аларның эшләренә «Казан утлары» журналының баш мөхәррир урынбасары Рамил Ханнанов, шушы басманың җаваплы сәркатибе Вакыйф Нуриев, проза бүлеге мөхәррире Камил Кәримов, «Безнең мирас» журналының бүлек мөхәррире Ленар Гобәйдуллин, КФУ профессоры Флёра Сәйфуллина, Казандагы Г.Тукай әдәби музее мөдире Гүзәл Төхвәтова һ.б. бәя бирде.

## АТЛАСИ ПРЕМИЯСЕ ИЯСЕ

Бөгелмәдәге татар гимназиясендә – тарихчы, мәгърифәтче, җәмәгать эшлеклесе, мөгаллим Һади Атласиның күпкырлы эшчәнлегенә багышланган конференция, татар мәдәнияте йортында кичә үткәрелде. Бу чараларда КФУ профессоры Хатыйп Миңнегулов катнашты һәм чыгыш ясады. Х.Миңнегуловка Бөгелмә шәһәре татар җәмәгатьчелегенең Һ.Атласи премиясе тапшырылды.

## ЯҢА ФИЛЬМ

Круглое Поле Мәдәният йортында Г.Тукайның соңгы көннәре турында «Күк капусы ачылганда» дип аталган нәфис фильм (сценарий авторы – Рабит Батулла, режиссёры – Фәрит Дәүләтшин) күрсәтелде. Рольләрне Г.Камал һәм Г.Кариев исемендәге театрлар артистлары башкара. Фильм тиздән Менделеевск, Арча һ.б. районнарда күрсәтеләчәк.

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Слово главного редактора»: И.ИБРАГИМОВ. «Журналу «Казан утлары» – 95 лет».*
*«Проза и поэзия»: исторический роман В.ИМАМОВА «Карабек»; повесть В.НУРИЕВА «Магдеев и...»; стихи Р.ЗАЙДУЛЛЫ, Р.БАШАРА, Ф.ТАРХАНОВОЙ; поэма Ф.ГИЛЯЗОВА.*
*«100-ая страница»: Р.ФАЙЗУЛЛИН. «Каждый номер – праздник для нас!»*
*«Нас поздравляют»: Р.РАТНИКОВА, М.ОНАР, Д.САЛИХОВ, Р.КИНЬЯБАЕВ, Д.ОСМАН.*
*«Вопрос от редактора»: «Роль журнала «Казан утлары» в развитии татарской литературы». Подготовил Рамил ХАННАНОВ.*
*«Наши юбиляры»: Ф.ГАЛИМУЛЛИН. «Чувствительная душа – чуткое перо».*
*«Воспоминания»: М.ХАРИСОВ. «Учитель стареет рано».*
*«История»: А.ФАЙЗРАХМАНОВ. «Музеи Арска».*
*«Журналу «Казан утлары» – 95 лет»: Ф.ГАЛИМУЛЛИН. «Журнал «Безнен юл» и Галимджан Ибрагимов»; Ш.БАЙЧУРА. «Татарские учителя в Туркестане во время царского правления»; М.ЯУШЕВ. «Лёд тронулся»; Д.ИРТУГАНОВ. «Татарская художественная литература на Донбассе»; Г.КАМИЛОВ. «Фронтовые газеты»; «Новости литературы и искусства»; Н.ДАВЛЕТ. «Татарская диаспора и Тукай»; Р.ЮНУС. «Фотографии, хранящие секреты»; М.ЮНУС. «На последнем дыхании»; М.ШАРИПОВ. «Что за место Суслонгер?»; Б.СУЛТАНБЕКОВ. «Татары и Игънатьев».*
*Из фотоархива журнала.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: Журналу «Казан утлары» – 95 лет;*
*Коллектив редакции и ветераны журнала «Казан утлары». 2017 год.*

## IN THIS ISSUE:

*«The editorial»: I.IBRAGIMOV. «The magazine» Kazan Utlary «is 95 years old».*
*«Prose and poetry»: historical novel by V.I.IMAMOV «Karabek»; novel by V.NURIEV «Magdeev and...»; poems by R.ZAIDULLA, R.BASHAR, F.TARHANOVA, F.GILYAZOV.*
*«100th page»: R.FAIZULLIN. «We make a day of every issue!»*
*«We are congratulated»: R.RATNIKOVA, M.ONAR, D.SALIKHOV, R.KINYABAEV, D.OSSMAN.*
*«Question from the editor»: «The role of the magazine «Kazan Utlary» in the development of the Tatar literature». Prepared by Ramil KHANNANOV.*
*«Our jubilees»: F.GALIMULLIN. «A sensitive soul is a sensitive pen».*
*«Memories»: M.KHARISOV. «The teacher grows old early».*
*«History»: A.FAIZRAKHMANOV. «Museums of Arsk».*
*«The magazine «Kazan Utlary» is 95 years old»: F.GALIMULLIN. «Journal «Beznen Yul» and Galimdjan Ibragimov»; SH.BAYCHURA. «Tatar teachers in Turkestan during the reign of the tsar»; M.YAUSHEV. «Ice is broken»; D.IRTUGANOV. «Tatar literature in Donbas»; G.KAMILOV. «Frontline newspapers»; «News of literature and art»; N.DAVLET. «The Tatar Diaspora and Tukay»; R.YUNUS. «Photos keeping secrets»; M.YUNUS. «In the last breath»; M.SHARIPOV. «What is a place Suslonger?»; B.SULTANBEKOV. «Tatars and Ignatyev».*
*From the photo archive of the magazine.*
*Diary of social and cultural life.*
*On our covers: The magazine «Kazan Utlary» is 95 years old;*
*The editorial staff and veterans of the magazine «Kazan Utlary». 2017.*

---

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Казан утлары» журналына – 95.

*Тышлыкның дүртенче битендә:* Журналыбызның редакция коллективы ветераннарыбыз белән. 2017 ел.